ISSN 0206—4189

казан утлары

2. 1984

Игътибар: конкурс!

«Казан утлары» журналы, КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы һәм «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән ижади элемтәләре турында»гы карарларын тормышка ашыруны тагын да активлаштыру максатыннан, иң яхшы хикәяләргә «Батырлык дәвам итә» конкурсы ача. Конкурс Бөек Ватан сугышында совет халкының тарихи җиңүенең 40 еллыгына багышлана.

Бөек Ватан сугышы елларында совет халкы фронтта һәм тылда тиңдәшсез батырлык күрсәтте. Бу батырлык бүгенге буыннарның җанында, рухында, кылган эшләрендә һәм хезмәтендә дәвам итә. Конкурска җибәреләчәк хикәяләр җиңүче солдат каһарманлыгының буыннан-буынга күчеп яшәвен, аның яшь буынны хәрби-патриотик рухта тәрбияләүдәге ролен, совет кешесенең гражданлык һәм югары әхлак сыйфатларын, тынычлык өчен көрәштә һәркемнең шәхси җаваплы булуын тасвирларга тиешләр.

Конкурска 1985 елның маенда йомгак ясалачак.

Конкурска килгән хикәяләрнең яхшы дип табылганнары журнал битләрендә басылып барачак.

Иң яхшы хикәяләр өчен түбәндәге премияләр билгеләнде:

Беренче премия (берәү) — 150 сум.

Икенче премия (икәү) — 100 әр сум.

Өченче премия (өчәү) — 75 әр сум.

Редколлегия язучыларның һәм башка авторларның конкурста актив катнашуларын көтә.

Машинкада басылмаган кулъязмалар кабул ителми, конкурс таләпләренә җавап бирмәгән хикәяләргә анализ ясалмый, кулъязмалар кире кайтарылмый.

ЖЮРИ.

КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

2

1984

КПССның ТАТАРСТАН өлкә КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

Бу санда

Я. ЧАНЫШЕВ. **Каләм һәм бомба** 3
Б. КАМАЛОВ. **Өметең өзелмәсен.** Роман 7
И. ЮЗЕЕВ. **Олы юлның каены.** Поэма 91
С. ШӘМСИ. **Нихәл, дустым!!** Хикәя 108

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ЗУЕВА. **Казанда Тукай урыннары** 120
З. РӘСУЛЕВА. **Тукай эзләреннән** 121

АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕНХАЛЫК ЭШЕ

Г. САТТАРОВ. **Мулны-ле — муллык ны-ле** 130

23 ФЕВРАЛЬ — СОВЕТ АРМИЯСЕ КӨНЕ

С. ШАКИР. **Хәйруллин утравы** 136

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

А. ӘХМӘДУЛЛИН. **Уңай герой — төп юнәлеш!** . 140
Р. САЛИХОВ. **Поэтикага игътибар кирәк!** 147

БИБЛИОГРАФИЯ

Р. ИДРИСОВ. **Аяз күктә карлыгачлар** 150
Ә. СӘХАПОВ. **Якты моң** 152

СӘНГАТЬ

К. МИҢЛЕБАЕВ. **Совет Татарстанының сынлы сәнгате** 155

ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ә. НИГЪМӘТУЛЛИН. **Әдәпнең үсү юлы** 159
Д. БАҺАУТДИНОВА. **Шәриф Камал хатлары** . . 168

ЮБИЛЕЙЛАР

М. СӘЙДӘШЕВА. **Ленинның тугрылыклы шәкерте** 171
Г. АРСЛАНОВ. **Сәхнә йолдызы** 174

Ф. ӘХМӘТОВ. **Моңлы якташыбыз** 176

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Р. МОСТАФИН. **Җәлил — әдәби тәнкыйтьче** . . 179

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Г. ЗӘЙНИЕВА. **Зур педагог** 186

Кызыклы хәлләр 190

Культура тормышы көндәлеге 191

Тышлыктагы сурәтләр 192

Баш редактор
РЕНАТ ХАРИС

Редколлегия:
ШАМИЛ БИКЧУРИН
МАНСУР ВӘЛИЕВ
РАЗИЛ ВӘЛИЕВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
РӘИС ДАУТОВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ЗӨЛФӘТ
САЛИХ МАННАПОВ
(җаваплы секретарь)
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
(баш редактор урынбасары)
ЗӘКИ НУРИ
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
АТИЛЛА РАСИХ
СИБГАТ ХӘКИМ
НИЛ ЮЗИЕВ

В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Перо и бомба». Публицистическое выступление генерала-лейтенанта в отставке **Я. Чанышева**.
Роман **Б. Камалова** «Не теряй надежду» (окончание). Поэма **И. Юзеева** «Береза на большаке». Рассказ **С. Шамси** «Как дела, дружище?!»
В рубрике «К 100 летию Тукая»: публикация **З. Расулевой** «По следам Тукая» (продолжение), рис. **Т. Зуевой** из цикла «Тукаевские места в Казани».
Очерк **Г. Саттарова** «Родимый край — земля изобилия». Зарисовка **С. Шакира** «Остров Хайруллина».
Продолжение дискуссии «Современная проза: герои, проблемы»: статьи **А. Ахмадуллина, Р. Салихова**.
Рецензируются новые книги Ш. Ракипова и Г. Рахима. Статья **К. Миннебаева** об альбоме «Изобразительное искусство Советской Татарии».
К 100 летию со дня рождения Ш. Камала: статья **А. Нигматуллина** о жизни и творчестве писателя, публикация **Д. Багаутдиновой** «Письма Ш. Камала». Юбилейные материалы к 90-летию С. Саитгалиева и Х. Уразикова, к 70-летию Х. Валиуллина.
Статья **Р. Мустафина** «Джалиль — критик». Статья **Г. Зайниевой** «Видный педагог» (о жизни и деятельности М. Курбангалиева).
«Занимательные истории (из жизни выдающихся деятелей татарской культуры). «Дневник культуры». «На наших обложках» — творчество народного художника ТАССР С. О. Лывина.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, жаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина*.

Производствога бирелде 1.12.1983 ел. Басарга кул куелды 24.1.1984 ел. ПФ 02018. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 63349. Заказ Я-482. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1984 ел.

Якуб Чанышев,
отставкадагы генерал-лейтенант

КАЛӘМ һӘМ БОМБА

Башлыча әдипләребез һәм әдәбият сөючеләребез өчен чыгарыла торган бу кадерле журнал битләрендә сүз әйтү мөмкинлеге тугач, минем телгә иң әүвәл шул ике төшенчә— каләм һәм бомба төшенчәләре килеп керде. Бөтен гомере Совет Кораллы Көчләренә хезмәт итүгә багышланган, өч сугышны кичкән Ленин солдатының, миндәй өлкән генералның җир йөзендәге иң изге эш коралыннан саналырга тиешле каләм һәм җанны тетрәндергеч утлы корал булган бомбаны рәттән куюына гаҗәпләнергә ашыкмагыз. Заманы шундый. Җир шарында Америка Кушма Штатлары империалистларының, һичнинди кысаларны чамаламыйча, өзлексез коралланулары дөньяның тынычлык сөюче илләрен дә яңа сугышка әзерлек чаралары күрергә мәҗбүр итә. Без һәр көн, һәр сәгать коточкыч үлем кораллары: канатлы ракеталар, «Першинг-2»ләр, нейтрон бомбалары турында яңадан-яңа хәбәрләр ишетеп торабыз. Мондый шартларда, минемчә, әдип кулындагы каләмнең роле ифрат та зурая.

Каләм һәм бомба. Беренчесе — кешеләрне матурлыкка, шәфкатькә, дуслыкка чакыра торган әсәрләрне, фәнни ачышларны мәңгеләштерү коралы. Икенчесе—җан иясенә кирәкле бөтен нәрсәне кырып, яндырып бетерергә, җирне үлем пәрдәсе белән каплап куярга дип ясалган ут чыганагы. Бер-берсенә капма-каршы көчләр. Каләм бәя биреп бетерә алмаслык байлыклар тудыра: китаплар, пьесалар, кинофильмнар, җырлар... Алар үзләренә миллионлаган кешеләрне ияртә, яктылыкка дәшә, кара көчләргә каршы көрәшкә өнди һәм оештыра торган искиткеч рухи куәткә ияләр.

Хәтерегездәдер: әле күптән түгел, үткән елның октябрь аенда безнең Ташкент шәһәрендә Азия һәм Африка илләре язучыларының VII Конференциясе булып узды. Бөек Октябрь революциясе вакытында, әле яңа гына оешып килүче Совет Армиясенең татар сугышчыларыннан төзелгән махсус бригадасын җитәкләп, мин ул якларда басмачыларга каршы көрәшеп тә йөрдем.

Безнең ул поход турында минем рухыма бик хуш килә торган бер җыр да бар:

Фергана-Бохара — без үткән ара, их!
Фрунзе — безнең командарм,
Дошманнарның җиңдек барын
Данлы елларда!..

Бүгенге көннәрдә Ташкентның халыкара форумнар үткәрерлек шундый мәшһүр үзәккә әйләнүе мине нык шатландыра. Ташкентта мондый

Конференция инде икенче тапкыр уздырылды. Һәм аңарда катнашкач һәр язучы кабатлап үтте—Ташкент язучыларга моннан егерме биш ел элек үк, иң беренче булган шушындый конференциядә үк, безнең чор әдипләренең иң изге бурычы тынычлык өчен көрәш, дөнья халыкларын сугышка каршы туплау, дип билгеләде. Бәхеткә, бу беренчел принцип язучылар иҗатында якты чагылыш тапкан һәм 1983 елгы Конференция моны зурлап ассызыклады. Чыгыш ясаучы язучылар бик урынлы рәвештә:

Без Вьетнам халкының Америка агрессорларын батырларча җиңеп чыгуына да өлеш керттек,—диделәр. —Ангола һәм Мозамбик, Эфиопия, Лаос һәм Кампучия, Әфганстан һәм Никарагуада революцион халыкчан көчләрнең уңышлы көрәшенә без дә турыдан-туры катнаштык, дияргә мөмкин, чөнки каләмнәребез халыкларның азатлык өчен алып барган гадел көрәшен хуплады...

Бу сүзләрне укыганда, гаскәри хезмәт кешесе буларак, күз алдыма Бөек Ватан сугышы елларында күргән хәлләр килеп басты. Ул чакта фронтларда татар телендә дә дистәләрчә газеталар чыгарыла иде. Редакцияләрдә Татарстанның талантлы язучылары һәм журналистлары эшләделәр. Мин үз дивизиямнең солдат һәм офицерлары кулында ул газеталарны бик еш күрә идем. Дошман белән барган авыр бәрелешләрдән соң, аз гына вакытка ял бирелсә, кулларына газета алалар, иң якын дуслары, туганнары белән очрашкандай булалар. Җаннарына ятышлы, омтылышларына тәңгәл язмаларны табып алып, ни дәрәҗәдә шатланганнарын күрсәгез иде аларның! Сугышчы рухына хуш килүчән шигырьләр телдән-телгә сөйләнә торган иде. Күбесе, өйләреннән чыгып киткәндә, юлдаш итеп, Тукай, Такташ китапларын да алганнар. Авыр минутларда да, уңышлы һөҗүмнән соң да, солдат капчыгыннан чыгаралар да, шул шигырьләрне укыйлар, туган җирне сагыну хисен басалар, анда тизрәк кайту өчен, җиңү көнен якынайтырга кирәген тагын да тирәннәнрәк аңлыйлар иде. Мәскәүдән алып Берлинга кадәр барып җиткән сугышчан юлымда мин андый хәлләрне — солдат күңеленең әдәби әсәрләр белән ләззәтләнү, аннан көч алу мизгелләрен бик күп тапкырлар күрдем.

Бу хакта нигә шулай тәфсилләп сөйләп торуым аңлашыладыр: каләм белән бомбаның, бер-берсенә капма-каршы көчләр буларак, һәрчак, рәттән торуын аңлатасым килде. Тагын шунысы да бар бит әле, Татарстанның иң талантлы әдипләре каләм белән язган кыйммәтле сүзләрен гомер юлларының тугрылыгы белән раслыйлар. Сугышка, фашизмга мең нәләт укыган, илбасарларга ачы нәфрәт тәрбияләгән, тыныч хезмәт кәһарманнарына дан җырлаган дистәләрчә шагыйрьләребез яу кырында ятып калган икән—мин моны илгә, халыкка, Ленин идеяләренә бирелгәнлекнең һәм үз әсәрләренә тугрылыкның бөек үрнәге дип аңлыйм. Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Абдулла Алиш, Нур Баян һәм тагын да уннарча әдипләребезнең Бөек Ватан сугышында, батырларча көрәшеп, һәлак булып калулары — бер яктан, һич ни белән кайтарып ала алмаслык бинһая зур югалту, ә икенче яктан караганда, бу хәл — әдип сүзенең кылган эшеннән аерылмавын раслаучы, безнең әдәбиятның йөз аклыгын күрсәтеп торучы бик көчле дәлил. Киләсе елга без бөек җиңүнең кырык еллыгын бәйрәм итәчәкбез. Тирәннән ышанам ки, язучыларыбыз бу тантанага багышлап иң яхшы әсәрләрен язарлар!

Узган ел КПСС Үзәк Комитетында ветераннар белән очрашуы вакытында Юрий Владимирович Андропов бездән яшь буынны патриотик рухта тәрбияләүгә актив катнашуыбызны сорады. Минемчә, бик урынлы искә төшерелгән бурычыбыз бу безнең. Минем, мәсәлән, 45 ел гомерем Совет Армиясенә хезмәт итеп, сугыш юлларында, хәрби академиядә яшьләрне осталыкка өйрәтеп узды. Кирәк дип исәпләнә икән, мин

хәзер дә яшь буынны тәрбияләүгә бөтен тәҗрибәмне җигәчәкмен. Бу өлкәдә дә язучылар, журналистлар безнең кебекләргә каләм белән ярдәм итә ала.

Һич икеләнмичә әйтергә мөмкин, бүген дә татар совет әдәбияты сугышка нәфрәт тәрбияләүче, тынычлыкны яклаучы һәм шул ук вакытта, яңа афәт чыгуын истә тотып, илгә корыч холыклы патриотлар үстерүдә ярдәм итүче ышанычлы көч булып тора. Моның әһәмияте ифрат зур. Билгеле булганча, халык азатлыгы дошманнары тыныч кына яши алмыйлар. Дөньяда, бигрәк тә Америка Кушма Штатларында котырынып кораллану бара. Үлем чыганакларының моңарчы күренмәгәннәре уйлап табыла. Кешелеккә атом сугышы куркынычы яный. Совет Кораллы Көчләре исә һәр очрак өчен әзер торырга мәҗбүр. Совет Армиясе — бик уяу рәвештә тынычлык сагында сакта. Мең-миллион корбаннар бәрабәренә ирешелгән тынычлыкны саклауда сизгерлекне киметергә безнең хакыбыз юк. Дөрес, мин үз һөнәрем ягыннан, Совет Армиясе ил азатлыгын киләчәктә дә тулысынча саклый алачагына, хәтта үзара дус яшәүче социалистик илләр иминлеге өчен дә армиябезнең нык терәк булуына ышандыра алам. Тарих шаһит: Совет Армиясен җиңә алган көчнең булганы юк һәм булмас та! Безнең социалистик илнең үсешен буар өчен империализм ниләр генә кыланмады?! Гражданнар сугышы, чит ил интервенциясе, Совет илен озак еллар дәвамында экономик блокадада тоту һәм, ниһаять, Гитлер Германиясенең варварларча басып керүе... Бүген президент Рейган, тарих сабакларына күз йомып, империалистларның дистәләрчә еллар буе ирешә алмаган хыялларын тормышка ашырырга азаплана.

КПСС Үзәк Комитетында РСДРП(б)ның II съезды уздырылуга 80 ел тулу тантанасында мин АКШ коммунистларының җитәкчесе Гэс Холл белән очраштым. Хикмәт шунда ки, Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, Берлинда мин Американың хәрби һава десантлары корпусы генералы Риджуэй белән әңгәмә корган идем. Җиңү безне шактый якынайткан, дуслаштырган көннәр. Солдатларыбыз истәлеккә шинель сәдәфләре алмаша. Америка генералы минем муенга үз илләренең зур орденын да тагып куйды. Без кочаклаштык, үбештек, бер-беребезгә тугрылыклы булырга сүзләр бирештек.

Инде соңгы вакытта, дәүләтләребез арасындагы мөнәсәбәтләр бик киеренкеләнеп киткән көннәрдә, АКШның нык холыклы коммунисты Гэс Холлны күреп сөйләшү мөмкинлеге тугач, мин 1945 елгы вәгъдәләребезне искә төшердем. Ахырдан:

— Иптәш Гэс Холл, мөмкин булса, президентыгызга тапшырыгыз әле,—дидем. —Аңа үзенең киноактер һөнәре буенча китеп, гангстерлар, бандитлар роленда туйганчы уйнаса, хәерлерәк булыр иде! Югыйсә, аны да шул ук Гитлер язмышы көтә бит...

Ул, СССРны өзлексез коралланырга мәҗбүр итеп, тәмам чыгырдан чыгармакчы, империализм алдына тезләндермәкче, социализмның алга баруына киртә торгызмакчы була. Бу бичара президент ап-ачык хакыйкатьне аңламый: Врангель, Колчак, Деникин, Гитлер һәм Муссолини гаскәрләрен тарих чүплегенә илтеп ташлаган көч Рейган ракеталары алдында гына каушап калырмыни? Юк, әлбәттә! Бишектә чагында ук үз азатлыгын каһарманнарча яклый алган безнең дәүләт хәзер бөтен дөньяның таянычына, халыклар хокукын яклаучыга әйләнде. Без куәтле. Теләсә нинди дошманның янауларына каршы чыгарлык мөмкинлекләребез дә бар. Тик без бер вакытта да хәрби осталыгыбыз, утлы коралларыбызның муллыгы белән шапырынмыйбыз, чөнки һәр акыллы кешегә мәгълүм: атом-төш коралларын куллануны күздә тоткан сугышта җиңүчеләр дә, җиңелүчеләр дә була алмый. Андый сугыш кешелекне, җирне, тулаем йотачак. Шуңа күрә дә Совет дәүләтенең, совет халкының иң изге максаты — тынычлык!

Телгә, ихтыярсыздан, Тукайның гаҗәп оста әйтелгән юллары килде:

...Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез!

Безнең тынычлыкны саклау теләгебез хәзер дөньяны иңли, миллионнар теләгенә әйләнә бара. Җир шарының һәр тарафында тынычлык сөючеләр хәрәкәте көчәя, сугышка каршы күмәк авазлар яңгырый. Тынычлыкка сусаган кешеләр, зур-зур илләр бер-берсенә якынаялар, дуслашалар. Бу хәрәкәттә язучыларның урыны — иң алгы сафта.

Ә Кешелекнең иң якты киләчәгендә дөньядагы барлык кешеләр сугышның, бомбаларның ни икәнен дә онытырлар, үзара матур сүзләр белән генә аралаша башларлар. Киләчәк оста каләмнәр язган җанягымлы сүз алдында баш ияр. Ул чакта «бомба» сүзе дә әдәбиятта күчермә мәгънәсендә генә йөрер. Аны, Һади Такташ шигырьләрендәгечә, тормышка комачаулаучы күренешләргә каршы көч итеп файдаланырлар шикелле:

...Син комсомолмы?
— Комсомоллар —
Ящь ленинчылар алар,
Комсомоллар — искелеккә
Б о м б а л а р ! . .

Бүген үк әдәбиятыбыздагы һәр сүз сугыш чукмарларының йөрәгенә ярырдай әнә шушындый үк бомба мәгънәсен алсын иде! Ул чагында каләм дә, бомба төшенчәсе дә бер үк максатка — матурлык, хөрлек, тигезлек, рәхәт тормыш өчен көрәшкә хезмәт итәр.

Совет Армиясе төзелүгә 66 ел тулу уңаеннан Татарстанның язучыларына һәм әдәбият сөючеләренә әйтергә теләгән фикерләрем менә шушы иде минем.

Барлас Камалов

ӨМЕТЕҢ ӨЗЕЛМӘСЕН

РОМАН

Илшадия ник шат түгел?

Гадәттәгечә, Илшадия Маннурова, Агачбаш урта мәктәбенең директоры, районда киңәшмәдә булып, җомга көнне кич кенә кайтып төште. Агачбаш Ташбуага терәлеп үк тора. Соңгаруы юл ераклыгыннан түгел иде. Ул бик озак хәзер комсомол райкомында беренче секретарь булып эшләүче элекке укучысы Равил Сафинны көтте.

Равил кайсыдыр башлангыч оешмага отчет-сайлау җыелышына барган. Анда исә тәнкыйть сүзләре куерып киткән. Район комитетына да тел тидергәннәр. Шулай булгач, яшьләр белән азаккача аңлашмыйча, сайлау нәтиҗәләре тәмам мәгълүм булмый торып, секретарь кайтып китә аламы? Сафин Илшадиядән гафу үтенде һәм: «Менә хәзер төнгә чаклы да сөйләшергә мөмкин, Илшадия Фәйзерахмановна»,— диде. Аңлаштылар. Мәгәр Илшадиянең төн кичеп утырыр җае юк иде. Өйдә гарип энесе ялгызы ята. Ашарына-эчәренә әзерләп калдырган иде калдыруын, тик егетне тамак ялгаудан битәр ялгызлык тилмертә. Апасы мәктәптән соңарыбрак чыкса да, кәефсезлеген яшерә алмый. Солдат хезмәтен тәмамлап, бер ел БАМда эшләп кайткан әзмәвердәй егет кеше борчып, борын салындырып утырырга ярамаганны, килешмәгәнне үзе дә аңламый түгел. Әмма нервыларын тыя алмый.

Илшадия Ташбуа пионерлар йортына рәсем түгәрәге җитәкчесе кирәк икән дип ишеткән иде. Дөрес хәбәр булып чыкты, авыл районнарына сәнгать вузы һәм училищеларын тәмамлаучылар бик ашкынып килмиләр шул әле.

Апасының теләге — энесе Булатны эшкә кертеп мавыктыру. Эш монда акчасында да түгел, Илшадия энесеннән материаль ярдәм көтми, ике кеше көн итәрлек акчаны үзе дә таба. Булатны менә шул пионерлар йортына урнаштырасы иде.

Комсомол райкомында сүз шулай очланды: Равил иртәгәсен, ягъни шимбә көнне (комсомол работнигына шимбә, якшәмбе бик сирәк эләгә) Агачбашка үзе килергә, Булат белән сөйләшеп карарга булды. Бәлки егет, чыннан да, үзе яраткан хезмәт белән мавыгып китсә, тынычланыр,

---

Ахыры. Башы беренче санда.

көченә ышанычы артыр, дөньяга якты итеп карый башлар. Бүтән эшкә кушып булмый аны. Ике ягында ике култык таягы, шуның өстенә сул күзе нык зарарланган. Битендә гранит кыяның бик вак кыйпылчыклары. Шартлатучы иде ул. Армиядә алган белгечлеге буенча шушы төзелешкә киткән иде. Бер операцияне башкарганда, тоннель ачканда, үз гомерен куркыныч астына куеп, иптәшләрен саклап калган егет. Аны эшләгән җирендә калырга да кыстаганнар иде. Квартира бирәбез, пенсияң әйбәт, яшә монда, диделәр. Юк, Зөя буйларына, апасы янына кайтасы итте. Армия сафына озатканда карап кына торырлык чибәр, ярысландай егет иде. Хәрби хезмәте дә менә дигән узды. Илшадия часть командирыннан ике тапкыр мактау хаты алды. БАМда язмыш шулайрак борылыш ясады. Тора-бара аяклары савыгыр, төзәлер дип тә әйтәләр. Яшь организм бәлки алдырып та китәр. Күзе төзәлеренә гарантия бирмиләр. Егет моны төгәл белә, ләкин сыгылып-сынып төшүчеләрдән түгел.

Илшадия бик ашыгып, җайсызрак ирештердеме, Булатка аның эш эзләп йөрүе, комсомол райкомы кешеләрен үгетләве ошамады. «Мине үз жилкәсенә гомерлек йөк булыр дип куркамы әллә апа?— дигән уй аның йөрәгенә пәке белән сызган кебек тәэсир калдырды.— Минем пенсиям бик житкән югыйсә». Китек күңел җәһәт җәрәхәтләнә шул!

Шундый аңлашмау икесенең дә йокыларын качырды, тик утны сүндереп яткач, алар бер-берсенә эндәшмәделәр. Һәркайсын үз уе кимерә иде. Ниләр генә уйлап бетермәделәр!

Булат төзелешкә китү вариантына да тукталып карады. Ләкин Агачбашка кайтуына сәбәп булган икенче бер зат та бар иде монда. Классташ кыз Фирүзә. Ул читтән торып Казанда, педагогия институтында укый, Агачбаш урта мәктәбендә өлкән пионервожатый булып эшли. Аны да аңламый әле Булат. Кайтканына бер ай була, Фирүзәнең кергәне юк. Илшадия апасыннан гына тарсына, кыенсынамы, әллә егеттән гайрәте чикте микән? Төзелештәге больницадан хатлар язды ул Фирүзәгә, чынбарлыкны төшендерде, һич нәрсәне яшермәде. Кыздан шулай ук курку-читләшү сизелмәгән жаваплар килде. Алай булмаса, кайтыр идеме икән әле ул, уйлап, үлчәп, фикер бизмәненә салып карар иде...

Равил Сафин сүзендә торды, иртәгесен Илшадияләргә килде. Инвалид егет белән сүзне бик оста башлады, апагыз килеп сорагач, хәл белешергә килдем диюдән ерак торды. Илшадия өстәл хәзерләде, чәй өлгертте. Егетләр күптәнге дус-белеш кешеләр кебек әңгәмә кордылар. Баштарак сүзгә саран торган Булат, ят кешегә ияләшеп киткән төсле, мулрак сүзле була башлады. Радио тыңлавын, кичләрен телевизор караштыргалавын, әдәби китаплар укуын әйтте. Шуларны сөйләгәндә ул дәртләнә барды, коңгырт күзләре очкынланды. Аз гына читкәрәк күчеп утырыйм дип кымшанганда, таякларына ябышты да, әле генә янып торган Булат сүнде. Күзләре кысыла төшкән кебек булды. Гәүдәсе дә янә кечерәеп калды шикелле.

— Шулай, Равил абый,— диде ул, бөтенләй бүтән тавыш белән.— Дөньяның кеме генә юк. Нинди авыруы гына. Хәсрәт хәсрәткә охшамый, хәсрәт урыны бушамый...

Турысын гына әйткәндә, Сафин янә аптырап калды. Чәбәләнгән йомгакны ни рәвешле сүтәргә белми иде ул. Булат — сабый бала түгел, аны татлы тел белән юатырга маташуның хажәте юк. Үз хәлен үзе күреп, тоеп тора ул. Иллюзия корып көн көтүчеләрдән яралмаган.

— Булат, рәсемгә осталыгың бар, дип ишеткән идем,— дип, өзелеп калган сүзне ялгарга тырышты егет.

Булат ирен чите белән генә елмаеп куйды.

— Кул кычытканнан гына ул, Равил абый. Мактанырлык чама юк.

Секретарь сизде: әлеге тема Булатның кәефенә хуш килде. Сорауга

җавап дип кенә түгел, күңел эчкәресендәген кем беләндер уртаклашасы килүдән, сүзен дәвам итте.

— Кызык хәл ул, Равил абый, хыялга, күз алдына гажәеп картиналар килә. Кәгазь-карандаш алгач, яисә киндереңне тарттырып куйгач, күңелдәге буяулар әллә кая югала. Моны мин талант димәс идем. Киресенчә, шул байлыкның юклыгы дип аңлыйм. Шул булмаганга хыял да чикледер дип беләм. Ә бит хыяллана белү җирнең тарту көчен ачарга ярдәм иткән, радио, электр, рентген, телевизор уйлап табарга булышкан. Хыял әкиятләр ижат иткән, аннары космоска юл ачкан. Айга менү хакында күпме җыр бар! Менде бит кешеләр. Автоматлар менде. Минем рәсемнәр инде тел талдырып сөйләшерлек тә түгел. Канатсыз кош җилпенүе генә...

— Алай да миңа, мөмкин булса, берничәсен күрсәт әле, Булат. Хыяллану турында кызык кына сөйләдең.

Булат артыгын кыстатмады. Култык астына берничә альбом тотып чыкты да Сафинга бирде. Равил аларның битләрен актара башлады. Булат үзе бер читкәрәк утырды, муенын суза төшеп, һәр рәсемне берничә сүз белән генә аңлата барды.

Беренче дәфтәрдә тайга күренешләре иде. Гыйффәтле, кырыс табигатьне буйсындыру күренешләре. Сакал-мыекка бай, җылы, калын итеп киенгән чыдам кешеләр. Икенче альбомда шул якларның пейзажы башкачарак сурәтләнгән. Больница тәрәзәсеннән карап ясаганнары. Өченчесенә әле шушы көннәрдә генә ясалган рәсемнәр кергән.

Булат мактауга мәлҗерәп төшүчеләрдән түгел. Райком секретаре сүзләрен ишетеп тә житкермәгән кыяфәттә утыра бирде. Бары тик елмаеп кына куйды. Зыянланган күзенең кабагы тартышып алды.

— Менә моңысын да карап карагыз алайса...— Секретарьның хуплау сүзләренә каршы төзүче егетнең жавабы шул булды.— «Чигенмәсеңме?» — дип атарга мөмкиндер аны. Икенче төрле атарга да була. «Сыналыр көннәр». Алай дигәндә дөресрәк тә чыга шикелле. ... Больница палатасы. Аклык. Стеналар да, түшәмнәр дә. Тәрәзә рамнары да, пәрдәләр дә. Урын-жир дә. Кыш. Идәнгә кояшның сүлпән, саран нурлары төшкән. Тәрәзә төбендәге (Равил: «Больницаларда буламы икән,— дип уйлап алды,— әмма рәсемдә бик урынлы, хәтта кирәктер төсле иде) ялтыравык кәгазь белән тышланган кечкенә чүлмәктә яшь гөл. Ул кояш көтә. нур көтә. Аның шәбәеп үсеп китүе өчен якты кирәк, җылы кирәк. Гөл дә наз өмет итә төсле.

Ә койкада авыру егет ята. Аяклары гипсланган. Башы да бәйләүле. Сызлануы күзләренә чыккан. Шулай да аның ябык йөзендә тән сызлавы гына түгел, жан интәвенең эзләре дә бар. Әле кичә генә, бер атна элек кенә нык басып йөргән яшь, таза егет бүген, яралы арслан дай, больница койкасын инләп ята. Бәхетсезлек очрагы аны аяктан еккан.

Егет янәшәсендә инҗәренә ак халат салган кыз утыра. Ул хәл белергә килгән. Яралы дустының тизрәк савыгуын телидер, юату сүзләре әйтәдер. Ә йөзендә уйлар өермәсе. «Савыгырмы бу егет? Тагын гайрәтле арслан булып йөрерме? Әгәр савыкмаса? Ул чагында тормышка бергә керерлек пар булырмы?» Ә дуслыкның чынлыгы, вәгъдәләрнең ныклыгы иң кыен көннәрдә, иң авыр елларда сынала...

— Бик аңлашыла, Булат. Фажигале хәл турында сөйләсәң дә, кешеләрдә якты өмет канатлануын, үрмә гөлнең югарыга талпынуын төшенерлек сурәтләгәнсең. Ничек дип әйтим, безнең кешеләр характерының асылын тотып ала белгәнсең. Оптимизм һәм перспектива күз алдында булган,— диде Сафин.— Инде сиңа бер тәкъдим бар, Булат. Ташбуаның пионерлар йортында дүртенче-жиденче класс укучылары белән атнага ике мәртәбә түгәрәк үткәрер кеше кирәк. Ике урта мәктәпкә бер укытучы бар безнең. Аны анда жигеп булмый. Шәһәр буйлап лозунг, плакат язып йөри. Акча каера. Райүзәккә сезнең өй чатыннан

машина өзелеп тормый. Мәктәбегезнең дә машинасы бар, пионерлар йорты да менә-менә машиналы булачак. Алынасыңмы шул эшкә? Егермеләп бала анда. Алдан әйтеп, үтенеп куям: укучылар белән укытучыларча булырга кирәк...

— Ышансагыз, эшләп карыйм...

Шулай килештеләр, һәм Булат ике көннән соң беренче дәресенә китте. Илшадия аны дүрт күз белән көтте. Күңел күген галәмәт авыр шик болытлары томалаган иде. Моннан да зур шикләнүне Илшадия Маннурова моннан унсигез ел элек Алабуга районында кичергән иде. Үзенең коллегасы, Булатның әнисе үлеп, малайны үз энесе итеп алганда. Шуннан соң туган якка, Ташбуа районына кайтты ул. Юк, Булатның эзен җуяр өчен түгел. Ул аны улы итмәде, андый адымны күңеленә йөкләмәде. Булат үз фамилиясендә калды — Искәндәров. Документларына чын әти-әнисенең исем-фамилияләре язылган. Тик әнисе карынында сабый яралганын белгәч үк әти кешесе качып киткән иде.

Менә шундый катлаулы язмышка тарыган кеше янә бәхетсезлек кочагында.

Әйтергә кирәк: Илшадия апасы хозурында ул мохтаҗлык та, кыерсыту да күрми үсте. Мәктәптә әйбәт укыды. Югары уку йортына да аттестат алу белән үк керә ала иде, «Хәрби хезмәттә булып кайтыйм әле!»— диде. Аннан соң — БАМ.

Илшадия Булатны үз энесе иткәч, кайбер тел-теш тидермәстәй кешеләр, ир-ат затыннан дигәнем, берничә кат сүз кушып карадылар, ләкин Маннурова гаилә кору хакында алар белән сүз куертмады.

Булат шатлыгы — аның шатлыгы. Булат хәсрәте, яше инде иллегә якынлашып килгәндә, бәгыренә ачуташ булып утырды. Егетнең Фирүзә белән аралары икеле-микеле торуы да бик борчый аны, хафага сала. Әмма әлеге җәһәттән ак дип тә, кара дип тә әйтә алмый. Үз кул астындагы кыз балага әмер бирсенме? Кеше ашына катык катуны кемнең мактаганы бар әле?!

Шулай да пионерлар йортына барып кайтканнан соң кәефе әйбәтләнеп киткән энесе, Фирүзәгә тапшыруын үтенеп, кош теледәй генә язу биргәч, Илшадия кире кага алмады.

«Фирүзә! Мин сине көтәм бит, классташ. Вакыт табып, безгә кереп чыксана, яме. Ападан тартынма, аның гаделлеге сиңа билгеле ләбаса. Һич югы чал Себердән күңелемә салып кайткан сәламнәремне тапшырыйм. Булат».

Илшадия аңа ул көнне җавап алып кайта алмады. Фирүзә комач кебек кызарды, бер читкә китте, укытучысы һәм бүгенге директоры алдында ул телсез калган иде. Илшадия үзе дә моның сәбәбен беравыкка хәтереннән чыгарган иде. Моның уйлансаң уйланырлык нигезе бар иде шул.

...Фирүзә белән Булатның җиденчедә укыган чаклары. Яз. Апрель. Дәресләр тәмамлангач, мәктәп коридорыннан узып баручы Илшадия бер почмакта елап торган Фирүзәгә игътибар итте. Кызыйның янына килде.

— Ник елыйсың, Саматова? Ни булды?

Кыз эндәшмәде. Теләктәш юатучы табылгач, тагын да катырак елый башлады. Директор соравын янә кабатлады.

— Ник елыйсың, Фирүзә? Кем рәнҗетте? Ни булды?

Гөнаһсыз бала Фирүзә — педагог алдында бөтен күңелен актарып салды:

— Булат мине яратмый!

Көләргә дә, ачуланырга да белмәгән Илшадия, берни дә булмагандай, үтә дә битараф тавыш белән әйтте:

— Җүләр кыз! Бүтән хәсрәтең булмаса, бар, кайт та дәресләреңне хәстәрлә. Тапкансың елар нәрсә!..

Ул чагында, шул минутларда, күрәсең, Илшадия бөек педагогның алтын сүзләрен онытып җибәргән булгандыр. Ә Сухомлинский дигән олуг остаз болай әйткән: «Женси җитлегү чоры кыз балаларда малайлардан шактый элек башлана. Кызлар малайларга караганда ике, кайчакта өч елга элегрәк җитлегә... Әгәр табигатьнең закончалыклары искә алынмаса, бәлага юлыгуың мөмкин».

Бүген инде менә шул укучы үзе балигъ булган яшьләр арасында илче сыман...

Иннәрдә тау, күңелдә таң

Өсенә кайтып китәсе булуга куануданмы, мартның бишендә Хәбиб абзый гадәттәгедән иртәрәк торды. Болай да йокысыз карт бу төнне әллә бөтенләй күз йоммаган инде. Илфатның да уяу ятканын белеп, сөенеп киткәндәй булды: комачау кылмаячак, тынычлыгын бозмаячак, янәсе.

Иң әүвәле кырыну машинасын бик тырышып, ләззәт-тәм табып көйләп маташты карт. Аннары, тумбочкасы өстендәге терәүле көзгесен сөзәргә теләгәндәй, чекерәеп карый-карый, жиренә житкереп кырынды. Машинасын тоташтыргычтан тартып чыгарган иде инде, ияк тирәләрен бармак битләре белән капшаштырып карагач, кабат тоташтырды. Күңеле түгәрәкләнмәгән икән. Аны кызыксынып күзәтеп яткан Илфат көлемсерәп куйды да:

— Берәр кыз каршылыйдыр ахры үзегезне, Хәбиб абзый, бу тикле дә нечкәләмәс идегез, вообще-то,— диде.

Гайсин агай кеткелдәп көлде.

— Бар иде каршылаган чаклар.— Ул Илфатка карап ияк какты. Дөрес сукалыйсың, янәсе.— Бар иде. Андый хәлләр булып узганга күп тә түгел әле, ярты гасыр гына...— Аннары житдиләнеп әйтте.— Таныш-белешнең очравы бар, Илфат энем. Күрше-күлән. Абзый тиражга чыккан икән, димәсеннәр. Аннан соң бит адәм баласының үз күңеле... Кирәгенчә юынсаң-тарансаң, жан яктырып киткән төсле тоела. Жаның якты булса, сәламең дә татлы, сүзең дә йөрәккә ятышлы чыга...

— Дөрес, Хәбиб абзый, дөрес!— Илфат та шаяруны бер читкә куйган иде инде.— Хак сүзгә жавап юк.

Аннары агай бик кәефләнеп юынды да чиста күлмәк алып киде, галстук такты, тик пинжәгенә кагылмады. Вакыты байтак иде әле аның. Врачлар килгәч, обходлар тәмамлангач кына, анда да әллә ни кабаланып төшми генә әзерлиләр әле кәгазьләрне. Өйлә житә яза.

Хәбиб абзый, урындык алып, Илфат караваты янәшәсенә утырды. Аның шундый гадәте бар: уң аягын сул тезенә атландыра да, кулларын «йозаклап», кул сырты белән уң тезенә кагыла-кагыла сөйләшә, гүя һәр әйткән фикерен кадаклап бара. Мондый чакта аның гәүдәсе алгарак сөрлегә һәм куе чал чәче тузгып китә. Әле дә шул рәвешле сүзгә кереште.

— Бик күңелсез йортта очрашсак та, Илфат энем, көннәрне ярыйсы гына уздырдык. Инде тизрәк савыгып чыгуыгызны телимен. Бүтән авырмагыз, рөхсәтем юк. Тимер өзеп, бакыр сытып Казанга кабат килгәндә, туп-туры безгә төшегез. Квартир иркен, аннан бигрәк күңел киң. Адресны әйттем.

— Бик рәхмәт, Хәбиб абзый. Үзегез Гөл-Төркемгә кайтыгыз. Кунакка. Менә сабан туйлары житәр. Яшьлектә узган юлларыгызны тагын бер искә төшерерсез.

— Әйе. Саулык-байлык булса, Ташбуа тарафларыннан бер әйләнү ярап куяр иде. Җаны сауга көн дә туй диләр бит...

Алар шулай гәпләшеп-саубуллашып утырганда берәү палата ишеген шакыды.

— Рәхим итегез!— Гайсин абзый нигәдер урыныннан купты, Илфат та карашын ишеккә күчерде. Аннан Кави Сәмәрханов кереп килә иде.

— Һо-о-о!— диделәр палата хуҗалары икесе бер авыздан.— Делегат кайткан!

— Исәннәрмесез, иптәшләр!

— Исәнмесез, саумысез?

— Узыгыз, кордаш!

Тегә чакта, Илфатны больницага салган көнне, Хәбиб абзый белән Кави Салихович юньле-башлы таныша алмаганнар иде. Эш аңа терәлеп калмаган иде шул. Бу юлы инде кот алырлык хәвеф-хәтәр юк, иркенләп, күптәнге танышлар төсле сөйләшеп киттеләр. Юк вакытын бар итеп хәл белергә кергәне өчен Илфатның Мәскәүдән кайтып килүче кордашына рәхмәте зур иде. Мәгәр ул аны телләнеп әйтмәде (төчеләнү булыр дип курыкты). Ә йөзенә җәелгән якты нур барчасын сөйләргә өлгерде шикелле.

Ихластан һәм төпченә-төпченә бер-берсенең хәлләрен сораштылар. Маннуровның сәламәтлеге уңай якка үзгәрүгә райком секретаре бик шатланды: кан басымы нормада икән, уң аягы инде буйсынырга итә, йокысы — йокы, ашы — аш. Караватка торып утырырга рөхсәт биргәннәр, аякларын салындырып бераз утырып ала. Тиздән аякка басачак һәм карават тирәли «сәяхәт»ен башлаячак. Шулай бит ул, сырхау килгәндә генә чирү сыман ябырылып килә, киткәндә мыскаллап кына чигенә. Әйдә, сантиметрлап булса да чигенсен, тик чигенсен, китсен генә! Бер генә энәсен дә онытып калдырмасын, кабат килеп йөрерлек булмасын!..

— Яшибез, кордаш, болай булгач!— Кави караватка торып утырган Илфатның сәламәт иңенә суккандай итте. Аның зәңгәр күзләрендә куаныч чаткылары биешеп алды, борынының уң яфрагындагы кечкенә генә миңе сикереп куйган шикелле булды. Юка иреннәренә бәхетле елмаю кунган иде.

— Яшәмәскә ни! Дөбердәтеп яшәргә әле сезгә, Кави туган.— Хәбиб абзыйның дәртләнеп елмаюыннан чаларган кашлары өстендә баскыч-баскыч булып тезелешкән тирән җыерчыклар язылып киткән төсле булды.— Илне, халыкны сыйлыйсыгыз бар ич!

— Шулай, бик шулай, Хәбиб абзый!— дип җөпләде Илфат.— Илгә ризыкны без дә бирмәгәч, кем бирсен?!.

— Әйе, әйе...— Гайсин фикерен дәвам итте.— Совет властена кунакка килгән шикелле генә яшәргә чамалаучыларга җае чыккан саен әйтә киләм: ипинең кибет киштәсендә үсмәгәнен беләмсез, дим. Юкса бит...

— Бар әле андыйлар да...— Монысын Кави Салихович өстәп куйды.— Бар...

Гайсин абзый үзеннән яшьрәкләрнең аның фикеренә кушылуына шатлана иде. Шунлыктан рухланып, яшәреп китеп, сөйләп алды:

— Андыйлар уйларга теләмиләр. Аларны үзләре турында гына түгел, киңрәк уйларга мәҗбүр итәргә кирәк, Кави туган. Ник дигәндә, үзенең җанын саклау, гомерен коткару, тамагын — тук, өстен бөтен итү, хатынын кочагына алу турында гына уйлый икән, дача, машина, хрусталь, ковер дип кенә сызлана икән, бу — бик аз. Бу тиклесе, туганнар, күлдән бер тамчы, көшелдән бер бөртек. Һич арттырмый әйтим, Кави энем, гражданинмын дигән адәми зат иле, халкы, тарихы, киләчәге турында да уйларга тиеш. Кулыннан килгән микъдарда, көче җиткән дәрәҗәдә кешелек дөньясы турында да уйларга тиеш.

Шулай булмаганда, без дөньяга гел юкка килеп киткәнбез булып чыга. Мина калса, уйларга теләмәүчеләрне уйга салырлык итеп уйлый алганнар бәхетле. Фикерләргә иренүчеләр бик күп. Алар төрле пәрәнҗә кигәннәр, төрле җиләнгә төренгәннәр. Андыйның гади крестьян булуы да, зур начальник, министр булуы да мөмкин...

Аннан сүз партия съезды хәлләренә күчте. Хәбиб абзый Сәмәрхановтан сорамый булдыра алмады:

— Съезд тикле съездда булгач, кәефләр ничек соң, Кави энем? Ал да гөлме?

Кави Салихович чал картка текәлеп, берничә секунд кына тын утырды да баш чайкады.

— Юк! Ал да гөл генә түгел, Гайсин агай. Чемоданыма Мәскәү күчтәнәчләре төяп кенә кайтмыйм. Алай итәргә хакым юк. Иңнәрдә тау хәтле йөк кайта. Киләчәктә гамәлгә ашырасылар өчен жаваплылык. Әлбәттә, шыңшырга сылтау эзләмим, сәбәп юк. Кәеф боевой, Гайсин агай. Күңел күтәренке. Без малай чакта шәп бер җыр бар иде:

Уралып-уралып ага
Уралдагы елгалар;
Большевиклар алалмаган
Крепостьлар юк алар.

Съезд кушканнар үтәләчәк. Үтәү җиңел булмас, әмма үтәлер.

— Рәхмәт, Кави энем. Хак әйттең...— диде Хәбиб абзый.— Съезд карарлары — тормышны тотып торган «китлар» инде ул безнең...

Кави Сәмәрхановка бу чагыштыру ошады бугай. Картның сүзенә ялгап, өстәде:

— «Өч кит», Гайсин агай. Экономиканы күтәрү. Идея-тәрбия эше. Оборонаны нык тоту. Шул.

Хәбиб абзый баягы сүзләренә тагын әйләнеп кайтты.

— Барысы да эшләнер, менә тәрбия эше катлаулы. Тәрбия эшенә әһәмият бирергә кирәк. Шул чагында отачакбыз, Кави туган, шул чагында! Югары аңлы кеше, намуслы, вөҗданлы кеше начар эшли алмый. Ул, сүз дә юк, менә дигән патриот та була...

Карт коммунист тәмам гәп комарына бирелгән иде. Күпне күргән, аңлы гомерен илгә-көнгә хезмәткә багышлаган ир, халык тормышына катылышлы мәсьәләләр турында сүз кузгалдымы, битараф кала алмый иде. Әмма зур эшләр хакында борчылып та, иртәгәсе көнгә ышанып та сөйләшү шул урында туктап калды. Палата ишеген ачып:

— Иптәш Гайсин! Врач янына!— дип өндәделәр.

Ул чыгып киткәч, Илфат та:

— Шактый утырдым, мин дә ятыйм әле,— диде. Кави бу сүзне үзенчәрәк аңлады булса кирәк.

— Ят шул, кордаш, ят. Өзлегә күрмә. Сакла үзеңне. Мин дә китим,— дип, жыена ук башлады. Илфат, киресенчә, аның бераз утыруын теләгән иде.

— Сез, Кави Салихович, минем сүзне дөрес аңламадыгыз бугай. Ашыкмасагыз, тагын берничә минут кына торыгыз инде. Биш кенә минут...

— Мин алай ашыкмыйм, кордаш. Үзеңә читен килмәсен дим.

— Килми. Хәзер эшләр алга бит инде. Сезгә сүзем бар. Киңәшем. Уртага салып сөйләшергә иде вобщем-то...

— Пожалуйста...— Кави баягы урынына килеп утырды.— Тыңлыйм. Сөйләшик.

«Сүзем бар» дип әйтүе алай авыр булмаса да, сүзне өздереп сөйләп китүе кыенрак икән. Шул аңлашылды. Тик сүзар жай юк иде. Илфат, гадәтенчә, чәчәксез-чуксыз, ничиндн керешсез Рәмзия белән

икс арада урнашып киткән мөнәсәбәтләрне бәян итте, ул ханымның яшьлектәге танышы икәнлеген дә әйтте. Барсын тезеп чыккач, кем алдындадыр акланырга теләгәндәй:

— Хәл белешүчеләр күп. Рәхмәт! Алар бер килерләр, ике килерләр, шуның белән эш бетәр. Һәркемнең үз мәшәкате, үз шөгыле муеннан ашкан,— диде.— Балалар да карыйлар. Әти генә дип торалар. Анысына да рәхмәт! Ну бит аларның да үз тормышлары бар. Рәмзия бит инде, килә икән, бер атнага, бер елга гына түгел, гомерлеккә килә...

Сәмәрханов, беравык тын торгач, өздереп әйтте:

— Бик әйбәт, Илфат. Бик яхшы, кордаш! Моннан да артыгын хыялланырга да кирәкми. Бәхетле була күрегез,— диде.— Ә син нәрсә дип әле жайсызланып-уңайсызланып ятасың?

— Бу хәлләргә кем ничек карар диюем.

— Туп-туры карарлар. Дөп-дөрес итеп. Халык ахмак түгел. Мин менә икенче бер хакыйкатьне үйлап алдым әле. Берәүгә куркыныч янаганда икенче берәүнең характеры ачыла, холкы күренә. Димәк, мин әйтәм, авыр хәлләрдә тормыш мәгънәсе табыла икән...

Илфат, жилкәсеннән йөк төшкәндәй, иркен сулап куйды.

— Рәхмәт яхшы сүзегезгә, Кави Салихович. Үгезне мөгезеннән тотып сөйләшер кеше юк иде әле. Өйләнүен өйләнәм инде мин аңа. Дөрес булырмы дип киңәшүем иде. Райкомның мондый мәсьәләләр белән шөгыльләнмәвен дә беләм дә, кеше итеп соравым иде.

Кави Сәмәрханов карават тутырып яткан әзмәвердәй иргә тагын бер карап куйды, ләкин бер сүз дә катмады. «Сакаллы сабый,— дип үйлап куйды ул эченнән генә.— Тау жимертеп эшли торган герой. Ничәмә еллар басу иңләгән. Үстергән ашлыгын бергә өйсәң, болытлардан ашар иде. Белмәгән һөнәре юк. Авылның гына димик, районның, республиканың абруйлы кешесе. Өйләнергә чират житкәч, мәлҗерәгән дә калган. Менә беркатлылык!»

Нинаять, райком секретаре китәргә дип урыныннан торды.

— Кайтасы көнеңне хәбәр итәрләр. Мин монда бүлек мөдире белән конкрет сөйләшеп китәм. Поездда кайтасыңдыр бит? Икәүләшеп, димәк?

— Шулай дип бик ышанып торам инде.

— Ташбуада каршылармар. Анысы проблема түгел. Мин әйтеп куярмын.

Мәшәкать дәрьясы — тормышның дәвасы

Гаиләңә кайтып, үз ояңның мамыклы-сихәтле жылысын тоюга ни житә!

Кави Сәмәрхановны хатыны Камәрия дүрт күз белән көткән. Мәктәптән дә иртәрәк кайткан (ул — педагог, табигать фәннәреннән укыта), аш-суын да бәйрәмчә хәстәрләгән, йорт-жирне дә жыештырып жинаслап куйган. Тугызынчыда укучы улын инде әйткән дә юк. Апасы әтисен төшләрендә күреп йөдәп беткән. Төштә күрү сагыну галәмәте микәнни соң? Төзелеш институтында укучы кызы да — ул архитектор булачак — бервакытны: «Әти, жәйге ак костюмнан төшемә керден»,— дигән иде...

Өйдә әйбәт, өйдәгедән дә шәбрәге булмыйдыр. Шулай да өйдә утырыр чак түгел. Иркенләп бер чәйләде, сөйләште-гөрләште дә, төш авышыр-авышмас ук Кави партия райкомына китте. Озакламый бюро членнары да жыелып бетте. Аларның күбесе белән Сәмәрханов тимер юл вокзалында, рәсми каршылау вакытында ук күрешкән, сөйләшкән иде инде.

Утырыш башланды. Көн тәртибенә райондагы бүтенге хәлләр куелган иде. Ягъни язгы чәчүгә хәзерлек, техниканы ремонтлап бетерү, чәчүлек орлыкны кирәгенчә хәстәрләп кую, ашлама кайтаруны төгәллә̆ү, кар сулары тотарга керешү һ. б.

Бюро членнарына район хуҗалыкларында булып кайту кирәк булыр дип киңәш тоттылар. Кемнең кайда булачагын ачыклаганда, Кави бер нәрсәне искә алу кирәклеген әйтте. Ул, съезд делегаты буларак, район үзәгендәге предприятиеләрдә дә, колхозларда да чыгыш ясаячак, хезмәт ияләре белән очрашачак. Очрашу булачак колхозларны үзенә билгеләүне сорады.

Иртәгесен иртүк (сәгать әле жиде тулып узган гына иде) Сәмәрханов кабинетына райкомның илленче еллар азагындагы беренче секретаре Таһир абзый Идиятуллин килеп керде. «Исәнмесез!»еннән алда: «Алты яшәр юлдан кайтса, алтмыш яшәр хәл белсен», дигәннәрме? Рәхсәттер бит? Саумысез!»— дип гөлдерәде. Яше житмешнең югары ягына сикергән булса да, Таһир Идиятуллинның гәүдәсе төз, йөреше тотрыклы, тавышы көр иде. Күзләре генә бирешкән. Яшьтән үк күзгә йомшак булган, күрәсең.

— Әйдәгез, рәхим итегез, Таһир Минһажевич!— Кави аны каршыларга дип, ишек катына атлады.— Узыгыз, утырыгыз, хәл алыгыз...

— Арымадым. Пенсионер талчыгырлык эш майтармый. Я, ничек йөреп кайттыгыз? Шуны сорашыйм дип йөрүем.

Кави бер дә иренмичә съезд турында сөйләде, үзенә бик кызыклы, гыйбрәтле тоелган хәлләрне искә төшерде, илнең атаклы кешеләре белән очрашуларын да әйтеп узды. Идиятуллинга да шулары тансык иде. Матбугатта чыккаларның хәрефен дә калдырмый ул. Канына сеңгән гадәт. Кызыл карандашы да кулыннан төшмәс. Сызып-сызып, үзе генә аңлый торган тамгалар куя-куя укый.

Таһир абзый озак тормады. «Эшсез килсә, эш калдырыр. Күзгалыйм. Күңелем түгәрәкләнде»,— дип кайтып китте.

Ул киткәч, Кави күңелендә хатирәләр өермәсе күзгалып алды. Шул кадәресе кызык: моннан егерме биш ел элек булган хәлләргә Сәмәрханов съездда күңеленә сеңдергәннәр, күргәннәр, ишеткәннәр югарылыгыннан карый иде инде. Әйтерсең лә ул бу минутларда да Кремльнең Съездлар сараенда утыра һәм чирек гасыр элек булып үткәннәр кино булып күренә.

Районны дер селкеткән чаклары бар иде Таһир абзыйның. Кулы каты, тавышы гөрелтеле иде. Аяусызлык белән алдырып килде. Бюро членнары белән исәпләшүе дә бик чамалы булды. Дөрес, райбашкарма комитеты председателе белән хисаплашырга мәжбүр иде. Шәмсуллин агай, Бөек Ватан сугышына кадәр үк вуз тәмамлаган тарихчы, өч елдан артык утлы фронт юлларында йөргән берничә орденлы офицер, бик гадел, чамасыз принципиаль, үз бәясен белеп, жирдә нык басып торучы работник. Урындык өчен һич кенә дә калтырамаучы коммунист Таһир Идиятуллинның һәр адымына бәя биреп, әйтеп бара иде. Өстәвенә, алар якташлар, колхозлашу елларында комсомолда бергә эшләгән кешеләр дә икән. Кыскасы, Шәмсуллин якташын үтәли күреп яшәде. Ә колхоз председательләре, совхоз директорлары, предприятие житәкчеләре кан калтырап торалар иде. Хәтта район прокуроры да аңа каршы сүз ычкындырмас иде.

Бер бюро утырышын онытасы юк Кавиның. Ул чагында район авыл хуҗалыгы идарәсенең баш агрономы иде инде. Аны бюроларның һәркайсына йөрергә мәжбүр итмәсәләр дә, бик еш чакыралар иде. Монысы— аңлаешлы хәл.

Идиятуллин кабинетына райүзәк оешмаларының, колхозларның житәкчеләре һәм партоешма секретарьларыннан егерме биш-утызлап кеше жыелган. Алар стена буена тезелгән урындыкларга утырганнар.

һәркемнең җаны тыгызлана, чөнки белә̆ләр: бүген Идиятуллин каһәренә кемдер эләкми калмаячак бит. Мәгәр алай булып чыкмады, гадәтилекне үзгәртеп җибәргән хәлләр булып алды.

Зур, якты, биек кабинетның уртасында «Т» хәрефе сыман урнаштырылган өстәлләр янында бюро членнары.

Таһир Минһажевич әлеге утырышны конференциягә хәзерлекне йомгаклау чарасы итеп күрә иде. Көн тәртибе исә гадәттәгедән аерылмый: игътибар үзәгендә хуҗалыклардагы бүгенге хәл.

Беренче итеп «Ак күл» колхозы председателе Гафаровка сүз бирделәр. Нинди сөйкемле сөяге бардыр, беренче секретарь аңа гашыйк, җил-давыл тидертмәү ягын гына карый, канат астында тота. Сөйли беләме, көйли аламы?!

Гафаров тавышыннан танып була торган зат иде. Гөбедән чыккандай тавыш. Гәүдәгә дә әллә ни таң калырлык димәссең югыйсә.

— Без, иптәш Идиятуллин,— дип сөйли башлады ул, беренче секретарьның керфегенә кунардай булып,— һәммә күрсәткечләр буенча планнарыбызны намус белән үтәп чыгачакбыз. Дәртле хезмәт вахтасына баскан хәлдә, без ил алдындагы изге бурычыбызны төгәл башкарып чыгу өчен...

— Кышлыкка терлек азыгыгыз җитәрлекме?— Шәмсуллин аны кырт кисеп бүлдерде. Шулай да Гафаров иярдән тиз генә егылучылардан түгел иде, сүзендә булды.

— Районнан җиткерелгән план күләмендә хәзерләдек...

Шәмсуллин чырай сытып куйды.

— Былтыр да «күләмендә» иде, февраль аеннан Чувашиягә салам теләнергә йөгердегез.

Гафаров барыбер дәвам итте.

Аннары «Сигнал» колхозы башлыгы Сабитов купшыланырга керешкән иде, аны икенче секретарь Закиров туктатты.

— Ниткән тантана соң әле бу?— Ул җилкәсен җыерды.— Кышка кергә торабыз. Алда иң кырыс айлар. Җитмәгәнне кайгыртасы урында күкрәк сугарга керештегез.

Шәмсуллин белән Закировның төкселеге, дөресрәге, дөньяга аек караулары, Идиятуллинның каның кыздырды, җенен кузгатты. Аның исәбенчә, әлеге председательләрнең чыгышлары конференциядә сөйләячәк речьләр булырга тиеш иде бит. Ниятенә аркылы төшеп тәмам кәефен кырдылар. Шунда ул сизелер-сизелмәс кенә дерелди башлаган калын иреннәрен кысып торды да сүзләрне сыгып-сытып әйтте:

— Сорауларны соңыннан. Аңлашыладыр?

Эндәшмәделәр.

Тагын бер колхозның партоешма секретаре, Тияк совхозы директоры, РТС җитәкчесе сөйләде. Шуннан соң Идиятуллин тәнәфес игълан итте. Утырыштагылар тәмәке көйрәтергә ашыктылар. Кави ул вакытта тәмәке тартмый иде әле. Коридорда кабинет ишеге буена ук куелган диванга барып утырды да, ниндидер мәгълүмат эзләп, куен дәфтәре битләрен актарырга кереште. Шулчак үз күзләренә ышанмас булып калды. Уяу килеш төш күрә идемени?!

Кабинеттан Идиятуллин белән Шәмсуллин килеп чыктылар. Икесе дә ярсыганнар, бәйгедән килгән аргамаклар диярсең.

— Соңгы көннәрең димәкче буласынмы?— Таһир Минһажевич кабинетта башланган кискен бәхәсне дәвам итә иде булса кирәк.— Шаярмый тор!..

— Партконференциядә ышанырсың! Көпчәккә күсәк син хәзер...— Шулай диде дә Шәмсуллин беренче катка, үз кабинетына төшеп китте. Идиятуллин бер мәл каккан казык кебек торды. Аннары, корт чаккандай, кинәт борылып, кабинетына ашыкты. Әйтерсең лә креслосы суынмасын дип кабалана иде.

Конференциядә Шәмсуллин делегатларга ачыктан-ачык мөрәҗәгать итте:

— Коммунист иптәшләр!— Ул кыска гына тыныш ясады, залны күздән кичерде.— Делегат иптәшләр! Минем сезнең һәммәгез белән дә ихластан сөйләшәсем килә.

Безнең Ташбуа районы хуҗалык тормышында берничә елдан бирле торгынлык кичерә. Алай әйтү дә азаккача хак булмас. Кайбер өлкәләрдә элек яулаган үрләрдән дә чигендек. Иген уңышы, узган бишьеллык белән чагыштырганда, кимеде. Ике ел рәттән терлекчелектә сынатабыз. Кадрлар белән эшләүдәге кимчелекләр күз алдында. Коллегиаль җитәкчелек онытылып бара. Мондый хәлдән чыгу юлын без, коммунистлар, табарга тиешбез. Әйдәгез, чынлыкның йөзенә туп-туры карыйк, иртәгә ничек яшәргә тиешлегебезне ачыклыйк...

Шәмсуллин конкрет саннар китерде, делегатларны җентекле анализ нәтиҗәләре белән таныштырды. Залда аңа ышанмаган кеше калмагандыр. Чыгышының ахырында, бер дә икеләнмичә, район партия оешмасын бүгенгәчә җитәкләгән коммунист Идиятуллин турында үз фикерен әйтте.

— Иптәш Идиятуллин һаман да искечә фикер йөртә, житәкчелектә иске ысулларга ябышып ята. Ул, бу сүзем өчен тулы җаваплылыкны өстемә алып әйтәм, бугаз һәм йодрык тарафдары. Оештыручы, тәрбияче булудан бигрәк, администратор-боеручы. Мәсьәләләрне яңача хәл кылыр заман җиткәнен тоймау, эшнең яңа формаларын өйрәнә алмау, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең яңа характерын аңлау сәләтеннән мәхрүм булу — менә аның фажигасы нәрсәдә. Ышанып әйтәм: үзгәргә сонарган работник инде ул...

Әйе, менә тугыз ел Кави да шушы постта...

Кави Салиховичның уйларын телефон чыңы бүлде. Тимер юл станциясе начальнигы шылтырата иде. Кайбер колхозларның ашлама ташуга исләре китмәвеннән зарлана, вагоннарны вакытында бушатмауларын, шуның аркасында штраф артыннан штраф түләүләрен сөйли, беренче секретарьның катгый чара күрүен үтенә.

— Тынлагыз әле, иптәш Семенов,— диде аңа секретарь.— Сез бик урынлы борчыласыз һәм мәсьәләне дөрес куясыз. Ләкин соравым бар: әлеге мәсьәлә буенча район авыл хуҗалыгы идарәсенә хәбәр иткәнегез булдымы? Юк? Ә райисполком председателе белән сөйләштегезме? Юк?! Менә бит мәзәк килеп чыга, әй! Туп-туры партия райкомына шылтыратасыз. Бу эштә мин аларны алыштыра алмыйм бит. Әйе, әйе. Безнең эшкә тыгыла дип рәнҗүләреннән куркып түгел, әлбәттә. Һәр нәрсәнең җае бар. Хуҗалык җитәкчеләре әмереңә дә колак салмаучылар табылса, колхоздагы җитәкче коммунистлар белән райкомда аңлашырбыз. Әйе, әйе. Хушыгыз!

Техник секретарь туташ та килеп җиткән икән. Ул, кабинетка кереп, «Интернационал» колхозыннан Әхмәтов Хәйретдин дигән механизатор кабул итүегезне сорый, диде.

— Керсен, әйтегез,— Кави кәгазьләрен актарырга керешкән иде.

Ишекне кыюсыз гына ачып, Хәйретдин бусагадан атлады. Бүре тиресеннән теккән йөнтәс бүреген кулына тоткан. Өстендә карага каккан кайры тун, аягында өйдә баскан киез итек. Тун кесәләреннән тышланган тире бияләйләр тырпаешып тора. Котыпка җибәрсәң дә туңмаячак иптәш.

— Исәнмесез, иптәш Сәмәрханов!

— Исәнмесез, утырыгыз.

— Съездлардан әйләнеп кайтуыгызны бик тә көткән идем, атлап-тунлап килүемә күрә, ярый әле, туры килдегез.

— Тынлыйм.

— Гозер зур инде минем, иптәш Сәмәрханов. Ярдәмегездән ташламасагыз иде...

— Сөйләгез.

Хәйретдин өр-яңа трактор белән Казна бригадасындагы ферма бинасын «сөздерү» тарихын, бик авыр булса да, сөйләп бирде. Һәр гаепле кеше төсле үк, чит-чатларын «кисеп» сөйләргә тырышты. Кави аны бүлдермәде. Ахырдан, әлбәттә, туп-туры әйтте.

— Болай гына түгелен мин яхшы беләм. Кичә бюрога килгәч, председателегез Кәрим Хәлимович тулырак сөйләде,— диде.— Судка бирмәгәннәренә сөенегез. Миннән нинди ярдәм өметләнәсез соң?

— Ярдәмнең зурысын инде, иптәш Сәмәрханов. Ике ел тракторга утырмый ничек чыдармын мин? Ике ел хатынсыз торудан да хуже лабаса! Түлисең түләдем, төзәттерәсең төзәттердем. Машина әүвәлгедән дә шәбрәк.

Кавиның мондый сүзгә ачуы чыкты. Тик аның дорфалана торган гадәте юк. Бу юлы да:

— Әкият сабыйларга бик кызык була ул,— дип кенә каршы төште.

— Мин илле бердә инде. Заводтан кайткан тракторны җимерттереп төзәттер дә, ул «әүвәлгедән дә шәбрәк» булсын, имеш. Тракторга утыртмау турында карарны мин чыгармадым. Сез эшли торган коллектив килгән шундый карарга. Кол-лектив! Үлчәгәннәр, уйлаганнардыр.

— Сүктеләр инде, кыздырдылар, чүт кыйнап ташламадылар. Андый вакытта бүтәнчәли нинди карар көтәсең?! Хәзер булды бит инде. Сез әйтсәгез, иптәш Сәмәрханов...

— Мин гөнаһлыларны ярлыкап утыручы рух түгел, Әхмәтов. Бу язда нинди эш кушалар?

— Наладчиклыкта эшләргә дилəр.— Хәйретдин, эшәке ис сизгәндәй, борынын җыерып куйды.— Егерме ел трактордa эшләгәннән соң...

Сәмәрханов исә кырт кисте.

— Бик яхшы вариант. Җимерергә акыл да, белем дә кирәкми. Менә көйләүче-җайлаучы булып карагыз әле. Бозыкны төзәтеп.

Хәйретдин әле һаман саламга ябышырга азаплана иде.

— Наладчикның тияре дә инде аның...

— Ә «тияре»н сездән берәү дә тартып алмаган, үзегез ыргыткансыз. Эшләгез, ир-егет икәнлегегезне күрсәтегез, аннары коллективта уйлап карарлар. Тагын бер киңәш сезгә. Өченче елгы кебек газетадан-газетага язып йөрмәсәгез икән. Кешеләрнең кыйммәтле вакытын урламагыз. Дөреслек дөреслек булып калачак...

Әхмәт Хәйретдинне рәнҗеп, сыкрап-сыктап чыгып китте. «Шулай инде, көчлеләр замана!»— саубуллашу урынына әйткәне шул булды.

Ә өченче ел... Өченче ел Әхмәтов ким дә түгел, артык та түгел, «Правда» газетасына жалоба язган иде. Корреспондент килде, тикшерде.

Жалобасы янына район газетасында үзе турында чыккан мәкаләне дә кисеп куйган. Анда Әхмәтов Хәйретдиннең ашлык суктырып алу буенча «Интернационал» колхозында икенче урынны яулаганлыгы язылган.

Дөрес, ул икенче урынны алган иде. Әмма авыл хуҗалыгы работниклары көненә багышланган тантанада аны мактап бер сүз дә әйтмәгәннәр. Монысы да дөрес, Хәйретдин Әхмәтовны мактаучы булмаган. «Председатель Кәрим Вәлиевне тәнкыйтьләгән идем, шуңа үчегә» дип язган. Менә монысы инде дөрес түгел!

Кави Салихович ул чакта «Правда» хәбәрчесенә әйтте, Әхмәтов Хәйретдиннең партия органнарына мөрәҗәгать иткәне булмады, нәрсә килеп чыккандыр, хәбәрдар түгелмен, ләкин иманым камил: «Интернационал»да кешене тик торганда рәнҗетмәсләр, диде.

Шулай булып чыкты да. Әхмәт Хәйретдиненә «Тик кенә торасы икән дә бит, юк инде— яза, жалоба яза. Гадәтенә кергән, һөнәренә әверелгән, шөгыле булып киткән.

Хикмәт тәнкыйтьчән үч алуда түгел, бүтәндә икән.

Һәр гектары кимендә утыз центнер уныш бирер дип торган ужым бодаеннан нибары егерме жиде центнер бөртек алына. Кем урдырган? Әхмәт Хәйретдине.

Контроль урдыру ясарга булалар. Шул ук басуга, әле урылмаган ягына, Илфат Маннуров комбайнын кертәләр. Рәхим итегез — гектардан утыз центнер яҗым!

— Нишләдең соң син?— диләр Хәйретдингә.

Баксаң, ул сәрхүш, салмыш баштан урып суктырган. Тизлекне арттырган, вентиляторны ябарга онытқан, бөртекнең бер өлеше саламга чыгып барган...

Шул хәлдән соң өч көн дә узарга өлгермн, Әхмәт Хәйретдине тагын «фокус» ясый.

Илфат Маннуров ул көнне урып суктыру нормасын йөз кырык алты процентка үти. Аның удар вахтасы хөрмәтенә «Сугышчан листок» чыгарыла, хезмәт даны флагы күтәрелә. Моңа Хәйретдиннең эче борып-мы-бора һәм ул, хөсетлегенә тәкать тота алмыйча, листокны куптарып ала да ерткалап ташлый. Ә үзе басу янгыратып акыра: «Я бутаганнар, я өстәп язганнар! Ничек булса да ялган!»— ди...

«Правда»га жалоба юллаганда боларның берсен дә язмый. Пешермичә ашарлар дигән исәп белән эш майтармакчы...

Телефон чыңы. Партия өлкә комитетыннан шылтыраталар. Тиздән булачак пленумда чыгыш ясарсыз дип ышанабыз, диләр. Хәзерләнергә кирәк булыр...

Съезд карарлары рухында райондагы конкрет эшләр торышын анализлау, иртәгәсе көнгә перспективаны ачыклау зарур. Очрашулар вакытында шул фикерләрне район халкына иреш терергә кирәк. Кешеләр фикерен белергә. Шәп таяныч булыр. Пленумда сөйлисе сүз шулай калыпланырдыр...

Өйдә, бер көйгә...

Мартның егерме бере иде. Мул булып кар төшә.

Илфат белән Рәмзия Казаннан Гөл-Төркемгә кайтып төштеләр.

Соңгы араларда йортта төп хужа булган Харис әтисен һәм... һәм Рәмзия апасын үзе каршылады. Ул бүген мәктәпкә бармаган иде.

Колхоз «Волга»сыннан төшүенә, егет әтисен култыклап алды һәм ачык капкага таба сак кына алып китте. Болдырдан озаклап менделәр. Өйгә кереп житүгә, Илфат кече улын кире борды.

— Бар, Харис улым, Рәмзия апаңа булыш.

Әйберләрне шофер егет кертешә иде инде. Харис Рәмзия апасы кулындагы чемоданнарны жай гына алды да жил-жил килеп өйгә таба китте. Артына борылып:

— Әйдәгез, Рәмзия апа, әйдәгез. Әйберләрне үзем кертеп бетерермен,— диде.— Хәзер, момент!..

Рәмзиянең ашыгып керәсе килмәде. Ханым сүз белән аңлатуы читен булган халәт кичерә иде. Ничегрәк дип атарга микән аны? Ятсынып торумы? Тартынумы? Язмыш борылышында кинәт уянып китеп, кабат уйга калумы? Кайчандыр бүтән хужабикә жиң сызганып йөргән жирләргә кыю гына атлап узарга аяк тартмавымы? Юк, боларның барысы да иде. Жиде кат үлчәп кисте бит инде. Унжидесе тулмаган кыз түгел.

Каш сикерткәнгә баш сикерткәндәй булып чыкмады шикелле. Әмма ни генә димә, ул хәзерге минутларда җирдә дә түгел, күктә дә түгел иде. Чәчрәп торган берәр чая хатын юкса килен булып төшкән йортын энәсеннән җебенә, казыгыннан казанына кадәр күздән кичерер иде.

Кара син бу гурничәне! Авылда мондый өйләр аз түгел хәзер, мәгәр Маннуровныкыларныкы үзенчә. Сагызы агып торган нарат бүрәнәләрдән биек һәм иркен итеп салынган алты почмаклы бу өй ерактан ук сәлам биреп тора. Урам якка зур-зур дүрт тәрәзә карый. Аларның йөзлекләре — агачтан челтәр. Яртылаш пыяладан торган веранда. Яшелгә буялган калай түбә. Имән баганаларга береккән зур капка крепость дивары сыман. Бурап салган келәт-абзарлар. Абзарлар тулы мал-туар. Сиңа алардан бизгән идең, яшьлегеңне хәтерләргә туры килер. Гараж. Гаражда Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең бүләге — «Москвич». Аның янәшәсендә Хариснын «матае».

Каралты-кура артына күз салсаң, менә дигән җиләк-җимеш бакчасын күрерсең. Мәрхәмәтсез суык кыштан соң караеп утырган алмагачларны санамаганда, ул — үзе бер питомник. Алмагачларның яшьләре тамыр җибәреп өлгергән. Җимешен генә көтәсе. Бик татлы була ул яшь агачтан зарыгып җимеш көтүләре!

Кер әле син, Рәмзия, кыюрак басып кер. Өй эчендәге заманча җиһазны, зәвык белән тупланган хәзинәне күрерсең. Синең квартираң белән чагыштырганда, бу өй эчендә бер генә нәрсә ким: хатын-кыз кулы тиеп тормый аңа. Инде бүгеннән бу мохтаҗлык та бетте дип исәплик.

Илфатка килгәндә, ул үз нигезенә кайтып төшүгә чамасыз шат иде. Монда һәммәсе үз, җанга якын, рәхәт. Исе дә, төсе дә, һавасы да. Поезд «Интернационал» басулары буйлап йөгерә башлагач ук, аның күңеленә пар канат үсте. Бер кулының зәгыйфьлеген онытып җибәрде ул. Кеше әйтеп кеше ышанмас: онытып торды.

Рәмзия искәрдәме икән, юкмы, тимер юл станциясеннән Гөл-Төркемгә кадәр араны «Волга»да җилдереп узганда, Илфат авызына су капкандай сүзсез кайтты. Кәефсезлектән түгел, анысы менә дигән. Хисләр тулышты, сүзләр артык булып калды, алар төссез, бәһасез иде. Туганнан бирле һавасын сулаган киңлекләр, кырык елга якын хәләл көче белән иген иккән кырлар кочагына кайтып керү шулай итте. Солдат хезмәтен тутырып кайтканда да шундый тойгылар әсирлегендә булганы бар.

Үз куллары белән бураган, үз куллары белән күтәргән, һәр чөенә, һәр кадагына хәтле үз куллары белән каккан өендә Илфат чишелеп китте. Кунакханәдә, больница палатасында, Рәмзия квартирында, вагон купесында аның күнел түрендәге гаҗәеп нечкә кылларны кемдер берничә төштән төенләп куйган иде кебек. Ул төеннәр хәзер чишелделәр, эреп юкка чыктылар. Тын алуы рәхәт, сулышка иркен. Уйлар яктырды, фикер көчәйде. Даруларның бәлки кирәге дә калмагандыр, савыгасына тамчы да шиге юк!

Харис Рәмзия апасы алдыннан ишекне каерып ачты, аннары рәхим итегез дигәнне аңлатып, артистларча кулын алга сузды. Моны абайлап өлгергән Илфат көлеп куйды.

— Әйдә, әйдә инде, Рәмзия! Үзебезнең өйгә керәсең ләбаса!

Рәмзия аяк астымда нидер ватылып китмәгәе дигән кебек кенә аттлый иде. Кереп, артыннан ишек ябылуга:

— Хәерле сәгатьтә! — дип пышылдады.

— Шулай булсын, Рәмзия! Әйдә, хуҗа бул!

Харис Рәмзия апасына чишенергә булышты. Аның затлы тунын, мамык шәлен алып элде, сапожкиларын җайлап читкә куйды һәм йөгереп кенә киез төпле өй туфлилары китерде. Нәкъ шул мизгелдә Харис үеннан да, Рәмзия фикереннән дә яшендәй сызылып бер үк уй үтте:

«Әнкәйнең туфлилары!», «Хатирәнең җылы аягында тузарга өлгермәгән туфлилар!» Илфат моны искәрмәде. Искәрмәве хәерле. Бүтән чакларда да Хатирәне Рәмзия белән чагыштыра-чагыштыра искә алганнары булыр әле. Булыр, булмый калмас. Тормыш диләр аны...

Ярый Рәмзия югалып калмады.

— Рәхмәт, Харис,— диде ул бик ипләп кенә.— Әнә теге зур кара сумкада башмакларым бар минем. Сумкамны гына алып бирсәңче....— Аякларына кигәч, Рәмзия Илфат каршысына килде. Илфат аңа беренче тапкыр күргән кешесенә карагандай томырылып карады. Аның күзләрендә бәхет нуры балкыды.

— Киленне бөтен йоласын китереп төшерә алмадык, бигайбә,— дигән булды Илфат. Беренче карашка өнсез-җансыз күренүе ихтимал булган бу ирнең шукланасы килә иде. Күңеле бәйрәм итә иде.— Авызына бал белән май каптыра алмадык, аяк астына келәм җәеп булмады, урындыгына мендәр түшәмәдек. Аннары үзеңне сынап бага алмадык. Токмач кистерәсе, йон эрләтәсе, чишмәгә суга җибәреп кайтарасы иде дә, вакыты ул түгел...

— Менә чәй куеп җибәрәбез хәзер, сынарсың. Карын ачты...

Рәмзия тагын нидер әйтмәкче иде, авызын ачкан килеш калды. Стенадагы сәгатьнең күкесе, сараеның ишеген ачып, ике мәртәбә кычкырды да, бу йортта ят кеше бар икән, оялам мин дигән шикелле, кереп качты. Рәмзия белән Илфат бер-берсенә карап елмайдылар. Сүзсез дә аңлашылды: кырык дүртенче елны хәтерләделәр. Илфат бүләк иткән күкеле сәгатьне.

— Икене кычкырды, икебезгә бер тиң бәхет теләде.— Илфат шулай юрады. Рәмзиянең ул юрамыш белән бик тә килешәсе килә иде. Кемнең генә бәхетле буласы килми соң?!

— Харис!— Әтисе ни беләндер маташа башлаган йорт хуҗасын янына чакырды.— Күрсәт әле Рәмзия апаңа самавырын, күмереп, суын. Куегыз әле чәй. Туйдым чәйнек чәеннән...

Харис моңа ихластан риза иде.

— Егерме беренче март — тарихи көн. Үндүрт сәгать өч минутта өй эчендәге бөтен вазифаларны җилкәмнән төшерәм, йорт кына минем биләмәм булып кала. Кабул итеп алыгыз, Рәмзия апа.

Рәмзия шаяруны кабул итсә дә, сүзне икенче үзәннән җибәрде. Сак кына, тыныч кына:

— «Сез» дип кенә сөйләшеп бетерә алмабыз, үскәнем. Бер-беребезгә «син» дип эндәшсәк, әйбәтрәк булыр,— диде.

— Килештек. Инде гарнизонны кабул ит, Рәмзия апа. Самавырның берсе монда. Әти ярата торганы. Икенчесе...

Бәхетле авызлар, чәй өлгертеп, өстәл хәзерләп бетүгә, Зөбәйдә белән Даниял килеп җиттеләр. Бабаларын күрергә Рафис белән Хафизны да алып килгәннәр. Китте исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сорашу, китте сабыйлар белән мавыгу. Өй эче гөж килеп тора башлады.

Сабыйларга мәми бир син аларга. Бабаларын онытмаганнар. Бигрәк тә Рафис. Дүртенче яше бит инде. Әбиләрен ятсыналар, белмиләр.

— Монысы — бабай, бабакай,— дип аңлатып маташты Зөбәйдә.— Монысы — тәти әби, әбекәй...— Шулай дип таныштыра башлагач, Зөбәйдә яшьле күзләрен яшерер өчен башын читкә борырга мәҗбүр булды. Шуннан соң, нидидер йомыш-сылтау табып, өстәл яныннан китте һәм әйләнеп килде. Рәмзия чамаладымы моны, чамалап та сиздермәдеме, сүзсез генә уздырдылар.

Кыз белән кияүнең аягы җиңел булды. Бик нечкәләп тормый гына, ишекне бер генә шакып, колхоз председателе Кәрим Вәлиев килеп керде. Гәүдәгә сөбханалла, тазалык җитү, тавыш моржадан чыга диярсең.

Керүе булды, бүреген-тунын да салмастан Илфатны килеп кочаклавы булды.

— Кайттыңмы, герой? Исәнме, Илфат абый! С приездом! — Аннары Рәмзия белән баш иеп исәнләште.— Хәерле көн! Исәнмесез!

Рәмзия дә аягүрә басып, күрешергә кул сузды.

— Рәмзия.— Ни әйтергә белми торганда, ярдәмгә Илфат килде.

— Рәмзия Маннурова булыр, Кәрим энем.

— Аңлашыла. Болай хәбәрдар идек анысы. Никахыгыз белән котлыйм. Бәхет телим. Ә сиңа, Илфат абый, с ходу благодарность. Идарә исеменнән...

— Нәрсә өчен әле?— Илфат председательгә гажәпсенеп карады.— Авырып яткан өченме?

Кәрим тип-тигез тезелешкән ак тешләрен күрсәтеп көлде.

— Син тирәк белән кирәкне бутама, герой иптәш. Кирәкне эшләгәнең өчен благодарность. Тегү эше остасы алып кайткансың бит, рәхмәт яугыры. Моннан бер атна элек кенә быткомбинат директоры белән якалаштым. Бина бар, җиһаз бар, ачыйк тизрәк Гөл-Төркемдә тегү мастерское, тегү цехы дим. Ул миңа тилегә караган төсле акаеп әйтте дә салды: «Кесәмнән чыгарып биримме мин сиңа мастерны?»— ди. Булды, ялыныч бетте, Илфат абый. Шулаймы, Рәмзия апа?

— Уйлашырбыз әле,— диде Рәмзия, сүзсез калмас өчен генә.

— Юк, юк, бүген-иртәгә эшкә чумарга димим лә мин. Принципта вәгъдәгезне алмак булам. Ә расписание мондыйрак. Апрель икесеннән санаторийга китәсез. Васильевога. Партком белән идарәнең карары бар, путевкалар гарантияләнгән. Туй сәяхәтегез шул булыр... Бер генә чәшкә чәй эчерегез дә китәм, Ташбуадан әйләнәсем бар... Болар белән сөйләшеп тормыйм инде.— Кәрим Зөбәйдә белән Даниял ягына баш какты,— күрә-күрә күз күгәргән, һәр көнне сугышабыз...

— Сугышмыйбыз ла инде, Кәрим абый...— Зөбәйдә төзәтеп куйды. Рәмзия апасы шиккә төшмәсен диде бугай. Даниял эндәшми генә утырды. Күп сөйләнә башласа, Кәрим аның «градусын» сизәчәк.

Председатель китеп, биш минут узды микән, дивана Җәләлетдин килеп керде. Аны күтәреп алгандай каршыладылар. Диванага почет дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр.

Керде Җәләлетдин. Шартын китереп сәлам бирде. Ашыкмый гына чишенеп, киемнәрен элде дә ишек төбенә барып чүгәләде Җәләлетдин. Илфатның хәлләрен бәйнә-бәйнә сорашты, Рәмзиянең кемлеген белештә, Даниял белән бер-ике авыз сүз сөйләшеп алды. Чәйгә кыстадылар, утырмады.

— Әле генә чәй яныннан тордым. Баллап чәйләдем. Ташбуа базарыннан килосын җиде тәңкәгә алып кайткан идем,— диде.

— Казан күчтәнәчләреннән авыз итәрсең, Җәләлетдин.— Илфатның аны чын күңелдән өстәл янына өндәве иде.

— Күчтәнәч — күчкән аш инде ул, Илфат абый.— Җәләлетдиннең ни әйтергә җыенуы булгандыр, анысын аңлап җитмәделәр.

Сүзгә Зөбәйдә кушылды.

— Әти синнән яшь бит, Җәләлетдин абый. Ник син үзеңнән яшьләргә дә «абый» дисең?

Җәләлетдиннең айның ундүртенче кичәсе төсле түгәрәк йөзенә, аксыл чыраена (ул бик пөхтә, кырынып йөри, чәч үстерми) хәйләкәр елмаю чыкты.

— Картаймас өчен,— диде дә көлеп җибәрде. Гадәте шул: ыһы-ыһы дип, кинәнеп көлә.— Картаймаска була шулай дим.

— Картайсаң нәрсә? Синнән генә калган мәллә?— Дивана белән дипломатик сөйләшүләргә Даниял да кушыласы итте.

— Картайсаң, пенсиягә чыгаралар.

— Чыгарсалар ни? Эшләми генә акча аласың.

— Барыбер шәп түгел!— дип өзде дә куйды Җәләлетдин.— Пенсиягә чыккач, мин кем? Просто Җәләлетдин.

Бу урында көлү килешеп тә бетмәгәндер дә, чыдый алмадылар, дәррәү көлеп җибәрделәр.

— Ә бу килеш кем син?

— Җәләлетдин Хаялетдинов. Белдеңме?

— Синең белән сөйләшсәң!— Даниял кул селтәде дә кухня ягына кереп китте. Берсеңә дә күрсәтми генә берәр чокыр тегене авыз итмәкче иде. Тельняшка астында ак башлысы бар иде аның

Сорауга җавап биреп утыру гына түгел, Җәләлетдин үзе башлап сүз кушарга да күп алмый. Әнә ич:

— Илфат абый, миңа акча бирәсеңме?— дип чат ябышты.

Әтисе аны-моны әйткәнче Зөбәйдә сорап өлгерде.

— Нишләп сиңа акча бирсен ул, алып торганы бармы әллә?

Җәләлетдиннең колагы да селкенми, күзен дә йоммады, дәгъвасын үзенчә нигезләде дә бирде.

— Ул бит герой. Геройдан садака тиеш.

Илфат бик гадәти эш эшләгән шикелле, кесәсеннән акча чыгарды һәм Җәләлетдингә бирде. Рәмзия теге еллардан бирле бу дивәнаны оныткан булгандыр инде, мәзәк катыш сәерсенү белән аның сөйләшүләрен тыңлап торды һәм үзенә дигәндә бер дә дивана түгел бу, дип нәтиҗә ясады.

— Сиңа хәзер начар эшләргә ярамый инде, Илфат абый, э?— Акчаны пинҗәгенең түш кесәсенә салып куйгач, Җәләлетдин геройга шулай эндәште.

— Начар эшләргә беркайчан да ярамый, Җәләлетдин.

Кухня ягыннан морадына ирешеп чыккан Даниялның кәефе күтәрелә төште булса кирәк, дивананы шаяртырга кереште.

— Синең хатын кайсы авылдан әле, Җәләлетдин.

— Өчмунчаныкы.

— Холкы әйбәтме? Тату торасызмы?

— Ярый. Елгасына күрә басмасы, күперенә күрә тактасы. Менә сез тату торасызмы, Даниял абый?

Даниял ник дәштем дигән көнгә төште, кәмит итә бит бу дивана хәзер үзен. Чыннан да, шулай килеп чыкты, көч-хәл уенга сабыштырып котылдылар. Нәрсә ди?

— Синең хатын әйбәт, Даниял абый. Шуңа әйбәт торасыз. Ату бит син кызлар артыннан чабасың...

— Житте, теленә салышма!— Кызмачаланып алган Даниял тавышын күтәрмәк булган иде, бабасы тынычландырды. Куй, янәсе дивана белән дивана булма!

Җәләлетдиннең китәргә ният сизелми иде әле.

— Мин син кайтканны көттем, Илфат абый,— диде ул, бер дә көткән кешегә охшамаганча гына.— Әхмәт Хәйретдинне өстеннән жалу бирәсем бар. Жир бит ул! «Илфат байлыгыннан гарык, иту көчәнә, барып чыкты әнә» ди. «Гомере буе чапты» ди...

Рәмзия дивананың сүзләрен колак торгызып тыңлый башлады. Илфат та житдиләнде. Җавабында тимер суыгы сизелде. Мәгълүм инде, ул Җәләлетдингә генә сөйләми, кызым сиңа әйтәм, киленем син тыңла төзлерәк чыга.

— Минем сөйләгәннән сүтелер чагым үткән, Җәләлетдин. Син дә борчылма. Тыңлама да син андыйларны. Вообще-то, әйтсәң-әйтмәсәң дә, тамагым тук, өстем бөтен, йорт-жирем төзек, мал-туарым житәрлек минем. Машинам да бар. Урлап жыймаган, юлбасарлык итмәгән, барчасы — хәләл көч жимеше. Ну бит илнең һәр нәрсәгә дә туенган чагы

юк бит әле. Менә нилектән тырышырга кирәк. Аннары дөньяның бер сыныкикмәккә тилмергән сабый-нарасыйлары бар. Аларга да өлеш чыгарасы иде, Җәләлетдин дус. Шунысы да хак: без бит җан асрау, тамак туклыгы хакына гына эшләмибез, тәм табып, ләззәтләнеп эшләр өчен дип тә яшибез. Карын тутырыр өчен генә тырышып-тырмашып йөрсәк, пучтәк булыр иде. Якты дөньяга килгәнбез икән инде, значит, юкка түгел... Әхмәт Хәйретдине ишеләрдән бердәнбер файда: андыйлар үзләренең әшәкелекләре белән чын кешеләрнең кадерен белергә ярдәм итәләр. Акны карадан аерырга...

Зөбәйдә Рәмзия апасы янына барып утырган иде. Уллары аның тезләренә ябышканнар, итәгенә үрмәләмәкчеләр. Хатыннар Илфат сүзләрен әсәрләнеп тыңлыйлар иде.

Кече яктан тагын бер урап чыккач, Даниял бабасын тырга мата-ша башлады.

— Сөйләдең ни аңа, бабай, сөйләмәдең ни! Талдырма теленне, кирәкми.

Даниялның бурлаттай кызарып чыкканын искәреп алгач, әйтиммеюкмы диебрәк торган иде. Рәмзиянең беренче аяк баскан көне ич, Илфат барыбер шактый кырыс әйтеп салды:

— Аңа дип кенә сөйләмим мин. Синең колагыңа да кермәсме дию-ем. Безнең буын үз эшен үтәде, сез нишләп бетәрсез?— диде.

Уйландырган сәлам-хат

Соңгы елларда кешеләр хат язышуга артык бер шөгыль итеп карый башладылар шикелле. Телефон бар, телеграф. Әвакыт тар, дөнья куабыз. Озаклап каләм тибрәтеп утырганчы тот та шалтырат, ун-унбиш сүздән телеграмма сук. Фикереңне аңлаячаклар, морадыңа ирешәчәксең. Шулай, анысы хак. Ләкин... җырда «хатка язып сүзләр бетми, бик күп сүзләрем кала» дигән зар булса да, хат аша тәмләп сөйләшүләргә ни җитә!

Евгений Иванович Логинов та (малай чактагыча әйтсәк, Детдом Женя) шулай уйлый булса кирәк. Илфатка ул елына бер-ике хат язмый калмый. Сугыш астыннан качып килгәч, сыену тапкан төбәге шул Ташбуа җире. Тагын шул: Гөл-Төркемнән ике генә чакрымдагы Петровка зиратында аның әнисе күмелгән.

Женяның хаты Илфатлар иртәгә санаторийга китәбез дип торган көнне килде. Рәмзия белән бергәләп укыдылар. Ә бит Рәмзия ул егетне бик әйбәт белә.

«Сәлам Белоруссиядән!— Женя һәр хатын шул сүзләр белән башлый.— Сәлам Могилев каласыннан! Хәерле көн, Илфат!

Бу хатны төн уртасында язам дисәм, гажәпләнмә, яме. Балалар изрәп йоклый, Наталья да жиденче төшен күрә бугай инде. Көнозын аяк өстендә бит, арыганнар. Мине йокы алмады. Озак кына уйланып яткач, торып утырдым. Тукта әле, мәйтәм, Илфатка хат язып ташлыйм әле, дим.

Йокы качуның үзенә күрә сәбәбе бар, дускай.

Кичә безнең цехта тантана булып алды. Моның сәбәпчесе мин идем. «Строймаш»та эшли башлавыма утыз ел тулуны билгеләп үттеләр. Почет грамотасы бирделәр, төсле телевизор бүләк иттеләр. Завод директоры үзе тапшырды. Депутат ул безнең, атаклы кеше. Кулымны кысып: «Так держать, Иваныч!» дигәч, кочаклап үбәсе килде үзен. Син беләсең, Илфат, мин шактый коры адәм, тормыш та чыбыркылап, кырыс итеп үстерде, хискә бирелү — минем стихия түгел. Шулай да хезмәтең өчен зурлаганда күңел йомшый, тойгылар кузгала икән. Йокы качу да шуның нәтиҗәседер инде.

Утыз ел! Әйтергә генә ансат. Армиядән кайткач, илле беренче елны өйрәнчек булып урнашкан идем бу заводка. Хәзер ветеран инде. Я хода, гомер дигәнең ничек уза!

Ветеран дип тә хөрмәтлиләр, остаз дип тә зурлыйлар, ышанычны аклап бетерәсе дә җиңел түгел, әй! Турысын гына әйткәндә, синдәге уңай якларга күз йоммасалар, күңелгә хуш килә икән ул, Илфат Фәйзерахманович. Мораль стимулның бер өлеше шулдыр, күрәсең. Кеше күңелен күрү, гади генә әйтсәк.

Мактый торгач, мәзәк хәлләргә дә җиттеләр. Тантана вакытында хәзерге өйрәнчекләремнең берсе (алар өчәү минем) әйтте: «Безнең Евгений Ивановичның белмәгәне юк. Ул ат та җигә белә»,— ди. Шәһәр малае шул инде?! Ат җигүне дә эшкә саный бит. Ул да проблема...

Шул сүзләрдән соң залдагылар башта гөр килеп көлделәр. Завод директоры: «Ат җигү үзен эш түгел ул. Димәк, Евгений Иванович — чын ир кеше» дип куйган иде, ду китереп кул чаптылар. Шунда инде мин яшьлегемә кайткан төсле булдым, уйларым белән сугыш елларына, Ташбуа якларына, Гөл-Төркемгә синең яныңа юнәлдем. Ат жигәргә дә, үгез жигәргә дә сезнең авылда өйрәндем бит мин, беләсең.

Мине мактаган егет моны кайдан белә дисеңме? Көзен без шефлыкка алган колхозыбызга бәрәңге алуда булышырга бардык. Комбайн казыган бәрәңгене басу читендәге өемнәргә атлар белән ташыйлар. Төш вакытында атларны туарып, ялга куйганнар. Ашагач-эчкәч, бахбайларны жигәргә кирәк ич инде. Колхоз егетләре безнекеләргә төрттерәләр. «Җигеп бирмәссезме?», янәсе. Ике-өч егет маташып карады, кулларыннан килмәде. Миннән азрак кына яшьрәк ир дә хурлыкка кала язды. Камытны кире ягы белән кидертеп азаплана бит бичара. Шуннан үземә жигәргә туры килде. Нужа печән ашата ул, мин әйтәм... Авылын да күрдек, атын да, үгезен дә жиктек, дим. Син аңларсың, Илфат, шул сүзләрне бик горурланып әйттем...

Бу хатны язудан максат — синең белән киңәшү, синең рөхсәтеңне сорау да, Илфат, эш шунда, мин быел җәен, туры китереп булса, сабантуй көннәренә Гөл-Төркемгә кайтырга жыенам. Наташаны да алып, Славканы да ияртеп (ул быел тугызынчы классны тәмамлый бит инде). Ирина исә быел дүртенче курсны бетерә, ул студентларның төзелеш отряды белән китәчәк.

Семья белән сезнең якларны күреп кайтырга планлаштырып торабыз, шулай итеп. Үзем Зөя буйларын сагындым. Гомер узып бара, бер барып кайту шәп булыр иде дим. Сабан туена да туры килсәк, ни әйтер идең. Бездә дә бәйрәмнәр аз түгел, әмма минекеләрнең татарча милли бәйрәм күргәннәре юк бит әле. Сина барып төшәргә дип планлаштырам. Рөхсәт итәрсең, кабул күрерсең дип ышанам. Ышану — бер нәрсә, жавап хатында конкрет рөхсәтеңне язарсың әле, яме.

Гөл-Төркемгә барудан, үзең әйбәт төшенәсең, тагын бер максат бар: әни каберендә булып кайту. Килене дә, оныгы да ул жирләнгән туфракка аяк бассыннар дим. Сина мең-мең рәхмәтләр, әнинең каберен карап, чардуганын буяп торасың. Имин-тыныч елларда мин бу эшләрне үз кулым белән дә башкарып кайтырга бурычлы бит.

Үзеңдә ни хәлләр? Нинди яңалыклар бар? Язгы чәчүгә хәзерләнәсездер. Балаларың ни эш бетерәләр? Иренми генә, озакка сузмыйча жавап яз әле, яме. Көтеп калам.

Барчагызга күп сәламнәр юллыйм. Евгений...»

Гадәти бер хат. Мондый сәлам-хатларны Евгений Логинов сирәк булса да язгалый тора. Бусы Илфатның уйларын чоңгылдагы су сыман бөтерә башлады. Жавап дигәндә, язар ул аны. Бүген үк. Рәмзия белән икәүләп язарлар.

* * *

Гитлерчылар илебезгә басып кергәч, тормыш төбеннән-тамырыннан үзгәрде. Яу басып алу куркынычы янаган шәһәрләрдән ерак тылга эвакуацияләнгән кешеләр кайта башлады. Гөл-Төркемгә дә Мәскәү, Ленинград, Донбас якларыннан берничә семья кайтып төште. Аларның бер ишеләре моңа тикле ишек-тәрәзәләре кадакланып буш торган өйләрдә яши башлады, икенчеләре бүтән гаиләләргә өйдәш булып керде.

Илфатларга да өйдәшләр табылды. Могилев шәһәреннән улын ияртеп килгән тетя Катяны (авылда аны һәркем шулай атады, Екатерина Николаевна икәнен колхоз председателе белән бухгалтер гына белгәндер) аларга керттеләр. Күчеп килүчеләр кече якта торасы булдылар.

«Күчеп килү» мәзәк кенә яңгырый. Бәгырьне телгәләрдәй мәзәк. Өсләренә ни кисәләр, шуның белән чыгып киткәннәр инде алар. Чемоданнарына да кул асларына ни эләксә, шуны гына салырга өлгергәннәр. Туган-үскән җирләреннән купкан сугыш качаклары алар. Этиләре шуннан өч-дүрт көн элек кенә сугышка алынган булган. Шулай да гаиләсенең Татарстанга җибәрелүен белеп калган ул.

Женя, Екатерина Николаевна Логинованың улы, әнисенә бик охшаган. Қойган да куйган тетя Катя инде менә. Какча гәүдәле, озын буйлы, ак йөзле, зур зәңгәр күзле. Икесенең дә чәчләре арыш саламы төсле аксыл-сары. Русчаны, белорусчарак итеп, сузыбрак сөйләшәләр. Ә татарча ләм-мим. Қаян белсеннәр?! Сугыш чыкканчы тере татарны күргәннәре дә булмаган лабаса. Маннуровлар гаиләсе аларны кызганып та, теләктәшлек күрсәтеп тә кабул итте. Механизаторлар семьясының күңеле киң иде.

Табигате-холкы белән кешене якын итүчән Маһибәдәргә Екатерина Николаевна бик тиз ияләште. Хатынны фермага сыер саварга куйдылар. Берсе — басудан, икенчесе фермадан кайтып керә алмасалар да, бер-берсенең гелләрен белүләре ташка үлчим генә булса да, аңлаштылар, уртаклык таптылар. Ил өстенә килгән афәт ерак кешеләрне дә якын итте. Бер-берсенең күңелләрен аңлаган хатыннар, ике семья бергә укмашып яши башлагач, яңа бер көч белән тернәкләнеп киткән төсле булдылар. Хәсрәт кочагында күгәреп-күшегеп утырып чак түгел иде. Малайлар да эшкә ябышты. Илфат белән Женя, ат атланып, катлаулы сугу машинасыннан чыккан саламны эскертләргә тарттырдылар. Гөл-Төркемнәрчә әйтсәк, «возилка»да эшләделәр. Ашлык суктыручыларга яртышар кило икмәк бирәләр, төшкә аш пешерәләр иде.

Илфат — тәпили башлаганнан бирле ат ялына ябышып үскән малай. Ул аңа күнеккән. Женя баштарак ат менеп йөри алмыйча тәмугъ газаплары кичте. Ике боты белән атны кысып алу дисеңме, әледән-әле чытырдап ялына ябышумы, курка-курка бара торгач ат өстеннән мәтәлеп төшүләрме — берсе дә калмады. Маңгаена «мөгез» чыгуга да, тез күмәчләренең зәңгәрле-күкле күгәрүенә дә, йомшак җирнең суелып-чиләнеп чыгуына да чыдады рус малае. Атка ул гашыйк иде. Шул түзем бирде, шул коткарды.

Қырык бернең көз азагында Гөл-Төркемгә Ржев шәһәреннән эвакуацияләнгән балалар йорты киләчәк иде. Йөздән артык ятим баланы каршылап урнаштырасы, туендырасы, урын-җирен әмәллəп бирәсе, укуларын башлап җибәрүгә хәстәрлисе бар иде. Рус балалары киләсе булгач, Екатерина Николаевнаны да шул эшкә күчереп тордылар.

Ятимнәрнең килүенә дип авыл халкы үз өеннән онын, бәрәңгесен, сөтен, маен китерде. Ятимнәр йорты элеккеге ике катлы мәчеткә, сугыш алдыннан авыл Советы булып торган бинага урнашырга тиеш иде. Авылның нәкъ уртасына — Ураздан Ташбуага уза торган юл буендагы бинага.

Пыскак яңгыр илəп торган көн иде. Ындыр табагында эш тынып калган. Илфат белəн Женя да Ржевтан килүчеләрне каршыладылар. Малайлар ниндидер серле яңалык көтте.

Менə бер заман Бикмураз ягыннан атлы олаулар килеп чыкты. Утызлап олау иде шикелле. Атлары шактый өшəнгəн, Тəтештəн үк кайтулары, кырык чакрым ара узганнар дигəн сүз. Һəр арбада дүрт-биш бала, кечкенəләрне хəтта алтышарлап та утыртканнар. Иске мəчет янына килеп туктауга, ояларын тузгыткан кырмыскалар сыман, барысы да арбалардан сикерешеп төштеләр. Күшеккəннəре байтак иде. Алжыганнар, ачыкканнар, төсләре качкан. Өсләрендə дə ни эләкте шул. «Авызларын ачкан» ботинкаларының башларын юкə белəн бəйлəп, тимер чыбыклар белəн каптыргалап куйганнары да бар. Юлда килгəндə, кесəләренə бодай уып тутырганнар. Малайларның күбесе бəләкəй учларында авыш-тəвеш китереп, шуны җилгəрəләр дə авызга озаталар. Кызлары алай ук чəчрəп күзгə керми, тыйнаграк, эдəплерəк булып, бергəрəк жыелышып торалар иде. Наташа исемле бер бик сөйкемлесе бар. Илфатка аның фамилиясе кызык тоелды — Дроздова. Миләш чыпчыгы дигəн сүздəн микəнни?

Балалар йортының күчеп килүе авыл халкы өчен галəмəт зур яңалык булды. Ул көнне иске мəчет яны Ташбуа базарын хəтерлəтə иде. Бала-чага, хатын-кыз, карт-коры умарта иле кебек. Бер ишесе юлдан килгəн чит-ят балаларны мескен ятимнəр дип кызгана, икенче берəүләр авылга балалар йорты күчеп килүне хəерлегə түгел дип юрый, капканы, ишекне, кар базын ныгытырга кирəк дип сөйләшəләр. «Бу чирү көн күрсəтмəс безгə! Тенкəләребезне корытыр эле», дип сагаеп калучылар да табылды.

Атлы олаулар тирə-юньдəге авылларга, үз колхозларына кайтып киттеләр. Юлдан килүчеләрне елгага алып төшеп юындырдылар, ике чиратка бүлеп, аларга кайнар аш ашаттылар, район үзəгеннəн кайтарылган матрац тышлыкларына салам тутырттылар. Караватлар һəммəсенə житмəде. Малайларның əллə ничəсе беренче көннəрдə урынны идəнгə жəеп йокларга тиеш булды. Тик моңа аларның бик исе китмəде. Тамак ялгагач, кəефләре күтəрелеп китте булса кирəк, Гөл-Төркем малайлары белəн аралашып, татарча икмəк, бəрəңге, сөт, йомырка сорарга өйрəнə башладылар. Авылныкылар эйтə, тегеләрнең тел эйләнми, «икмик», «биранга» дип бозып сөйлилəр. Авылныкыларга кызык тоела, көлə башлыйлар, тегеләрнең ачуы килə. Этəч шикелле, бер-берсен чукышып алырга дəртлəнүчеләр дə табыла.

Ятимнəрнең килүе олыларның хəсрəтен куертып, ишəйтеп кенə жибəрде. Күз көекләре бит балакайлар!

Борчу өстенə борчу, хəсрəт өстенə хəсрəт килеп кенə торды. Авыл боегып калды. Һəр тумыш көнне армиягə китүчеләрне озаттылар. Беренче яралылардан хəвефле хəбəрләр килə башлады. Һəлак булучылар хакындагы кəгазьләр саны да ишəя барды. Һəр йортның диярлек түр башына кайгы аяк бөкләп кереп утырды. Бүген кермəгəн өйдə дə аны иртəгə-берсекөнгə килер дип көттеләр.

Сугыш башланганга ярты ел булып килə иде. Бу вакыт Екатерина Николаевна өчен бик-бик озак булып тоелды. Дөресен генə əйткəндə, аның сугышны күз алдына китерүе бик томанлы иде. Кайдадыр канлы бəрелешләр бара, гаскəрләр авылларны һəм калаларны яулап алга ыргылалар. Алай да булмый, кире чигенəләр. Ləкин артка чигүләре вакытлы хəл генə. Менə алар — совет гаскəрләре — ташкын булып алга ташланалар да эреле-вакты хуторларны, шəһəрләрне лəгънəт сугасы нимчурадан бөтенлəйгə азат итəләр. Белоруссиядəн кубып-каерылып китəргə мəжбүр булган кешеләр дə үзләренең жылы, жайлы өйләренə кайтып урнашалар, ямьле көннəр башлана...

Екатерина Николаевнаның фəкать шулай гына уйлыйсы килə һəм

ул бары шул рәвешле генә уй йөртә ала иде. Белоруссия җиреннән сакта, билгесез татар авылында уза торган бу көннәре кыска вакытлы бер сынау гынадыр сыман тоела иде. Ул җаны-тәне белән фашистлар өренә тиз көндә әҗәл килүен тели, аларның дөмегер сәгатьләре менә-менә сугар төсле тоела иде. Һәрхәлдә, сугыш озакка китмәс, юк, китмәс!..

Әмма Совинформбюро хәбәрләре аның ашкынулы өметләрен боз белән томалый торды, хыялларының чынга әверелүен күпкә кичектерде. Сугыш өермәсе китереп ташлаган төбәктә тамырланырга, көн итәр өчен эрсезләнергә кирәк иде. Җан асрау кайгысы гына түгел, фронтны туйдырышу, ут эчендәгеләргә кулдан килгән ярдәмне күрсәтү бурычы да бар иде бит.

Укулар башлангач, өйдә Илфат, Женя, Илшадия хуҗа иделәр. Өлкәннәрнең кайтып керергә дә вакытлары юк. Кайтып йоклыйлар гына. Илфат татар классында алтынчыда укыды, Женя рус классында — балалар йортындагылар белән бергә шулай ук алтынчыда белем алды. Иртәгесе көнгә дәресләрен хәзерләп бетергәч, ике малай «тел түгәрәге» уйнарга керешә торганнар иде. Илфат бер сүзне татарча язып куя, Женя шул ук сүзне янәшәгә русча, белорусча яза. Бу уен белән алар шул тикле мавыгалар, әниләре кайтуга чәй кайнатырга да оныталар иде. Илфат рус, белорус сүзләрен бик авырлык белән генә әйтә, Женя да татарчаны шактый авыр эләктерә. Малайларның бу шөгыле әниләренә бик ошый иде.

Фронтлардан берсеннән-берсе күңелсез хәбәрләр килеп торса да, гомер дигәнең үз көенә ага бирде.

Мәскәү янында безнең гаскәрләрнең хәлиткеч һөҗүмгә күчүе, айлар буе сөремләнеп яшәгән күңелдә нур сызды. Кешеләр башларын күтәреп карады, иркен сулап куйды һәм газапларның һәртөрлесен ерып чыгарлык кодрәтләре барлыгын ныгытып төшенде. Шулай итеп, кырык икенче ел керде. Иң авыр елларның берсе, сугыштагы кешегә дә, ерак тылда калып көн итүчегә дә бик кырыс имтихан булган ел.

Январь азагында Екатерина Николаевна хат алды. Урау юл үтеп килгән иде ул хат. Омскидан, госпитальдән. Ире Иван Данилович язган иде. Каты яраланганнан соң, аны шул шәһәргә дәваланырга озатканнар икән. Иван Логинов хатының һәм малаеның адресын төгәл белмәгән, республиканың эчке эшләр халык комиссариатына язган һәм семьясын табып, тапшыруны үтенгән.

Үзара киңәш-уңаш иткәч, Екатерина Николаевна ире янына барып кайтырга дигән карарга килде. Юлга чыгарга рөхсәт кәгазен председатель Кәлимулла абый Алимов юллашты. Хәлдә барынча күчтәнәч тә хәстәрләделәр. Тирә-күршеләр дә хәзинәдә булганыннан өлеш чыгардылар. Екатерина Николаевна хәтта сәерсенеп тә калды.

— Ничек инде бөтенләй белмәгән кешегә карата мондый юмартлык күрсәтәләр?

— Безнең халыкның гомерлек гадәте инде ул, Катя,— диде Мәһибәдәр.— Бары — бергә, югы — уртак. Яралы кеше янына буш кул белән бармасын диюләредер. Илгә килгән бәла бер йодрык итә...

Чуен юлга, Канаш станциясенә Екатеринаны ат белән илтеп куйдылар. Кыскасы, ире дәвалана торган госпитальгә барып ирешү кадәресе заманына күрә алай ук та зур газаплы булмады. Ире белән иркенләп күрешеп сөйләшергә дә мөмкинлек бирделәр. Әмма Иваны белән күрешү Екатерина Николаевнага гомерлек җан әрнүе китерде. Иван Логинов ярты кеше генә иде: ул сул кулын һәм уң аягын өздергән булып чыкты. Протез киярен әйтте, бер миңа гына килгән бәхетсезлек түгел, ил белән дип юатырга теләде. Ләкин аның сүзләре көчсез, күз карашы солдатның киләчәк язмышы күңелне шомландырырлык булу хакында сөйли иде.

Иван ике сүзнең берендә Женяны сорашты, улын бик-бик сагынганлыгын әйтте, Татарстан хәлләре белән кызыксынды һәм, әлбәттә, сугыш беткәч, туган төбәкләренә әйләнеп кайту өмете белән яшәвен дә әйтми түзә алмады.

Екатерина Николаевна башта елады да елады, тыела алмады. Беравыктан үзенең хисләрен тезгенләгән сыман булды һәм уллары хакында да, Гөл-Төркем авылы, аның кешеләре, колхоз тормышы, дөнья четереклекләре турында бәйнә-бәйнә сөйләде.

— Һәркайда мәрхәмәтле кешеләр бар икән, Иван,— диде ул.— Илдә чыпчык үлми диләр бит, без дә сыеныр урын, ашар ризык, э эшләр эш таптык. Җиңел түгел, о-о-х, жиңел түгел, әмма чыдыйбыз. Түзәрбез! Бу елларда кемгә генә ансат соң?! Тизрәк фашистларны дөмектерүне теләргә кала. Аннары гәүдәбез тураер, йөзебездә нур артыр иде әле...

Екатерина Николаевна ире янында өч көн булды. Әмма житәсе аерылышу сәгате житә инде ул. Саубуллашыр минут килеп житте. Кул бирешеп аерылу тагын да газапка әверелде. Хәтта Логинов үзе дә, авырлыкларга теш кысып, тел тешләп чыдаган кеше, чакматаштай ират та азаккача түзә алмады, күзләренә яшь тулды.

— Озак кына «ремонтлар» әле мине,— диде яралы.— Берничә айсыз бу ак палата белән саубуллашып булмас. Аннары сезнең янга, Татарстанга кайтырмын. Шуннан соң күз күрер... Исәнлектә күрешү насыйп булсын...

Үзеннән-үзе телгә килгән бу сүзләрне әйткәндә, утлар-сулар кичкән каты яралы солдат хәләле белән кабат күрешә алмасын уена да китермәгәндер, мөгаен. Ә язмыш аларның бу очрашуларын соңгысы итәргә әзерләнеп торган икән...

Аркасына биштәрен аскан килеш Екатерина Николаевна Канаштан Гөл-Төркемгә кайтырга чыкканда, көне дә аяз, жиле дә юк шикелле иде. «Юлның яртысын булса да үтеп, берәр авылда кич кунармын, иртәгә төштән соң, бәлки, кайтып та житәрмен», дип уйлаган иде ул. Өч-дүрт чакрым үтәргә дә өлгермәде, күз ачкысыз буран күтәрелде. Кире борылырга килмәде, аз булса да алга атлыйм дип тырышты, ләкин барыбер чамасы калмады. Җил аны очыртып китәрдәй булып шашынды, күзенә-йөзенә юеш кар сылады, хәлдән яздырды. Шабыр тиргә баткан Екатерина Николаевна тора-бара аяк астында юл катысын тоймас булды: адашты. Иң авыры юлдан тайпылгач башланды. Бата-калка атлаганда, киез итек кунычларына кар тулып, аяклары манма су булды. Өсте-башы кургашын кәгазьгә төреп куйган сыман иде. Тирә-юньдә ак дәһшәт торган саен ныграк котырынды. Юлаучы хатынның утырып сулу аласы килде, әмма утырса, яңадан торып китәренә ышанмый иде. Шуңа күрә һаман кыймылдарга азапланды. Тик егәре болай да чамалы булган хатын ерак китә алмады, биштәрен салып, карга утырды. Аз булса да хәл кермәсме дип, соңгы кисәк икмәгенә ябышты... Юк, көче тәмам беткән иде инде. Төн карангысы да гүя аны йокыга тартты. Үзе йоклап китмәскә кирәген бик яхшы белә, ләкин күзләре йомылуга каршы тора алмый башлады. Аңында «Бетәм бит, болай булгач! Туңып үләчәкмен!» дигән коточкыч уй сызылып узды. Аннары ул фикер дә томанга урала барды һәм, ниһаять, юкка чыкты. Екатерина Николаевнага рәхәт булып китте, күзләре йомылды.

Екатеринаның гәүдәсен өч көннән соң гына таптылар. Ире янына баруы турындагы кәгазьләренә, паспортына карап, кем икәнлеген, кайда эшләвен, нинди сәфәрдән кайтканда вафат булганын бик тиз ачыкладылар.

Маннуровлар йортына олы хәсрәт килде. Туганнарыдай күрә башлаган бу рус хатынының вакытсыз үлеп китүе, Женяның ятим калуы

Илфатлар гаиләсендәге һәркем йөрәгенә яңа җәрәхәт салды. Кеше күңеле, гомумән әйткәндә, бәлагә ышанмаска тырышучан булса да, көтмәгәндә ябырылган олы бәхетсезлек Женяны сугыш миңгерәткән кеше сыман итте. Әнисенең гәүдәсен кайтарган көнне малай хәтта елый да алмады. Күз яше катты. Ә берничә көн үткәч, үз иңнәренә төшкән фажигане аңлап, үлчәп карарлык акыл килде бугай,— Женя тыелгысыз елый башлады.

— Әнисез нишлим инде мин? Эти дә сугыш гарибе, госпитальдән кайчан кайтасын да белгән юк,— дип, әрнеп-әрнеп яшь түкте. Ниләр генә әйтеп юатырга да белмәделәр аны.

Моның өстенә күңелне аяусыз телгәләгән, бәгырь итен көйдергән тагын бер четрек бар иде әле: Екатеринаның үлеме хакында инвалид иренә хат язу. Менә бит газап, менә җаннарның тетрәве! Җеп нечкә җиреннән өзелә, дигәннәр шул... Ничәмә көннәр буена Иван Логиновка мондый хат язарга куллары бармады. Тик иртәме-соңмы, хәбәр итәргә барыбер кирәк иде.

Иван Даниловичтан күңел төшенкелеге һәм ирләрчә күз яше белән тулы җавап килде. Женяның язмышын хәл итү турында да фикерләре бар иде. Март башында, барлык документларын рәтләп, малайны балалар йортына урнаштырдылар.

Көздән үк балалар йортындагылар белән бергә укыса да, анда яши башлауга ияләшә алмыйча интекте Женя. Көндезләрен, төшке ашны ашап чыгуга, юыртып Илфат янына килеп җитә иде. Дәресләрен дә аның янәшәсендә хәстәрләүне кулайрак күрде. Кай көннәрне кичләрен дә килгәли, язгы каникул алдыннан хәтта, озак кына кич утыргач, кунып та китте. Алар группасының тәрбиячесе Варвара Яковлевна Мордюкова, Женяның Маннуровларда икәнен белгәнгә, бик үк хафаланмаса да, шактый борчылып Мәһибәдәр белән сөйләшергә мәҗбүр булды. «Сез инде аны вакытында кайтарып җибәрә торган булыгыз, зинһар,— диде ул, педагогларча такт сакларга тырышып.— Минем карамакта егерме бишәү бит алар. Һәркайсы төрле җиргә таралып төн чыга башласа, миңа нәрсә диярләр? Логинов өчен директор беркөн дә кисәтү ясады».

Мәһибәдәр үзенең Варвара Яковлевна белән килешүен әйтте. Женя белән дә әйбәтләп сөйләшәчәген белдерде. Тик — әлеге дә баягы — ананың йомшак күңеле ике канаты да каерылып ятим калган малайга гайрәт чигергеч сүз әйтергә базмый иде.

Әнә Илфат нинди нык үсмер булып бара, куәт дисәң куәте бар, буйга-сынга да күз тимәсен диярлек, эшкә дә кулы ята: тактасын да юна-шомарта, кадагын да кага, сәгатен дә төзәтә, өр-яңа баштан җыя, ат җигеп эшләргә дигәндә дә ашкынып тора. Өстәвенә ул үз кешеләр арасында, туганнары белән бергә. Ә Женяның хәле бүтәнчәрәк бит. Аның бик тилмергән чагы.

Әмма, ничек кенә булмасын, ул — балалар йорты кешесе хәзер. Андагы тәртипләрне санга сугып яшәргә бурычлы. Шуңа күрә, көннәрнең берендә Женяның янә үзләрендә кунып калырга теләвен күреп, Мәһибәдәр бик сак кына сүз башлады. Русчасы үтә чамалы булганга, татарча аңлатырга тырышты. Хәер, Женя татарчаны да шартлатып өйрәнгән иде инде.

— Илфат белән дус булуыгызга мин шатланам, Женя,— диде ул.— Ну чүтеки сиңа киңәшем бар, наным. Син хәзер дитдом кешесе. Гел генә дә бездә яшәп калган булыр идең дә, әтиең тегендә урнаштырырга кушты. Ул да, значит, авыр ранный булса да, сиңең киләчәк көнең турында төрлесен уйлагандыр. Ил канат астындагы кеше ятим булмас, үксезлек сизмәс, дип уйлагандыр. Значит, сиңа дитдомда күңеленне утыртып яшәргә кирәк. Сүзем юк, һәрвакыт безгә килә-китә йөрерсең. Илфат та сезгә барыр. Тулыке тәрбиячеләрең дә, директорыгыз да сине тәртип боза дип битәрләрлек булмасын, яме, наный?

Женя Маһибәдәр апасы әйткәннәрне әйбәт аңлый иде, йөрәк дигәне генә ризалашып бетмәде. Балалар йортына күңеле ятмый иде. Ятмый и вәссәлам! Маһибәдәр дә бу сөйкемле рус малаеның тел төбендә әйтеп бетермәгән сүзләре барын белә. Җаен табып, Илфатка Женя белән сөйләшергә кушты.

Женя Илфатның төпченеп хәл-әхвәл сорашуына ихлас күңелдән сөенеп, барысын ачылып сөйләде, күңелен тырнап торган нәрсәләрен дә яшермәде.

Ят күрүчеләр бар икән аны. Бер кичне, ул йоклап киткәч, сиздерми генә ике аягын бергә бәйләп, бауның очын карават башына беркеткәннәр. Женя иртән сикереп торыйм дисә, үзенең бәйләп куелганлыгын абайлап алган. Кинәт тартылып, аягы авыртуга гына чыдаган да булыр иде, гарьлегеннән бугазына төер утырган. Баудан арынып, аягына басуга, бүлмәдәгеләр бөтенесе шаркылдашып көлә башлаганнар.

— Төнлә женнәр алмаштырган сине!

— Ап-ак йөзле рус малаен чуендай ком гарәбе иткәннәр! Ха-ха-ха! Ком гарәбе!

— Африкага озатырга кирәк аны!

Хикмәт шунда икән: бөтен битен кара корымга буяганнар. Бер адым да артыннан калмый үртәшеп йөргән Юрка Сухаревка Женя җилле генә төртеп җибәргән икән, тегесе детдомда иң өлкән малайга— Хәбри Тәкәнәевкә барып әләкләгән (аны моннан ике ай элек кенә Казаннан китерделәр, ул беренче көненнән үк атаманлык итә башлады). Юрка — Тәкәнәевнең «ялчысы», шуңа күрә теге һәрвакыт аны яклый. Хәбри-Кобраның (кушаматны да үзе кушкан. Янәсе, ул бик усал, агулы «күзлекле» елан) явызлык житәрлек. Унбишне тутырган булса да, алтынчы класстан ары китә алмаган. Башсыз малай түгеллеге әллә каян күренеп тора, этлекнең җитмеш төрлесенә акылы житә. Тик уйлау сәләтен башка юнәлештә эшләтә, гел кирегә ишә.

Менә шул Кобра Тәкәнәев, Юрка килеп шыңшыгач, Женяны ике колагыннан ике кулы белән тарткалап-йолыккалап торган да, уңлы-суллы яңаклап җибәргән. Женя елап, караватына барып ауган. Группадагылар, Кобра әмерен үтәп, Женяга берәм-берәм тибеп чыкканнар. Тәрбияче Варвара Яковлевна килеп кергәндә, малайлардан инде җилләр искән булган. Алар, көлешә-көлешә, ашханәгә китеп барганнар. Ә Варвара Яковлевна группада ни булганын аңламыйча, Женяны ныклы кына орышып ташлаган. Нахакка тиргәү Женяны янә ярсыткан.

«Яңа кешегә бирәсе «җәзалар» алда сөйләгәннәр белән генә бетмәгән иде әле. «Кобраныкы замана» икәнлекне Женя тагын берничә кат татыды.

Корымга буяп хурланган Женя Варвара Яковлевнага дөресен сөйләде. Әләкче булырга теләп түгел, тәрбияче аның турында хаклыкны белсен өчен шулай итте. Мордюкова үз чиратында бу хәлне директор Иван Васильевичка иреште. Директорга Юрий Сухаревны, ә бер-авыктан Кобраны да чакырып керттеләр.

— Син, башыңны тилегә салып, үзеңнән көчсезләрне кыерсытудан кайчан туктыйсың?— дип, ямьсез итеп кычкырды Тәкәнәевкә директор. Балалар йорты башлыгының түземе төкәнеп бара иде. Чөнки Гөл-Төркемгә килгәннән бирле Хәбри тәрбиячеләр канына тозны аз салмады. Директор, дәү аю кебек, кәкре аяклары белән лас-лос басып, Тәкәнәев янына килде һәм көчле зур куллары белән тегенең изүеннән әләктереп алды да кабинет стенасына «дыңк!» иттереп терәп куйды. Гәүдәгә Иван Васильевичтан кайтыш булса да, буйга ярыйсы ук озын Хәбри дә көзге яфрактай калтыранырга уйламый иде.

— Саграк, директор, саграк кыланыгыз!— дип, мәсхәрәле тавыш белән сөйләшә башлады ул.— Хөкүмәт карамагындагы балаларга кул

ягарга ярамаганлыгын беләсездер... Тәкәнәев сезнең крепостноегыз түгеллекне хәтер хәзинәгездән чыгармагыз, хөрмәтле Ван Василич...

Директор аны стенадан кире кубарып алды.

— Ә Логинов һәм бүтәннәр Тәкәнәевнең крепостнойларымы, әдәпсез? Сиңа биредә ике юл: я безнең эчке тәртип кагыйдәләрен карышусыз үтисең, я... без сине колониягә озатырга мәҗбүр булабыз. Сайла!

Хәбри һаман эре кыяфәт сакларга маташа иде: ташкүмер төсле күзләрен кысыбрак, директорга көйдергеч итеп карый, тешләрен кыскан, шуңа яңак итләре калтырана, күкрәген киергән, башын күтәргән. «Керпе»дәй тырпайган чәчләренә тикле аның тәкәбберлеге турында сөйли иде шикелле.

— Кайда да казна икмәге белән казна шулпасы ла, Ван Василич... Кайда да бер кояш...

— Казна икмәген ашаганның кадерен белергә кирәк, Тәкәнәев. Сүз шул турыда бара. Уйла һәм икенең берсен сайла. Синең белән курчак уйнап тормам мин. Марш корпуска!

Кобра корпуска кайтып тормады, туп-туры ашханәгә китте: кечерәкләр группасы өстәлләр буена утырышкан, аларга икмәк һәм аш өләшәләр иде. Юрий Сухарев аркылы Кобра Женяны таптырды.

— Кичкә сиңа трибунал!— диде Хәбри Женяга.

Кобра сүзен җилгә җибәрүчеләрдән түгел иде. Кичен Варвара Яковлевна малайлар бүлмәсен күздән кичереп, аларга хәерле төн, тәмле йокы теләп чыгып киткәч, күп тә үтмәде Тәкәнәев Женялар бүлмәсенә килеп керде. Ул, тавышын күтәрмичә генә, Женяга әмер бирде:

— Исән-сау чагында элдерт идән астына! Таң аткач, чыгарырга кушармын. А ну, яшен бул, әләкче селәгәй!

Женя одеялы өстеннән пальтосын да ябынып яткан һәм урынын җылытып өлгергән иде инде. Берничә минуттан йоклап та киткән булыр иде. Тик ни хәл итсен, курыкты һәм буйсынырга мәҗбүр булды. Кобраның «ялчылары» ничәү бит! Һәммәсе өерелеп дөмбәсле башлаячаклар... Ул өстенә бишмәтен киде дә идән астына төшеп чүмәшеп утырды. Бераздан ишекне сак кына ачып Хәбринең чыгып киткәнен сизде ул. Идән такталары селкенешеп алды. Бүлмә тынып калды. Әмма ул тынлык Женяны шомландырды гына...

Шул рәвешле күпме утыргандыр, Женя төгәл генә хәтерләр хәлдә түгел иде. Малайлык йокысы үзенекен итми калмады. Юрка Сухарев идән тактасын ачып: «Чык тизрәк! Хәзер явыз Варвара керәчәк»,— дип пышылдаганда, ул гәүдәсендә өзлексез калтырау тоеп, йокылыуяулы хәлдә, бөрешеп утыра иде. Апрель таңы күптән аткан, көн яктырып килә иде инде.

Женя идән астыннан чыкты да караватына ятып, одеялын башыннан ук томалады. Бүген дәресләр бетүгә, Илфат янына барырга дигән ныклы карарга килгән иде ул. «Барырга, бөтенесен сөйләргә! Кобра Илфат белән исәпләшми булдыра алмас...»

Уйлануларның дәвамы

Дәресләр тәмамлангач, Илфат туп тибү хәйләсе белән мәктәпнең спорт мәйданчыгына килде (авылныкылар да, балалар йортындагылар да аның футболны әйбәт уйнавын беләләр иде). Кобра да шунда, тик ялгызы гына түгел иде. Җиденче рус классындагы Наташа Дроздова белән нидер сөйләшеп торалар.

— Кобра, монда килеп кит әле!— Бу сүзләрне Илфат бик тыныч, сабыр тонда әйтергә теләде, ләкин йөрәге көчле какканын тойды. Хәбринең бу чакыруга аз гына да исе китмәде, гамендә дә юк иде. Ил-

фатка таба кырын карап алды да теш арасыннан черт иттереп төкереп куйды. Аннары Наташа белән сүзен дәвам итте.

— Кобра әфәнде! Сине көтәм!— Монысы тагын да катгыйрак яңгырады шикелле, һәрхәлдә Хәбри игътибарсыз кала алмады. Ләкин ул бер тешләүгә ватыла торган чикләвек түгел! Авыл малайлары каршында гына түгел, Ван Василичның үзе янында да мәлҗерәп тормый. Кирәгенчә тота белә үзен.

— Үзең кил! Наташа — изге кеше, өнендә дә, төшендә дә тешләми, шүрләмә...

— Кил, кил, рыцарь Илфат Маннуров!— дип, һич көтмәгәндә Дроздова да әйтеп куйды. Ул шундый сөйкемле итеп, чыңлап торган тавыш белән эндәште, Илфат аңа хәтере калу түгел, Кобрага булган ачуын да бер мизгелгә онытып торды. Чыннан да, Наташа балалар йортындагы иң чибәр кызларның берсе. Арада иң зурыдыр да, мөгаен. Ул елмайса, кинодагы Любовь Орлова кебек елмая. Әйбәт кенә җырлый да белә. Шуңа күрә Илфат кына түгел, Гөл-Төркемнең байтак малайшалае аңа кызыгып карый, тик берсе дә якын килеп сөйләшергә кыймый. Ник дисәң, ул һаман Тәкәнәев белән бергә. Төгәлрәге, Хәбри үзе һәрчак аның тирәсендә бөтерелә.

— Ипи корсак артыннан йөрми, үзең миңа таба шуыш!— Кобра Илфатны көтте. Маннуров та гарьләнде: «Сүзләрен генә тыңлап кара син аның, э? Үзең миңа таба шуыш, имеш!»

— Э бит Женя синең тырнагыңа эләккән чебеш түгел, Кобра. Әйдә, сөйләшик әле.

— По-о-о-ожалуйста, Илфат-илпат!

Кара син миләш чыпчыгын! Нинди итеп, көмеш тәңкәләр чәчеп җибәргәндәй, яңгыравык тавыш белән көлеп куйды. Әмма сүзендә Илфатка карата төртке барлыгына шик юк иде.

Мәйданчык читендә яткан бүрәнәгә барып утыргач, Кобра, ясалма илтифат күрсәтүен яшерергә дә теләмәстән, ачыктан-ачык мыскыл итеп, пинжәгендәге күкрәк кесәсеннән газета кисәге чыгарды һәм чалбар кесәсен кырып-себереп, самосад тәмәке вагы жыештырды.

— Төреп җибәр, ирләрчә булсын!— Хәбри кимсетүле елмайды.— Куркытырга килдеңме?

— Аңлатырга килдем, Хәбри. Кагылма син Женяга. Аның күңеле болай да сыек.

— Детдомда кем күңеле бөтен дип беләсең?— Тәкәнәев тәмәке төтенен мул итеп суырды, шунда чак-чак кына тончыкмый калды. Күзләренә яшь бәреп чыкты, йөткереп алды. Шулай да, сырты сынса да сынатмаска әрсезләнеп, төтенне ирене читеннән генә Илфат ягына өрде. Ул һәр хәрәкәте белән Маннуровтан үзенең өстен икәнлеген исбатларга тырыша иде.— Э син, Илфат-илпат, ул әләкче малай өчен ник ертылып йөрисең? Кем ул сиңа, туганыңмы, кардәшеңме, авылдашыңмы? Я әйт, үзәгеңне өзәрдәй кешеңме?

— Туганым дип бел, Кобра! Күптәннән ул — минем туганым. Әгәр ялгыш кына тагын бер кыерсытсаң да, үзеңә үпкәлә. Аның өчен расчетны мин ясаячакмын.

— Нишләтерсең?

— Тире жыйдырып, күн эшләтермен.

— Кулың кыскарак.

— Синең бугазыңны буарга гына житәр...

— Син әниеңнең тәти малае бит, Илфат-илпат. Сугышып йөргәнең өчен әнкәң сине салып суктырыр. Пенальти эләгер үзеңә...

Илфат сабырын жуя баруын яхшы тоеп утырды, алай да кызуланып, этәчләнеп китәргә ярамаганын да белә иде, чөнки ул бу юлы Кобра йодрык көчен түгел, э бәлки йөрәк чыдамлыгын сынап карарга жыена иде. Хәзер ул, мөгаен, сугышмаячак. Ник дигәндә, жиңеп чыга-



Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме

рын төгәл белми. Ә кыйналасы килми. Наташа Дроздова карап торганда хур булырга теләми. Шуңа күрә Илфат та аны булдыра алганча ныкысытте.

— Женя өчен мин бугазыңны чәйнәрмен, шуны борыныңа киртләп куй. Кирәксә, Гөл-Төркемнең бөтен малайлары җыелып измәңне изәрбез. Алар минем тикмәгә тукмашмаганны беләләр. Ә хәзер ычкын! Киләсе күрешү әйбәт булыр дип ышанам.

— Хуш, синьор, ху-у-уш! Сирәгрәк күрешсәк икән...

Ул көнне алар шулай аерылыштылар. Илфатның үз кисәтүе җитә калдымы, әллә Гөл-Төркем малайларын — яшьтәшләрен — искә алуы Хәбри күңеленә шик салдымы, сәбәбен кистереп әйтүе кыен, тик Кобра Женяга бәйләнмәде, бүтән бәләкәйләрне дә бөтенләй диярлек рәнжетмәс булды. Алай гына да түгел, җир кибеп, үләннәр тернәкләнә башлагач, Екатерина Николаевна каберенә чардуган-рәшәткә ясаганда такта башларын кисеште, юнышты, иске кадакларны турайтышты.

Илфат белән Женя Екатерина Николаевна каберенә яшь каен утырттылар. Чардуганны күршедәге Әкрам бабай тотышты...

Язгы чәчүнең башланып киткәненә атна да юк иде әле. Тагын икеөч көннән Май бәйрәме җитә. Маһибәдәр, басудан арып-талып кайтса да, юынырга-җыенырга, өй җыештырырга исәпләде, язгы төнне шул эшләргә багышламакчы булды.

— Теләсәң нишлә, билләһи, хет аклы дигән керләреңне дә селте белән ю менә!— дип зарланды. Аннары Илфатка Аръяк урамга, Җамали Хәдичәсенә барып килергә кушты.

— Менә акча, улым, бар, зинһар, Хәдичәләргә. Эштән кайткандыр. Эни бик гозерләп сорады диген, ярты кило чамасы гына булса да сыек сабын биреп жибәрсен. Күңелләр кара, керләр кара, дип яшәп булмый инде лабаса. Олы бәйрәм җитә...

Илфат чыгып киткәч, Маһибәдәр өстәл буена барып утырды да уйга калды.

Бар иде заманалар, бәйрәм җиткәндә халык күңеле күкләргә ашардай булып талпына иде. Яңа кием тектерүме, аш-суның менә дигәнен хәстәрләүме, колач җәеп, кунак сыйлаумы, клубына чыгып, күңел ачумы, ел матур килгәндә габигать кочагына чыгулар дисеңме — бөтенләй башкача иде. Кайәр суккан сугыш бигрәк боектырды халыкны. Бүген-иртәгә генә бетәсе дә күренми бит әле... Сталинград янында хәлләр бик хәтәргә әйләнеп бара, ди әнә. Кырым тирәсендә дә хәлләр авырлашканнан-авырлаша, диләр. Дөрес, Мәскәү тирәсендә фашист чукынчыкларның кабыргасын санадылар инде санавын, алай да мәкерле, көчле әле илбасарлар. Икенче фронт дигәннәр иде, анысы да юк. Шуңа күрә дә Гитлер-аждаһа әлегә каты торадыр... Тизрәк кенә дөмектерсеннәр иде канэчкечләрне!

Илфат кайтып кергәндә, Маһибәдәр уйларына оеп утыра иде әле. Көне буе басуда ватылганлык та үзенекен иткәндер инде.

— Юлың уңдымы соң?— диде ул, йокысыннан уянып киткән кеше төсле.— Сабын алып кайта алдыңмы?

Илфат гөнаһ кылганда тотылгандай, читенсенеп кенә җавап бирде.

— Юк шул, әни. Хәдичә апа әйтә, акчага чирек кадак та бирмим хәзер, онга гына алмаштырам, Маһибәдәр апа ачуланмасын инде, ди. Акчаның кадере китте бит, ди...

— Шулаймени?— Маһибәдәр бүтән бер сүз дә әйтмәде. Өстенә киде дә каядыр чыгып китте. Бүтән берәрсенә сугылып карарга уйлавы булгандыр, күрәсең.

Әнисе китүгә, Илфат немец теленнән дәрес хәзерләргә утырды. Бәхеткә һәм куанычка каршы, Женя килеп керде. Ул немец телен ярыйсы маташтыра. Илфат аңардан бер дә тартынып, читенсенеп тормый, бел-

мәгәнен туп-туры сорый. Тегесе тәрҗемә итеп бирә, сүзләрнең дөрес әйтелешен өйрәтә.

— Белеп килгән шикелле әле син. Әйдә, булыш әле азрак,— диде аңа Илфат.

Женя исә, әллә нигә пошынганмы, сөенгәнме төсле, кыбырсып утырды. Илфат дәфтәрен бер читкә алып куйгач кына, зур сере бар шикелле, аңа үзенчә тирән мәгънәле итеп карады.

— Беләсеңме, мин нәрсә таптым?— диде ул.

— Нәрсә? Наганмы әллә?

Аптырабрак торган Женя кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Наган? Каян килсен ди ул?

— Алайса нәрсә соң ул тикле?

— Сабын! Ике кисәк сабын, Илфат.

Илфат, үз колакларына ышанмаган кебек, кайтарып сорады:

— Ике кисәк дисеңме? Әкияттәгечә килеп чыга. Мин сабын теләнеп буш кайттым. Ә син — ике кисәк... Иллә дә әйбәт булган! Әнкәй сөенер ичмасам! Мин бит, беләсеңме, «боламык сабын» теләнергә барган идем. Бирмәде. Акчага сатмыйм дип кире борды. Онга гына бирә. Он үзебезгә дә умачлык кына. Чын сабын булды, ур-ра! Рәхмәт яусын сиңа! Кайдан таптың, ничек? Кайсы җүләр төшереп калдырган?

— Көтмәгән төштән таптым, гел уйламаган җирдән...

— Шулай да?

— Бәйрәмгә лозунглар кадаклап йөри идек. Ашханә өенең кыегына. Баскычка басып кына кадаклау читен. Мин эчке яктан бау белән тартып торыйм дип, чормага менеп киттем. Эш беткәч, кәрнизгә күз салсам — сабын!

Чыны шулай иде. Башта Женя каушап калды, күзләрен әлҗе-мөлҗе китереп, нишләргә белми торды. Шулай да сабыннарны түшенә тыгып төшәргә булды. Ул чормадан төшеп җиткәндә, җир астыннан калкып чыккандай, каршысына Хәбри килеп басты. Гомердә булмаганча, Женя белән көлә-шаяра башлады Тәкәнәй. Ә үзе шундук малайның түшен капшарга да онытмады.

— Һо-о-о, хәзинә! Моның һәрберсенә авыл кешеләре түгәрәк ипи бирәләр. Вәт бәхет синең.— Хәбринең тавышында еламсырау ишетелеп калды. Гүя аның тәненнән ит каезлап алганнар иде, ә чем-кара күзләрендә көнчелек очкыннары уйнаклап куйды. Ымсынудан иреннәрен ялады хәтта. Тик, ни хикмәт, үзеннән кайтышрак малай кулында күз яндырырлык, нәфес аздырырлык нәрсә күреп тә, талап алмады. Киресенчә, аңа булышырга ашыккандай итте.

— Бар, ычкын, Женька! Җил бул, житез бул, малай! Гөл-Төркем татарларының теләсә кайсының тәрәзәсеннән төрт—теш арасына кыстырырга ризык әләгәчәк. Бар, тиз бул, югыйсә Крылов бабай каргасы хәлендә калырсың...

Женя икеләтә аптырашта калды, башы түнде. Кобра тикле Кобра сине имин-аман җибәрсен әле! Сөенерсең дә. Сабынны кемгә илтергә дигәндә, ике дә уйламады инде, туп-туры Илфатларга килде...

Ул кыршылып беткән портфеленнән ике кисәк сабын чыгарып артсыз урындыкка куйды. Шуннан соң гына Илфатка сорау бирде:

— «Боламык сабын» нинди була ул?

Илфат «боламык сабын»ны повидлога охшаган дип аңлатты.

Вакыт кичке унынчыга авышканда Маһибәдәр кайтты. Чәй яңартырга кереште. Женя байтактан киткән иде инде. Илфат әнисеннән сөенче алырга ашыкты. Әмма Маһибәдәр тырнак очы кадәр дә сөенмәде. Бөтенләй киресенчә булды. Ул югалып калды. Эштән алып кайткан ипиеннән кисеп капкан кабымы тамагына утырды.

— Монысы ниткән эш тагын? Женяга да ике кисәк артырлык булган. Ниткән эш бу?

Шулчак моннан өч кенә көн элек Жанбулат балалар йортындагы завхоз хатынның сельпо склады буенда әрнеп яшь түгүе исенә төште. Мария Семеновна: «Егерме кисәк кер сабынымны урлаттым! Бухгалтериягә биш минутка гына дип кергән идем, чыксам, олаудагы әржәм ярты лаш бушаган. Кулы корсын иде хәерсезнең!»— дип өзгәләнгән иде. Мәһибәдәр күрше авылдагы кордашы Марияне күптән белә. Аның ире фронтта, өч баласы бар. Сукыр каенанасы да аның тәрбиясендә. Сабынның бәясен түләтерләр, эштән куарлар дип кенә дә курыкмый ул, спекуляция белән шөгыльләнәсең дип гаепләүләреннән дер калтырап төшкән иде. Сугыш вакыты бит, андый шөгыльгә керешкәннәрнең башыннан сыйпамыйлар...

Шуларның һәммәсен хәтереннән уздыргач, Мәһибәдәр эчәр чәен һәм чәйнәр ризыгын да онытты.

— Әйдәле, Иван Васильевичны күрик,— диде ул Илфатка.— Сабынны детдомныкылар урлаган булып чыга. Очына чыкмый ярамый бу хәерсез эшнең. Мария Семеновнага йөз аклыгы булыр ичмасам, нахак бәлаләрдән арыныр...

Балалар йорты директоры Женяны, аннары берничә бүтән малайны, шул жөмләдән, Хәбри Тәкәнәевне дә чакыртып, жепнең очын табарга маташканда, ашханә чормасында калган соңгы биш-алты кисәк сабыннан жилләр искән иде инде. Хәбри аларны бик тиз арада аргы якка чыга торган күпер астына күчереп күмгән иде. Женяны тиз генә озатып жибәрүе дә эшне тиз башкарырга теләүдән иде.

Балалар йорты завхозы Мария Семеновнаның гөнаһсызлыгына бердәнбер дәлил булып Иван Васильевич кабинетындагы өстәлдә ике кисәк сабын торып калды. Хәер, алай гына дию бөтенләй үк дөрес булмас. Бу кичтә Хәбри күңеленда да сорау калкып чыкты. Аңа да уй кергән кебек иде.

«Сабыннарның калган кадәрен кире бирү — ахмаклык,— дип фикер йөртте ул. Караватында әле бер ягына, әле икенче ягына әйләнгәләп ятты. Бу төнне ул рәтләп йоклый алмады.— Кире илтсәң, кирәкне бирәчәкләр. Арт сабакны укытачаклар. Харап буласың көн кебек. Ә Мария Семеновна дигәннәренә бераз булышасы иде бит. Каян акча чәлдерәсе икән?»

Тәкәнәев уйларының очына чыга алмады, өзеп кенә бер план корып житкермәде. Таң алдыннан йоклап китте, тик йокысы тыныч булмады: буталчык төшләр күрде, саташты, нидер сөйләнде, кычкырынды. Ә иртән торып аякка басканда, Мария Семеновна кайгысы аның өчен егерме бишенче хәсрәт булып калган иде инде. «Сабынны завхоз үзе урламаганлыгы беленде ич инде. Төрмә булмый хәзер ул хатынга!» — дигән уйга килде Хәбри. Үз-үзен тынычландырырга шул тулысынча житә калды. Кичә кичтән йомшап китүенә үзен тиргәп, мыскыллы елмайгандай итте. Кыңгыр кеше кыек елмая, дигәннәр шул...

Июль башында балалар йортына Бәбки урманыннан кышлык утын кайтара башладылар. Кисеп яру, әрдәнәләргә өеп киптерү кулларыннан азмы-күпме эш килерлек балаларның үзләренә төште. Бала-чага баштарак эшкә бик дәррәү керешүчән бит ул, аннары гына күңеле сүрелүчән. Өлкәнрәкләр сынатмадылар. Женя бик тырышты. Кинәнеп ярды ул утыннарны. Төшлектә утынчыларга дип хәзерләнгән махсус ашны да ашагач, егет жилкенеп үк китте. Ярды-ярды да сулу алырга туктады. Күзләре белән генә Наташаны эзләде. Юк иде кызый. Әһә, корпусның аргы башына китеп утырган икән. Әллә аның кәефе юк инде... Женя кыз утырган чатка якынлашты. Сискәнеп, куркып китмәсен дип, берничә адым калгач үк эндәшә килде.

— Наташа, ни булды сиңа? Нишләп ялгызың гына боегып утырасың?— диде ул һәм бүтән сүз таба алмый тынып калды. Читтән бераерсе күзәтеп торса, аның комачтай кызарганын күрерләр иде. Сүзсез

торуы читен иде, ә кыз эндәшмәде. Ул үкси-үкси елый иде. Женя аның янына ук килеп чүгәләде һәм «Наташа, ни булды сиңа?» дигән соравын кабатлады. Наташа Женяның болай әрсезләнүен ошатмадымы, кинәт сикереп торды да уң йодрыгы белән күзләрен сөрткәләп, ләм-мим бер сүз катмыйча, урамга чыгып китте, Женя да, инде килеп сүз кушканмын икән, болай жавапсыз китә алмыйм дип уйлады бугай, акрын гына аның артыннан кузгалды. Наташаны бөтенләй китеп барыр дип тә уйлаган иде ул. Ләкин кызый алай итмәде. Олы юл буендагы зифа каенга барып сөялде дә Женяны көткән кебек басып торды.

— Нигә эндәшмисең син, Наташа?— диде Женя.

— Нәрсә дип әйтим соң?

— Ни булды? Ник елыйсың?

— Бернәрсә дә булмады. Просто күңелем тулды. Шул гына.

— Гажәп!— дигән булды Женя, тик нәрсәсе гажәп икәнен үзе дә тәгаен генә әйтә алмый иде.

— Бәхетсез мин, Женя. Менә шул. Тормыш мине бөтен яктан кыерсыткан. Хәзер дә кыерсыта...

— Нәрсә, әллә Кобра рәнжетәме үзеңне?— Бу сорауның теленнән ычкынып китүен Женя искәрми дә калды. Шуның белән күңелендәгесен ачып сала язды. Хәбридән көнләшкәнен чак сиздермәде ләбаса. Ә кыз шундый төрпәләнеп куйды, Женя бер мизгелгә имәнеп үк китте.

— Кем ул миңа Кобра?! Бәйләнеп карасын, күзен чукып чыгарырмын... Син әйт әле менә, Женя...— Наташаның тавышында ирония яңгырап китте шикелле.— Нигә барысы да мине Кобра белән бәйләргә телиләр?

— Кемнәр шулай итә?

— Әйтик, Варвара апа... Ни хакы бар аның? Син Тәкәнәев арбасына утыргансың, кара аны, аң бул, югыйсә башың төрмәдән чыкмас, ди. Ике-өч тапкыр шулай кисәтте инде. Ни өчен?

Наташа Дроздова күңеленең бөтен тирәнлеге белән рәнҗегән булса кирәк: тавышы тагын калтырый башлады, тамагына яшь төелде, тынгысызланып, бер урында тиктомалга таптанып куйды. Аннары чыдый алмыйча янә елап жибәрде.

— Әнием гөнаһлы булган өчен генә миннән шул тикле шикләнәләр микәнни? Минем ни гаебем бар соң?!

Сүз болай тирәнгә китәр дип уйламаган иде Женя. Ул күсәк кебек үрә катып торудан уза алмады. Шулай да мондый йогышсыз хәлдән чыгарга кирәклекне акылы белән сизә иде. Наташаны юатырга кереште.

— Тукта, тынычлан әле, Наташа. Мин синең хакта бернидә белмим бит. Теләсәң, сөйләшик. Кирәк булса, өлкәннәр белән дә киңәшербез,— диюдән гайре чарасы юк иде.

— Рәхмәт, Женя...

Алар олы юлны аркылы чыгып, чирәмгә утырдылар...

Наташа Дроздова гомерендә беренче тапкыр чит кешегә йөрәген ачып салды. Яхшы эшләдеме ул болай итеп, юкмы — әлегә үзе бәя бирә алмый иде, фәкать бер хакыйкатьне генә тоя иде ул: шунсыз булдыра алмавын. Үткәннәрнең авыр йөге аның тормышын агулый шикелле иде. Шуңа күрә, сөйлә дип буып бәйләнмәсә дә, Женяга эч серен бушатты ул. Хәбринең бик беләсе килеп, кат-кат сораштыргалап караган чаклары да булмады түгел, аңа теле чишелмәде. Тышкы яктан үзен бик батыр, бәйсез тотса да, курка ул Тәкәнәевтән. Эчкерле малай дип саный ул аны. Теленә генә түгел, кулына да ирек бирергә тартынмый ул...

Женя өчен ялгыш та уена китермәгән нәрсәләр мәгълүм булды.

Шушы көннән башлап Наташа Дроздова аның өчен бөтенләй бүтән кеше. Элек ул аның хакында исем-фамилиясеннән кала, жиденче класс-

ны тәмамлаучы кыз булуыннан кала, ни генә белә иде соң? Белми, ләкин якын итә, күңеленнән үз күреп, шуны бөтен кешедән яшереп йөри иде. Бүген әнә ни тикле яңалык сөйләде ул аңа.

— Мин Калинин шәһәреннән,— диде Наташа.— Шунда үстем.— Ул сүзен авыр башлады, сөйләве читен иде, күрәсең. Әмма сөйләми дә кала алмаячагы ачык иде.— Базар күршесендә кечкенә генә бер өй иде безнең йортыбыз. Әни баштарак кондитер фабрикасында эшли иде. Этине мин бөтенләй белмим. Бәләкәй чагында әни мине алдап килгән, бездән китте ул, хәзер бүтән җирдә тора, ди торган иде. Өченчедә укыганда микән, әллә дүртенчедәме: «Этием кайда? Ни исемле ул? Ник безнең белән тормый? Бүтән кызларның этиләре үзләре янында бит!»— дип, әнигә чытырдап бәйләндем. Әнинең жан ачулары чыкты. Илереп-котырып кычкырды: «Үзем дә белмим этиең кем икәнен! Яздырганда Михаил кызы дип яздырган идем. Әмма Михаил ул минем читтән генә кызыгып йөргән кеше, магазин директоры иде»,— диде. Шул сүзләрне ишеткәч, чиксез хурландым, гарьләндем, оялдым. Яшисем килми башлады. Җилдән туганмын лабаса дип айлар буе ут йоттым. Тик нишләмәк кирәк? Бу дөньяда берәү дә эти-әнисен үзе сайлап ала алмый! Кәефем гел бетте, көннәре дә төнгә әйләнде минем өчен. Укуымның да рәте китте. Мәктәпкә йөрсәм дә йөрдем, йөрмәсәм дә... Укытучылар: «Ни булды сиңа, Наташа?» — дип йөдәп беттеләр. Берсенә дә бер сүз дә әйтмәдем. Минем хәсрәтем кешегә сөйли торган ише түгел иде шул... Аныcы меңә иң яманы. Кемгәдер сөйли алсаң, жиңелрәктер ул...

Наташа алдына гына карап беравык тын утырды. Тамагына кайнар төер тыгылды да шуны эретеп жибәрә алмыйча аптырады. Аннары гына, беравык сүзсез торгач кына, сүзен дәвам итте.

— Кичләрен өебезгә ир-ат килеп йөри башлады. Әни рөхсәте белән инде. Ул чакырганга. Эчеләр. Мин нәүмизләнеп бер читкә килеп баса идем, ә алар миңа колбаса кисәкләре, сыр сыныклары, конфет сузалар... Аннары утны сүндереп, шунда йоклап калалар иде. Мин шул көнгә життем: башымны бет басты. Юып, башыма керосин сөртеп кенә чистартып булмады, чәчемне тап-такыр итеп кырдырдым. Шуннан соң класска күренергә оялып, мәктәпне ташладым. Озакламый мине балалар йортына бирделәр. Сугыш чыкмаган иде әле, анда элэгүнең сәбәбе башка...

Бу минутта Наташа үз яшенә караганда житдирәк булып калды.

— Әни шул хәлгә төшерде мине,— диде ул, тирән көрсенеп.— Бишенче класска барган елның көзендә мине универмагка иярткән китте. Хәзер юньләп хәтерләмим дә инде, ниндидер кыйммәтле товар саталар иде. Чиратка басканнарның чуты юк. Әни дә чират алды. Мине үз алдына бастырды. Беравыктан, минем колагыма пышылдап, безнең алда торучы хатынның сумкасыннан акча төргәген алырга кушты. Каш жыерып, каршы килергә исәпләгән идем, кайткач көн бирмәячәген сиздереп, бер генә акаеп карады. Мин төргәкне алдым да, кан калтырап, өйгә чаптым. Озакламый әни дә кайтып керде һәм оятсызланып:

— Нәчәлство хатыны ул, аның акчасын тавык та ашамый, ире тагын алып кайтыр әле,— дип сөйләнде. Мине үтереп мактады, күкләргә чөйде. Кичен үзе шикелле бер хатын-кызга ияреп, ике ир килде. Мине, гадәттәгечә, кечкенә бүлмәгә сөрделәр... Тагын нинди эшәкелеккә тартканбулырлар иде, әнине дә, аңа иярепйөрүче хатынны да эләктерделәр. Милициядә мин бар белгәнемне дөп-дөрес итеп сөйләп бирдем. Теге ләрне төрмәгә яптылар, ә мине Ржевтагы ятимнәр йортына бирделәр... Сугыш башланыр алдыннан минем адресны кайндыр юллап, әни бер хат жибәргән иде. Укырга куркыныч хат иде ул. «Төрмәдән чыккач, жир астыннан булса да эзләп табып, мин синең кирәгеңне бирәм», дип язган иде...

Женя хәзер төшенә иде инде: Хәбри үз тирәсендә буталганда Ната-

ша аңа каршы сүз дә әйтә алмый, шул ук вакытта куркуын да сиздерергә теләми. Чынында жаны-тәне белән ят күрә икән ул Хәбринә. Тормышның әчесен шулкадәр яшьли татыган кызда кара эшне ике дә уйламый эшләрлек кешегә жан жылысы була аламы соң?..

Тып-тыныч кына сөйләшеп торганда, яшен ташы төсле булып, әллә кай тарафтан гына Кобра килеп чыкты. Гарьлегеннән шартлар дәрәжәгә житкән иде ул. «Әһә, икәүләшеп аулакта утыралар!» — аны шундый көнче уй буа иде.

— Сәлам бәхетле парга! — Хәбри шулай диде дә мәсхәрәле елмайды һәм черт иттереп төкереп куйды.— Ни хәлләр, гашыйклар?

— Безнең хәлләр әйбәт. Утын кисеп ярдык, менә ял итәбез.— Каян көч алгандыр, каян ышаныч туплагандыр, Женя бик тыныч кына жавап бирде.— Синең хәлләр ничек? Эшләмичә йөрү әйбәтме?

Кобра кара янып чыкты.

— Әйбәт булса-булмаса, эшләсәм-эшләмәсәм, анда синең ни эшең бар? А ну, катись моннан шушы секундта! Әгәр хәзер күз алдымнан югалмасаң, миеңне эчәм мин синең... Тавык миен суыргандай итәм!

Женя тәмам чыгырыннан чыкты һәм каерылып торып Кобраның яңагына чалтыратты.

— Подлец! Әрәмтамак!

Шулчак аның күз алдыннан яшен ялтырап узгандай булды. Кобраның кулында финка уйный иде.

Женя ялт итеп читкә тайпылып өлгерде һәм яшен тизлеге белән бер кararга килде. Билендәге офицер каешын тиз генә чишеп алды да, ерактанрак торып, каеш житәрдәй арадан, тимерле башы белән Кобраның уң кулына сукты. Нык сукты бугай, тегенең кулындагы пычагы очып төште. Сикереп барып, Женя пычакны бер читкә тибеп жибәрде. Аннары каешны кулына урап, Кобра өстенә ташланды. Женя нык урды аны. Барысы өчен дә: кечкенәләрне кыерсытканы өчен дә, детдомга килгән мәлдә үзен хурлаганы өчен дә, караклыгы өчен дә, Наташага кул якканы өчен дә, тәрбиячеләрнең теңкәсен корыткан өчен дә. Ниһаять, пычак белән кизәнгәне өчен дә...

Шул көнне Хәбри Тәкәнәев юкка чыкты, бөтенләй күзгә-башка күренмәде. Пычак йөрткән өчен хөкемгә тарту ихтималы нык өркетте бугай аны. Уеннан уймак чыгасын төшенеп алды шикелле ул. Иртәгесен иртүк Женя янына килде шулай да. Үжәтлеген, тискәрелеген, усаллыгын, баш иргә хурлануын да жиңеп килде. Женяның гажәпләнеп таң калырлыгы бар иде, Кобра булып Кобра гафу үтенде. Аңа ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр. Тукмашуның шаһиты булган Наташа: «Ой, Женя, бу гафу сорау артында тагын берәр этлек ятмый микән?» дип сагайды. Ятмый иде бугай. Хәбринең кикриге, чыннан да, шиңде. Женяның абруе малайлар арасында бермә-бер үсте. Соңыннан, колхозда эшли башлагач та, авыл малайлары Логиновка олылап карыйлар иде. Тыныч кына йөри дә ул йөрүен, бер кабынса, бер тәвәккәлләсә — чыдап кына тор!

Эч серләрен бүлешкән, Кобраны иманга китергән көнне яралган хис торган саен көчлерәк тернәкләнә барды, үсте, сүнмәс булып китте, еллар буе дәвам итте. Солдат хезмәтен төгәлләп кайткач, Женя Логинов Калинин шәһәренә килде һәм Наташа Дроздованы яшь килен итеп Белоруссиягә алып китте. Сугышта имгәнү этисе Иван Даниловичның егәрен алган, яшәү тамырын кискән иде. Илле өчнең язында авыр яралы солдат дөнья куйды. Евгений өчен иң якын кеше булып Натальясы калды. Аның белән утыз елга якын дөнья көтәләр...

Сирәк язышалар, кырык бишенче елның языннан бирле күрешкәннәре юк, ләкин бер-берсен онытырга уйламыйлар да Илфат белән Женя. Авыр еллар якын иткәнгә шулайдыр. Яшьтән, малай чактан, уртак га-

запларны бергә кичкәнгә. Алай гына да түгел, җитлеккән акыл белән дуслыкны бәяли, кадерли белгәнгә. Бу дөньяда дуслык-туганлык тойгысы белән яшәүнең яктырак икәнен тирәнтен аңлаганга.

Борчулар...

Шәһәр мәктәпләрендә язгы каникулга мартның соңгы атнасында туктыйлар. Авылларда исә кайсы елны кайчан, каникул гадәттә юл өзелгән чакта башлана. Күрше авыллардан йөреп укучылар өчен аяк асты җайсызлангач.

Агачбашы урта мәктәбендә язгы каникул апрельнең беренче дүшәмбесеннән башланды. Шул көнне директор Илшадия Маннурова уку елының өченче чиреге йомгаклары отчеты белән Ташбуага, район мәгариф бүлегенә барды. Мөдир аны килеп керүенә үк кабул итте, җылы гына сәлам бирде, исәнлек-саулык сораштылар. Аннары мөдир мәктәптәге өлгереш, йөреш процентлары белән җентекләп танышты. Һәр санны, һәр билгене дигәндәй, энә күзеннән үткәрде. Башта дустанә тонда җайлы гына башланган әңгәмә тора-бара кырыслана төште, рәсмилек өстенлек алды. Илшадия үз фикереннән чигенми, ә мөдир өлгерештәге югары билгеләрнең азлыгыннан һич канәгать түгел иде. Шуңа күрә үз туксаны туксан булды.

— Сез җитәкләгән мәктәп өчен сыйфат ягы гел генә дә мактарлык түгел, Илшадия Фәйзерахмановна,— диде ул, «сыйфат» сүзенә булдыра алган кадәр басым ясап.— Мәгариф отличнигы, тәҗрибәле педагог командалык иткән мәктәптә күрсәткечләр болай гына булырга тиеш түгел. Һич тә! Әгәр барлык мәктәпләрдән дә шундый отчетлар күтәреп килә башласалар, Илшадия Фәйзерахмановна, район буенча күрсәткечләр ягыннан без ярык тагарак янында утырып калачакбыз. Аңлыйсызмы? Ярык тагарак янында...

Илшадиянең чибәр, мөлаем йөзен ачу болыты басты. Мөлаемлыкны сөмсер коелу алыштырды.

— Сезнең нәрсә теләгәнегезне мин яхшы аңлыйм,— диде ул, дорфалана язып. Гаделлеккә күрәләтә каршы төшүчеләрне күрә алмый иде ул.— Сезгә һәр мәктәптә, һәр класста дистәләгән отличниклар, алардан да күбрәк ударниклар кирәк. Отчетлар кызыл билгеләрдән балкып торсын, жиләкле аланны хәтерләтсен! Реаль тормышта алай түгел. Түгел! Байтак фәннәрдән «өчле»гә укучылар шактый. Моның бер гажәбе дә юк. Нормаль хәл. Табигый күренеш. Әле аның, турысын гына әйткәндә, тартып-сузып куйганнары да бар... Бар, чөнки теләр-теләмәс кенә мәктәп юлын таптаучылар да очрый тора. Барыбер класста икенче елга калдырмаганыбызны беләләр, барыбер аттестат бирәп чыгарасыбызны да беләләр. Шуңа пошмыйлар. Аларга «өчле»не тартып-сузып куймый ниишлисең?..

Мәктәп директорының үз позициясенә теше-тырнагы белән ябышып ятуы, уртак тел табарга уйлап та карамавы мөдиргә ошамый иде, билгеле. Ул Илшадияне үз коралы белән үк егып салырга теләде.

— Сез, үзегез дә сизмәстән, педагогик хезмәтегездәге аксаган якларыгызны саный башладыгыз, Илшадия Фәйзерахмановна.— Мөдирнең чыраена баксаң, чамасыз җитдилек күрер идең әлеге минутта.— «Тартып-сузып куйган «өчле»ләр һәм гомумән «өчле»ләр — сезнең коллективтагы укытучыларның эшләп житкермәү жимеше бит ул. КПД кечкенә, файдалы эш коэффициенты... Туры әйткәнемә үпкәли күрмәгез, үзегез укыта торган классларда да рус әдәбияты буенча билгеләр бик елмаймый... Бик уртача картина, мин әйтер идем...

Үзенә төбәп әйткәннәргә Маннурова аз гына да кылтаймады, аз гына да кәефсезләнмәде.

— Дөрес,— диде ул шундук килешеп,— мин билгегә бик саран. Тик шуны яхшы беләм: мин куйган билгеләр инфляциягә бирелми. Югары уку йортларына керү имтиханнарында да, хәрби училищеларга кергәндә дә кыйммәтләрен жуймыйлар. Миңа шунысы кадерле... Коллектив хезмәтенә килсәк, бер селтәнүдә өреп очырырга җыенмагыз әле. Житәкче кешегә бер минутлык настроение белән сүз сөйләү ярап бетми шикелле. Миңа ачуыгыз килү Агачбаш мәктәбе коллективын тоташтан яманларга хокук бирми дип беләм.

— Мин бит...

— Бүлдермәсәгез икән.

— Гафу...

— Былтыр безнең мәктәптә министрлыктан килгән авторитетлы комиссия эшләгәнен беләсез. Фронталь тикшерү нәтиҗәләрен игълан иткән педсоветта үзегез дә катнаштыгыз һәм аларга каршы бер сүз дә әйтмәдегез.

— Илшадия Фәйзерахмановна, зинһар аңлагыз, шул ук министрлыкта миннән сыйфат проценты таләп итәләр. Якалап даулыйлар...

Илшадия, артыгын нечкәләп маташмастан, урыныннан сикереп торды да, китәргә җыена башлады. Кәгазьләрен җыештыра-җыештыра әйтте:

— Ә сез принципиаль булыгыз. Коммунистларча. Процент маниясенең зарарлы икәнен исбатлагыз үзләренә. Процент шаукымы үз-үзебезне генә алдау түгел, азак килеп, бөтен ил жәмәгатьчелеге алдында күз буяу икәнлеген исбатлап күрсәтегез. Безгә таянығыз, турыдан-туры белем бирүчеләргә... Без, практиклар, укучыларның сәләтен, белем дәрәҗәләрен билгеләүдә сирәк ялгышабыз. Ә менә аңлы рәвештә «тартып-сузуыбыз» өчен гаепсезләр дип булмый әле безне. Анысына сез этәрәсез. Дөмбәсләп...

Мөдир Маннурова белән сүз куертудан һичнинди мәгънә чыкмасын, ниһаять, төшенде шикелле. Коры гына саубуллаштылар. Илшадия Агачбашына кайтып китте. Машина да чакыртмады, рейс автобуска да утырырга ниятләмәде. Жәяү атлыйсы килә иде аның. Көне бик матур. Жилкендергеч язгы көн. Кояш көлә, олы юл читендә баш төрткән ямьяшел үлән бөртекләре, кояшка карап елмая-елмая, тернәкләнеп маташалар. Юкә, каеннарда, америка чаганында бөреләр бүрткән. Тимерчыбык сыман булып шоп-шома утырган ботак-чатакларга хәзер бөре песиләре ябышкан. Куак башларына ерактан карасаң, аларга сирәк челтәрле шәл бөркәндергәннәрдер кебек.

Язгы һава, табигатьтәге жанлану галәмәтләре, кышкы өшәнгәнлекне куарга теләгәндәй назлаган кояш нурлары, мәгариф бүлеге мөдире кабинетында туган киренкелекне акрынлап юкка чыгарды. Илшадия күңеленә нур өстәлә барган шикелле булды. Узган уку елындагы чыгарылыш классында Язилә исемле бер кыз бар иде, язга гашыйк кыз. Директор шуның хыялый сүзләрен исенә төшерде. «Карагыз әле, апа,— дигән иде ул бер язны, дәрестән кайтырга чыккач.— Кояш бүген гел бүтәнчә елмая. Иркәләп, яратып. Биттән үбәсе килгән шикелле. Каен бөреләренә карагыз. «Менә хәзер шыртлап ачылабыз!» дип тора-лар. Мин аларның сөйләшкәннәрен ишетәм. Билләһи менә! Честное комсомольское!»

Класташлары кычкырышып көлгәннәр иде. «Билләһи!» белән «Честное комсомольское!» икесе бергә булгач, ышанмый хәл юк инде, янәсе. Ә Язилә, дөньядан үткән зат сыман, үз фикерен аңлатуда булды.

— Тыңлагыз әле, тыңлагыз, койма буенда тернәкләнгән үлән кыяклары да жырлый. Яшел моң килә алардан. «Сиңа бүген унжиде тулды!» диләр кебек...

Шул сүзләреннән соң гына һәркемгә ап-ачык булып калды: Язилә-нең туган көне икән ләбаса! Тотындылар котларга, тотындылар тәбрик-

ләргә. Шатлыгы ташуыннан хәбәр салуының азагы шул булды: класташлары кичкә табан Язиләгә кунакка барырга карар иттеләр. Юбилярны кайтарып жибәрделәр дә, аңа бүләк алу, кичәгә үзләреннән өлеш кертү хакында киңәш кордылар.

Илшадиянең дә, Язилә сыман, «Бөреләр пышылдавын ишетәм!» диясе килә башлады. Синең ничә яшьтәлегеңне сорап тормый бугай ул язгы жилкендерү куәте...

Язиләне ачык дәресләрнең берсендә, районның дистәдән артык рус әдәбиятчысы дәрескә кереп утырган чакта «ачкан» иде Илшадия. Әдәби әсәр туу турындагы сүз, дәрес темасыннан читкә китеп, куера калды (Илшадия мондый «читкә китү»ләрдән курыкмый һәм ачык дәрес аның өчен карачкы түгел), Фадеевның «Тар-мар» әсәренә килеп терәлде. Шунда Илшадия класска сорау бирде: «Күз алдыгызга китерегез әле, укучылар: «Тар-мар»ның соңгы битләрен Александр Александрович Фадеев түгел, ә сез, һәркайсыгыз аерым-аерым язып бетерергә тиеш, ди. Сезнең карашыгызча, кем һәлак булырга тиеш, Баклановмы, әллә Левинсонмы?»

Берәү дә жавап бирми. Ә вакыт уза. Күрше мәктәпләрдән килгән укытучылар бер-берсенә караша башладылар. Кинәт гадәттә аз сүзле, оялчан гына йөрүче кызчык кул күтәрә. Жавабы — икеләнүсез. Фадеев вариантын яклый. Авторның хаклылыгын шундый итеп исбатларга тырыша, судта үтә жаваплы эш буенча адвокат диярсең. Аны ничәнче ел укытып та мондый чаялыгын күргәне юк иде әле Илшадиянең. Молодец Язилә! Каян килгән аңа шундый батырлык, фикер ачыклыгы, матур мәгънәсендә үзсүзлелек? Дәрестән соң ипләп кенә сораштыра торгач, Илшадия аңлады: укытучысын, яраткан укытучысын бәладән коткарырга теләгән икән Язилә. Ачык дәрес бит, класста күпме кунаклар утыра...

Ачык дәрестәге тәвәккәллеге Язилә өчен исемсез-атсыз психологик бусаганы, барьерны үтеп чыгу булды. Шул хәлдән соң ул кыюланып китте, уйлау өлгерлеге дә үсте. Укучыларның мөстәкыйль уй йөртүләрен һәм уйлаганнарын бәян итә белү осталыкларын тикшерү ниятe белән стандарт булмаган сорауларга жаваплар язып килергә кушты Илшадия. Әйтик, Раскольников, әнисеннән килгән хатны ачканчы ук, анда ни язылганын белмәс борын, конвертны шашынып үбә башлый. Ник? Ни сәбәпле?

Икенче сорау. Ни өчен Сальери Моцартның: «Дәһилык һәм явызлык — бергә сыеша алмый торган нәрсәләр»,— дигән сүзләрен ишетүгә аның чәшкәсенә агу сала?

Сорауның өченчесе. «Гроза»дагы Катерина: «Балакайларым юк бит минем»,— дип өзгәләнә. Әгәр «балакайлары» булса, ул бакча артына, Борис янына чыгар идеме? Һәм гомумән — тормыштан китәр идеме?

Укучыларның жаваплары кызык иде. Төпле иде. Кыршылып, таушалып бетмәгән сораулар һәрчак эзләнергә мәжбүр итә. Эзләндеме, кеше бервакытта да стандарт жаваплар бирми. Язиләнең жаваплары исә күпләргә үрнәк-өлге булырлык иде.

Укучыларга авыр сорау биргәч, классның тынып калуы ошый Илшадиягә. Көтелмәгән сорау классны уйга сала. Ул укучыларга сокланып карап тора. Ә кайчагында чыдамый, әйтә: «Нинди тынлык, ә?! Уйлагыз, уйлый белүегез өчен рәхмәт сезгә, укучылар!» — ди.

Язилә хәзер колхозда эшли, фермада сыерлар сава. Групкомсорг. Районның яшь терлекчеләре арасында алдынгылардан санала. Тугызун ай гына эшләсә дә, район газетасына мактап яздылар, комсомол райкомының Мактау грамотасын алды. Бер көн очрагач, Илшадиягә сөйләп торды: «Укымыйча каласым килми, апа. Читтән торып ветеринария институтына керергә ниятем бар»,— ди.

Атлый торгач, Илшадиянең Язилә турындагы уйлары укучыларның

хезмәт берләшмәсенә барып ялганды. Апрельнең унбишенә Татарстан мәктәпләрендәге хезмәт берләшмәләре житәкчеләрен һәм директорларны республика киңәшмәсенә чакыралар. Берләшмә советы председателе — уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары, математик Зәки Газизов белән Илшадия барачаклар. Министр Зәки Газизовичның тәжрибә уртаклашуын сорады. Хәзерләнүен хәзерләнде инде ул. Сөйләр сүзе, уртаклашыр тәжрибәсе бар. Аннан соң беренче тапкыр гына чыгыш ясавы да түгел. Газета, радио, телевидение әһелләренә интервью бирә-бирә дә шомарып бетте. Шулай да республика киңәшмәсенең колачы, масштабы бүтән. Тезисларын бергәләп күздән кичерү зыянга булмастыр...

Кайтып төшке ашны житкерде дә (Булат шулпасын кайната торган, апасына булышырга өйрәнеп бара), район үзәге хәлләрен сөйләшә-сөйләшә, тәмләп әбәд ашагач, Илшадия мәктәпкә керде. Зәки Газизович аны көтә иде инде. Ул, таза гәүдәле, нык бәдәнле, киң битле, аксыл чырайлы тыныч кына кеше, һичкайчан каушап калмас, ашыгып төшмәс, кайнарланмас. Бу юлы да үзенең киңәшмәдә сөйлисе чыгышының план-тезисларын җайлап кына директор алдына куйды.

— Җентекләп карагыз, Илшадия Фәйзерахмановна. Үземчә, мин башкарган эшләребезнең һәммәсен телгә алам шикелле инде. Кайберләре бәлки артыктадыр. Вакланып китүдән дә сак булган хәерле. Киңәшмәдә бит күпне күргәннәр киләчәк.

— Хәзер карыйбыз, Зәки Газизович. Сезгә бик тыйнак, ләкин бик саллы итеп чыгыш ясарга кирәк. Күрсәткечләребез бер дә мескенләнә торган түгел,— диде Илшадия һәм бөтен дикъкатен хезмәт берләшмәсе башлыгы язган текстка юнәлтте.

Моннан егерме ел элек, партия һәм хөкүмәтебезнең «Мәктәпнең тормыш белән элемтәсен ныгыту һәм илебездә мәгариф системасын тагын да үстерү турында»гы карары игълан ителгәч, Агачбашы урта мәктәбендә кырык алты укучыны берләштергән производство бригадасы төзелә. Бу бригада колхозга өч гектар мәйданда шикәр чөгендере һәм кукуруз үстереп бирә, мең чебеш үстерә. Елларына күрә шушы күрсәткеч тә телгә алып сөйләрлек санала. Бүген УХБ карамагына колхоз өч йөз гектар җир һәм техника бирде.

Берләшмәдә хәзер өч йөз илледән артык укучы эшли. Берләшмә советы — җитәкче орган. Аның составына өлкән класс укучыларыннан биш кыз һәм егет, ике укытучы, колхоз председателе һәм баш агрономы керә.

Узган ел укучылар кырык мең сумлык эш башкарганнар. Бу сумма берләшмә членнарына, куйган хезмәтләренә карап, эш хакы рәвешендә бүленде. Тулай сумманың өч проценты берләшмәнең җәмәгать фондына кертелгән.

Илшадия чыгышның план-тезисыннан канәгать иде. Шулай да искәреп алды.

— Зәки Газизович, чыгышыгыз бик әйбәт, конкрет, фактлар һәм саннар кире каккысыз. Киләчәккә планнарның реальлеге дә бәхәссез. Тик нигә алган бүләкләребез турында бер сүз дә әйтмәскә булдыгыз? Аны барыбер сораячаклар. Бүләк — хезмәтне бәяләү ич ул,— диде.

— Өстәрбез алайса...— Берләшмә җитәкчесе моны үзе дә белә, директорның «Лаф ормагыз, зинһар!» дип әйтүеннән генә шикләнгән иде.— Өстәрбез, Илшадия Фәйзерахмановна.

Директор кабинетының бер почмагындагы журналлар өстәленә куелган телефон чыңлады. Илшадия ашыкмый гына барып, трубканы кулына алды. Трубкадан көр тавыш ишетелде.

— Мәктәпме? Исәнмесез! Илшадия Фәйзерахмановна, сезме? Саумысез, саумысез! Сәмәрханов иде әле.

— Исәнмесез, Кави Салихович!

— Ни эшләр бетерәсез?

— Укучылар бүгеннән каникулда. Үзем РОНОга отчетлар тапшырып кайттым. Унбишенә Казанга чакырулыбыз. Иптәш Газизов республика киңәшмәсендә чыгыш ясарга тиеш. Шуны хәзерлибез...

— Бик әйбәт,— дип хуплады райком секретаре.— Минем нәкъ шул хакта шылтыратуым иде. Ярты сәгать элек кенә мәгариф министры шылтыратты. Хәлләрне сорашты, сезнең мәктәптәге эшләр белән кызыксынды. Чыгышыгызда, Илшадия Фәйзерахмановна, колхоз идарәсе һәм партоешмасы белән контактны тулы итеп күрсәтергә тырышсагыз икән. Ялгызак батырлар булып күренергә тырышмасагыз, отышлы булыр диюем...

— Әлбәттә, Кави Салихович. Без колхоз җитәкчелеге, партоешма һәм коммунистлар булышлыгын авыз тутырып сөйләргә жыенабыз.

— Шулай дөрес булачак. Юкса кире мисалларны да беләбез ич. Колхоз кирәгенчә ярдәм итмәгәндә, эш майтаралмый калган производство бригадалары үзебезнең районда ук булды... Сездә положение бик күпләр кызыгырлык... Инде сер итеп кенә сөенеч әйтим үзегезгә. Зәки Газизовичка да чишәргә мөмкин ул «сер»не...

— Ул үзе дә монда, Кави Салихович. Бергәләшеп аның чыгышы тезисларын карадык.

— Шулаймы? Бик шәп. Уртак сөенеч шул: былтыргы хужалык елы нәтиҗәләре буенча сезнең мәктәп берләшмәсе республикада беренчелекне алган һәм автомашина белән бүләкләнә. Котлыйм!

Илшадия кыз-кыркынча:

— Ура! Ура! — дип куйды.— Рәхмәт, Кави Салихович.

— Пожалуйста. Ярый, хушыгыз!

— Хушыгыз, Кави Салихович! Бик рәхмәт, куандырдыгыз!

Маннуровны «Ура!» дидертерлек ни булганын Газизов төшенми тора иде, Илшадия телефон яныннан килә-килешкә аның беләкләреннән тотып, күзләренә карады һәм бәхетле елмайды. Күзләрендә шатлык чаткылары биешә иде.

— Беренче урынны алганбыз, Зәки Газизович! Беренче һәм... һәм бүләге нәрсә дип беләсез?

— Әйтә алмыйм, Илшадия Фәйзерахмановна.

— Шулай да?

— Мәктәп радиоузелына жиһазлармы әллә?

— Зурданрак кубыгыз!

— Әйтә алмыйм.

— Автомашина. УАЗның йөк машинасы итеп эшләнгәне.

— «Ура!» кычкырырга да язык түгел икән шул... Шатмын, шатмын. Сезне дә котлыйм, Илшадия Фәйзерахмановна!

— Сезне дә...

Кабинет нурга чумгандай булды. Мәктәп алды бакчасындагы бөреләрнең ачылуы һәм ямь-яшел яфраклары кинәт күзгә чалынды. Күңелләрдә шатлык тантана итә иде. Хезмәттән килгән шатлык һичнигә алыштыргысыз сөенче...

— Тырышуыбыз юкка түгел, юкка булмады! Шунысы — барыннан да кыйбат. Коллектив фидакарьлеге юкка түгел! Киләчәккә стимул да әле ул, Зәки Газизович, бүгенге сөенечле хәбәр...

Алар, мәктәптән чыккач, икесе ике якка киттеләр. Зәки Газизов — үз өенә, Илшадия — үз квартирына. Кайтып житәрәк күзенә чалынып калды, мотоциклын пырылдатып, Харис китеп барды бугай. Әйе, шул булырга тиеш. Пионервожатый Фирүзә белән сөйләшеп торгандыр, күрәсең, Фирүзә мәктәпкә килә шикелле.

Исәнләштеләр. Илшадия кыздан сорыйсы итте:

— Безнең Харис түгел идеме ул китеп баручы?

— Әйе, Илшадия Фәйзерахмановна. Харис. Ташбуадан кайтып барышы. Ашыгам, өйдә эшләр күп, ди.

— Ташбуага ник бардым, ди соң?

Бу сорауны бирүе бик урынлы түгел иде. Фирүзәнең җавап бирә алмавы бик мөмкин ич. Ләкин Илшадиядә анлык кына мутлык бар шул: Фирүзә белән Харисның яхшы танышлар икәнен дә, сердәшләр сыман мөгамәләдә икәнен дә белеп тора.

— Сорамадым шул, Илшадия Фәйзерахмановна,— диде кыз, белмимнең беләге авыртмый дигәннән чыгып.— Ул әйтмәде, мин сорамадым. Йомышы-мазар булгандыр инде...

Директор сукмакны турыдан ярып карамакчы булды.

— Мария янына бардым, димәдеме?

Фирүзә алдаша белми, һәрхәлдә үзен бишенче класстан алып укыткан педагогы каршында алдашырга базмады. Уңайсызланды, колакларына тикле кызарынып китте, башка чарасы юк иде, дөресен әйтте.

— Әйе, Машаларга барган...

— Әйтәм ич. Мәктәп тирәсеннән тиз-тиз төтен бөркеп ычкынуыннан ук сизеп торам мин аны... Иртә ирәймәсен икән бу малайлар!

Ике арада сүз шуның белән бетте. Фирүзә мәктәпкә юнәлде, Илшадия квартирына кереп китте. Әле генә җанында балкыган салават күпере юкка чыкты. Күкрәк читлегенә ябышып, ниндидер хафа мәчесе тырмаша башлады. «Педагогика безгә тукый: балаларга өлкәннәр булып карарга мөмкинлек бирегез, яшүсмерләрдә өлкән кешеләрне күрергә тырышыгыз, моның өчен үзегез бала булып, үсмер булып карагыз. Бик азга гына булса да шулай итегез!» — ди. Беренче карашка килешергә мөмкин таләп шикелле бу,— дип уйланды Илшадия.— Икенче баксаң, менә шушы Хариска, унжидесен тутырганга ярты ел узган яшүсмергә, ничек әле өлкән кеше итеп карарга мөмкин. Ничек әле аны үзеннән ике-өч яшькә өлкән хатын хозурында күрмәк кирәк?»

Илшадия белә: «Ташбуада яшәүче Мария, чуваш кызы, Фирүзәнең яшьтәше, белеше, моннан ике елдан артык элек Харис белән танышкан. Чаңгы буенча район ярышларында. Танышканнар, аралашып киткәннәр, очрашкалап йөргәннәр. Ташбуа урта мәктәбен тәмамлагач, Мария район азык комбинатына хисапчы булып урнашкан, әле дә шунда эшли. Унынчыны бетергәч үк, яшьлек жүләрлеге беләндер инде, бер электрикка кияүгә чыккан. Төзелеш оешмасының тулай торагыннан бүлмә биргәннәр. Әмма ир дигәне озын-озак яшәүчеләрдән булып чыкмаган, Мария белән арасын өзгән дә, япа-ялгызы Магадан якларына китеп барган. Уракны яшелли урган Мария бала кочаклап ялгызы калган. Элеккеге таныш-белешлекләре сүнеп-сүрелгәндә көннәрнең берендә Харис аны янә очрата, янә сөйләшеп китәләр. Шуннан бирле Харис әледән-әле Ташбуа юлында мотоцикл куа.

Кече улының бу кыланышын Илфат һич өнәми. Этисе авырып киткәч, аннары менә санаторийга да барасы булгач, егет иркенләп жибәрде. Әле аңа хатын-кыз тирәсендә сырпаланырга бик иртә, яшьлек дуамаллыгына бирелеп йөри. Мәктәпне тәмамлыйсы, аттестат аласы, армиягә барып кайтасы... Эшләр күп әле. Балалы хатынны алгысытып бер генә дә буталасы түгел дә соң, кана. Үз акылыңны кешегә бүлеп биреп буламыни? Сөйләшеп карамады түгел Илшадия энесе белән, бик сөйләште. Тиң кешеләр, яшьтәшләрчә күреп тә, өлкән туган булып та, педагог позициясенә басып та. Юк, житдигә алмый юньсез. Гел уен-көлкегә борып котылмакчы... Мария янына сукмакны суытмаганын белсә, Илфат абыйсы тагын борчылачак инде. Теге вакытта сөйләшкәндә үк ул Хариска: «Син жил кай якка иссә, шул тарафка авышып йөрисең, улым. Төптәнрәк уйлап карау кирәк иде»,— дип рәнжү катыш ризасызлык белдергән иде...

Харис белән Марияның кабат очрашып, дуслык мөнәсәбәтләрен

янартып жибәрүләре кышын, каникул көннәрендә булды. Харис район буенча чаңгы ярышларына күлгән һәм өченче урынны яулаган иде. Кәефен начар дип булмас иде. Чаңгыларын күтәреп, Культура йортыннан чыгып барганда (анда ярыш йомгакларына багышланган тантана булды), күземә күренәме дип тора, Мария үтеп бара. Харис башта бу кызый юри сагалап тормадымы икән дип тә уйлаган иде, соңыннан аңлашылды, алай түгел икән. Үз авыллары — Рунгага әнисен озатып кайтып килүе булып чыкты. Сәлам дә сәлам, исәнмесез дә исәнмесез. Икеөч минутта бәйләме белән яңалыклар сөйләшеп ташладылар, танышбелешләрне искә алдылар, ярышка да кагылып уздылар.

— Гөл-Төркемгә китешеңме? — диде Мария, курчакныкы төсле жете-зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп. Күзләре генә түгел, үзе дә курчак сыман ул. Юк, алай раслау хак булмастыр. Курчак матур, ләкин аңарда суык матурлык. Мария бит бөтергәләнеп торган чибәр, җанлы, житез, йокыларыңны качырырдай сөйкемле хатын.

— Авылга, Маша.

— Әйдә безгә, чәйләп чыгарсың.

— Рәхмәт, Машенька. Юл кешесенең юлда булганы яхшы.

— Шикләнәсеңме? Өйдә берәү дә юк. Бүлмәмдә үзем генә. Вовканы әни авылга алып китте.

— Ирең командировкадамы?

— Гомерлек командировкада ул.

— Нәрсә? Үлдеме әллә? — Харисның күзләре маңгаена менгәндәй булды. Керфек какмый торды, Мариядан җавап көтте.

Мария язмышына күнгән тавыш белән җавап бирде.

— Минем өчен үлде.

— Аерылыштыгызмыни?

— Шулай килеп чыга. Суд белән. Законлы итеп. Тол хатыннан курыкмаска да мөмкиндер, Харис, әйеме?

— Бик күңелсез килеп чыккан бит әле бу, Машенька.— Харис, яшь яшәгән кеше диярсең, яшь хатынга теләктәшлек итеп, шулай сөйләнде.— Кушылып өлгермә, икең ике якка каерыл! Бала белән ялгызың нишләрсең икән инде?

— Мин күрәсең кеше күрмәс, Харис. Әти-әни исәннәр әле. Тормышлары ярыйсы. Орчык кадәр бер малайны гына ничек тә үстерешерләр. Башны ташка бәреп булмый инде. Үзе егылган еламас, диләр ич.

— Анысы шулай шулаең да...

— Я, ярар, хәсрәт күленә чумарга жыенып торма әле. Минем чумып чыкканым да житәр. Әйдә, кереп чыгасыңмы минем янга?

— Әйдә, дөнья бездән генә калмаган, Машенька! — диде Харис.

Чәй эчкәндә, Харис бер сорауга ачык кына җавап алмакчы булды.

— Ник аерылыштыгыз? Гаеп кайсыгызда? — Маңгайга бәреп шулай сорады.— Син гаеплеме, иренме?

— Гаеп атта да, тәртәдә дә булгандыр, Харис. Өзеп әйтүе авыр. Аны гына гаепләсәм, аның өстенә генә юынтык су сипсәм, мин дөрес эшләмәгән булыр идем. Аның мина кадәр яраткан кызы булган. Мин фактта алар арасына кергән булып чыктым. Жырдагыча, беренче мәхәббәт онытылмый икән. Магаданга киткәндә шул кызга өйләнеп китте. Нишләтәсең, йөрәк эше.

Харис, чәен эчеп куеп, чәшкәсен ераграк этәрде дә кәефсез генә:

— Һе! — дип куйды.— Унсигез ел буе алимент түләр мена!...

Мария уң кулы белән чебен куган сыман хәрәкәт ясап, Харис сүзенә каршы төште.

— Бер тиене дә кирәкми! Баланы үстерүгә катнашы булмасын. Үлмәмен. Ике жирдә эшләрмен, өч жирдә. Төн йокламам, отпускыга чыкмам, әмма аңардан акча теләнмәм.

— Теләнү түгел, закон нигезендә...

— Кирәге юк. Үзенә дә шулай дидем. Яшәр җирем бар. Күрәсең бит квартирны. Патша пулаты.— Мария ике кулын җәеп, кечкенә бүлмәсенә күрсәтте.

Бүлмә унике квадрат метрлы гына. Әмма анда шул тикле җайлы. Якты, җылы, чиста. Бөтен җире ялт иткән. Тәрәзәләрдә, диванда, өстәл өстендә һәм урындыкларда челтәр пәрдәләр һәм җәймәләр. Ишектән керү уңаена стенада роза гөле чигелгән тукыма рам эченә алып куелган. Түр якта, ике тәрәзә арасындагы стенада Мария белән иренең (элекке иренең) загста язылышкан көнне төшкән фотосурәте. Мария Харисның карашы шул фотога төшкәнне абайлагач, ни өчендер, ашыгып әйтте:

— Алып куям мин аны. Кадерен җуйды инде ул фоторәсем.

— Тимә, тарихка калсын,— диде Харис.

— Көлмә! — Маша кырыслык белән әйттс бу сүзне. Харис тол хатынны рәнжеттем ахры дип ни әйткәненә үкенде.

— Гафу ит, Машенька, мин көләргә уйламадым да. Тимә истәлек фотога диюем генә иде. Ярый, китим, я ачуланыша башларбыз тагын. Сыең өчен рәхмәт!

— Килгәнең өчен сиңа рәхмәт, Харис. Килгәләп йөр, яме. Миңа бик күңелсез икәнен кайчак исеңә төшергәлә. Кайтканда Агачбашына керәсеңме? Фирүзәне очратсаң, сәлам әйт...

Танышлыкны әнә шул рәвешле яңартканнар иде алар. Әлеге очрашудан соң Харис үзендә аңлатуы читен булган үзгәреш тойды. Аңарда Марияне кызгану, аңа теләктәшлек итү хисе баш калкытты. Яшьлеген дә сизми калган бу тол хатынга (сүзләре нинди — тол хатын!) әллә нинди изгелекләр эшлисе килә иде аның...

Крестьян өммәтеннән

Кичә партия райкомыннан хәбәр иттеләр: Чувашстанның Яльчик районындагы «Победа» колхозыннан — бу хуҗалык берничә елдан бирле «Интернационал» белән ярыша — кунаклар киләчәк. Кунаклар дигәнебез — бысел урта мәктәпне тәмамлаучы яшьләр. Алар Гөл-Төркемдәге хәлләр белән кызыксыналар. Яшьләрнең колхозда төпләнеп калуларына аерата игътибар бирәчәкләр икән.

Кәрим Вәлиев, районда гына түгел, республикада да алдынгы колхозның председателе, аларны кабул итәргә, хуҗалык тормышын сөйләргә, сорауларга җавап бирергә тиеш була дигән сүз.

Идарәдә иртәнге ыгы-зыгы, кимеп калгач, Кәрим Хәлимович шул очрашуга хәзерләнү кирәген уйлап алды.

Яшьләр авылдан ник китә? Төпләнеп калучыларны нәрсә тотып кала? Бу сорауларны аңа әледән-әле бирә торалар. Һәркемне канәгатьләндерердәй мөлдерәмә тулы җавап бирүе ансат кына түгел, ләкин ул сорауларга җавап бар. Бар!

...Гөл-Төркем, Казна, Каенлык авылларын берләштергән «Интернационал» колхозы. Нишләп монда яшьләр күп? Машина төзү заводы, шикәр заводы, тимер юлга, азык промышленностена караган предприятиеләре, автохуҗалыгы булган район үзәге дә ун гына чакрымда. Казан да, хәзерге заман транспорты йөреп торганда, якында гына. Китәм дип җилкенүчегә ара ераклыгы да киртә түгел.

Саннар өздереп сөйли: колхозда эшләүчеләрнең уртача яше — утыз алты. Авыл җирендә пенсионер да кул кушырып утырмый. Моны да искә алып хисаплагач килеп чыккан сан ул — утыз алты. Колхозчыларның өчтән берсе утыздан яшьрәк. Былтыр көзен армиядән кайткан унҗиде егет эшкә ябышып яталар.

Бу колхозның да кытлык кичергән хәлсез заманнары бар иде. Уңыш

алу дигәндә, «уңыш» сүзен әйтергә тел күтәрелми иде. Чәчүлек орлыкны икеләтә кайтарып алу гына сарыф иткән хезмәтне, көч-куәтне акламый, келәтләр тулмый иде. Техника житмәде, авыл халкының күңеле күтәрелмәде ул елларда.

Шулай да Кәрим Вәлиев моннан ун ел элек колхозга житәкчелекне кабул итеп алганда, күмәк хуҗалык шактый хәл җыйган иде инде. Ул тиклесе аңа кадәр председательлек иткән фронтовик авылдашының тырышлык жимеше. Шулай да Кәримгә, колхозны башлап төзешкән һәм беренче рейс булган Әхмәтжан карт онытына, шөгыль дә, мәшәкать тә, баш ватарлык хуҗалык табышмаклары да, әйле-шәйле генә йөргән агайларның характер кроссвордлары да житәрлек иде. Кәримнең башта бер генә отышлы ягы бар иде, армия хезмәтеннән соң институт бетереп кайткач, Гөл-Төркем урта мәктәбендә директор булып эшләде ул. Шуңа күрә туган авылының да, күрше бригадаларның да халкын биш бармагы кебек белә. Балалар — аның укучылары, өлкәннәр — ата-аналар, һәр тумыш көнне аралашып яшәгән кешеләр. Халыкны белү — житәкченең көч чыганакларыннан берсе.

Инде менә дистә ел үткәч, колхоздашлары Кәрим Вәлиевнең беренче егетлеге дип кирпеч заводы салдыруга «башы җитүен» саныйлар. Алга китү шуннан башланды шикелле. Хәзер колхоз елның елында миллион кирпеч суга. Гөл-Төркемдә генә дә, колхозның үзәк утарында, соңгы ике бишьеллыкта йөздән артык яңа йорт авыл урамнарын бизәп утыра башлады. Заманча проект белән мәктәп, ясле-бакча, сәүдә үзәге салынды. Өйләнешүчеләр яңа житкергән өйгә күчәләр. «Баш җитү»нең күзгә күренеп торган дәлилләре шундый. Яшәр җае бар кешенең эшләр җае да була. «Кай тарафка табан ялтыратырга икән?» дигән уй аңа кереп тә чыкмый.

Тормыш итү, дөнья көтү хакында гәп куерса, «Интернационал»ныкылар гап-гади генә итеп: «Эшләгән кеше — бай кеше бездә»,— диләр. Яшь җилкенчәк һәр егетнең «матае» барын әйтергә дә онытмый. Киленкиленчәк шөкер итеп туймыйлар, «Детсадка чират юк бит бездә, малайкаем!» — дип куаналар. Механизаторлар: «Һәр бригада станында душ эшләп тора безнең, агай-эне!» — дип җибәрәләр. Бәс, шулай булгач, күпме боргаласаң да, материаль тәэмин ителгәнлек мәсьәләнең кендеге булып чыга түгелме? Бөтен шарты килгән жылы, якты, иркен өйдә тамагың тук, өстең бөтен булып яшәү. Авыл кешеләрне шуның белән тотып торамы?

Моңа җавап итеп Кәрим Вәлиев былтыр көзен комсомолның туган көненә багышлап үткәрелгән тантананы исенә төшерде.

Сәхнәдә көрәшче егет, төп кебек нык, мускуллары уйнап торган авылдаш Сәлмән Кариев. Культура сараеның зур залын тутырган колхозчылар гөр килеп кул чабалар, Сәлмәнгә «Бишьеллыкның яшь гвардиячесе» значогын тапшыралар. Райкомның комсомол секретаре Равил Сафин уңган егетнең кулын кыса, аннары кочаклап ук ала. Сәлмән шат, әмма бик тыйнак, көчле кешеләргә хас тыйнаклыгын жуймый, елмаеп тик тора.

Сәлмән егерме бердә. Армиядән хезмәт итеп кайткач, фидакарьлек күрсәтте. Хезмәте зур калада узды аның. Шунда яшәп-торып калырга бөтен мөмкинлеге бар иде. Авылга ник кайткан димсез? Ул бу сорауга үзе елмаеп кына жавап бирә:

— Гөл-Төркемнән кала бер жир дә тартмый мине, жәмәгать. Монда безгә ышаналар, безгә таяналар. Үзеңнең киләклегеңне тою, үзеңә таянганнарын белү — ул инде... ул инде мәсьәләнең хәл кылынуы...

Колхозда культура тормышы кайнап тора. Культура сараенда ике ансамбль эшли. «Интернационал» үзешчәннәре — республика смотры лауреатлары. Туган туфракка берегүнең серләреннән берсе, ихтимал,

шул дадыр? Кичләрен кайда ничек уздырырга каңгырып йөрүчеләр юк монда. Яшьләр, җае чыкканда, мактанып та алалар:

— Җәйләрен безнең танцы мәйданында өчәр йөз кеше була. Күрше колхозлардан да киләләр!

Шуларның һәммәсен бергә туплагач, яшьләрнең ата-баба туфрагында төпләнүләре хакындагы сорауга җавап табылды да төсле. Тик моны соңгы сүз дияргә ашыкмыйк әле, дип уйлый Кәрим Хәлимович.— Туган колхоздан аерылырга теләмәүнең тамырлары тирәнрәк. Кызларның һәм егетләрнең бик гадәти итеп кенә әледән-әле әйткән сүзләренә колак салу кирәк: «Монда бит барысы да үзебезнекеләр. Бөтенесе дә колхоздашлар!»

«Үзебезнекеләр!» үтә тыгыз мәгънәле сүз бу. Ул «үз» эченә мәктәп дусларын, әти-әниләрне, олы һәм кече туганнарны, туган-тумачаны гына алып калмый, тирә-күршене дә, һәммә авылдашларны да сыйдыра. Шулай булгач, үзара бәйләнешләрнең бихисап бай һәм күпкырлы икәнлеге ачыклана. Монысы инде кешенең туган авылына кан якынлыгын тоюы, «кан тартуы». Ул — гасырлар кичеп, ныгып, буыннан-буынга күчеп килгән хис, рухны җылытучы көч.

Шәһәр җирендә уңганнарны телдә тибрәтеп: «Бу — хезмәтчел семья, уңган гаилә» диләр. Авылда масштаб киңрәк, монда ыруг колачы белән фикер йөртәләр, нәселеңне искә алалар. Яшьләрне мактаганда:

— Нәселе шундый. Нәселдән килгән уңганнар! — диләр. Әйтик, Маннуровлар хакында кемнән генә сорама, әйтерләр: «Күкенекеләр бит алар. Нәсел-нәсәбе белән тырышлар, булдыклылар» дип бәяләрләр. Илфатларның күршесен, Габделхак Насыйровларны ал. Аларның нәселе хакында да гомеренда яман сүз ишетмәссең. Габделхак — Илфат Маннуров яшьтәше, ә тракторга аңардан да алдарак, унөч яшендә, кырык өченче елны утырган кеше. Илфатның әнисе белән бергә эшли башлаган. Беркөнне генә сөйләп торды әле.

— Көл дә, ела да, баш каткан чаклар бар иде,— ди.— Тракторга утырдым утыруын, эш майтара алмыйм гына бит! — Үзе шунда металл һәм ягулык белән эш итүдән тупасланып калган зур кулларына карый.— Шунда Маһибәдәр апа бригадир янына китте.— Кабыза алмый тракторын, ди икән, соң бигрәк бала бит әле, жәлләмичә ничек утыртгыгыз? Бригадирны да иярtеп килүенә мин инде тракторны кабызган, сөрә башлаган идем...

Аның каравы хәзер инде Габделхак, малае әйтмешли, машинаның кай җире төзек түгелен тавышыннан белә. Атаның үзе турында сүз кузгалса да, улларын сөйләсәләр дә бер генә билгеләмә: «Насыйр бабаң нәселе шул!»

Тормыш юлын сайлаганда, нәселең кемнең дәвамы булу бик мөһим икәнлеге бәхәссез.

Әйбәт нәсел хезмәт сөю, уңганлык белән генә билгеләнми. Фидакарьлек яңашәсендә вөждан сафлыгы да бар. Авыл халкы кешегә ярдәмле, ил-көн өчен тырышучы кешене олылый. Үз бакчаңда күпме генә казынма, маңгай тиреңне күпме генә агызма, ни тикле акча сукма, колхозда шәләй-вәләй йөрүең белән бүтәннәрне рәнжетәсең икән, синең бәяң базарның кызуында да бер тиен.

Шунысы да бар: уңган да син, булган да, үткен дә, зирәк тә. Укымышлылыгың да зур, әмма ата-анаңа аяулы түгелсең, мәрхәмәтең юк икән, авылдашларыңның синнән йөз чөерәсен белеп тор. Шуңа күрә дә ир-егетләр ерак-ераклардан авылда ялгыз калган әнкәләре янына кайтып төпләнәләр.

Крестьян тормышының тамырлары җиргә тирән киткән, дип куйды Кәрим һәм урыныннан торды, фермаларны урап кайтырга исәпли иде.

Ишек шакып, кабинетка Даниял Имамов керде.

— Ярыймы, Кәрим абый?

Кәрим көлемсерәп алды.

— Кереп беткәч, ярыймы дип торган буласың. Уз әйдә, ни эш майтарып йөрүең, Даниял?

— Шәл бәйләдем, шәл бәйләдем, шәлем түгәрәк түгел, диләрме әле? Минем дә күнел түгәрәк түгел әле, Кәрим абый. Ремонт дип, оя баса торган каз шикелле атна-ун көн буена мастерской белән гаражда кадакланып яттым. Иртәгә бабай янына барып, хәл белешеп кайтырмын дигән идем. Рөхсәт итсәгез...

Кәрим Даниялга үтәли күрергә теләгән сыман кадалып карады.

— Илфат абыйның эшләр шәп аның. Өченче көн шалтыратты. Әйбәт дәваланам, ди. Дарулары да килешә, массажы да шәп, дәвалау гимнастикасы да файдага, ди. Спротсмен кебек тренировкалар ясыйм хәзер, ди. Күбрәк кыймылдаган саен хәлем арулана бара, ди. Рәмзия апаң янында. Син барып йөрмәсәң дә ярый диюем...

Даниял мутланырга булды.

— Бөрлегәнем, бер дигәнем дигәндәй, Кәрим абый, бердәнбер бабай бит инде ул минем. Җиләк кебек кыз үстереп биргән бабай. Кияү килеп хәл дә белешми дияргә мөмкин. Сау-сәламәт кеше, чыннан да, Васильевога барып кайтуны чутка сукмаска тиеш ич инде, Кәрим абый.

— Син Илфат абый янына бару хәйләсе белән берәр көнеңне антигрустинга багышламакчы буласың бит, егет.— Кәрим аңа янә төбәлеп карады һәм беравык карашын алмый торды. Даниял чыдамады башын читкә борды.— Шулаймы?

Даниял, бер дә кирякмәскә, тотынып баскан артлы урындыкны сыйпаштыргалап, үпкәләгән кеше кыяфәтенә кереп, җавап бирде.

— Авыр сүзне яра диләр дәрләп янган йөрәккә дигәндәй, Кәрим абый, алай кыерсытмагыз әле, пожалысты... Авыр сүз хәнҗәр кебек, ярасы төзәлсә дә эзе кала. Мин авыру кеше турында кайгыртып йөрим, сез фәлән дә фәсмәтән.

Кәрим тел шомартканны яратмый. Даниял исә, башны дәрвишлеккә салып, аның каршында әкият сөйләп тора, фәлсәфә сата.

— Син, егет, теш агартма, яме. Мин әйткәнмен икән, значит, уйлап әйткәнмен. Туктат син антигрустин белән шөгыльләнүләреңне. Әхмәт Хәйретдине язмышы сиңнән дә ерак йөрми ул. Трактор белән ферма сөздермәсәң, күпердән очарсың, бәла мең төрле, сәрхүшлә сагалап кына йөри.

— Рөхсәтме соң инде?

— Бар. Иртүк китәсең, төнге поезд белән тут как тут. Аңлашылдымы? Иртән жидегә паркка үзем барып тикшерермен, бел!

Даниял рәхмәт әйтеп чыгып китте. Кәрим дә фермага китәргә тора иде, бусагада диярлек районның баш ветврачы белән очраштылар.

— Кунак килә, ә сез, Кәрим Хәлимович, каядыр китәргә ниятлисез,— диде баш белгеч.— Беразга гына тоткарлана күрегез, киңәшәсе нәрсәләр бар иде.

— Рәхим итегез. Барыр жирем ерак түгел, фермаларга юл тотуым иде,— диде председатель.— Сөйләшик...

— Фермаларга бергәләп барырбыз,— диде баш врач.

Ниләр күрми ир-егеткәй белән ир башы

Апрель ямьсез, шыксыз килде. Язгы көн ярты акыл дигәннәре растыр, күрәсең. Кояш, бер көн елмайса, ике-өч көнен болыт артына яшеренеп уздырды. Халык явым-төшемне кармы, яңгырмы дип атарга кыенсынып калгалады. Жилсез көн булмады диярлек. Төньяктан искән салкын жил тәмам үзәкләргә үтте.

«Чулпан» колхозы умартачысы Шәяхмәт абзый, бал кортлары белән мәшгуль башка осталар шикелле үк, чын язны көтеп җиткерә алмый изаланды. Аның карамагындагы бихисап җан иясенә ямьле көннәр аерата тансык иде. Кышны имин чыккан корт семьялары язның соңгаруын, чыгымчылап килүен бер дә өнәмиләр, борчылалар, тынгысызланалар, хәлсезләнәләр, үләләр.

Май ае кергәч, үк инде дә табигать миһербансызланмас, кары-суыгы беткәндер, дип яхшыны-хәерлене өметләнеп, Шәяхмәт карт умарталарның барысын да бакчага чыгарды. Ике көн рәттән, вакытында ашау-эчүне дә онытып, алны-ялны белми тырыштылар. Бүгенгә эш аз калган иде, иртәнге мәлне генә бераз кыймылдадылар. Аннары ярдәмчесе авылга кайтып китте.

Карт, мәктәптә укулар булмаудан файдаланып, умарталыкка пәреп килгән Илсурны чакырып алды (Илсур — Шәяхмәт кызының кызыннан туган бала, икенче буын оныгы), һәм алар бакчадагы өйгә керделәр. Умартачы электр плитәсенә чәй куйды, өстәлгә бәйрәмдә пешкән ризыкларны тезде. Аннары, иркенләп бер тирән сулады да: «Яле, скрипкә-моңлыбикә, муртаймадың микән?» — дип сөйләнә-сөйләнә, чаттагы өстәлдән скрипкасы белән смычогын алды.— Муртаймагансың муртаюын, алай да картаясың, үзем кебек»,— диде.

Илсур бабасының скрипка көйләвен, күз буучы циркач әкәмәтләрен караган төсле, онытылып күзәтте. Аннары скрипка моңына сокланып, бабасының җыерчыклар ермачлаган, җилдә-кояштa какланып бронзаланган олпат йөзенә текәлеп утырды. Зәңгәрсу-шәмәхә тамырлары бүртеп чыккан сул кул бармакларының кылларын капшаштыргалап торуына, уң кулдагы смычокның бермәл бик салмак хәрәкәтләнүенә, ул да булмый ашыгып-ашкынып китүенә игътибар итте. Малай нинди көйләр башкарылганын белми иде, ләкин көйнең озыны, сузынкысы да, дәртле, кыскасы да аңа ошады. Күңелне әллә нишләтә иде скрипка моңы.

Шәяхмәт карт, уйнап туктагач:

— Менә бармакларны яздык бераз. «Гөлҗамал»ы булды да, «Ком бураны» булды,— дип аңлатты. Көй исемнәре малайга зерә дә сәер тоелды, тик ул алар хакында сүз кузгатмады, бабасының җырлап та бирүен үтенде. Әнисенең: «Бабаң әйбәт җырлый безнең!» — дип катkат сөйләгәнен исенә төшергән иде ул.

— Дәү бабай, бер сугыш җыры җырлап күрсәт әле, ә? — диде.

— И-и-и, балакаем! — Бабасы кытыршы зур кулы белән Илсурның башыннан сыйпады.— Әниең менә синең кебек чакта, икенче-өченче классларда укыганда, җырлый идем әле бераз. Аннан соң да утыз ел гомер үткән инде. Сиксәнне куып килгәндә, җырларга түгел, мырларга гына калды инде дәү бабаңа...— Шәяхмәт көрсенеп алды. Шулай да малайның гозерен илтифатсыз калдырмаска булды, берничә тапкыр тамак кыргалады да җыр башлады. Тавышы тәрәзә пыялаларын зыңгылдатырлык көчле түгел түгелен дә, колакны назлый торган моңы бар. Матур тавыш. Җырлавы тыныч, сабыр, көчәнүсез:

Чит илләрдә күп йөредек,
Вакыт түгел микән кайтырга?
Йөргән җирнең курае юк,
Күргәннәрне көчләп тартырга...

Җырлап бетергәч, Шәяхмәт «Вот шулайрак, балакаем!» диде һәм оныгына күз кысып куйды.

— Әйбәт җыр! — Илсур олыларча житди итеп әйтте.— Тулькe бу сугыш җыры түгел, дәү бабай.

— Ник алай дисең, балакаем?

— Түгел.

— Сугыш җыры булгач, дөбер-шатыр килеп торырга тиешме, синеңчә? Сугышта да бит, балакаем, танк, пушка, самолет та бомба гына түгел, кешеләр... Аларны һәр сәгать үлем сагалап йөри. Яралануымгәнү көтә. Сугыш тынып калган минутларда солдат туган жирен, якыннарын уйлый, имин узган елларын сагынып искә ала. Шул минутларда ул үзенең сагышын жырга куша, балакаем. Мин гел шул жырны жырлый идем. «Азамат» дигән жыр бу. Чын сугыш жыры...

Дәү бабасы Илсурны ышандыра алмады, сүзләре шул урында бүленеп калды, өйгә кемдер кереп килә иде. Ишек шакуга жавап итеп Шәяхмәт карт:

— Ишек уйган, тәрәзә куйган, керә бирегез! — дип кычкырды.

Өйгә Кави Сәмәрханов килеп керде. Өстенә — эчле плащ, аягына калын олтанлы ботинка кигән, башында эшләпә. Һәрвакыттагыча галстуктан.

— Хәерле көн, Шәяхмәт абзый! — Кави Салихович картларча күрешергә итеп, агайга ике кулын да сузды. — Исәнмесез! — Аннары Илсургә сәлам бирде. — Исәнме, зур үскән егет!

— Исәнмесез! — диде Илсур да һәм, борынын тартып, читкәрәк елышты. Олылар янында бутала торган гадәте юк.

— Ни хәлләрдә яшисез, Шәяхмәт абзый? Саулык әйбәтме?

— Егетләрчә, Кави энем. Картлык белән генә беленми. Утырып алыгыз. Өстегезне салыгыз. Чәй өлгерә, тамак ялгарбыз.

— Рәхмәт, Шәяхмәт абзый. Тамак тук минем. Тоныксуда ашап чыктык. Берәр чынаяк чәйне кинәнеп эчәр идем.

— Хәзер була!..

Чәй янында соңгарып керешкән язгы чәчүнең барышы, дым каплауны мөмкин кадәр тизрәк тоту зарурлыгы турында сөйләштеләр. Райком секретареның сүзләреннән Шәяхмәт карт районда язгы кыр эшләренең әйбәт башланып китүен аңлады. Әңгәмә умартачылыкка да кагылмый кала алмый иде. Сәмәрханов сорашмаган очракта да Шәяхмәт абзый үз хәлләрен сөйләми жибәрмәс иде. Район башлыгы да, бакчага тикле килгән икән, бал житештерү белән кызыксынмый каламы?!

— Ничек, Шәяхмәт абзый,— дип сорашты Кави,— варроатоз биел да жәфалар микән?

— Бездә әллә ни кыйрата алмастыр, Кави энем. Кулдан килгәнен кыландым кебек. Галауный — вакытында... Былтырлары аның зәхмәте ник көчле булды? Галим-голәмә ул каһәр суккан талпан белән сугышырга әзер түгел иде. Белеп тә тордылар торуын, күрше илләрдә варроатоз бар, безгә дә килергә мужет. И килде дә. Мине дә читтә калдырмады. Ары йөгердем, бире йөгердем, варроатин файдалы, диделәр. Биш ояны шуның белән эшкәртеп караган идем, өч семья кырылды. Миндә генә түгел, бүтәннәрдә дә булды үлем. Шунысы тагын: варроатин балны боза, балавызны... Кайберәүләр талпанга каршы эшкәртүне көзен уздыралар. Ну бит балны иң мул суырту вакытында, жәен үк, талпаннар кортлар семьясында була! Көз житкәндә алар кортларны эштән чыгарып өлгерәләр...

Мин ул каһәрләр белән августта үк якалаша башладым. Бал алу беткәч үк. Соры корт үрчемен чистарттым, картоннарга вазелин сылап рамнар астына куйдым. Төнәткечкә имән, шомырт йомычкалары тутырдым. Шуның төтененнән талпаннар вазелинлы аскуймага мәтәләләр дә ябышып калалар. Картоннарны алып яндырдым.

— Бүтәннәргә дә өйрәтергә иде моны.

— Район гәзитенә яздылар, Кави энем.

— Күрми калганмын алайса.

— Яздылар. Бик баявай егет кылган иде, мин сөйләп тордым, ул

язып барды. Аннары, дөрес язганмынмы дип, укып күрсәтте. Шулай булды. Ну, Кави энем, әйтми булмый, бал кортының иң зур дошманы без үзебез...

— Ничек дидегез, Шәяхмәт абзый! Аңлап бетермәдем.

— Бал кортына иң зур дошман үзебез, мәйтәм.

— Нилектән алай дисез?

— Күп кешенең уенда күбрәк бал алу гына. Азыкка дигән балны шикәр белән алмаштыралар. Кортка фәкать бал белән чыршын, ягъни бал икмәге, перга кирәк. Аларда, шикәрдән кала, аксым, витаминнар, ферментлар, минераллар, кислоталар бар. Кешегә нәрсә кирәксә, бал кортына да шулар кирәк... Кышлыкка мин азыкны мул, бик мул калдырам. Икенче алымнан, иң бай дигән җәйге балдан. Үзләре җыйган хәзинәдән җитәрлек азыклары булса, талпан дигәнең дә ул чаклы шүрләрлек түгел... Күз житми бездә кортларга, күңел күзе, Кави энем. Күңелегезгә авыр ала күрмәгез берүк, безнең районда да пачуты юк бал кортларының.

— Килешергә туры килә, Шәяхмәт абзый. Моңача кул житмәде. Балны һәммәбез дә ярата, умартачылыкны онытып җибәрәбез.

— Шул-шул! — дип жанланып китте карт. Райком секретареның үз фикерләрен куәтләве күңеленә бик хуш килде.— Бал кортлары ул бит бал гына да түгел әле, иген уңышы, жиләк-жимеш, яшелчә уңышы да, Кави энем. Умарта корты йөрмәсә, карабодай белән көнбагыш та, жимеш куаклары да, дару үләннәре дә, чәчәкләр дә аталанмый калгач, уңыш бирәлми бит. Тарих әллә нинди кыенга калган чакларны белә. Акыл сатуым түгел, укыганымны гына әйтәм, Австралиядән клевер алып кайткач, орлык ала алмыйча ни интеккәннәр. Клевер буйга үскән, матур итеп чәчәк аткан, орлык бирмәгән. Ник? Серкәләндерүче бөжәкләр булмаган. Шөпшәләрне, бал кортларын чит илләрдән кайтарткач кына эш худка киткән...

Жае гына чыксын, бал кортларының тырышлыгы, игелеге, файдасы турында Шәяхмәт абзый сәгать буе сөйләргә әзер. Бабасыннан, атасыннан килгән һөнәре бит аның умартачылык. Шуңа күрә, чәйләрне эчеп бетергәч тә, Кави Сәмәрханов китәргә ашыкмады, картның сөйләвен кызыксынып тыңлады. Ә бит шушы кешене каты кыерсыткан заманнар бар иде. Колхоз умартасыннан читләштерү генә түгел, күзен дә ачырмыйча кимсеткән еллар да булып алды. «Чулпан» умарталыгына аны нәкъ менә Сәмәрханов беренче секретарь булып сайлангач кайтарды. Шуңа да Кавига рәхмәте таудан зур Шәяхмәтнең, шуңа да серләре килешә аларның. Шуңа күрә дә умартачы карт сугыштан соңгы гомерендәге ике зур шатлыкның берсе итеп колхоз умарталыгында кабат эшли башлаган көнен саный. Икенче шатлыгы — Шәяхмәт Вәлиуллинга райвоенкомның сугышта катнашучы дигән таныклык биргән көне. Болар онытылмый...

Сугыш башланганның икенче көнендә Вәлиуллин, «Чулпан» колхозының тракторчысы, аркасына юл капчыгын асып, призыв пунктына китте. Капка төбендә имчәк баласын күкрәгенә кыскан Гөлсеме елап калды. Аның чабуына тагын өч сабый ябышкан иде. Бу китүдән Шәяхмәтнең алты ел аерылып торасын, ике мәртәбә авылга үлгән хәбәре киләсен, солдат башының тәмуг газаплары күрәсен берәү дә белми иде әле.

Баштагы ике ел ярымын ул тырналмыйча да йөрде, йөк машинасы йөртте. Северский-Донец буенда, Святогоровка янында, бөтен взводтан бер ялгызы исән калды. Котырган ут астында штабка донесение илтергә кирәк булгач, санитарка: «Вәлиуллинны жибәрегез, аны пуля алмый»,— дип киңәш иткән иде.

Белгород янында Шәяхмәт машинасына снаряд тиде. Автомобиль чыра кебек яна башлады, ә шоферны шартлау дулкыны юл кырыендагы ерымга алып ыргытты. Аңына килгәч, беленде: битенә кан кат-

кан, кулын снаряд кыйпылчыгы ярган, телогрейкасы тетелеп беткән, бүтәне — тәртиптә! Дошман зонасыннан көч-хәл белән чыгып, үзе кебек частьларыннан аерылган солдатларны эзләп тапты, бер ай дигәндә, үз частена барып кушылды. Бу вакытта авылга аның үлеме турында хәбәр киткән иде инде.

Сугыша-сугыша барып, Харьковны, Полтава, Краматорскны узды, Кременчуг тирәсендә Днепрны кичте, э Ингулец елгасында әҗәл чолганышында калгач, сугыш Шәяхмәт Вәлиуллинга яңа исәп ачты. Котылыч исәп-хисап кенәгәсе...

Әсирлек... Анда күргәннәрне искә төшерү дә газапның иң-иң авыры. Ярый әле, кеше хәтере жан сыйдыра алмаган дәһшәтләрне бер читкәрәк этәреп торырга сәләтле. Ә хәтер яхшылыкның бөртеген дә читкә тибәрми. Олы яшьләрдәге поляк хатыны... Әсирләр колоннасына көлдә пешкән дүрт-биш бәрәңге ыргытканы өчен конвойный аның күкрәгенә автомат приклады белән сукты, хатын егылып, карда аунап калды... Норвегиядә үлем чәчеп торган чәнечкеле тимерчыбыклар һәм сак манаралары белән уратылган лагерьга килеп, жирле халык шырпы тартмасы кадәр генә бутербродларны, пакетка салып, әсирләргә ташлыйлар иде. Кайберләре сак офицерыннан рөхсәт сорап кечерәя: «Офицер әфәнде, әсирләргә тәгам бирергә рөхсәт итсәгезсәнә?» Симергән унтер хахылдап көлә: «Нигә ризык әрәм итәсез? Барыбер дөмегәселәр ич алар!» Әйе, лагерь миналанган, үзләреннән үк кабер казытып куелган иде. Тере калдырмаячаклары көн кебек ачык. Ә норвегияле карт китми, ялына. Ниһаять, фашист мыскыллы елмаеп рөхсәт бирә: «Ташла тимерчыбык аша!»

Шуларны сөйләгәндә Шәяхмәт абзый күз яшьләрен тыя алмый һәм ихлас күңеленнән чыккан сүзләрен әледән-әле кабатлый:

— Чын коммунистлар иде ул Норвегия кешеләре! — ди.— Үзләре карточкага яшиләр, ачлы-туклы. Шуны авызларыннан өзеп безгә бирергә тырышалар...

«Дине ят, теле ят рус әсирләренә, сәләмәгә төренгән, сөяк белән тиредән генә калган ярты үлекләргә мондый ярдәмне коммунист булмаган кешеләр күрсәтә алмый...» Крестьян жанының гадилеге, эчкерсезлеге белән Шәяхмәт абзый шулай уйлый. Шуңа иман китергән ул. Нәфрәт һәм аяусызлык кешеләрне аера, ераклаштыра, дошманлаштыра; аның каравы изгелек кылу һәм теләктәшлек итү кешеләрне туганнарча якынайта. Шуңа күрә дә могҗиза белән генә исән калган татар колхозчысы, ике кат үлеп терелгәнгә чутланган Шәяхмәтнең йөрәге барлык жан ияләренә карата мәхәббәт белән тулы. Шул сәбәпле бал кортларын да ул тасвирлавы читен булган бер ярату белән ярата. Аның бер әйтеме бар: «Бал кортлары — кояшлы ыругдан». Кояш булмаса, алар ояларыннан чыкмыйлар. Кояш күрендеме — эшкә. Кешенең кәефсафа корып, йоклап калып эшкә кичегүе мөмкин. Бал кортында мондый тәртипсезлек юк. Әгәр кешеләр умарта кортлары кадәр тырышсалар, тездән байлык эчендә йөрер идек...

«Бал корты,— ди тәжрибәле карт,— сабый бала кебек: әле ашыйсы килә аның, әле йокысы төшә, ул да түгел, ирек ачасы килә башлый. Шул шартларны булдырмадыңмы — авырый, үлә. Күз уңында тотсаң, бик яратсаң гына көчен кызганмый ул...»

Шундый нечкә күңелле кеше башына язмыш күсәк белән тондырсын әле. Сугыштан да читтә тормады бит, сугышты да, яраланды да. Командирларыннан рәхмәтләр дә ишетте. Әсирлек дигән гөнаһ-шомлык аларның һәммәсенә тәре сызды да куйды. «Вәлиуллинмы? Нинди фронтовик булсын ул! Сугыш беткәнне пленда көтеп яткан бәндә» дигән сүзләрне ишеткәндә, аның йөрәк ярасын ачып тоз сипкән шикелле тоела иде. Дуска түгел, дошманына да анда утырырга язмасын. Ул лагерьларда бер гаепсез меңләгән кешеләр авып калды. Шәяхмәт Вәлиуллин-

ның кайтуы да теге дөньядан кайту белән бер үрде. Алай да ни кыласың, ил авызын томаларга илле яулык кирәк, дигәннәр. Озак еллар буена аны сугышта катнашкан дип искә дә алмадылар. Кем гаепле? Сугыш. Үзе күптән тарихка калды, әтере кешеләрнең йөрәген каеэлый бирә. Менә нилектән военкомның таныклык тапшырган көне Шәяхмәт өчен иң зур бәйрәм! Димәк, җирдә гаделлек бар, һәм ул иртәме-соңмы барыбер тантана итә. Шуның өчен илгә-көнгә рәхмәте чиксез Шәяхмәт Вәлиуллинның...

Атап әйтүле тагын бер кешегә рәхмәте бар әле аның. Гөл-Төркем авылыннан Илфат Маннуровка. Сулаган сулышы кебек киряксенгән эшенә — колхоз умартачылыгына кабат кайтару юлында башлап йөргән кеше шул. Илфат Маннуров барды беренче башлап райкомның беренче секретаре янына. Барды да әйтте: «Иптәш Сәмәрханов! Мин ерак туганымның хәле турысында килдем сезнең каршыгызга,— диде.— Булышыгыз аңа, район башлыгының кулыннан килмәс эш түгел бу. Шәяхмәт абзый йөзебезгә кызыллык китермәсенә изге ипи тотып ант итә алам. Коммунист анты бирәм. Язмыш аны болай да күсәкләгән. Олыгайган көненда буй-сынын турайтып бер яшәп калсын әле...»

Шактый сөйләшеп-киңәшеп утыргач, умартачы карт Сәмәрхановны озата чыкты. Кави аңа язгы чәчүне төгәлләгәч, район умартачыларын киңәшмәгә җыячакларын әйтте, зур сөйләшү булырын, анда Шәяхмәт абзыйның да катнашуы кирәген искәртеп куйды.

— Машинагызны бик ерак калдыргансыз лабаса, Кави энем! — Карт моңа уңайсызланып алды.— Койма буена хәтле дә килеп җитмәгәнсез.

— Кортлар бензин исен яратмыйлар дигәнегезне онытканым юк әле, Шәяхмәт абзый.— Кави Салихович саубуллашырга кул сузды.— Кортларны борчыганнарын Шәяхмәт абзый өнәми...

Хәсрәт хәсрәткә ошамый...

Илфат белән Рәмзия Гөл-Төркемгә бәйрәм алдыннан кайттылар. Дәваланудан һәм ял итүдән бик канәгать иделәр, кәефләре әйбәт.

Больницадагыдан аермалы буларак, санаторийда дәвалау гимнастикасын алга сөрәләр. Гомер-гомергә эшләп өйрәнгән кеше, аягына басарлык, хәрәкәт итәрлек рәте булуга, бер минут та тик тормасын икән. Үзенә кулай спорт җиһазлары янында рөхсәт ителгән вакытның соңгы минутына кадәр шөгыльләнсен икән. Илфат шуны тирән төшенде һәм үзен аямаска булды. Арыса, арыды, алҗыса алҗыды, хәл җыйды да янә талчыкканчы шөгыльләнде. Кәефе күзгә күренеп яхшырды. Уң аяк көч туплады, дөрес баса башлады, төз атлады. Әлбәттә, ул тизрәк арый иде әле, ләкин монысына гажәпләнергә кирәкми инде. Өзлексез күнегүләр, даими массаж, ничәмә-ничә төрле дәвалау уң кулны да акрынлап «уятты». Санаторийга килгәндә, ул әйберне тота алмый, ә бер эләктерсә, ычкындыра алмый аптырата иде әле. Акрынлап бармакларга җан керде. Моны сөенечле алга китеш дими, ни дисең?! Сабый бала һәр мөстәкыйль адымына шатланган шикелле, сырхау кеше дә савыгу юлындагы алга таба китүгә куана. Чөнки һәр карыш яңа өмет уята, күңелне үстерә, җанга якты өсти.

Әле кайчан гына Илфат чалкан ятса — түшәмгә, борылып ятса стенага карау белән чикләнергә мәҗбүр иде. Караватка торып утырып; дөньяга үз биеклегеңнән карау да бәхеткә әйләнгән иде. Башның чатнауларын әйтәсе дә түгел иде. Карават тирәли «сәяхәт» тә олы җиңү булып тоелуга да гажәпләнмәде ул. Хәзер инде кеше ярдәменнән башка чакрым ара үтә ала. Наратлык эченә чумып утырган Васильево санаториесенең сукмакларын аз таптамады ул.

Саф һава, минутка-минут төгәл үтәлергә тиешлеге бәхәссез режим, заманча дәвалау чаралары, караучы персоналның искиткеч игътибарлы мөнәсәбәте — һәммәсе бергә тупланган, каты авыру алган көчне акрынлап кайтарырга булышты. Алган чакта сырхау дигән ләгънәт дәрт-дәрманны көрәп-каерып, умырып-ялмап ала, кире кайтканда сәламәтлек тамчылап кына җыела. Алай да тамчылар тама гына торсыннар икән, туктамасыннар гына, алар башта күлдәвек хасил итәләр.

Рәмзиянең дә байтак еллар санаторийда, курортта, ял йортында булганы юк иде. Килгән мәлгә ул эшсезлектән аптырады. Казна эшенә дә йөрмә, өй мәшәкате дә юк, аш-су да хәзерләмә, хәтта табак-савыт та юма, көнне ничек үткәрмәк кирәк?! Таңны төнгә ялгап дөнья куарга өйрәнгән зат баштарак утырып арбасын табалмый аптырады. Әмма моңдый кысыр хәсрәттән тиз арынды. Санаторийның китапханәсе бай, ул укуга бирелде. Боргаланмый гына икърар иткәндә, производствода чагында күп укый алмый иде ул. Теләк юклыктан, китаптан бизгәннән түгел. Төп хезмәте дә мәшәкатьле, җәмәгать эшләре дә житеп ашкан, арый иде. Китап алып яттымы, сихерләп куйганнар диярсең, керфекләрне хет шырпы белән терәт, йокы килә дә төшә...

Саф һавада күп йөрделәр, ничә еллык хатирәләрне яңарттылар, килер көннәрдә кыласы эшләрен сөйләштеләр. Күңелләр якын булганда, сөйләшер сүз чыгып кына тора икән!..

Тагын бер файдалы эш майтарды Рәмзия. Массажчы егетнең Илфатка массаж ясаганын бер карап торды, ике карап торды да, өченчесендә сорады:

— Энем, мин дә азмы-күпме өйрәнә аламдыр бит бу һөнәргә? Өйрәтсәгезче,— диде.

Массажчы егет бер дә иренмичә, түзем-чыдам булып, Рәмзия апасына барлык алымнарны кат-кат күрсәтте. Гөл-Төркемгә кайтыр алдыннан егет аңа үзенә генә массажларга рөхсәт бирде. Бу — имтихан алу сыман бер нәрсә иде. Шул рәвешле, начармы-яхшымы, Илфатка массаж ясар кеше үз янында хәзер. Авыл жирендә гомер итүче өчен уенмуен гына түгел.

Апрельнең утызында, иртәнге якта, аларга Кәрим Вәлиев керде. Кырда, фермаларда, төзелеш мәйданында, ремонт мастерскоенда, амбарларда булырга туры килгәнлектән, һәрвакыт эш киеменнән йөрүче, гомумән, өс-башына әллә ни игътибар итәргә күнекмәгән председатель бүген энәдән-җептән генә чыккан куе зәңгәр төстәге костюм кигән, ак күлмәгенә, костюмына иш галстук таккан иде. Аягындагы күпне күргән ботинкаларны ялык-йолык килеп торган туфлилар алыштырган. Колхоз башлыгының өстендә плащның да яңасы. Башында велюр эшләпә. Шартын житкереп кырынган-таранган. Күңеле күтәренке.

Кәрим гадәттәгечә шау-гөр килеп күреште, кәефләрне белеште, аннары урындыкка җәелеп утырып, сүзенең төп өлешенә күчте. Ул кырт кисеп, үтә конкрет гәпләшергә күнеккән, кул бармакларын берәм-берәм бөкли барып сөйләүчән.

— Беренчедән,— диде Кәрим бу юлы да, чәнти бармагын бөкләп,— радиодан колагыгызга кергәндер дип беләм, бүген Культура сараенда Беренче Майга багышланган тантаналы җыелыш. Парлашып шунда киләсез. Җыенып торыгыз. Шушы кичәдә сине котлау булачак, Илфат абый. Колхоздашларга Алтын Йолдыз таккан килеш күрсәтеп тә булганы юк бит әле үзеңне. Кыскача гына жавап сүзе әйтерсең, фикерләреңне чиратка тезә тор... Икенчедән... председательнең тагын бер бармагы бөкләнде. Ул Рәмзиягә карады.— Икенчедән, Рәмзия апа, майның унбишеннән без кием тегү мастерскоен ачып жибәрик инде, яме?

Әлеге мәсьәләдә ирле-хатынлы уртак фикергә килеп куйганнар иде ахры, Рәмзия, уйный-көлә жавап бирде:

— Эшләми торырга өйрәнеп җиткәч, бик ансат булмас та, Кәрим энем, колхоз житәкчесе әйткәч, буйсынмый да ярамас,— диде.— Ярар, килештек...

Кәрим аны мактап ук җибәрде.

— Менә рәхмәт, Рәмзия апа! Егет тә ханым инде үзегез! Инде килеп, өченчедән,— урта бармак бөкләп куелды,— мин хәзер райком бюросы утырышына китәм. Өйлә авышмый кайтып булмас. Сез әзер торыгыз...

Язгы кичтә колхозның Культура сарае электр балкышына чумган иде. Шәһәр жирендәгечә, лампочкаларның аллы-гөллеләреннән озын чылбырлар сузганнар. Бина түбәсендә зур кызыл йолдыз яна. Ул, мөгаен, Казанга да, Каенлыкка да күренә торгандыр. Аның янәшәсендәге флаг талгын жилдә салмак кына жилферди. Флагка Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларга куелган һәйкәл чәчәклегеннән прожектор яктысы төшеп тора. Почет тактасын да яңартканнар. Культура сараенын зур биек тәрәзәләренә яңа шторлар эленгән, сәхнәгә кирпеч төсендәге хәтфәдән яңа пәрдә тегеннәр. Сәхнәдәге озын өстәлгә чүлмәкле гөлләр тезгәннәр.

Маннуровлар килеп житкәндә, халык байтак жыелган иде инде. Әле килә торалар. Аръяк яшьләре гармун сайратып, жырлап чыгалар. Тантанага килүчеләргә текәлеп карасаң, биниһая зур чәчәк бәйләме күргәндәй буласың. Шул тикле килешле, матур итеп киенгәннәр. Йөзләрендә елмаю, телләрендә тәбрик сүзләре. «Имин елларның бәхетле көннәре,— дип фикер йөртте Илфат, алгы рәтләрдә колхоз уңганнары өчен калдырылган урыннарга таба атлаганда.— Кадерен белергә кирәк имин заманның! Күрсәнә яшьләрнең хозурлануын! Безнең үсмер чак белән чагыштырасы да түгел. Яшьлек юлларында күп кенә хыялларыбыз хәрабә сыман өелеп калды шул. Дөньялар тыныч булсын да бәхетләре гел генә түгәрәк торсын!»

Маннуровларны партком секретаре, авыл Советы председателе һәм колхоз башлыгы каршы чыгып алды. Фойега керүгә, Илфатларны механизаторлар әйләндереп алды. Моңача күрешмәгәннәре аны илнең иң зур бүләге белән котлады, бәйрәм тәбриге дә әйтте. Рәмзия белән дә бик жылы күрештеләр. Шартын китереп, бәйрәмчә киенгән, сизелерсизелмәслек итеп кенә бизәнгән ханыма карап сокланып торалар. Капкадан чыккач та, аның күңелендә шушы абруйлы кеше янәшәсендә бару белән горурлану тойгысы канатлана башлаган иде. Шушы һавалырак хискә елышкан бүтән бер тоем да бар: Хатирәне алмаштырган хатынга Гөл-Төркем кешеләре ничегрәк карарлар? Мәгәр андый сагаю бик тиз юкка чыкты, аны гүя язгы кичнең талгын жиле очырып алып китте. Әнә бит нинди якын итеп, көләч йөз белән каршыладылар аларны!

Әхмәт Хәйретдинена генә бүтәннәрдән уздырырга маташу кытыгы тынгы бирмәде. Ул, тешләрен агартып:

— Чәчләр чәчкә бәйләнгән булгач, безнең авыл туфрагы тәки тартып китерде бит үзеңне, Рәмзия, ә? — дип тел шомартты.— Магниты көчле шул безнең Гөл-Төркемнең! Син, давай, геройны стройга тизрәк бастыр инде...

— Тиздән басар, Хәйретдин. Ул бит мәлҗерәп калганнардан түгел,— диде Рәмзия кырт кисеп.

Хәйретдин тагын ниләр болгатыр иде әле, Кәрим Вәлиев аңа шундый иттереп карады, Әхмәт Хәйретдине телен тешләгәндәй булды.

Тантаналы жыелышны партком секретаре ачты. Кәрим аңа сүз биргәч, секретарь пролетар бердәмлек бәйрәме турында кыска, әмма мәгънәле итеп доклад сөйләде. Шуннан сүзне янә Кәрим Хәлимович алды.

— Хөрмәтле колхоздашлар! — Ул залның тәмам тынычлануын көтеп, озак тыныш ясады.— Бәйрәм кичәсенә без колхозыбызның атаклы

механизаторы Илфат Фәйзерахман улы Маннуровны тәбрикләргә дип тә җыелдык. Билгеле булганча...

Кәрим Вәлиев бүгенге җыелыш түрендә утыручы Илфатка Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелүен, аның тормыш юлының биредәге халыкка яхшы билгеле булуын әйтте, кырык елга якын вакыт эчендә ул башкарган эшләрне тасвирлады, аның килер көннәренә изге теләкләр теләде, якын арада кыр батырын янә трактордә, комбайн штурвалында күрербез дигән ышаныч белдерде.

Председатель сүзләрен Культура сарае алкышларга күмде.

Аннары Илфатның хезмәттәшләре, эшкә аңардан өйрәнгән яшь механизаторлар котлау сүзе әйтте. Пионерлар тәбриге булды. Геройга мәктәп теплицасында үстерелгән чәчәк бәйләме бүләк иттеләр. Һәр сүзне күңеленә сеңдереп утырган Илфат, үзенә чыгыш ясар вакыт җиткәндә, дулкынланган һәм кәефенең киргә китүен чамалый башлаган иде инде. Шатлыклы, бәхетле сәгатьләр дә ярамаса ярамый бит сәламәтлеге кителгән кешегә. Алай да Илфат ирлеген итте, сер бирмәде, трибунага тыныч узды. Кул чабулар тынганны көтеп, ашыкмый гына сөйләп китте:

— Кадерле колхоздашларым! Минем хакта бик күп яхшы сүз әйттегез, зурладыгыз. Бик рәхмәт сезгә. Рәхмәтемнең иң зурысы — партия һәм хөкүмәтебезгә! Эшләгән кешене олылый белә безнең ил. Мин нәрсә әйтә алам? Үземә бирелгән зур бүләкне, мактаулы исемне барыгыз белән дә уртак саныйм. Ник дигәндә, минем хезмәттәге уңышларымда коллективның да зур өлеше бар. Саулык булса, ил алдында бурычлы булып калмам, хәлемнән килгәннең һәммәсен эшләргә җиң сызганып торам. Инде озакламый эшкә ярармын дип ышанам.

Мин, үзегез беләсез, үгездән атка, аттан тракторга, комбайнга күчеп утырган кеше. Артыгына чама җитмәде, әмма ләкин бүгенге һөнәремне бүтән бер һөнәргә дә алмаштырмас идем. Ник дигәндә, җавап ачык: игенче-механизатор ашлык үстерә. Игенче — җир йөзендә иң борынгы, иң изге профессия кешесе. Дөнья аны, шатлык килсә дә, хәсрәт басса да, онытмый, чөнки, иптәшләр, ашлыкның һәр бөртеге алмаздан, алтыннан кыйммәтрәк. Приискаларда самородок алтын табалар, ә самородок ашлык булмый. Ул үзеннән үзе үсми. Аны игенченең алтын куллары, сезнең белән безнең куллар үстерә. Шуңа күрә ашлык-икмәк тә иң югары пробалы алтыннан да кыйммәтлерәк булып китә. Икмәксез җирдә тормыш юк, ризыксыз яшәп булмый. Без беләбез, дөнья күләмендә алсак, бөтен кеше тук булсын өчен, чутсыз тир түгәргә кирәк әле. Кешелекнең шактый өлеше ачтан интегә яисә ачлы-туклы яши. Без, совет кешеләре, интернационалистлар, моны да истән чыгара алмыйбыз. Иптәшләр, җирдә яшәвебезнең юкка түгеллеген, без, игенчеләр, ризык муллыгы булдыру белән исбатларга тиешбез. Рас игенче һөнәрен сайлаганбыз икән, без шуның өчен җаваплы...

Илфат залдагы авылдашлары белән күзгә күренмәс җепләр аша бәйләнгән, кешеләр аның фикерен ярты сүздән аңлыйлар иде. Шунлыктан, ул сөйләп бетергәч, озаклап кул чаптылар.

Үзешчәннәр концертын карап утырганда, Илфат хәле китүен сизде һәм Рәмзиянең колагына гына пышылдап: «Кайтыйк әле булмаса, кәеф чыгымчыларга җыена бугай»,— диде. Хатыны үзе дә шул хакта уйлап, борсаланып утыра иде. Күзләре генә сәхнәдә, уйлары Илфатта. «Бүтәннәргә комачауламый гына чыгыйк»,— диде.

Тәэсирләр күпкә китте, күрәсең. Илфатның кан басымы күтәрелгән, күңеле болгана, буыннарының куәте киткән иде.

Кайткач Рәмзия ирен җайлап кына чишендерде, даруларын эчерде һәм урын җәеп яткырды, аннары аның караваты читенә килеп утырды.

— Өзлегеп китә күрмә тагын,— диде ул, кулын Илфатның маңгаена куеп.— Бармый да булмый иде шул җыелышка да...

— Хәлем зерә дә әйбәт иде бит әле...— Илфат Рәмзияне хафага салмаска тырыша иде. Хәтта елмаеп шаярткан да булды.— Син янымда булгач, Рәмзия, өзлегү юк инде ул...

Чүп өстенә чүмәлә, иртән уянсалар, Харис кунарга кайтмаган булып чыкты.

— Иптәшләрендә бәйрәм каршылаганнардыр да, шунда йоклап калгандыр ул, Илфат.— Рәмзия ирен шулай тынычландырмак булды. Илфат «Алай түгел» дигән сыман баш чайкады.

— Юк, Рәмзия,— диде ул ятагыннан күтәрелгәч, пижамасын кия-кия.— Иптәшләре янында булмас ул. Мотоциклын карап кер әле. Иренмә, яме. Чыгып кер.

Мотоцикл гаражда юк иде.

— Әйтәм ич.— Илфат, тәненә без кадалган шикелле, чыраен сытты. Аның кара тут йөзен сөрем басты. Күзләрен элпә каплады.— Ташбуага сыпырткан малай актыгы...

Ул Рәмзиягә хисапчы яшь хатын Мария турында сөйләде. Рәмзия мондый борчу булырын башына да китермәгән иде.

Сәгать иртәнге уннар тирәсе булгандыр, Рафис белән Хафизны ияртеп, Зөбәйдә килде (бәйрәм көн аның ял көне дә булып чыккан, фермада сыерларны алмашып сава).

Сабыйларын гөлчәчәктәй киендергән Зөбәйдә. Ничек өлгерәдер, балаларын һәрвакыт бик пөхтә йөртә.

Нәниләр, килеп керүләре булды, бабаларына барып сарылдылар. «Тәти әби»ләреннән дә беренче күргәндәгечә ятсынмыйлар инде. Шоколад-конфетлар белән сыйлагач бигрәк тә. Кочакларга да ризалар, үбәргә дә.

Зөбәйдәнең төп йортка килүенең максаты әтисе белән Рәмзия апасын бәйрәм чәенә үзләренә дәшү иде. Әтисенең хәле мөшкелләнеп тору аны да шиккә салды. Теле белән әйтмәсә дә, эченнән: «Рәтләнеп китә алмас микәнни әти?» дип уйлап алды. Илфат хатын-кызларны тәшвишкә төшермәскә теләп:

— Барырбыз, кызым, барырбыз. Кунакка бару — таш кисәргә бару түгел,— дигән булды.— Хәмернең гайрәтлесең хәстәрләдеңме соң? Мин ни җитте кызыл-мызыл белән генә маташмыйм бит хәзер...

Әтисенең шаярырга теләвеннән Зөбәйдәгә күңеллерәк булып китте. Уен-көлке сөйләрлек булгач, хәле бик үк начардан түгел икән ич әле, дип фараз кылды.

— Чәе-мәе әзер, әти. Ирләргә дигәне дә, Рәмзия апа белән мина дигән сорты да... Даниял Имамов йортында ансыз дөнья сансыз.— Зөбәйдә шулай дип елмайды, тик бу елмаю артында әллә ни яшеренергә дә уйламаган сагыш та бар иде.

— Кияү ничәләрдә кайта?

— Ул көндезге сменада. Җидедән калмам дип китте.

— Бәйрәмне ничегрәк каршылады соң?

— Зыянлы түгел. Иртүк эшкә барасы иде бит...

Илфат кызының шыңшык холыклы булмавына шатланып бетә алмый. Белә бит, төгәл белә: иртәгә чәчү чәчәсе булу гына түгел, военкоматка барырга дисәләр дә, туйганчы сыйланмый калмый Даниял. Ә Зөбәйдә, авызы тулы кара кан булса да, ата-анасын да борчымас, кеше алдында да төкермәс. Яклап кына тора ул Даниялын. Бәлки бик дөрес тә эшлидер. Очраган бер кешегә ирен яманлап, хурлап йөрсә, нәрсә отар иде? Бер нәрсә дә отмаячак. Дус бар, дошман бар, бер ишесе кешеләрнең тату яшәвенә хөсетләнә, андые синең өеңдә савыт-саба шылтыраганга куана гына. Ирләрне ир иткән дә хатын, аяк астына са-

лып таптаган да хатын, дип дөрес әйткәннәр... Әнә ич, Даниял турында сүз чыккач, Зөбәйдә этисен ни рәвешле тынычландырмакчы.

— Аңа шәләй-вәләй йөрергә ярамый да. Әрсезләнә торгач, беренче урынга чыкты бит. Быел басуда син дә булмагач. Бүтәннәргә махы бирми ул. Әхмәт Хәйретдиненең теле авызына сыймый икән сыймавын да, Даниял ана: «Эт өрә, бүре йөри, жиренә житкереп эшләвем хак булсын»,— дип кенә карый. «Теге елларда күке үзе правофланговый иде, хәзер ул миссияне киявенә тапшырган», ди икән Хәйретдин.

Илфат өчен зур яңалык түгел бу. Даниял эш дигәндә тауны жимерә. Сыйфатка һич кайчан зыян китермәс. Булсын дип эшли, чын крестьянча. Жирне ярата. Үз бәясен дә белә. Кемнеңдер эшенә бармак төртеп күрсәтүен теләми, андыйга чыдый да алмый. Былтыр да бер бишкөнлектә күчмә вымпелны үзендә тотты.

Чүкердәшеп чәйләгән вакытта бусагада Харис күренде. Сау-сәламәт, күңеле күтәренке. Һич ни булмагандай кайтып керде, сәлам бирде, бәйрәм белән котлады. Чәй янына чакыргач, юынып өстәл буена утырды.

— Кайларда булдың инде син, улым? — Илфат әр-шелтәсез генә бик сабыр сорап куйды.— Бәйрәмне ничек каршыладың? Кайда, кемнәр белән?

Харис, гадәтенчә, сүзне уен-көлкегә бормакчы иде дә, этисенең йөзенә күз салгач, бу сөйләшүнең бер дә уен-муен булмаячагын абайлап, әдәпле генә җавап бирде.

— Башта Агачбашында, апаларда булдым. Булат белән гәпләшеп утырдык. Яңа рәсемнәрен күрсәтте. Аннары...

Сүзгә Зөбәйдә кушылды.

— Аннары Ташбуага киттеңме?

Харис аңа күзенең агы белән карады. Эчә торган чәй йомрысын читкәрәк этәреп куйды. Апасын бөтенләй санга сукмаска теләгән төсле:

— Үземә рапорт бирергә рөхсәт итсәгез икән, мадам Имамова-Маннурова,— дип мыскыл төтене очырды.— Әйе, Агачбашыннан Ташбуага киттем.

— Шунда кунып та кайттыңмы? — Зөбәйдәнең жан эчкәресендәге ниндидер пружина ычкынып өлгергән иде, ул, кусаң да китмәс көзге чебен кебек, бәйләнә бирде.

Харис баягы тонда ук, ләкин тагын да ирониялерәк итеп әйтте:

— Кунып кайтуның сүзлектәге мәгънәсе адәмнең йоклавын аңлата шикелле. Мин керфеккә керфек тә ормый өстәл буенда утырып, таң аттырдым. Иртәнге чәйдән соң менә сезнең хозурыгызга кайттым, мадам Имамова,— диде.

— Мотоциклыңны биклән куясы бар, тыр-пыр жүләр сатып йөри алмас идең!

— Синең сумнарыңа алынган мото түгел ул, хәләл көчне колхоз басуында түгеп алынган, мадам. Көпчәкләрдә сезнең эшегез булмасын...

Илфатка улының орды-бәрде сөйләшүе бөтенләй ошамады. Башында «Кай арада бу тикле йөгәнсезләнергә житеште соң әле бу малай?» дигән сорау туды. Шулай да тавыш куптарырга теләмәде, үз кәфенә начар булырын уйлый иде. Тагын тыныч кына әйтте:

— Каян таптың әле син, улым, ул «мадам» нарыңны? Туган апаң сиңа ниткән «мадам» булсын?! Кешечә генә сөйләш.

Харис апасының тыгылуына үртәлә, балтыр итен умырырдай булып ябышуы белән килешә алмый иде.

— Ә ул ник прокурор булып утыра? Мин имчәк баласымы әллә? Әнә Рафис белән Хафизга әмер бирсен, аларны тикшерсен!

Зөбәйдә сирәк кыза, бу очрак шул сирәкләрнең берсе иде булса кирәк, ни уйлаганын туп-туры ярды да салды.

— Синең ул хатын белән ник бәйләнгәнеңне белмиләр дисеңме әллә? Һе! Син генә башлы, бүтәннәр көйгән кашлы, ә?! Чын мәхәббәт, чын яратумы? Тузга язмаганны! Хатыннар белән эш җиңелрәк дип... Сөйрәр әле ул сине сазлыкка!..

Ачу ташының шартлап кызуына чыдый алмыйча, Зөбәйдә әтисе алдында фикерен артык шәрәләндерүен дә сизми калды. Хатасын төшенүгә, шып туктады һәм кискен хәрәкәтләнеп, өстәл яныннан торып укн китте. Илфат аның сүзләренә дикъкать итмәгән кыяфәттә калды. Хариска исә катгый таләбен куйды: «Улым, синең кайгың хатыннар тирәсендә чуалуда булмасын! Унынчыны яхшы бетерү турында уйларга кирәк. Аннары солдат хезмәтең көтә. Мине ике сөйләтмә!» — диде.

Харис апасына ныклап ачулы иде, әрепләшүнең килешкән эш түгелен белә торып, тел тешләп калмаска җыенды.

— Апага да әйтер идең, әти, бөтенләй белмәгән кеше турында начар уйларга ярамыйдыр ич. Апа Машаны белми бит, гайбәт куертырга дигәндә, авызы көйләп куйган...

— Җитте. Бәхәсләшмибез.— Илфат бу хакта сүзне шунда өзде. Рәмзия ак та, кара да димәде. Дөньяның чәчәген дә, чәнечкесен дә күргән кеше буларак, ул Харисның яшьлек аумакайлыгы белән балалы хатын янында болгануын һич тә хуплый алмый иде, билгеле. Шулай да егет күңеленә шырпы булып кадалырлык сүз әйтүдән тыелды, сүзләрен Харисның дөрес аңламавыннан сакланды. Туган әнисе түгел бит. Үгинең сүзе үзәккә үтә, үтне сыта, дигәннәр. Алны-артны карабрак эш иткән хәерлерәк.

Харис та бу хәлендә әтисен аз гына да борчырга ярамаганлыкны аңлый, дөньяда иң якын кешесе бит ул аның. Өйдә булышырга, күз алдында булу кирәк. Ләкин, ни чаклы тырышмасын, бүген алай итә алмый. Машага биргән вәгъдәсе бар, кичкә әйләнеп киләм диде. Берәү дә теленнән тартып, көчләп әйттермәде, үзе сүз куйды. Таш яуса да бармый калырга ярамый иде. Һәм ул кояш баер алдыннан мотоциклының стартер педаленә басты, рульне Ташбуа тарафына борды.

Маша аны тагын хәзерләнеп көткән иде. Бәйрәмне дәвам иттеләр. Спорт белән шөгыльләнеп, режим сакларга күнеккән егеткә шәрабның бер-ике рюмкасы да тәэсир итми калмады. Аның бәйнә-бәйнә итеп барысын Машага сөйлисе килә, әмма кесәне әйләндереп кагудан да сагая иде. Маша: «Әй, балакай! Әтиең каршында калтырап торасыңмы? Апаңнан котың алындымы? Шулай икән, буталма әле минем аяк астында, авызыңнан сабый сарысы китмәгән килеш! Дүрт ягың кыйбла!» — дип җибәрсә, асылын да үл, әкәмәт.

Харис өйдә булган сөйләшүне Машага чишмәскә карар кылды. Маша барыбер сизенде.

— Битәрләделәрме үзеңне? Коры себерке белән мунча чабындырдылармы? — дип сорамый калмады.

— Булды бераз. Өйдә кунмаган өчен почет грамотасы бирсеннәрме әллә? — Шушы җавап белән котылуны Харис иң кулай вариантка санады. Барысы әйтелде дә, бер нәрсә дә әйтелмәде дә. Мескенләнеп, кыерсытылган бәндә булып, фаҗига ясап утырасы калмады. Җанына дулкын булып бәреп кергән җиңеллек теленә дә күчте. Мария ни әйтер дию булдымы икән:

— Өйләнешик кенәме соң әллә, Машенька? Гайбәте дә тынар иде,— диде. Шул ук мизгелдә куркып та калды. Нәрсә дияр бу чибәр хатын?!

Маша колбаса кадап авызына китергән чәнечкесен кире куйды.

— Син нәрсә, егеткәй? Йөз грамм винодан төш күрә башладыңмы әллә? — дип гаҗәпсенде. Ачуланмый иде ул болай, сүзе генә төрткеле килеп чыкты.

— Ник? Дөньяда юк эшмени? Яратканымны беләсең...— Машаның кире җавап бирәсен чамалагач, остарырга була иде инде.— Үзең дә ярата-сыңдыр ич...

Мария уен-көлкене читкә куеп, житди сөйләшүне кирәк тапты.

— Дөньяда һәр эшнең үз вакыты бар. Яратам дип элмәккә керүчеләр минем кебек төп башына утырып калалар икән бит. Укуыңны бетер, армиядә булып кайт, шуннан соң сөйләшербез. Ул чагында да бер тормоз булачак әле.

— Аныcы нәрсә тагын?

— Мин синнән өч яшькә өлкән, Харис.

— Ерунда!

— Син моның ерунда түгеллеген соңрак аңлаячаксың әле.

— Ма-ша! — Харис үрсәләнеп чыкты.— Юкны сөйләмә. Мондый гына яшь аермасы безгә барьер була алмый. Шунысы гына: мин армиядән кайткачы син яңадан кияүгә чыгасың инде.

Мария көлү аралаш ымансулап куйды.

— Чыкканына үкенеп бетә алмаганны күреп торасың...

Тиз генә әйләнеп кайтырга ниятләгән иде Харис. Барып чыкмады. Ул Гөл-Төркемгә кайтып кергәндә, төн уртасы җиткән иде инде. Өйләренә якынлашкач, мотоциклын сүндерде дә җитәкләп алып китте. Йортка мотор шаулатып керәсе килми иде. Гаражны да булдыра алганча тыныч кына ачты, андагы лампочканы да кабызып тормады. Машинасын урынына куйды да, гараж ишеген йозаклап, болдырга килеп утырды. Үткән төнне дә йокламый кичеп, янә дә төн уртасын җиткезү аны тәмам талчыктырган иде. Башы мендәргә тисә, шундук изрәп йокыга талыр төсле тоелды аңа.

Чолан ишеген сак кына шакыды. Ишетмәделәр бугай. Беравык көткәч кабат шакып карады. Дөбердәтергә кыймый иде. Әтисе йоклап киткән булса, уятырга ярамый бит инде. Йокысын бүлдерсәң, күзен түшәмгә текәп тик ятачак. Рәтле-чутлы йоклый алмадымы, көне буе ыңгыр-шыңгыр йөрисен көт тә тор. Нервылары ял итмәгән кешедә нинди кәеф булсын!

Ишекне Рәмзия апасы ачты. Алар Зөбәйдәләрдән кайтып, моннан сәгать ярым чамасы элек йокларга ятканнар иде. Әтисе уянмады ахры. Берүк шулай гына була күрсен.

— Әтиеңнең кәефе әйбәт түгел,— диде Рәмзия апасы.— Иртүк районнан врач чакыртырбыз...

Харис Рәмзия янында да озак тормаска, тоткарланмаска тырышты, бүлмәсенә кереп китте. «Ярамый! Вино исен сизәчәк. Сизсәләр, икесе бергә тагын да яманрак борчыла башлаячаклар».

Урын салып яткач, мә сиңа, йокы алмый аптыратты. Йөзгә кадәр санап карады Харис, барып чыкмады. Меңгә тикле санап бакты, юкка гына булды, күзләре шардай ачык иде. Күңелгә берсеннән-берсе шөкәтсез уйлар килә, тузга язмаган фикерләр калкып чыга, барысы бергә буталышып бетә. Қойрык чәнчеп чапкан кырыкмыш тай сыман йөрим бит дип, үзен гаепләде ул, ниһаять. Ә зәңгәр күзле, озын керфекле, алтын чәчле Машенька күз алдыннан китмәде...

Кырга тартыла күңел

Юеш-елак елдан гажиз булган көннәр тәэсире тоныкланырга да өлгермәде, кайнар җилләр сиксән беренче елга коточкыч корылык китерде. Апрель азагыннан алып йөз көн буе бер тамчы да яңгыр төшмәсен әле! Табигать мең тугыз йөз егерме беренче елдагы афәттән дә уздырып җибәрде.

Игенче май яңгырларына өметләнгән иде, алданды. Июньдә явым булмый калмас, сабан туе көнне яңгырсыз ел бик сирәк ул, дип тә ялгышты. Июль дә яндыргыч сулыш кына өрде. Август башы да. Язы, җәй башы алай ук котны алмаган иде. Матур көннәре истә. Сиксәненченең көзеннән калган дым кодрәт биреп торгандыр, бермәл халык уфтанмый гына йөрде. Сандугачы да сайрап торды, күкесе дә кычкырды. Тирә-юнь туйга киенгән кәләш иде. Шау чәчәк диңгезе күз камаштырырлык булды. Яшеллек хакимлек итте. Игеннәр кояшка үрелде, куе кучкылланып үсеп китәргә дәртләнделәр.

Аннары китте! Көйдерепме көйдерә! Эсселек шул дәрәҗәгә җитә, сулар һава калмый, тын кысыла, елга ярындагы комга күкәй күмсәң, күкәй пешә. Яфракка яфрак орынса да, очкын чәчрәп, янгын чыгар төсле. Чишмәләр кибә, Зөя күзгә күренеп саега...

Быел сабан туен да яңгыр куып таратмады. Моңа берәү дә рәнҗемәячәк, чиләкләп орса да мәйдан уртасында басып торачаклар иде югыйсә.

Сабан туй дигәннән, Илфат бәйрәмгә Женяны бик көткән иде, кайталмады. Хат язып җибәргән. «Студентка кызым кияүгә чыга. Ике якта да туйлап йөргән чагыбыз. Хәзерге заман туйларын син беләсең инде, Илфат, зурдан кубабыз бит. Безнең парлашкан чаклар түгел... Гөлтөркемгә уңыш бәйрәменә кайтабыз»,— дигән. Насыйп булса диген, Евгений Иванович! Булыр микән быел уңыш бәйрәмнәре? Бу — бердән. Тагын килеп, берәр мәшәкать килеп чыкмасмы тагын? Тормыш безнең өчен расписаниене бер дә иренмичә үзе төзи. Бик үзсүзле диспетчер шул Тормыш дигәнең! Әмере катгый, боерыгы — закон.

Хәбиб абзый Гайсиннан да хат килде. Аның хаты туй шатлыклары белән түгел, янә саулыгы китү хәбәре белән тулы. Тагын больницага яткан. Яше дә байтак шул инде. Хәер, чынбарлыкка, тормыш диалектикасына аек карарлык акылы да, батырлыгы да бар аның. «Минем яшьтә зур прогресс көтү — иллюзия корып юану булыр иде», дигән...

Илфат тирән, тәмле йокы белән йоклады да, иртәнге өч булгач ук торды. Кояш та чыкмаган иде әле, әмма аның нур-чапкыннары офыктан сәлам бирәләр иде инде. Көн туар яктагы сыек кына кысыр болытлар алсуга манылды. Алар талгын җилдә теләр-теләмәс кенә кузгалган вак дулкынлы су өстен хәтерләтәләр. Кызыл су өсте... Бу чагыштыру үзе үк дәһшәтле икән, әй! Юк, юк! Алай булмасын әле! Яңа көннең безгә алсу чәчәк бәйләме сузуы дип юрыйк.

Рәмзия бик тәмләп йоклый әле. Ул да көнозын эштә. Тәжрибәле тегүчесе берәү генә. Өйрәнчек кызлар белән әвәрә килә.

Илфат бүген Ташбуа станциясенә барачак. Варис та шуңа атап Казаннан кайтты. «Колос» комбайны көтә аларны тимер юл станциясендә. Варис белән Харис эшлисе машина. Аңа кадәр механизаторлар җыелышында утырмакчы. Колхозның машина дворында.

Ә хәзер ул санаторий методистлары өйрәткәнчә иртәнге гимнастикасын ясады, верандага Харис көйләп биргән «Штурвал»ны әйләндерде, бер башын стенадагы ыргакка элэктереп куйган ике генә пружиналы эспандрны уң кулы белән үзенә тарткалады, бер килограммлы гантельны учына кысып, хәрәкәтләр ясады.

Һәр көнне берничә мәртәбә кабатлый ул мондый күнегүләрне. Ялгызы гына да, Рәмзия булышлыгы белән дә җилкә мускулларына, беләккә, кул чугына һәм бармакларга тынгы бирми. Тоеп тора: хәрәкәттә — бәрәкәт!

Иртәнге аштан соң алар өйдән бергә чыктылар. Соң кайтып яткан Варис белән Харисны да уятып киттеләр. Рәмзия мастерскойга юнәлде. Илфат машина паркына атлады.

Кояш иртүк гайрәтләнергә исәпләсә дә, сулар һава бар иде әле. Куак яфраклары да, әнә, төнге салкынчада хәл алганнар һәм әле көчәергә өлгермәгән жилдә лепер-лепер серләшәләр. Койма буйларындагы үләннәр дә кыяк турайтканнар, төн аларга да сихәт китергән.

Авыл чите. Машиналар паркы. Баганаларын кирпечтән өеп, тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган зур мәйдан. Тракторлар, комбайннар өчен биек әвеслекләр. Тагылма машиналар рәте. Анда — сабаннар, чәчкечләр, дискалы тырмалар, лущильниклар. Автомашиналар өчен гаражлар. Складлар. Моннан ике ел элек кенә төзелгән зур ремонт мастерское. Авыл ягындагы кушкапкадан кергәч, уң кулда түбәсе шифер белән ябылган ике катлы кирпеч бина. Икенче этажда баш инженер кабинеты, механик һәм диспетчерлык бүлмәләре. Анда рация эшләп тора. Аста кызыл почмак һәм ашханә. Кызыл почмакны агитаторлар тырышып бизәгәннәр. Монда лозунглар да, плакатлар да житәрлек, иминлек техникасын төгәл сакларга өндәгән плакатларны аслыөсле ябыштырганнар. Түрдә сул почмакта телевизор, аның янәшәсендә радиоалгыч. Стеналар буена артлы урындыклар тезелгән. Иркен бүлмәнең уртасындагы яшел постау ябулы озын өстәлгә техника һәм механизация буенча брошюралар куйганнар. Түрнең уң почмагындагы шкафта китаплар...

Илфат бу дворның (ул әле дә булса аны «парк» дип атарга күнегә алмый иде) теге еллардагы, МТСлар бетерелеп, колхозга иске тракторлар алып кайткан чактагы торышын һич онытмый. Хәзер ул завод цехыдай жиһазланган. Электр кергән, су үткәрелгән, газ белән эретеп ябыштыру аппаратлары көйләнгән, шиннарны тутыру, радиаторларны өрдерү өчен баллоннарда кысылган һава бар. Душ бүлмәләренә кадәр эшләп тора. Ә теге елны, мең тугыз йөз илле сигездә, кары тапталып, галәмәт зур ямаулыклар кебек мазут таплары белән чуарланып беткән бер бушлык иде. Механизаторларга йөгереп кереп ышыкланырлык, аягын-кулын жылытып чыгарлык урын да хыял иде ләбаса. Кайнар аш, куе чәй дигәнең жәннәт сые, фантазия иде. Колхозныкы булып әверелгән техникага беренче ремонтны ачык һавада (баш өстендә түбә — күк гөмбәзе), карга чумып дигәндәй ясадылар. Монысы ни нәрсә икәнен ул елларда үзе шул ремонтта катнашкан зат кына белә. Куырып ала торган суыкта, бәгырьләргә үтә торган жилдә металл белән эш итү — ялан кул килеш ялгыш кына тимергә тотынсаң, бармак һәм уч итенең умырылып калуы дигән сүз; май поддонын алу, моторны рамга беркеткән болтларны, гайкаларны бору өчен, карга жәйгән юка брезентка аркан белән ятып, желегенә кадәр суык үтү, тешең-тешкә тими дер-дер калтырый башлау дигәнең дә шул; чирек сәгать-егерме минут саен бер читтә сүнми янган учак янына йөгереп, бармакларыңны ялкынга сузу, тагын беравык гайка ачкычы һәм чүкеч тотарлык хәлгә килим дип изалану кадәре дә шул. Ул чаклар искә төшкәч, Илфатның аркасыннан хәзер дә кырмыскалар йөгерешә башлый, беләкләренә, ботларына «каз тәне» чыга.

Ремонтчыларның ярдәмчесе булып, күтәрешеп-төшерешеп, тегене илтеп, моны китереп йөргән Жәләлетдин генә боекмый иде ул чакта. Ни хикмәттер, суыктан сыгыла белмәде ул.

— Ничек туңмыйсың син, Жәләй?— диләр иде аңа, һич шаяртмыйча.— Сине хода үзгә балчыктан әвәләгән мәллә?

— Ат ите ашаганга туңмыйм!— Дивана саргайган тешләрен күрсәтеп елмая да, шулай жавап кайтара. Чыннан да, Жәләлетдин елның-елында ат симертә, ат суйдыра янсә кемгә булса да өлешкә керә иде. Кемнән өйрәнеп калган булгандыр, ат итенә бик хирес.

— Аның жылысы артыграк мени?— диләр тракторчылар.

— Бабаңнан кайтып сора, әйтер.

— Безгә дә алып кил әле син алайса ат ите.

— Бер килосына ике кило сыер ите, яме.— Җәләлетдин шартны куя белә. Алдатырга исәбе юк.

— Ә-әй, синең белән сөйләшсәң!..— Механизаторлар кул селтәп, учак яныннан кузгалалар, көчләп алып барган кешеләр төсле, салкын тимер чүмәлә булып утырган тракторлары астына үрмәлиләр.

Зәмһәрир суыкта айлар буе күшегеп, күгәреп, учак янында телогрейкаларны, киез итекләрне көйдерә-көйдерә әвәрәләнеп ремонтны төгәлләгәч, шатлыкның очы-кырые булмый торган иде. Сиксәненче еллар космонавты гына, галәм киңлеген урап кайткач, шулай шатлана алгандыр...

Паркка килеп кергәч, Илфат гаскәр кебек тезелешеп торган комбайннарга күз салды. Ничә еллар буена үзе йөрткән СК комбайны янында аръякның Зариф малае Фатих йөри. Ул Варистан да өч яшькә яшьрәк әле. Быел язын армиядән кайтты. Малай чактан комбайнда ярдәмче булды, солдатка китәр алдыннан мөстәкыйль эшләде. Тырыш егет — шапырынмый-һаваланмый, теленә салышмый, тыныч кына үз эшен жиген-жиккә китереп башкара, күп кенә тәтелдек яшьтәшләрен узып та китә; менә Илфат комбайнын аңа биргәннәр. Яңа булмаса да, нык әле ул машина. Илфат кыр корабын карап йөртә белә иде, трактторны да, комбайнны да талкыганы булмады, комсызланып гектарлар саны артыннан куам дип, техниканың җелеген суырмады. Фатих та СКда кинәнеп урдырыр, Илфатка рәнҗемәс...

Маннуровка «Колос»ны берничә елдан бирле вәгъдә итәләр иде инде. Ниһаять, кайткан да әнә. Тик... бу урак Илфатсыз гына узар шул инде. Язгы эшләрне дә аңардан башка гына түгәрәкләп куйганнар иде. Дөнья шулай ул, меңнәр — ил тоткасы, берәү булмаганыннан һич ни терәлеп калмый. Шул берәүнең үзенә генә күркәм сабырлыклар насыйп булсын. Адашып калган кыр казыдай каңгырып утырмас өчен килеп бара бит бу кеше машина паркына...

Капка буенда Илфат токарь егетләрне очратты.

— Кәрим килмәдеме әле, егетләр? Саулармы?

— Исәнмесез, Илфат абый? Килүме? Кәрим абый инженер бүлмәсендә.

— Башладылар дамы әллә?

— Юк, болай гәпләшәләр. Җыелыш тышта була.

Шулай икән шул. Ике катлы кирпеч бина янына кызыл почмактан урындыклар чыгарганнар, озын-озын эскәмияләр дә куйганнар. Халык байтак, өч бригададан да килгәннәр.

Илфат, алар янына килеп житү белән, җанында рәхәтлек тойгысы уянды. Күңелен һаман кымыржытып торган тойгы — колхоз тормышыннан аерылып тору тойгысы кимеп калды төсле. Сау-сәламәт чагында да жыелыш-киңәшмәләрдә беренче рәткә утырырга ярата иде, бу юлы да алга ук барып утырды. Күрешәсе күрешеп, сорашасы кеше хәл сорашып бетергән иде инде. Әхмәт Хәйретдине дә килеп күреште. Сер бирмәскә тырыша, шаярган була, мәзәк сөйләп маташа. Шулай да Илфат аны кызганып куйды. Бүтән еллардагыча штурвалда була алмавына үкенүе әллә каян сизелеп тора. Ләкин бит берәү дә гаепле түгел, эзләп тапкан җәзасы.

Диспетчер бүлмәсеннән Кәрим Вәлиев чыкты. Аның артыннан токарь егетләр кечкенә өстәл һәм урындык күтәреп килделәр. Президиум да, трибуна да шул. Председатель куенынан алып өстәлгә урталай бөкләнгән дәфтәр һәм ниндидер кәгазьләр куйды.

— Башлыйбыз, иптәшләр!— Кәрим механизаторларны, ремонтчыларны, аларның булышчыларын күздән кичерде.— Барыбыз да жыелып беттек бугай. Баш инженер Казанда, бик мөһим эш белән йөри,

тагын бер «Колос» тәтемәсме, дибез. Аның өлешенә тигән сүзне үзем әйтермен. Бүген урып-җыюга хәзерлекнең торышы турында сөйләшербез, быел нинди хуплау чаралары билгеләнгәнен аңлашырбыз, урак өстенә төзелгән звеноларны күздән кичереп, барлап чыгарбыз. Звено членнары, бергәләшеп, ял-койрыкларны җыештырырга тиеш булалар, бер-бөрсенә булышырга... Кайчак машинадагы вак-төякне берәүнең генә күреп бетермәве дә ихтимал, икенче механизатор аңа ярдәм кулы суза ала. Уракка төшәргә күп калмады. Елның нинди икәнен сезгә сөйләп торасы юк. Җәһәннәм кызуы. Уңышны көнләп түгел, сәгатьләп урлый торган кызу. Шуннан аңлашылса кирәк, үстерә алган кадәр уңышны сыңар бөртеген дә югалтмыйча...— Кәрим Вәлиев аңлы рәвештә тукталыш ясады һәм басым белән янә кабатлады,— бер бөртеген дә югалтмыйча җыеп алырга бурычлыбыз. Иң кыска вакыт эчендә...

Маннуровлар агрегатына килеп житкәч, Кәрим Хәлимович Илфатка күз ташлады. Гүя ул: «Хәзергә мин сиңең исемеңне атый алмыйм, үпкәләмә!» — ди иде.

— Агалы-энеле Маннуровлар. Варис белән Харис... Харис — ярдәмче. Әтиләре дәваланган чорда яңа «Колос»та алар урдырачак. Ә «Колос» ветераныбыз, героебызның үз исемендә кала...

Соңгы җөмләсен әйтмәсә, Илфатның кәефе кырыласы икән. Кәримдә мәктәптә эшләгән елларыннан ук килә торган дипломатлык бар шул, кешеләр күңелен таба белә.

— Үзем дә күз-колак булмый калмам әле, Кәрим энем.— Илфатның кырга, диңгездәй чайкалып утырган иген басуларына тартылган күңеле дәшми утырырга җай калдырмады, ашкынды, ярсынды.— Үзем дә онытып бетермәм малайларны...

Кәрим, рәхмәт яхшы сүзеңә, ләкин артыгын каударланып төшмә әле син, дигән кебек караш ташлады да:

— Беренче чиратта ныгытып савыгуың кирәк безгә, Илфат абый,— диде.— Типсә тимер өзәрлек хәлгә кайтуың кирәк. Киләчәк елларда синнән бик күпне көтәбез...

Авырткан җирләр турында сүз кузгалуга, җыелыштагылар дәррәү җанланып киттеләр. Үзе көйләүче-төзәтүче булып кына эшлисе булса да, Әхмәт Хәйретдине, узган еллардагы тәжрибәсеннән чыгып, комбайннарга ягулык тутырылган өстәмә баклар кую турында сөйләп алды. «Әбзәтельне кирәк!— Ул кулын селтәп, һаваны тураклагандай итте.— Заправкага туктый-туктый әллә ни гомер заяга китә...»

Аның фикеренә күпләр кушылды. Кәрим үзе дә хуплады. Тик менә баклар булдыру кадәресен ашыктырырга кирәк иде.

— Кайсыдыр звенода гел автомашиналар гына, кайберләрендә арба таккан тракторлар. Алай батмас!— диючеләр дә табылды.— Үги балалар юк бездә... Транспортны тигез бүлергә кирәк. Берәүләр рекорд куйганны бүтәннәр авыз ачып карап торырлык булмасын. Хәйран-тамаша түгел!

— Ходовой каешларны басуга кузгалганда ук запаска алып чыгарга кирәк, җәмәгать. Кызып эшләгәндә, ремень өзелеп, машина паркына, складка йөгерерлек булмасын. Рас һәр минут кадерле дибез икән, алдан ук барысын уйлап куярга тиешле...

Председатель механизаторларның дәгъваларын тыңлап кына калмады, акыллы таләпләрне, колакка ятардай эшлекле тәкъдимнәрне блокнотына терки барды һәм азактан әйтте:

— Якындагы ике-өч көнгә сораганнарыгызның барысын да бирербез, иптәшләр. Давайте, аякларны шәплэп киеник, жиңнәрне терсәктән югары сызганыйк. Быелгы ашлык аеруча кадерле,— диде.

Машина паркыннан әйләнеп кайтканда, Илфат шактый талчыккан иде, тик ул моны улларына бөртек тә сиздермәскә җыенды. Җыелыш хәлләрен сөйләгән булды, Маннуровлар экипажына төшәчәк эшләрнең

үтә киреңке буласын кисәтеп куйды. Ашыкмый гына, шартын китереп кенә чәйләсәм, егәр керми калмас, дип ышанды ул. Шулай да сырхаудан айнып житмәгән кешенең хәлен теле сөйләми, йөзе, чырае сөйли. Этисенең авырыксынуын Варис шундук төшенде. Җайлап кына:

— Әткәй, әллә син Ташбуага ук барып йөрмисеңме? Документларны миңа бирәсең дә... Безне машиналар паркында каршыларсың,— дип карады. Аның сүзләре Илфатка тискәре тәэсир генә ясады. Әйтмәсә, яхшырак буласы икән:

— Син, улым, булмас нәрсә белән кыстама мине, яме. Гомеремдә үзем эшләячәк машинаны үзем барып алмый калганым юк иде әле. Бу юлы кайтарып биргәнне көтеп утырыймммы? Юк, яшәргә, эшләргә әле минем исәп. Әйе, әйе, исәп бик бөтен...— Канына тоз салма икән син аның, аз сүзле дигәнебез дә пулеметтан сиптерә башлый.— Кырга чыгудан да шәбрәк дару табалмассың син миңа. Кайтарып биргәнне көтим, имеш. Нинди механизатор булам мин аннан ары?!— Йорт башы моны шактый кырыс әйтте. Ризасызлыгы коңгырт күзләренә бәреп чыкты. Канәгатьсезләнсә, ул бер дә кирәкмәгәнгә авыз-борын тирәләрен сыпыргалый, бармакларын тырпайтып, кара чәчләрен аралый-тарый башлый. Кара тут йөзенә күләгә төшә.

— Улларың алып кайтып биргәч тә, бик почетлы инде ул, әткәй.— Варис монысын сүзеннән акрынлап чигенү хакына гына әйтте. Этисенең үзенекен итәсен белә иде ул.

— Өчебез дә барабыз. Син, Харис улым, бар «Москвич»ны кара. Көйләп куй. Варис комбайнны алып кайта, без икәү — аның артыннан...

Көн кыздыра. Юлда тузан юрганы. «Москвич» жиленнән генә дә ярты чакрымга сузылып «койрык» кала. «Комбайннардан — ындыр табакларына, аннан ашлык кабул итү пунктына бөртек ташый башлагач, район юлларында ни булыр?» — дип уйлап барды Илфат. Шул ук вакытта күз кырые белән генә Варисның машина йөртүен күзәтте. Улы «Москвич»ны гажәп тә оста алып бара. Гомерен рульдә уздырган таксист диярсең. Артист прәме... Харис арткы утыргычта тын гына бара. Имтиханнар пешекләдеме, Машасы сагындырып сагышка саламы, суырылып калды малай. Кадаклаган кебек өйдә бу арада. Чираттагы имтиханын биреп кайта да, янә китапка кадала. Этисе белән Рәмзия апасының күзләренә генә карап тора. Аттестат алыр көне житте. Аттестат белән бергә, өченче класслы тракторчы таныклыгы. Руслар әйтмешли, кусок хлеба. Мактап бетергесез эш. Комбайнны ул басуда эшләп өйрәнде. Кулында — һөнәрең, капчыгында икмәгең. Икмәк булса, бүтәне булмый калмый аның...

«Интернационал» кырларыннан Агачбашы басуларын аерып торган кыр ышыклау урманына житәрәк, Илфат Вариска машинаны сулга тотарга кушты. Анда, урман тасмасы буйлап, тар полоса итеп нибары унбиш гектарда яңа сорт уҗым бодае өлгереп килә. Тәжрибә өчен, сынап карыйк дип чәчеп калдырганнар иде. Илфат чәчте. Ул сортны мактыйлар. Туфрактан үзләштергән жимнең күбрәген сабакка түгел, бөртеккә бирә, сабагында нык тора, жил-яңгырда егылмый икән. Аксымга, протеинга бай, диләр. Авыруларга каршы торучанлыгы нык. Монысы агулы химикатлар кулланусыз киметә төшүе белән бик кулай. Кошлар, файдалы бөҗәкләр азрак кырыла. Уңышны мул бирүе чәчү мәйданнарын арттырмыйча күбрәк ашлык жыеп алуга булыша. Сөрү жирләре арта бармый, алар чиксез түгел. Киресенчә, цивилизация гасыры ризыкка иген игәр мәйданнарда әледән-әле төзелешләр калкыта.

Уҗым бодае участогына килеп житкәч, өчесе дә машинадан чыктылар. Басу карап туймаслык иде. Бодай куе, көр булып буй тарткан, яшеллене саргылт төс алыштырып бара. Башаклар Илфат бармагыдай. Алар әлегә дугаланып, бөгелеп төшәргә өлгермәгәннәр, шулай да очла-

ры җиргә карый инде. Явымлы елларда, урман буенча кышын кар күп ятканга, монда иген чери иде. Быел, баксана, дым муллыгы могҗиза тудырып килә, кана!

— Кем генә төп-төгәл күрәзәлек итсен соң,— дип ачынды Илфат,— тамуг кызулары ябырыласын белсәк, бу бодайны монда йөз илле гектар чәчкән булыр идек. Бирәчәк бу участок уңышны, бирәчәк...

Базалардан, берләшмә складларыннан, бигрәк тә «Сельхозтехника»га бәйләнгән урыннардан берәр нәрсә аласы булдымы, тоткарлык чыгасын күңелеңә киртләп куй. Комбайн мәсьәләсендә дә шулай булды. Гөл-Төркем белән телефоннан сөйләштеләр, «Сельхозтехника»ның район бүлекчәсенә барып килделәр. Документлар кирәгенчә рәсмиләштереп беткәч, кояшта кызып, креолин исе аңкытучы шпаллардан эрелеваклы титаклап, станция пакгаузлары буйлап «Колос» торган платформага юнәлделәр. Платформаны тупикка куйганнар иде.

Әфлисун төсендәге «Колос» Маннуровларның өчесен дә сихерләгәндәй итте. Башын артка чөеп, беравык карап торгач, Харисның сокланулы теленә бәреп чыкты:

— Вәт баһадир, ә?! Күз нурыңны алырлык, ә?!— Аннары әтисенә карады.— Галәмәт шәп бит, әткәй, ә?

Илфат эндәшмәде. Энесенә җавап биргән кебек, Варис дәвам итте. Ул да соклануын яшерә алмый иде.

— Моның белән басуны бер уравы бер гомер, әткәй! Махина! Моңа кадәр «Колос»ны да, «Нива»ны, «Сибиряк»ны да күргәннәре бар егетләрнең. Мәгәр платформа буендагы сокланулың үз төсмерләре, үз нюанслары бар иде. Әлеге куәтле комбайнда агалы-энеле Маннуровлар эшлисе!

Әтиләренең бу минутта сөйләшәсе килми иде. Сүзсез гашыйк иде Илфат бу чакта. Үзенә атап билгеләнгән комбайнга механизатор-ветеран йөрәгендә кабатланмас якынлык уянды. Хуҗаларча якынлык.

Юлда имин барсын дип, комбайнны платформага урдыргычыннан аерып урнаштырганнар. Ургыч, тезем җыйдыргыч, запас частьлар янәшәсендә. Аларны алып кайту өчен машиналар чакыртмый булмый. Беренче генә кайтарулары түгел, монысын Кәрим белән сөйләшеп килгәннәр иде.

Варис станциянең йөкләр җибәрү конторасына телефоннан хәбәрләшергә китте. Илфат машинаны тизрәк җиргә төшерергә, нитробуяу һәм утыргычлардан аңкып торган дермантин исе белән тулган кабинаны ачып җилләндерергә һәм кереп утырырга, приборларның кара циферблатларына күз салырга, моторны эшләтеп карарга ашкына иде. Бу машинадагы шартлар, уңайлыклар — тракторга тагылмалы «Коммунар»лар, «Сталинец»лар белән, хәтта үзйөрешле СКлар белән чагыштырганда да оҗмах.

Гөл-Төркемнән машиналар килгәнче, һәммәсен платформадан бушатып аларга төягәнче вакыт байтак үтте. Төш авышты. Обкатка үтмәгән моторга көч килмәсен өчен, Илфат Вариска комбайнны акрын гына алып кайтырга кушты. Үзләре райүзәк ресторанына кереп, тамак ялгап чыгарга булдылар. Рульгә Харис утырды.

— Авылга җитәрәк куып тотабыз без сине,— диде әтисе Вариска.— Кума, кара аны!

Даруларын кабып, ашап-эчеп алу тернәкләндереп җибәрдеме, «Колос»ны алып кайту сөенече җилкендердеме, Илфатның кәефе күз тимәсен диярлек иде. Комбайнны авылга чакрым чамасы калгач куып җиттеләр. Узмадылар, «Колос» җаена гына кайттылар.

— Почетлы эскорт!— дип көлде Харис.

— Булса да җирендә...

Илфат шулай дип кенә куйды. Заманча ясалган машиналарның механизатор өчен җайлылыклары турында уйлый иде: «Баштан ук ме-

нә шундыйларда эшләргә туры килгән булса, сәламәтлек болай ук какшамас иде дә соң, һәр нәрсәнең үз вакыты. Ничек кенә, нинди шартларда гына азапланмадык. МТСлар чорын ал. Бигрәк тә сугыштан соң... Заманы шундый иде. Ничарадан бичара ертылдык. Шулай да шыңшу дөрес түгел. Тирәннән уйласаң, тырышлыклар юкка булмады, заяга китмәде. Бүгенге рәхәтләр өчен нигез бүрәнә булып ятты ул көннәрдәге көчәнүләр...»

Шул чак аның күңелендә «икенче» Илфат пәйда булды. Анысы бүтәнчәрәк фикер йөртмәкче һәм «беренче»сенә шактый төртмә сорау куя: «Шул дәвердә көчәнүләреңә кемнең исе китә? Яшьләр аңлый дип беләсеңме? Ике ятып бер төшләреңә дә керми!»

«Беренче» Илфат нык, кире каккысыз итеп җавап бирә. «Исе китә, бик китә. Ватан белә кадерен үзенең тырыш улларының. Түшеңдә Алтын Йолдызың. Аны аклыйсың бар әле, бик зур аванс та бит ул. Яшьләр дә аңларлар. Акыллары бөтен, камил. Тормыш чын-чынлап бөтереп алмаганнары гына әйле-шәйле буталалар. Җигелсеннәр әле тормыш арбасына, чикләвекнең кайсы куакта икәнен атнасы-ае белән төшенәчәкләр. Хезмәт төзәтә ул. Аңардан да яхшы докторны эзлисе дә юк. Ә син үз эшеңне бел. Башкарган эш кемнең кем икәнен үзе күрсәтә. Һәркемне үз урынына куя. Менә шунда яшьләрне урыннарына куярга син дә булыш, үз тәнең җылысына куанып, читтә торма. Сине дә кемдер җитәкләп олы юлга чыгарды бит. Уйла, кыска хәтерле булма!»

Машиналар паркында аларны председатель, партком секретаре, әле генә Казаннан кайтып төшкән баш инженер, ремонт мастерскоендагы егетләр каршылады. «Колос» парк капкасыннан килеп кергәндә, бөтенесенең чырае ай-кояштай балкый иде...

Рәмзия дә аларны бик көләч каршылады.

— Карагызчы боларны, өчесе бер тиң елмаешып кайтып киләләр, бәхет кошы тотканнармыни!— диде ул, уртак куанычны үзенеке дә итеп.— «Колос» тикле «Колос» кайтты бит! Барып кararга кирәк. Ә хәзер юл тузаннарыгызны кагыгыз, юыныгыз да әбәдкә. Көттердегез болай да...

— Мондагы исәп анда ярамый бит, Рәмзия.— Илфат үзләрен капка төбенә чыгып каршылаудан бик канәгать иде. Болай каршы алуларны онытып бара иде инде ул.— Ярый, очлап кайттык.

Машинаны гаражга куйгач, егетләр чишенеп ташлап, пошкырынапошкырына юындылар, салкын су рәхәтен тоеп кинәнделәр. Илфатны ипләп-җайлап Рәмзия үзе юындырды. Гаилә тулы килеш өстәл янына утырды.

Аштан соң Харис, китапларын күтәреп, бакчадагы беседкага чыгып китте. Анда күләгә, тыныч, һава саф. Бал кортлары уйнаган скрипка моңы астында таныша әле Артур Конан Дойлның мажаралы геройлары белән.

Өлкәннәр дөнья хәлләрен сөйләшә калдылар. Варисның Казанда эшләре бетеп җитмәгән иде әле, төнге поезд белән ул башкалага китәчәк. Әтисе белән, хәзер инде Рәмзия апасы белән дә, җитди сөйләшәсе бар аның. Монысы Ташбуа станциясеннән комбайн алып кайту гына түгел инде. Киңәш-уңашның бүтән төрлерәге. Гомерлеккә дип атлыйсы адым турында.

— Икегез дә бергә чакта зур бер киңәш корасым бар минем,— диде егет, тәвәккәлләп. Кайчан да булса бер авыз ачып әйтәсе иң инде моны. Әйтми котыла торган эш түгел.— Сез моны белеп тә торасыз инде дә, уртага салып, өзеп кенә сөйләшкән булмады. Без Миләүшә белән өйләнешергә булдык. Сезнең ризалыгыгыз кирәк, икегезнең дә. Картлар ничек дигәннәр, хәер-фатихамы? Яхшы теләгегез, рөхсәтегез.

Әти Миләүшәне азмы-күпме белә. Синең күргәнең генә бар, Рәмзия апа. Байтактан дуслар инде без аның белән...

Ачык нәрсәне аңлатып утырудан да читен эш бар микән ул дөньяда? Төшендерми дә булмый.

Көтелгән сүзләр иде болар. Бүген булмаса, иртәгә, иртәгә булмаса берсекөнгә дигәндәй, әйтеләсе сүзләр. Илфат та, Рәмзия дә моны бик табигый кабул иттеләр.

— Алданрак та кузгалган булыр иде бу тема... Варис олыларның үзенә иғътибарлы карашын сизеп, ышанычлырак сөйләп китте.— Вакыты андый булмады, килешмәс кебек санадык. Инде әти савыгып бара, аякка басты, сафка басасына да шик юк. Шуңа күрә бүген кузгатуым... Ни әйтерсез?

Илфат сул кул бармаклары белән яңакларын сыпыргалап алды, уң кул беләген сыйпап төште, аннары бик тыныч кына:

— Монда ике сүзнең булуы мөмкин түгел, улым,— диде.— Өйләнешерсез, туй итәрсез. Безнең эш бәхет теләү, тигез мәхәббәт теләү. Иртә дип әйтер урын юк. Дөрес, бер ел укыйсың бар әле. Турысын әйтим, анысы да өркетми. Армиядә булып кайтасың бар, бу инде башка коймак, Варис. Миләүшәнең көтәренә, әйле-шәйле булмасына ышанасыңдыр, дип уйлыйк.

— Ышанам, әти. Үземә ышанган кебек ышанам.

— Шулай булганда гына гомерлеккә дип кул бирешергә ярый. Соравым шуңа: яшьлектә аерым яшәү бик четрекле хәл ул, Варис. Миләүшә, белгәнем кадәренчә, итагатьле, олыларга ихтирамлы бала күренә. Парлашкач та шулай булса, үзе дә хөрмәт татыр, безнең күңел дә тыныч булыр.

— Миләүшә белән синнән генә калган эш түгел, Варис,— дип Илфат сүзен җөпләде Рәмзия дә.— Тигез гомер итәргә насыйп булсын. Теләкнең иң олысы шул. Тигез мәхәббәт белән. Бер-берегезне санга сугып, киңәшеп, бер-берегезнең акылын тотып. Бер җан булып яшәргә дигәнем.

Мәсьәләнең үзәге хәл кылынгач, гадәттәгечә, кайчан, ничегрәк дигән сораулар баш калкыта һәм алар бөтен бер чылбыр булып тезеләләр. Әлеге сөйләшүдә дә шулай булды.

— Миләүшәнең эшкә Казанда калуын хәл итәр өчен, никахлашуны ашыктырырга кирәгәчәк.— Варисның эшне кызу тоту ягында икәнлеге аңлашылды.

— Өйләнү — түгел сөйләнү дигәнме Тукай бабагыз? Аның артында туй дигән зур эш бар. Аңа хәстәр особый кирәк. Гамил ниләр планлаштыра икән?

Әтисенең бу соравына каршы Варис ачык җавап бирде:

— Мәсьәлә принципта хәл ителгәч, һәммәсен уртага салып сөйләшергә Гамил абый үзе Гөл-Төркемгә кайтачак. Ул миңа конкрет әйтте: «Иң беренче чиратта Илфатның рөхсәтен аласыз. Шуннан соң калган мәсьәләләр хәл кылыныр. Мин синең Миләүшәне соравыңа риза»,— диде. Зәйтүнә апа белән алар уртак фикердә.

— Шулайдыр. Кыз биргәндә ансыз булмый да инде.— Илфат мәзәк кенә әйтеп куйды. Кыз биргәндә талашып, икесе ике фикердә булган ир белән хатынны күз алдына китерә алмый иде бугай.— Без дә уртак фикердә Рәмзия апаң белән. Безнең дә риза-бәхиллекне ишеттең. Хәерле сәгатьтә! Кайтсын Гамил, зыянга булмас. Алай да бер нәрсәне алдан ук кырт кисеп әйтеп куям: туйны ике якта да итәргә уйлаган очракта... анда инде сезнең дусларыгыз, курсташларыгыз бар... Шулай уйлаган очракта да төп туй менә шушы йортта, син туган нигездә булачак. Гамилгә ап-ачык шуны ирештер. Маниуровлар килен төшерә. Варис әбисе-бабасы хозурына йортка керми, атасы йортына хатын алып кайта. Аңлашыламы? Ачыкмы мәсьәлә?

Варис көлеп җибәрде.

— Хәзер инде, әткәй, «йортка керү» дигән төшенчә искергән. Бигрәк тә шәһәр җирендә.

— Минем өчен искергәне юк әле аның...

— Кайсы якта яшәр җай бар, яшьләр шунда тора.

— Кемгә ничектер, белмим. Кеше эшенә тыгыласым юк. Бездә мин әйткәнчә булыр, яме. Өйләнешкәч тә, фатирга чыгасыз. Беренче мәлдән үк үз көнегезне үзегез күрә башлыйсыз. Без кулдан килгәнен булышырбыз. Аңлашыламы?

Варис уйлана калды. Сүз өзелмәсен өчен генә:

— Аңлашыла, нәрсәсе аңлашылмасын?!— диде. Тагын уйланды. Бераздан терәлеп калуының сәбәбе аңлашылды.

— Миләүшә бездә яшәрбез диебрәк тора иде...

— Бик иртә хәл иткән түгелме соң?

— Зәйтүнә апа да шул фикердә.

— Гамил Зәйтүнә апаң сүзеннән чыкмый инде, әйеме? Полковник— өйдә санитар, Зәйтүнә апаң — комиссар. Шулайракмы?— Илфат күңелсез итеп, үзен иректезләп елмайды.

— Алар бик килешеп яшиләр.— Варис әтисенең энәле сүзләрен ошатмавын сиздерде.

— Ирләр йорт башы икәнлекләрен онытkан семьяда, вообще-то, тып-тын була. Ишетелсә дә хатыннар тавышы гына ишетелә. Ә аерым сиңа минем әйтер сүзем шул: өйләнешүегезнең беренче көненнән үк аерым яши башлагыз. Еллар узгач, аягыңа сыер баскач, бу киңәш өчен миңа рәхмәт укырсың. Җылы почмакка мохтаж йөргән шикелле калырга син ятимнәр йортыннан сөрелгән малай түгел.

— Баштарак...

— Юк!— Илфат чабып өзгәндәй кычкырып куйды. Тавышы үзенә дә ят тоелды ахры, җайсызланып, тынычрак сөйләүгә күчте.— Курыкма син икегез генә яшәүдән. Яшьләргә аулак тансык була ул. Миләүшәң дә эшкә өйрәнер, Зәйтүнә апаң әзерләп китергәнне көтеп утырмас, үзең дә житезрәк булырсың; күбрәк булышырсың. Гамиллар да, без дә менә, кунакка барырбыз. Сез дә аларга кунак булып килерсез, монда кайтырсыз, кендек каның тамган нигезгә. Шундый нигезең барын онытма беркайчан да. Ерактагы кояш җылы була, аерым тору сагынышып йөрешергә бик әйбәт.

Варис тагын бер яктан килеп карады.

— Мин армиягә киткәч, Миләүшә барыбер әти-әниләренә кайтып торачак бит инде, әткәй.

Илфат бу кадәренә һич каршы түгел иде.

— Анысы инде, улым, бүтән җыр, бүтән такмаза. Син югында әти-әнисе янында була икән, анысына кул куярга кирәк.

— Да-а-а,— дип сузды Варис.— Тагын БМО сессиясе җыясы була икән әле.

— Нишләп?

— Синең позицияләрне аңлату өчен, әткәй.

— Анысы да кулыңнан килмәсә, Варис улым, бүгенге сүзне башларга да кирәкми иде. Күрәм, өйләнмәс борын тышаулангансың әле. Үз-үзеңне тышаулагансың...

Зал якта тынлык урнашты. Һәркем үз уена баткан иде.

Илфат, артыгын да уйлап алды бугай, хафалана башлады. «Ни дип әле бу малай шул хәтле гипнозланган? Өйләнмәс борын, бала-чагага буялмас борын, булачак хатынының күләгәсеннән үк өркергә тора. Зәйтүнә апасы да женский родтагы аллага әйләнә язган. Әллә соң эшләре, кирәкмәгән бормалар ясап, тирәнгә киткәнме боларның? Шуңа көйрыгы бозга каткан килеш үрсәләнәме бу малай? Тормышны ул

рәвешле башласа, толк чыкмасын бел дә тор. Укасы коелган, энҗесе сибелгән булып чыга андый тормышның... Юк ла, юк! Варис андый егетмени соң инде! Үз баламны үзем белмәскә. Сәламәт тәндә генә сәламәт акыл, диләрме? Мин авыру булганга күрә тузга язмаганнарны уйлый башладым бугай. Вообще-то, куарга кирәк сәләмә уйларны кибәннәр артына! Ярата Варис Миләүшәне, бик ярата. Моны кызның үзенә дә кабатлый тора күрәсең. Кыз бала алдында ләббәйкәңне таң атырдан алда, вакытыннан элек әйттеңме, ияреңне аркаңа бәйлә, менеп атланачак. Хаталана башлый кыз бала, «Мин — мин микән, мин кем икән?» дигән уй керә. Мондый уйга бирешмәс өчен ир-атка да, хатын-кызга да акыл кирәк. Төпле акыл дигән хәзинәне һәркемгә дә кушучлап өләшмәгәннәр. Вариска да акылның мәхәббәтне тезгенләбрәк торырлыгы житенкерәми. Үземә охшаганрак, вообще-то. Мин дә күп нәрсәне соңгарып төшендем. Рус әйтмешли, человек позднего зажигания. Акыл да, акча да бирер якыным юк иде. Бәхетемә, Хатирә дөнья бәясе кеше булып чыкты. Кая ул! Хатирәләр һәр түтәлдә үсми. Имгәтомга гына алар...»

Рәмзия Илфатның ата була белүенә эченнән күл куеп утырды. Вариска ирмен дигән ир булып яшәргә кирәген, ирлек горурлыгын жуймаска тиешлеген әйтүе белән Илфат бик хаклы дип санады. Хатын-кызлар ирләр белән тигез хокуклы дигәнне эгоистларча аңларга тырышмыйча, дөрес-туры итеп кенә уйлаганда, бүгенге дөнья ганлә дилбегәсен нык тота торган ир-атка мохтажлана түгелме соң? «Үзем дә эшлим. Ашарыма житә, кияремә бар. Икеләтә эшлим әле мин! Өй мәшәкатьләре дә минем инемдә»,— дибез. Дөрес әйтәбез. Әмма чыпчынлап үз итешеп яшәгәндә, йорт эшләрен тигез бүлү генә бер дә авыр түгел. Шуны сылтау итеп, башны дуга кыңгыравына күтәрергә маташу — без, хатын-кызларның акылсызлыгы гына. Командир погоны тагарга чәбәләнәсе түгел безгә, командир ирләребезнең киңәшчесе, жан терәге булырга тырышкан хәерле. Безнең назга, безнең тәрбиягә мохтаж ич балалар белән ирләр... Һәр көн яныңда булганда, ирле тормышның кадерен белми башлаган чакларыбыз булгалый түгелме? Тормыш арбасын ялгызың гына сөйри башлагач, беленә икән ир кадере. Акча житмәүдән генә түгел, акчаны да, ризыгын, малын да юнәтеп була. Икешәр жирдә эшләүчеләр күпме... Жанга терәк табулары, айһай, авыр. Кара-каршы утырып, үз кешеңә эч сереңне сөйләвең генә дә ни тора!

Алай да Илфатның кулы катыга охшый. Жайга гына торучан кеше кебек күренсә дә, татарлыгы уянса, талканы коры моның, коры. Улым, сиңа әйтәм, хатын, син тынла шикеллерәк килеп чыкты әле бу... Булсын! Мәлҗерәп торганнардан ни көтәсең? Сугып ега белгән ир тартып торгыза да белүчән. Сугып дигәч тә... уйлап, үлчәп бер карарга килгәннән соң үзенекен итә алуы дөюем...

Варисның да аллы-гөлле буяуларга манып күз алдында йөрткән кул сузымындагы якын киләчәк көннәренә кинәт кырыс төсмерләр куган кебек булды. Мәхәббәт дигән кайнар хисне сөешү дигән шәраб сәрхүшлегеннән айныта торган бәлзәме дә бар икән ич. Мәхәббәтнең Икария иле түгеллеге, аның тулган ай, хуш исле чәчәкләр фәлсәфәсеннән, танцылар, дискотекалар, заманча ритмдагы жырлардан гына тормавы ачыклана башлады түгелме? Беренче пәрдә, беренче күренеш... Кодалар, кодагыйларның үзара мөнәсәбәтләре, фатирга чыгу, үз көненең үзең күрә башлау, үз-үзеңне тышаулау яки тышауламау мәсьәләләре... Әткәй таякны артыгын бөгә түгелме? Ә бәлки нәкъ шулай киректер? Миңа начарлык теләми бит инде ул. Миләүшә ничек кабул итәр әткәй талэпләрен? Зәйтүнә апа белән Гамил абый нинди позиция алырлар?..

Һәммәсен уйларыннан араларга теләгән шикелле, стенадагы сәгать

күкесенең өч тапкыр кычкырып куюы булды, Рәмзиянең утырган җиреннән сикереп торуы булды.

— Сүз бозау имезә менә шулдыр инде. Сөйләшә торгач, соңгарып ятам икән ләбаса!— Ул эшкә ашыкты.

Аталы-уллы әңгәмә тагын яңарып алды. Гәпләшә торгач, уртак фикергә килделәр кебек. Шуннан соң Илфат Вариска гозере барын әйтте.

— Харис белән по душам сөйләш әле син, улым. Мин үземә тиешлесен тукыдым. Син — абый кеше. Ара якынрак сезнең. Яшь ягыннан, бер заман балалары булу ягыннан. Вообще-то, сиңа тел ачканы да бардыр. Ташбуадагы бер яшь хатынны ярата башлаганмы дим. Ачалак-йомалак йөрмәсен, күзен ачып карасын иде. Дүрт күз белән карасаң да таманга килә дөньяда. Намусны яшьтән сакларга кирәк.

Варис бакчага чыгып китте.

Харис, ике кулын баш астына куеп, гамакка сузылып яткан, аяз күккә текәлеп, уйга чумган иде. Китаплары янында. Ачып та карамаган бугай. Абыйсы килгәнне тоймады.

— Җиңеп буламы Шерлок Холмсны?

Харис сискәнеп китте, тик шунда ук җавап тапты.

— Ничья! Холмсның ми тышчасын ертып керәсе килми, мин көчләп тартмыйм. Нейтраль хәлдә икебез дә.

— Мәхәббәт галәмәте, димәк?

— Әткәй сөйләп чыгардымы? Кирәкми, аңлатма. Сүзсез дә аңлашыла. Син илче булып килдеңме? Тренер-психологмы? Әйдә, тире иләгән кебек эшкәрт әле мине, абый. Ефәк яса киндер ыштырдан...

Варис энесенең маңгаена чиртте.

— Бик кирәгең бар иде,— диде, гамьсезлекнең аргы ягына чыккан кыяфәткә кереп.— Үз хәсрәтем үземә җиткән, син саргайтасың тагын. Өлкән комсоставтан өйләнергә рөхсәт алып чыгуым, белдеңме?

— Тарихи көн, тарихи сәгать! Бар, абый, эрбет куагына чокып яз, «Июль, 2, 1981».

Варис уң учы белән энесенең җилкәсенә шап иттереп сугып куйды.

— Акылың алтын икән, үзең көмеш кенә булсаң да. Киңәшнең кәттәсен бирдең, энекәш. Эрбет кайрысына кагылып кара, этинең кай жиреңне каезлаганын күрерсең.

— Котлыйм!— Харис башта кулын өскә күтәрде, аннары, буй җитмәс җиргә үрелгән кебек, каршысында торган абыйсына сузды.

— Рәхмәт, агай-эне!— Варис аны гамактан тартып төшерде.— Сине дә хатын-кызлар фронтында активлашып киткәнсең, диләр. Расмы шул? Өйләнергә үк түгелдер бит исәбең?

Харис китапларын баудан үргән асылмалы койкасыннан алып беседка өстәленә ташлады һәм сүз чикләвек вату хакында барган кебек кенә сөйләнеп куйды.

— Өйләнешикме әллә, дип караган идем берәүгә. Чынлап, чынлап. Ник мыскыллы елмайган буласың? Дөресен әйтәм. Тәтемәде, син — мамык сарысы китмәгән бәбкә әле, диде. Сүзгә-сүз түгел, мәгънәсе шулай...

— Баласы белән алмакчы идеңме?

— Ни булган ди?

— Бер ни дә юк. Героизм, киресенчә. Үзең белән бергә үсәчәк. Их, син, тишек борын!

Харис башын артка ташлап көлде.

— Абый, үзеңнән яшьрәк кешегә акыл сатасы кызыкмы?

— Акылны, энем, алырга хәленнән килгән кешегә генә саталар. Кем туры килдегә түгел.

Алар өстәл янына килеп утырдылар. Харис та шамакайланудан туктады һәм абыйсына карап җитди сөйли башлады.

— Өйләнергәме әллә диюем шаярып кына әйтү иде, абый. Балалы икәнен дә беләм, өч яшькә өлкән икәнен дә... Йөрәккә приказ биреп булмый... Булмый да — бетте-китте!

Терсәкләрен өстәлгә терәгән килеш, учлары белән чәчен сыпырасыпыра, Варис аңа:

— Уза торган хәл, энем,— диде.

— Узмый бит менә. Ун көн күргәнем юк, бер минутка да онытканым юк. Төшкә керә, чамалыйсыңмы, төшкә!

— Менә Мәҗнүн!

— Теләсәң кем дип ата, ихтыярың. Синең соң шулай яратканың булмадымыни? Миләүшә апаны шулай яратмадыңмы? Әгәр үлеп ярата алмаган булсаң, ни пычагыма дип өйләнәсең?

— Яратмыйча өйләнүче мин түгел ул.

— Алайса минем хәлгә дә керә бел.

— Кереп нишлим?

— Кирегә ишмә. Кимсетеп маташма.

— Ярый, бер сүз дә әйтмим. Син дә өлкәннәрне борчудан тукта. Әткәйнең нервылары, беләсең, болай да — балалайка.

Харис янә кыенсынды.

— Әй, аңламыйсыз да, аңларга да теләмисез! Яратам мин аны. Ник икәнен генә әйтә алмыйм. Андый хәлне аңлатып булмыйдыр ахры. Машадан чибәррәкләр юкмыни? Бик күп. Акыллыраклар? Күп. Әдәпләрәкләр, мөлаемраклар? Дөнья тулы. Дөрес бит? Дөрес. Миңа андый дөреснең поты бер тиен. Бүтәннәрдәге әйбәт яклар — минем өчен тораташ, үлек. Ә Машаның чибәрлеге дә, акылы да, әдәплелеге дә жанлы, тере. Ул мине дә сафрак, көчлерәк итә. Шул оныттырмый. Ярый әле, имтиханнар бетеп котылды, аттестат кулда... Кабат килеп очрамаса, бәлки яхшырак булган булыр иде...

Энесен тыңлап торды-торды да, Варис ни дияргә дә белмәде. Харис шаярудан узган, теге яшь ханым аның бар булдыгын биләп алган. Ярату үзе өйрәтәдер, күрәсең, мәхәббәт галәмәтләре турында бөтен бер трактат сөйли бит. Гамәлдә, чынбарлыкта нишләп була соң? Тормышта үз сукмагын тапмаган килеш, алда әле хәл кылынмаган эшләр өелеп ятканда, «Әйдә, өйлән!» — дип кинәш бирмәссең ич инде. Үтә кызыл тиз уңа, аларның ике арасындагы мөнәсәбәтләрнең көннәрнең берендә суык мунчага әйләнеп калулары да бар...

— Урак житә, Харис. Кырга чыккач, басылыр йөрәк януларың,— диюдән бүтән чарасы калмады Варисның.— Яңа комбайнда, беләсеңме, безгә шедеврально эшләргә кирәк, энем. Бердән, әткәй канәгать булырга тиеш. Мактарлык эшли алсак, әткәйнең саулыгы өчен даруларның даруы булачак. Моны алдан ук уйлап тор. Икенчедән, армиягә китәсе елың. Үзең солдатта чакта да сагынып сөйләрлек булсын. Кайтуыңны көтеп алсыннар.

— Ул көнне мин дә көтәм, абый. Көнең төнгә ялгап эшлисе иде! Бөтенесен баштан чыгарып атып...

Мәшәкатьләр чылбыр-чылбыр

Июль башы. Бөркү иртә. Кояш, колга буе күтәрелүгә, кыздыра да башлады. Жир төнлә дә суынып житмәгән иде. Көндезләрен исә ми кайный башлар төсле була.

Кави Сәмәрханов икенче катка урнашкан кабинетының балконга чыга торган ишеген ачып куйган. Затлы челтәр пәрдә аша күләгә яктан азмы-күпме салкынча һава кергән кебек.

Кави Салихович «Авангард» колхозының партком секретаре белән сөйләшә иде.

— ...Беләм мин, Сәйхунов, беләм председателегезнең өйдә юклыгын. Низамовның үрдәк фермасы өчен Яльчикта кирпеч юллаганын да беләм, аннан маймычлар хакында сүз беркетергә балык питомнигына китәсен дә беләм. Сездән сорыйм мин, конкрет сездән: Яруллинны гаугасыз гына, тәмсезләнми генә җибәрә алмадыгызмы? Беләсегез килсә, аның ике ел рәттән отпускы алганы юк.

Райком секретаре, ияк кага-кага, колхоз партоешмасы җитәкчесе сөйләгәннәрне тыңлап торды.

— Кеше таба алмадыгыз?— дип гажәпсенде ул аннары.— Тыңлагыз әле, ипташ Сәйхунов, тавыклар көлдермәгез, яме. Булдыксызлыкка кул куеп торасыз бит, я. Симертү группасына өч көнгә алмаш таба алмагач, ферма мөдиренә ни дияргә дә, үзегезгә ни әйтергә?! Ягез әле, ирләр булыйк, коммунистлар булыйк, ниһаять. Сез бит, ипташ Сәйхунов, бер үк вакытта председатель урынбасары да. Кулалмаш булдыруда шул хәтле көчсез икән, ферма мөдирен үзен эшләтеп торыгыз. Укасы коелмас... Яруллин туйга бара, туйга! Кызының никах туена. Җибәрә алмыйм дип, карусыз эшли торган терлекченең, фронтовик-ветеранның, уңган коммунистның күңелен кырасыз. Үтенеченә шулай карагач, киләчәктә нинди дәрт белән эшләр ул? Үзегезне Яруллин урынына куеп карагыз әле. Менә мин сезне, хөрмәтле ипташ Сәйхуновны, балагызның олы бәйрәменә җибәрмәдем, ди...

Сәйхунов гафу үтенәме, нидер аңлатып, аклануын дәвам итә иде-ме, Кави тагын беравык тыңлап кына торды.

— Ярый, монысына нокта куйдык. Планны үзегез билгеләдегез, бер сүзсез үтисез... Корылыкка сылтап, терлекләрнең баш санын киметүгә дә, продукт алуда чигенүгә дә юл куелмаячак. Аң булыгыз. Кайткач та, Низамов минем белән бәйләнешкә керсен, тапшырыгыз...

«Яңа председатель җилле алынды,— дип уйлады Кави Салихович.— Булдырачак. Янып йөри. Кулына карандаш тотып саный, исәпли белә. Кешеләр белән эшли ала. Кирәксә кискен, эш интереслары таләп итә икән, бик җайлы, ипле дә була белә. Алга карый ала. Әнә бит, берәү дә мәҗбүр итмәде, Бола буенда үрдәк фермасы төзергә керешеләр. Кирпечне дә Ташбуадан түгел, Чувашиядән юллады. Яльчик аларга биш километр, Ташбуага килә калса — утыз километрдан артып китә. Бер урынына биш-алты рейс ясый ала. Төбеннән бихисап чишмәләр, теш сындырырлык салкын су тибеп тора торган күлләре бар. Ничә еллар буе аңа игътибар иткән кеше юк иде, Низамов шунда балык үрчетергә алынды. Ә менә комиссары Фурманов түгел шул, түгел... Сәйхуновны аңлавы кыен. Ир уртасы кеше, колхозчыга батырып сүз кушарга кыенсына. Оештыру сәләте үтә чамалы. Киләсе сайлауда әлеге мәсьәләне яңадан карарга туры киләчәк. Ялгышны төзәтә белү кирәк...»

Бу — Сәмәрханов уенда Яруллинга кагылышлы төстә, хисләр чайпалып түгелүдән генә туган нәтиҗә булмыйча, айлар буе күзәтүләрдән, анализдан килеп чыккан сөземтә иде. Кайда-кайда, ә «Авангард»та председатель белән парга җигелеп тартырлык партком секретаре булу — әйтеп бетергесез әһәмияткә ия фактор. Хуҗалыкны юлга салу партоешманың киреренке эшчәнлегеннән башка мөмкин булмаган эш...

Сәмәрхановның эшкә сәгать биштән килеп утыруы колхозларга шылтырату максаты белән түгел иде. Тик, өстәлдәге кәгазь битендә кичтән язып калдырган: «Авангард». Сәйхунов. Терлекче Яруллин турында» дигән сүзләренә күзе төшү белән, колхозга шылтыратмый булдыра алмады. Шунсыз ярамый иде. Кешеләргә васемсыз карашка чик куярга, юк кына мәсьәләләрне дә хәл кыла алмыйча эш кешелә-

ренең настроениеләрен бозучыларга чара күрә барырга кирәклеге ачык. Уңышны кешеләр хәл итә, һәркемнең күңеле — үзе бер дөнья. Кешеләрнең хезмәте, тормышы һәм көнкүрешенә кагылышлы барлык мәсьәләләргә партия, профсоюз, комсомол оешмаларының, хуҗалыкчыларның игътибарына партия съездында тикмәгә генә басым ясалмады...

Кави өстәл тартмасыннан юка папка алды. Анда «Социалистик Татарстан» газетасына дип яза башлаган мәкаләсе бар иде. Республика газетасыннан шылтыратып сөйләшкәннәренә атна булды, Сәмәрхановның язып бетерә алганы юк әле. Агымдагы эшләр белән агып бару түгелме соң бу? Вәгъдә — иман, дип сөйләү бер нәрсә, үзең сүздә тора алмасаң, ничек аңлатырсың?

— Бүген-иртәгә тәмамлап җибәрергә кирәк! Эленке-салынкы маташыр чак түгел!— Кави Салихович үзенә-үзе боерык бирде. Әлегә шартлы рәвештә генә «Съезддан соң уйланулар» дип исемләнгән язмасының баш өлешен янә күздән кичерде. Фикерләрне ялгап китәргә кирәк иде.

Гомуми фикерләрдән соң Кави Салихович алдынгы хуҗалыкларның казанышларын мисалга китерә. Бөртекле ашлык проблемасын уңышлы хәл итү нәтиҗәсендә җәмәгать терлекчелегендәге күтәрелешне тасвирлый, уңышларның төп ачкычы белемле, тәҗрибәле, тырыш механизаторлар, терлекчеләр, белгечләр кулында булуын раслый.

Фикер туплап, язуын дәвам итә генә башлаган иде, телефон трубкасын алмый булмады. «Чулпан» колхозыннан председатель хәбәр сала: төнлә колхоз умарталыгын басканнар. Умартачы Шәяхмәт Вәлиуллинга атканнар! Картны район больницасына озатканнар. Милиция килгән, карак-бандитларны эзлиләр...

Кавиның күз аллары караңгыланып киткәндәй булды.

— Менә варварлар, ә?!— диде ул үз алдына.— Нишлиләр бит сволочьлар! Ачтан шул адымга баралармы, ялангачлыктанмы? Юк бит, юк. Майларына чыдаша алмый кабәхәтләнәләр, ач күзләр! Хәшәрәтләр! Халык байлыгына күз яндыралар, бал урлап сатасылары килгән. Беләләр нәрсәнең ни икәнен...

Ул шундук район больницасының номерын җыйды.

— Дежур врач Сәлимов.— Трубкадан шул сүзләр ишетелде.

— Исәнмесез, иптәш Сәлимов. Райкомнан Сәмәрханов. Мине «Чулпан» колхозыннан китерелгән Шәяхмәт Вәлиуллинның хәле борчый. Ничегрәк?

Врач картның сәламәтлеге куркыныч хәлдә икәнлеген әйтте, кризис үтмәде әле, диде. Кулдан килгән барлык чараларны күрәбез, баш врач үзе аның янында, обрез ядрәләрен дә үзе операцияләп алды, дип аңлатты.

— Мин сездән, иптәш Сәлимов, сәгать сигездә райкомга хәбәр итүегезне сорар идем,— дип үтенде Сәмәрханов.— Зинһар, авырсынмагыз. Максимум тырышлык куюыгызны сорыйм...

Кулыннан каләм төште Кавиның. Кәефе бөтенләй бозылды, коелып инде. Күңел әчкәресенә шомлы суык кереп оялады. Күз алдыннан Шәяхмәт абзыйның җыерчыклар ермачлаган йөзе китмәде. Әле кайчан гына дәртләнеп, җилкенеп, умартачыларның район киңәшмәсендә катнашырга йөри иде. Килсә дә килә икән кешегә бәла артыннан бәла! Үз гомерендә ниләр генә күрмәгән Шәяхмәт абзый! Инде менә тыныч-нмин заманда, сыйныфлар көрәшеннән азат бер илдә, бәхетле көннәр кичергәндә — мә сиңа! Вәхши комсызлар кеше атуны чебен үтерүгә дә санамыйлар. Кемгә атканнар диген жәмгыятьнең соры кортлары? Ватан азатлыгы өчен кан түккән, илгә, яраткан һөнәренә гомерен багышлаган олы йөрәкле фидакарь картка!.. Яңа дөнья төзүдә зигзаглар, дибез. Бу фажига — шуларның берсе.

Әүвәлрәк елларада җәмгыять тормышындагы тискәре күренешләр-

не капитализм калдыгы, аерым кешеләр аңында иске дөнья калдырган яман шешләрнең яшәүчәнлеге дип аңлата идек. Әле дә булса шул шешләрдән эренле үлек саркыймы? Октябрь җиңүенә алтмыш дүрт ел тула бит инде. Кышкы сарайны штурмлаган елда дөньяга килгән кешеләр картаеп бара. Хәзерге яшь буыннар тере капиталистны телевизор экранында гына күрә. Каян борынлап чыга кабәхәт җаннар? Капиталистик дөньяның сөремле сулышы чик аша узып үстерәме андыйларны? Мул тормыштан азынучылар деградациясеме бу? Тәрбия эшен һәркайда да тиешле югарылыкка җиткерә алганыбыз юкмы? Кешеләр белән индивидуаль эшләвебез аксыймы? Җәза көченә ия гадел законнарыбызны тиешенчә кулланмыйбызмы? Кара ниятле бәндәләргә, миһербансыз ерткычларга мәрхәмәт күрсәтәбезме? Артык гуманлыга әйләндекме?..

...Сәгать сигез тулып узгач, иртәнге почтаны китерделәр.

Кави Салихович беренче итеп район газетасын күздән кичерергә күнеккән. «Агитаторлар җәйләүдә», «Солтанмы, хан Солтанмы?» Фельетон. Халык контроленең район комитеты члены Фәйзиев Ташбуа кирпеч заводы директоры Солтан Ярмиевнең бюрократлык кыланышларын, тупаслыгын камчылый. Бастырып бик дөрес иткәннәр! Матбугат камчысын татысын әле дорфа егет. Аны бюрога чакырмый булмастыр. Яшь кенә килеш ничек шул кадәр һаваланмак кирәк? Кара син аның ветераннарга мөнәсәбәтен!..

Телефон чыңлады. Район больницасының баш врачы шылтырата иде. Шәяхмәт абзый аңына килгән, тел тибрәтеп сүз әйтә алган. Кан күп югалтканлыктан, бик хәлсез икән әле, шулай да врач, кризис узды, агай яшәячәк, дип исәпли.

— Хәбәрегез өчен рәхмәт, Вадим Николаевич, рәхмәт!— Сәмәрханов аз гына булса да тынычлана төште кебек.— Төштән соң тагын белешермен әле...

Техник секретарь керде, Яртуганнан бер апа килгән, туганыгыз, керергә рөхсәт сорый, диде.

— Кем икән ул?— Кави, урыныннан торып, секретарь-машинистка бүлмәсенә чыкты. Анда әтиләре бертуган апасы — Хөршидә утырып тора иде.— Әйдә, Хөршидә апа, рәхим ит. Кер әйдә. Нинди җилләр китерде үзеңне?

— Дөнья нужасы китерә инде, кем, Кави энем, дөнья мәшәкате,— диде Хөршидәттәй, исәнлек-саулык сорашып.— Ни хәлләрдә ятасыз? Камәрия килен сау-сәламәтме? Кызың, улың исән йөриләрме, укулары барамы? Үзең ничегрәк, бик арымыйсыңмы? Съездга да барып кайттың инде...

— Барысы да искечә, Хөршидә апа,— дип җавап бирде Кави.— Хәзергә зарланырлык түгел. Камәрия эшли, балалар укый, мин әүвәлгечә эшләп торам. Корылык кына кәефне бик кырды...

— И-и-и, әйтәсе юк инде, кем, Кави энем. Җелекләрне киптермәле эссе, ходайның хикмәте... Яңгырсыз еллар була тора инде аның, абау да моның ишесен хәтерләмим дә...

Болар һәммәсе төп сүзгә кереш, үгезне мөгезеннән эләктерүгә увертюра иде әле. Тик Хөршидә бәгыре сызлавын капылт кына сөйләп китә алмады. Кави, мондый очракларга күнеккән кеше, аны аңгәмәгә үзе тартты.

— Нужа китерде дидең дә, Хөршидә апа, йомышыңны сөйләмәдең бит әле,— дип көлемсерәде.— Нинди нужа төште? Олыгаймыш көнендә бәла-казага тармагансыңдыр бит? Ни булды?

Сөйләве ансат түгел иде шул. Хөршидә туздырып бәйләгән ак яулыгының ияк астындагы төенен капшады, чигә чәчләрен яулык астына яшерде, бармак битләре белән ирен читләрен сөртеп куйды, соры-коңгырт күзләрен челт-челт йомгалап торды.

— Әйтүе дә кыен инде дә, Кави энем, үз үтерми, ят ярлыкамый, дип килүем иде яныңа. Төне буе йокы алмады, таң белән тордым, юындым-киендем дә Яртуганнан китүче беренче рейс автобусына чыктым. «Барыйм әле, райкомның беренче секретаре булып утыручы энем яныңа, мәйтәм. Җан тартмаса, кан тартыр. Булышмаса да, куып чыгармас. Ходай күңеленә миһербан салса, ярдәменнән дә ташламас, шаять»,— димен.

Кереш сүз шактый бормалыга киткәч, Кави конкрет сорады.

— Миннән нинди булышлык кирәк соң сиңа, Хөршидә апа?

— Үземә түгел, энем,— диде апасы.— Үзем өчен борсаланып йөрмим. Урыным жылыда, аягым корыда. Пенсиям бар, колхоз эшенә дә чыкмый тормыйм әле. Дөньям дүрт аягында минем. Әнә шул килешми икән кешегә, дөньясының дүрт аякта булуы, бер аягы аксабрак торса, хәерлерәк, ахрысы. Түм-түгәрәк тиз кителә, диләр ич. Үземә бер ни дә кирәкми минем...

— Кемгә нәрсә кирәк инде, алай булгач?

— Улымның эше күңелсезләнеп китте, Кави энем. Закирның. Тәмам да күңелсезләнде, гөнаһ шомлыгы!

— Машинасын бәрдердеме? Әллә кеше таптатканмы?

Хөршидә ике кулының да бармакларын җәеп, нәрсәнедер үзеннән этәргән төсле хәрәкәт ясады, гүя йөк машинасында эшләүче шофер улының бәласе бик кечкенә иде.

— Юк, юк, алла сакласын! Машинасын җаныннан битәр саклый ул. Бәрдерәме соң?! Кеше дә таптатмаган, мең шөкер. Эчми бит, авызына да алмый. Шуңа күрә юлда имин йөрененә иманым камил, Кави энем. Бик тәртипле улым. Аталары дөнья куйгач, төп терәгем булып шул калды инде... Туп кебек тәгәрәшеп өч баласы үсә. Илгә солдатлар, ир балалар...

Кави тагын сорарга мәҗбүр булды.

— Нишләгән соң Закир улың, Хөршидә апа? Кыска гына, аңлатып кына әйт әле, зинһар. Нинди бәлагә тарган?

Хөршидә, кайнар аш салган савыт тирәсендә бөтерелгән мәче сыман, төп йомышының тирәсендә тулганды. Әйтергә дә кирәк, тел дә күтәрелми.

— Болай нәфесле олан да түгел инде ул үзе, Кави энем. Кеше хакына кергәне юк гомер бакый да... үзенекен тартып алмасалар, бик риза булып йөри торган адәм инде дә менә, кичәгенәк хаталанып куйган шул, хаталанган...

Кавига мәсьәлә нигездә ачык иде.

— Нәрсә урлаган?— Сәмәрханов ачуланып сорады. Апасы имәнеп китте, тавышына калтырау чыкты.

— Урлаган дип, кем, Кави энем... Бик ямьсез сүз әйттең ич әле син. Ни бит, бер машина комбикорма алып кайткан.

— Сатып алгандыр инде дә... Квитанцасы юк шул акча түләгәнгә...

— Аңлашылды.— Кави урыныннан торып, бүлмә буенча йөренә башлады. Шәяхмәт абзыйга аткан бандитларга кәһәре тоныкланырга да өлгермәгән көйгә тагын бер «сөенче» — туганнан туганының баласы колхоз байлыгын таларга керешкән.— Бик аңлашылды. Артыгын сөйләмәсәң дә була. Хәзер үзем белешәм...

Кави милициягә шылтыратты. Әйе, Закир Сөләйманов, «Кызыл яр» колхозы шоферы, бер нинди документсыз-нисез өенә бер машина комбикорма урлап кайткан. База складчысы белән килешенеп эшләнгәне ачыкланып бара. Икенче машинасын склад хужасына илтергә килешкән булганнар дип уйларга тулы нигез бар, Сөләйманов та, склад мөдире дә кулга алындылар...

— Ишкәннәр икән ишәк чумарын!— Кави Хөршидә апасына рәнжеп шулай диде.— Халык ут йота, жәмәгать терлекчелегенә кышлык азык

булдыру дип аяктан калып чаба. Ә болар дәүләт кесәсенә, колхоз кесәсенә кул тыгалар. Җиңел генә мал симертәселәре килә... Хапугалар!..

Хөршидә Кавиның соңгы әйткән сүзен аңламады, бик әшәке сүздер инде дип кенә юрады. Аның хәле хәзер туган телендә әйтелгән сүзне дә аңлатырлык түгел иде. Калтырап төште, башы әйләнеп, күз аллары әлҗе-мөлҗе килде, авызы кипте, сабын тәмнәре тоя башлады. Теле дә игәү сыман кытыршыланып, катып калган кебек иде. Аны көч-хәл әйләндереп, Кавидан сорады:

— Закирга нәрсә булып бетә инде, Кави энем?

— Законда каралганча срокка төрмәгә ябу белән бетәчәк аның эше, Хөршидә апа. Улыңны түгел, сине бик кызганам. Балалары жәл...

— Син коткара алмыйсыңмы соң инде, Кави энем? Район башлыгы әйткәч, дим, төрмәсез генә котылдыра алмаслармы?

— Ә ни дип котылдырырга кирәк аларны? Сабыйлар түгел. Нишләгәннәрен белеп эшләгәннәр. Урлашкан өчен җәза барын белмиләрме алар? Беләләр. Белә торып комсызланалар. Шома гына үтеп китсә, эчләреннән генә көлеп, без кем дип йөрмәкчеләр. Ә бер мескен карчык тавыкларыма сибәргә җим каян алыйм дип уфтанырга тиеш... Олы башын кече итеп, правлениега килә ул, дүрт-биш кило бөртек язып бирегез әле, ди. Закир ишеләр машинасы белән кайтарып аудара... Кулларын кыскартырга кирәк андыйларның, хәләл көч белән яшәргә өйрәнсеннәр...

Бер уйласаң, Хөршидәгә беренче секретарь кабинетында утыруның хаҗәте калмаган иде инде. Кави әйтте, моннан да артык ачык әйтүнең кирәге юк. Мәрхәмәт көтәргә калмаган икән. Кулы белән кылганны җилкәсе белән күтәрергә тиеш була Закир да...

— Каршы күршегез Әхмәдулла картны беләсең бит, Хөршидә апа, әйеме?— Кави апасына бөтенләй көтелмәгән сорау бирде. Туганы хәтта аптырап калды.

— Беләм, белми ни... Тугызынчы дистәсен ваклады инде.

— Менә шул карт җитмеш өченең язында, корылыклы җәйдән соң кыш җиткәч, үзе урак белән урып, капчык белән ташып киптергән бер олау печәнен колхоз терлекләренә бирде. Сыеры казалагач, калган печәне булган. Я, әйт инде, олы кеше буларак, колхозны талау егетлекме, әллә Әхмәдулла карт кебек булышу әйбәтме?

— Әхмәдулла инде ул шундыйрак, Кави энем. Аңлап бетермәссең. Шуңа күрә «Җете» диләр аны...

— Менә безгә шундый «Җете»ләр кирәк, дөньяның кендеге шуларга тоташкан, Хөршидә апа. Закир юлына басканнар халыкка иш түгел... «Җете»ләрне аңлап була, колхозны үз итәләр алар, аның байлыгын үзләренең байлыгына хисаплыйлар.

Артыгын орды-бәрде итмәде бит әле Кави, тагын бер ялварып карыйм булмаса, дигәнрәк уй кузгатты секретарьның тыныч кына аңлатып торуы. Хөршидә, иелгән башны кылыч кисмәс, дип тәвәккәлләде.

— Кави энем, алай да бу Закирны штраф түләтеп кенә калдырып булмас иде микән соң? Таш капчыктан бозылып кайтыр инде ул, андагы җыен азган-тузган янында...

— Менә бу мәсьәләне мин хәл итмим инде, Хөршидә апа. Законга таянып, прокуратура, суд органнары хәл кыла. Әйтмәсәм дә беләсең син моны. Минем законны әйләнеп узарга маташмасымны да белеп торасың син. Шулай бит? Бу очракта мин кыл да кыймылдата алмыйм һәм тиеш тә түгелмен. Рәнжемә, үпкәләмә. Ачтан, ялангачлыктан эшләмәгән. Әлеге дә баягы, симерүләре җитте кайберәүләрнең. Зурдан күпмакчылар, ә хәләл көч куйган өчен санап кына бирәләр. Боларга кешедән артыгы кирәк... Алай булмый ул. Хәрам бер бүлтәеп чыкмый калмый...

Кави Хөршидәне урамга кадәр озата чыкты. Апасы китеп баргач, олы юл буена күз салган иде, автобус тукталышыннан ашыкмый гына баручы Илфат Маннуровны абайлап алды. Аны көтте. Гадәттәгечә, бик жылы күрештеләр. Секретарь аны туп-туры үз кабинетына алып кереп китте. Баскычтан күтәрелгәндә үк газетада Зөбәйдәнең портреты басылуын сөйләде. Кабинетка кергәч, Илфатның сәламәтлеген Кави бәйнә-бәйнә сорашты. Болай әрсезләнеп йөрү зыянга булмасмы дип шиген дә белдерде.

— Зыянга түгел, Кави Салихович,— диде Илфат, нык ышанып.— Һич тә зыянга түгел. Врачлар да күбрәк хәрәкәтләнергә киңәш итәләр, үзем дә сизәм, вообще-то: аяк-кул күбрәк хәрәкәттә булды исә, кәеф яхшыра. Арысам, ял итәм... Аннары тагын кул өчен күнегүләр... Ятып кына торсаң, ятып китәрсең. Аннары миңа жәйрәп ятарга просто ярамый хәзер, туй көтелә, Кави Салихович. Бер атнадан туй...

Секретарь аңлап алды: Варис өйләнә, димәк.

— Студент башлы-күзле булырга карар кылдымыни?— дип сорады.

— Әйе, Варис өйләнә. Минем яшьтәш, классташымның кызына. Кәләше быел гына мединститутны бетерде. Әтисе полковник, Казанда военком...

— Хәерле сәгатьтә булсын!— Кави шулай хуплау сүзе әйтте.— Һәр жимешнең үз вакыты. Ә уракка кайталмый буламы инде? Бик жиң сызганып торган иде кышкы мәлне.

— Кайта, Кави Салихович, кайтмаган кая!— «Колос»та урдырачаклар, яңа машинада. Энесе белән икәү. Ул мәсьәлә хәл ителгән... Корабльдән балга түгел, балдан корабльгә, ягъни туйдан уракка булачак...

— Алайса бик шәп! Нормально.

— Әле менә кода буласы кеше кайткан иде, полковник Нургасимов. Аны тимер юл станциясенә озатып килешем. Рәмзия дә килде, ул быткомбинатка кереп калды. Вакытыгызны күп алмам, Кави Салихович. Шулай да киңәшәсем бар сезнең белән.— Илфат, уң кулының бармакларын сул учына куеп селкеткәли-селкеткәли (бу гадәтенә кереп киткән иде инде), сөйләп китте.— Минем кияүне беләсез инде, Даниялны...

Кави, шаяртып каравыңмы соң бу синең дигән сыман, кашларын күтәрде, зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп Илфатка текәлде, көлеп куйды.

— Иске авыздан яңа сүз! Белми ни! Мин, кордаш, район механизаторларының басуда тулы бер сезон эшләгәннәрен һәммәсен яхшы беләм. Тракторга яңа утырганнарны гына чамалап бетермәвем бар. Даниялны аны, минемчә, бөтен район беләдер. Синең үкчәнә басып эшли торган механизатор ич...

— Сүзем аның хакында. Эшләвен эшли ул. Иренә дә белми, карусыз да. Килде-китте эшләгәнне дә жене сөймәс. Чын жир кешесе ул, Кави Салихович. Анысына дәгъвам юк. Киңәш бүтәннән.

— Нәрсә булды соң?

— Былтыр көзен, урак бетәрәк, мин аңа партия членлыгына кандидатлыкка рекомендация биргән идем. Быел инде янә сорый.

— Шуннан?

— Шуннан шул: икеләнебрәк торам, Кави Салихович. Үзенә дә туп-туры әйттем, шигем бар, димен. Акларсыңмы икән, кияү, мәйтәм. Былтыр да тукый-тукый биргән идем, йөрәгемне тынычландырмадың, димен.

Кави Салихович Илфатны бүлдермәде, мәгәр тел төбен төшенгән иде инде.

— Ак шәйтанны яратарак төшә, Кави Салихович. Болай исереп адәм рисвае булганы юк. Анысын әйтә алмыйм, вообще-то. Ну барыбер

жаным тыныч түгел. Әле менә сабан туеның иртәгесен урманга барасылар иде. Таң белән торып, шешәгә сыенган. Ничек була инде бу?

— Трактор утырып юл чыкканда бер дә яраган эш түгел, билгеле. Акыллы егет күренә, нигә шулай ихтыярсызлык күрсәтә икән? Сүз уңаеннан сорыйм әле, кордаш, авырга алма: семьясында ничегрәк, тату торалармы?

Илфат бу сорауга әзер. Аның уенча, Зөбәйдә белән начар яшәү, гомумән, мөмкин түгел.

— Семьясында тәртип, Кави Салихович. Өстәлдән ялгышып кашык та төшкәне юк. Даниял юньсезләнмәсә, кызмачаланып, анда-санда буталмаса, өйләрендә ал да гөл. Минем кыз телен тешләп яши белә, өйдән ын-шын чыгасы юк. Үз сөяге үзенә авыр түгел дигән кебек, Зөбәйдә яклый да әле аны.

— Монысын аңлап була, аның ире ич Даниял. Балаларының атасы. Үз иренең яманатын сатып йөргән хатыннар, турысын әйтим, Илфат, кызганыч тоела миңа. Шуларны кабул итәргә туры килгәндә, тешемне кысып чыдыйм. Парадокс килеп чыга бит, парткомга чабалар ирләре өстеннән, райкомга киләләр, хәтта обкомга язалар, төнлә янәшә ятып йоклыйлар. Бер иптәшнең хатыны айлар буе теңкәгә тиде. Ире өстенә нинди генә пычраклар атмады. Тыңлап торганда колак шиңә. «Ярый,— дидем көннәрдән бер көнне,— без аны постыннан алырбыз, һәрхәлдә, бюро членнары белән уйлашырбыз. Сез өзми дә куймый, чат саен хурлап, яман атын сатып йөргәч, аңа коллектив белән эшләве, чыннан да, ансат түгелдер...» Күзләренең шар булганын күрсәң иде ханымның. «Што сез, иптәш Сәмәрханов! Бер үк алай итә күрмәгез, үтенәм сездән. Куркытыгыз гына сез аны. Минем сүздән чыкмаслык кына итегез»,— ди. Куып чыгарасым килгән иде, ярамый, тыелып калдым, ләкин кирәген әйттем. Зөбәйдәнең гаилә хәлен манарага менеп кычкыруны яратмавы, аңлый белсәң, күркәм сыйфат ул, кордаш.

— Анысына мин дә кул куям.

— Колхоз житәкчеләре белән арасы ничек Даниялның? Аларга рәнҗүе юкмы?

— Булырга тиеш түгел. Сизгәнем юк. Безнең Кәримгә дә рәнҗүче табылса инде, белмим... Гаделнең гаделе. Каты куллы, анысы дөрес. Нахакка бәйләнми, эшләгәннең кадерен белә, ярдәмчел. Даниялны да мактап кына тора ул.

Сәмәрханов кулындагы карандаш белән өстәлгә шакыштыргалап торды. Уйлана иде.

— Шешәгә гыйшкы нидән төшә икән соң дип аптырыйм әле. Хезмәт кешесе, тормышта максаты ачык булган кеше тиктомалдан эчми, кордаш. Син мине дөрес аңла, мин Даниялның йомшаклыгын акларга җай эзләмим. Нинди генә сылтау, нинди генә сәбәп белән эчсә дә, аракыга сыену — яраксыз эш. Аның белән проблема хәл кылынмый, четрекләр бетми, ишәя генә. Даниялга ни житми? Акчасы кычытамы? Алай гына булса, без аны тезгенләрбез дип беләм. Мин, мәсәлән, үзем ирләрчә сөйләшеп карар идем аның белән. Ачыктан-ачык, һәр нәрсәне үз исеме белән атап. Ничек уйлыйсың?

Илфат жанланып китте, күзләренә тикле очкынланды.

— Мишәйт итмәс иде дә соң андый сөйләшү... Сезнең эш болай да күп бит, Кави Салихович?!

Кави карандашын фарфор савытка тыгып куйды да, креслосына калкыбрак утырды, якаларын, галстугын жайлап куйгандай итте. Аннары бастырып-ныгытып әйтте:

— Райондагы һәр коммунистның пульсын тоярга бурычлы мин. Төп эшем шул. Коммунистларны яхшы белгәндә генә, аларны зур бурычларны хәл итүгә туплап була.

— Мин нишлим, Кави Салихович? Ышанып биримме рекомендацияне, әллә отказ итимме?

Беренче секретарь өзеп җавап кайтарырга ашыкмады. Иреннәрен бөрештереп, керфек какмый гына беркадәр сүзсез утырды.

— Әлбәттә, рекомендация биреп, ышаныч күрсәтү — үзе бер тәрбия чарасы. Аны бирмәүнең дә кайчак кешене тәрбияләве мөмкин. Үзең әйтмешли, кире кагу партиялелек сабагына әверелә кеше өчен. Син ашыкма әле, кордаш. Августка кадәр вакыт бар, мин иптәшләрчә бер сөйләшеп карыйм әле Даниял белән. Андый шаукымнан арынырга тиеш егет ул, арыныр дип ышанасым килә. Син бит рекомендация бирүче хезмәттәше генә түгел, син — аның хатынының атасы. Тормыш ямен китәрерлек драма тууы ихтимал, гомерлеккә бозылышуыгыз бар. Бер үк алай була күрмәсен. Җиде тапкыр үлчәми бүлмый мондый чакта.

Даниялга кагылышлы киңәштә шулай килештеләр. Илфат, Рәмзия белән универсам янында очрашырга булдык, дип, китеп барды. Кави аны дустанә озатып калды. Аннары агитация-пропаганда бүлеге мөдиренә шылтырататы.

— Урып-жыю чорына эшләнгән пропаганда планының соңгы вариантын алып керегез әле,— диде.

* * *

Олы юлдан универсам ягына атлаганда Илфат (ул автобус көтмәде. Машина килеп житкән булса да утырмас иде, салонда чыдап булмаслык бөркү) Ташбуа урамы башыннан Казанга китеп баручы пассажир поездына дикъкать итте. «Гамил китте,— дип куйды ул үз алдына.— Туй мәшәкатенә чумарга дип китте полковник иптәш. Шулай инде, кыз бирүнең мәшәкате егет өйләндерүдән һич тә ким түгел. Безнең якта бүрәнәнең авыр башы Рәмзиягә төшәчәк, чыдый гына күрсен!

Кичә Гамил Гөл-Төркемгә туган авылы Тоныксу аша кайткан иде. Илфатларда куныды. Булачак кодалар барысын да уртага салып сөйләштеләр. Төн буе гәпләштеләр дисәң дә, ялгыш булмас. Рәмзия яткач та, йокларга ашыкмадылар. Икәү генә калгач, чак кына ачуланышмадылар. Башта Гамил дәгъва белдерде.

— Ни өчен Варис белән Миләүшәнең бездә торуларына чәчрәп каршы төшәсең? Моңа нигезең бармы?

Илфат туры гына җавап бирмәстән, Гамилны чәнчеп алырга жыенды. Тавышын да аныңчарак итеп:

— Син кызыңны кияүгә бирәсеңме, әллә өйләндерәсеңме?— диде.— Өй-лә-нү! Шул сүзнең төбенә тоз коеп кара әле, иптәш полковник. Балалар өй-лә-нер-гә, үз өйләрендә яшәргә тиешләр. Пока фатирда дигән сүз. Гомере буе син дә, Зәйтүнә дә карап бетерә алмассыз аларны. Көн итәргә күнексеннәр. Суга ташлагач, йөзеп китә кеше. Шуны-сын да әйтим: Варис, семья башы буларак, тормышта нинди йөк тартачагын баштан ук һәйбәтләп аңласын. Әби-бабай каршында үксез бозау шикелле, йомышчы малай булып йөрү — егет эше түгел. Миләүшәгә дә әти-әнисенә аркаланып, үзен һавалы тотарга урын калмас. Минем сүзнең нигезе шул.

— Тагын?

— Тагын нидер әйтерем барын сизеп торасыңмы?

— Тел очында нидер эленеп калды.

— Тел очында булмас, йөрәк түрендә диген син, Гамил.

— Әйт, әйт. Барысы ачыклансын. Соңыннан бер-беребезгә бармак белән төртеп күрсәтә-күрсәтә, син болай да, син тегеләй диярга калмасын.

Илфатның кодалыкны һич кенә дә тәмсезләнеп, күңелдә чи калдырып башлыйсы килми иде. Мәгәр фикерен азаккача әйтми дә кала алмый иде. Чөнки ул аның өчен иң изге хакыйкатькә тоташкан, Илфат Маннуровның яшәү максатының асылына береккән.

— Сезнең канат астында яшәп китсә, крестьянлыгы югалачак Варисның. Әйе, әйе, гажәпләнгән булма. Синең дә, Зәйтүнәнең дә җир өчен, икмәк үстерү өчен бәгырегез көйми. Миләүшәне әйтмим дә. Мин инде дөньядан үз дигәнемә ирешеп китәргә тиешмен. Габдрахманнар, Фәйзерахманнар, Илфатлар эшен Варис белән Харис ары алып китсеннәр иде. Улларым җир кешеләре булып, илне ашатучылар булып калсыннар.

Гамил яшьлек дустының фанатикларча сөйләшүен өнәмәде. Алай да аны туктата да алмый иде. Алмый, чөнки Илфат хаклы. Шуңа күрә Гамил дипломатларча йөреш ясады.

— Илне туендыруга шәһәрдә яшәп өлеш кертеп булмый дип уйлыйсыңмы син? Әйтик, Варис авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының тәжрибә кырында эшли, ди. Мисалга әйтәм...

Илфат кул селтәде.

— Маташтырма, Гамил. Аңа калса, заводта авыл хуҗалыгы машиналары ясаучы да, минераль ашлама житештерүдә эшләүче дә, яңа орлыклар чыгаручы да — бик күпләрнең катнашы бар икмәк игүдә. Мин үз куллары белән башак үстерүчеләрне күз алдында тотам, буразна кешеләрен.

— Һе!— дип куйды Гамил, ризасызлыгын яшереп тормыйча.— Институт бетергәч тә буразнада калмас бит инде улың!..

— Колхозда инженер-механик булыр, район идарәсендә эшләр. Һәр көне, һәр адымы туган туфрак белән бәйле булыр. Монысы — минем иң зур теләгем. Варис та сүземнән чыкмас дип беләм.

— Уйлап карар, билгеле. Ата теләге — зур эш.

— Уйлап торасы да юк!— Илфат кыза башлады.— Сез менә, Мирзанур абзыйның уллары, кызлары, уйладыгыз, уйладыгыз да таралышып та беттегез. Тугыз баладан авылда берәү... Мирзанур абзый, мәрхүм, җиргә ябышып ята торган игенче иде бит. Үзенең дәвамын күрәсе килмәгәндер дисеңме? Уйнама, брат. Ансыз булмый ул...

— Безнең шулайрак килеп чыкты инде...— Гамил хак сүзгә каршы куяр дәлил тапмады.— Синең улларың үз эзеңнән барачаклар, хафаланма. Шатлан, горурлан. Вариста синең каның, синең холык. Миләүшә белән дә озак бәхәсләштеләр алар. Кыз үзенең киләчәген авыл белән бәйләргә ризалашкач кына өйләнешү турында сүз кузгаттылар...

Илфатка Гамилның мондый сүзләрен ишетү бик күңелле иде. Варисның аягында нык басып тора белүе өчен сөенеп туймады ата кеше. Еллар буе балалары күңеленә чәчеп килгән орлыкны җил алып китмәгән, шәһәр тормышы дигән кош-корт чүпләп бетермәгән булып чыга. Авылда да шәһәрдәгечә итеп яшәргә кирәк. Икмәк игүче моңа ирешә алмыймыни? Ирешәчәк!

Рәмзия килеп житмәгән иде әле. Илфат универсам янәшәсендәге киоскыдан газеталар алды һәм шәһәр бакчасы буена куелган артлы эскәмиягә утырып укый башлады. «Планета тормышы» — ул иң әүвәл шул тупланма белән таныша. Әйтеп бетергесез катлаулы чорда яшибез, гажәп киренке дәвердә, дип уйлый.

«Советлар куркынычы» дигән чеп-чи ялган тарату өчен ни көчәнәләр океан артында! Миләре сугыш сөреме белән агуланган сары алтын колларының тагын да явыз һәм мәкерлерәк максатлары бар. Кораллануның яңадан-яңа турлары совет экономикасын хәлсезләнүгә китерәчәк дип юаналар алар. Аннары Советлар белән көч позициясеннән сөйләшү җиңелрәк булыр, дип фикер йөртәләр...

Әнә шул рәвешле кешелеккә әҗәл хәзерләүче вандалларга каршы торырлык куәт, ихтыяр көче, ныклык, байлык кирәк безгә. Дөнья күләмендә уникә баллы өермә купканда да аякта ныклык басып торырлык, дошманны аяусыз кырырлык булырга тиешбез.

Яшьлек бәйрәмнәре — никах туйлары турында уйлаганда, тыныч-лык сагында уяу торырга кирәклекне дә истән чыгара алмыйбыз. Ил имин торса гына, һәркем имин булачак. Тыныч-лык безгә иң мөкатдәс ниятләребезне чынга ашыру өчен кирәк!

Күңел хозуры...

Башка чакта ансыз бер сәгать тә тора алмас кебек булса да, бу көнне Рәмзиянең эшкә китүен Илфат чыдамсызланып, тәкатьсезләнеп көтте.

— Соңгармыйсыңмы, Рәмзия?— дип сорады да хәтта.

Аны-моны уена китермәгән хатыны аңа каршы:

— Ниткән соңгару ди ул?— дип тыныч кына жавап бирде.— Әле ярты сәгатьтән артык вакытым бар. Монда ни... ике атлап, бер сикерсәң, мастерскойның түрендә буласың... Ә Казанда чакта, ни гомер эшләп, шулай да бер кичеккәнем булды.— һәм ул, Илфатны үчекләргә ниятләгәндәй, әллә кайчан булган вакыйганы иркенләп сөйләргә кереште.

— Ничәнче ел иде икән соң, кара бу хәтернең саегуын, житмеш икенчеме, әллә җитмеш өченчеме...

Күзе-кашы җимерелә язган Илфат, үртәлеп, дорфа гына әйтә куйды:

— Елындамыни хикмәт! Революцион вакыйга түгел ләбаса!

Рәмзия иренең борсалануын сизми генә түгел, киресенчә, үзен тәмләп тынларга җыена дип уйлый иде. Шуңа күрә бик канәгать булып сөйли башлады.

— Әйе шул... бер вакыт үз кул астымда эшли торган Дөбьяз кызы белән... Кара, кем иде соң әле исеме, ни атлы гына иде соң?! Биллаһи, Илфат, картаюым җитте, хәтер хәзинәм кимепме кими бит...

Илфат көлде, әмма каефсезләнеп көлүе иде бу аның. «Соңгармыйсыңмы?» дип соравына үкенүеннән көлүе иде. Шулай дип кыбырсынмаган булса, хатыны хан заманындагы хәлләрне хәтерләп утырмаячак иде бит. Моңарчы, мөгаен, тегү мастерскоена барып житкән булыр иде.

— Хәерле булсын, хикмәт ул кызның ни атлы булуында мени?!— диде Илфат чыдамсызланып. Аннары эченнән генә: «Мин барып житкәнче егетләр эшен бетереп куялар бит ул участокның!»— дип, пошынулы сөйләнеп алды.

— Әйе шул... Хикмәт исемендә түгел...— Рәмзия төгәл билгеле булмаган елда исеме истән чыккан кызга кагылышлы хатирәсен дәвам итте.— Каз өмәсенә дип кайткан идек шул кызларга. Бик чакыргач, бик кыстагач, күңелен кырмыйм дип ризалашкан идем. Галәмәт әдәпле, уңган бала иде үзе дә. Кайтканыма үкенмәдем. Каз өмәләрен менә дигән итеп уздыралар икән анда. Безнең Ташбуа тирәсендә суялар да йолкалар, юалар да элеп куялар түшкәләрне. Анда алай түгел, анда каз өмәсе — бәйрәм! Бәйрәмнең дә ниндие эле! Менә шунда тойдым мин әби-бабаларыбызның хезмәтне ничек матурлый белгәннәрен... Шу-ул, дүшәмбедә таң атуга кайтырга чыктык. Казанда эшләүче шофер егет утыртып алып китте безне. Әйбәт кенә барган җирдән машинасы шып туктамасынмы! Алай итеп карый егет, болай итеп бага, юк

кына! Машинасы төчкеренә, пошкырына да, тынып кала. Вакыт уза, безгә бит беренче сменага. Уйланып тордым-тордым да әйттем: «Болай булмый, сеңелем, мәйтәм, әйдә тәпили торыйк,— димен.— Аз булса да юл үрчесен, эшкә соңгарсам, гомеремдә булмаганны»,— димен. Сумкаларыбызны алдык та, миңа бер каз биреп җибәргәннәр иде, элдертәбез генә. Адымлап кына эш майтарып булмасын чамалагач, йөгерә үк башладык. Ярый әле, караңгы, кеше-кара күрәсе юк. Каравайга, тугызынчы трамвайга кайтып җитәргә кирәк ич. Аннары да, фабрикага барып ирешкәнче, күпме вакыт китә әле... Кыскасы, шул инде, сәгатькә якын соңгардык. Болай тәмсезләнмәделәр, иллә дә күңелгә авыр булды. Ниндидер юшкын калды. Сүксәләр, җиңелрәк буласы икән... Хәзер, каз түшкәлере күргәнем саен, шул хәлне искә төшерәм.

Рәмзия сәгатенә карады да ялт сикереп торды.

— Юраганың юш килә язды түгелме, Илфат. Вакыт бик җиткән икән ич миңа!— Ул киемнәрен янә бер кат рәтләштергәләде дә эшенә кузгалды. Илфат аның артыннан карап калды һәм «поход»ка җыена башлады.

Иң әүвәле куе зәңгәр төстәге комбинезонын киде. Аннары былтыр туздыра алмаган җиңел ботинкаларын эзләп тапты. Аларны киде. Ботинкалары иркенәеп калган төсле тоелды аңа. «Тәннән шул кадәр ит качты микәнни минем?» — дип имәнде Илфат. Аңа кинәт бик күңелсез булып китте. «Ябыкканымны белә идем, болай үк булыр димәгән идем»,— дип сөйләнде ул. Аннары, аптырагандай, кече якның өстәле буена барып утырды. «Да-а-а!— дип сузды.— Да-а!»

Бәхеткә, әлеге төшенкелек озакка бармады. Әллә каян килеп төшкән хисләр җанын яктыртып җибәрде, күңелдә басу шавы иде бит! Чоландагы чөйдән майланган кепкасын алып киде, аннары ныклап басарга теләп, көзге каршына атлады. Идәннән түшәмгә кадәр балкып торган көзгедән аңа еллар буе кыр киңлекләрен иңләгән механизатор карап тора иде. Туп-туры гына басып торганда, батыр да батыр, Илфат та батыр. «Тик менә басып торганда гына шул, рәешкә генә,— дип көрсенде ул,— тегендә ни эш кыйратырсың икән? Анда бит көзгедәге сурәт кирәкми, көч-гайрәт кирәк, агай-эне! Тилемсәләнеп йөрмәскәме соң әллә? Чишенеп ыргытырга да, түшәккә барып ятаргамы? Юк, чыгыйм әле кырга, чыгыйм. Арт тыкрыктан гына элдертим, кыймылдыйм әле. Шул басуны янә бер үз күзләрем белән күреп кайтыймчы. Бункерга гөжләп аккан бөртекләрне кушучлап бер исним әле...»

Ул үзләреннән ике-өч өй аша гына сузылган тар тыкрыктан Зөя буена чыкты. Сәер бер халәт кичерә иде: гүя кемдер аны абайлар да, качып барган бәндә санап туктатыр: «Нишләп йөрисең әле син сырхау килеш, иптәш Маннуров? А ну назад! Кайт та ят! Синнән башка да уракны очлап чыгарбыз, тузга язмаганны буталып йөрмә әле, яме»,— дияр төсле. Әлбәттә инде, алай диюче булмады. Каршысына очраган бала-чага исәнләшеп узды, капка төбенә чыгып, таяк таянып утырган йөзьяшәр Сабиржан абзый сәлам биреп калды. Шул гына. Картның үз уе үзенә җиткән иде бугай, Илфат хакында уйлап та бакмады шикелле. Барамы Күке Фәйзерахман малае басуга? Бара! Хуш, бара бирсен!

«Бара бирсен! Әйтергә ансат, чынында аяклар әүвәлгечә көч-кодрәтле түгел шул, юк. Күпме генә әрсезләнмә, авыру зәхмәте үзен сиздереп тора. Йөрәк исә тынгы белми. Белергә дә теләми. Ул канәгатьлек тоймый. Аның җиде тир чыкканчы эшлисе, рәхәтләнеп бер шатланасы килә. Илфат бу кадәресенә бик сөенә, йөрәк җилкенүе булганда, киләчәккә төпле өмет бар дип уйлый. Сәламәтлек кайтырдай булмаса, җан бу тикле канатланыр идемени? Ул шулай исәпли, шул уйларын һичнигә карамый ныгытасы килә. Сүнәсе, бөтенләйгә суласы булса,

күңелгә сүнек оялый диләр ич... Юк әле, иптәш, юк, бирешү хакында уйларга иртәрәк әле. Ул хакта шайтан кайгыртсын! Яшибез әле, дөбердәтеп яшибез! Туган басуларда без майтарасы эшләрнең чуты юк. Тан йолдызыбыз тиз генә сүнмәс, өметебез өзелмәс әле...

Зөя буеннан уңга күтәрелеп, бодай кырына аяк баскач, Илфат бер мәл туктап торды, кыр ышыклау урманы буеннан ишетелгән комбайн гөрелтесенә колак салды. Әйе, эшлиләр егетләр, урдыралар. Яңа комбайнда урдыруы үзе бер рәхәт инде ул, әй!

Мотор гөрелтесе йөрәгенә дәва бит бу кешенең, шунлыктан аның күңел күге биегәеп китте. Илфат адымнарын тизләтә төште, мәгәр беркадәр атлагач тойды: артыгын кызулый алмый шул әле, алмый. Әнә бит маңгайга тир бәреп чыкты. Комбинезоны кесәсеннән кулъяулыгын алып, битен, муен тирәләрен сөртте, җилләнгәндәй итте.

«Болай гына булыр инде ул,— дип юанырга тырышты Илфат.— Чакрым артык җир киткәч, шушы җәһәннәм кызуында тап-таза кешең дә сизми калмас. Бирешмик әле, Маннуров иптәш, бирешмик! Шайтан бирешсен, шайтан сукрансын!..»

Комбайн штурвалын тоткан Варис үз күзләренә үзе ышанмады. Басуның аргы башыннан килеп баручы кешене җентекләбрәк карыйсы итеп, агрегатын туктатты. Әйе, әтисе! Үз кешесенең сөяген сигез чакрымнан да таный инде ул адәм баласы. Нишләве бу әткәсенең? Врач ике сүзгә урын калдырмаслык итеп әйтте бит аңа: «Быелга, Илфат абый, басуны онытып торасың. Киләсе елга күз күрер»,— диде. Ә ул, тынгысыз да, тынлаусыз да жан, авылдан өч чакрымдагы җиргә тәпиләп килә. Йә, ни әйтерсең шуңа, әйтеп ышандыра алырсыңмы ул кешене? Үз туксаны туксан. Җиргә ябышып ятуның да бер чамасы буладыр ла инде! Әллә соң мин аңламый торган берәр хикмәт бармы монда?»

— Ни булды? Ник туктадың, абый?

Харис күңеле белән әллә кайларда, нидер уйланып бара иде бугай, комбайн туктагач, йокыдан уянып киткәндәй булды.

Варис, авыл ягына баш кагып, энесенең соравына сорау белән җавап кайтарды.

— Күрәсеңме, кем килә?

Харис абыйсын ым кагудан ук аңлап алды. Аның да күзләре шар булды.

— Ну, әткәй, бу тикле дә кырмыскалы йөрәк булырсың икән!— дип куйды ул, үтә борчылып.

Әтиләре, билгеле, бу сүзләрне ишетми һәм үзен шәйләп алганнардыр дип тә уйламый иде. Ул салмак кына атлап комбайнга якынлаша бара, әллары, сабак-саламга кыска булса да, башакка быелгысы корылыклы ел өчен ярыйсы гына ужым бодаен урдырып, аңа каршы кузгалдылар. Быелгы дәһшәт-көйдергечтә дә мондый уңыш үскәч, кыр ышыклау урманы буенда дым һәрчак артыграк булганлыгына иман китермәс хәлең юк...

Менә маңгайга-маңгай диярлек килеп терәлделәр. Егетләр комбайнны туктатып, камыл өстенә төштеләр.

Берничә мизгел сүзсез торгач, Илфатның ике улы бер авыздан:

— Нишләп йөрисең, әткәй? Бу хәлендә өйдә генә утырсаң соң инде,— диделәр.

Илфат, кара тутлы, тузынкы кашлы, яңак сөякләре күпереп торган йөзенә нур чәчкән сыман, ак тешләрен күрсәтеп елмайды. Аклану эзләгән кешенең ничарадан бичара елмаюы иде бу. Гәүдәгә шәп, ныклы бәдәнле, тамырлары бүртеп торган көрәктәй куллы кешегә бик үк ябышып та бетмәгән елмаю.

— Сез нишләп ятасыз икән дип килдем. Көздән үзем чәчеп калдырган басу лабаса!

— Рәмзия ападан качып чыктыңмыни?— Варис кырыс кына шулай сорап куйды.

— Соң ул эшкә китте инде, мастерскоена...

— Өзлегә калсаң нишләрбез?— Монысын Харис сорады.

— Әй, улларым, улларым!— Гаилә башлыгының елмаюы юкка чыккан иде инде. Тавышында зар галәмәте.— Басуга чыккач, өзлегәмме соң?! Авылдан бер ара киткәч, хәлсезләнгән кебек идем, башаклар кыштырдавын тыңлап килә торгач, тереклек суы эчкән кебек булдым. Кырык елга якын гомереңне шушы кырларда уздыр да, шунда килү бәхетеннән өзлегеп китме? Башыгыз яшь шул әле, белмисез, төшенеп житмисез...

Варис әтисен кызганып куйды, шулай да моны сиздермәскә тырышты. Юри кырысрак итеп:

— Нәрсәне белмибез? Син белгән, син яраткан һөнәрне сайладык. Син эшләгән басуларда эшлибез,— диде.

— Ул кадәресе өчен күпме сөенгәнемне үзем генә беләм. Анысына рәхмәт, улларым. Бабагыз исән булса, башыгыздан сыйпар иде. Инде, зинһар, комбайнда басуны бер әйләнеп чыгыйм. Кайсыгыз белән, йә?

Егетләрнең карышыр хәлләре калмады. Ничек итеп гомер буе механизатор булып эшләгән әтиләренең гозерен санга сукмасыннар?!

— По старшинству!— диде Илфат.— Варис белән кузгалып карыйк әле. Хәерле минутлар булсын!— ул ипләп кенә комбайнга менде.

Кузгалдылар.

Бу минутта Илфатка дөнья малы да, дан-шөһрәт тә кирәкми иде. Әлеге минут, бик ихтимал, илле яшенә житеп татыган иң ләззәтле минуты булгандыр аның.

«Берүк кәефе начарлана күрмәсен иде!» дип, чын-чынлап хафаланып барган Вариска да жан керде: алышгырып куйгандай булды ич әтиләре! Жырлап жибәрергә теләгәндәй бара. Күзләрендә шатлык очкыннары биешә, чыраенда әйтеп аңлаткысыз горурлык... Бәхетле минутлар шундый буладыр, күрәсең...

Икенче әйләнешне Илфат кече улы белән узды. Бу юлы штурвалны ук үз кулына алды. Шуннан соң инде аны теләсәң нәрсәгә тиңлә идең: бөркеткәме, тулпаргамы, арыслангамы!

Мөлдерәмә тулы бункерны агрегат янәшәсенә килеп сыенган йөк автомашинасы әрҗәсенә бушатканда, Илфат алтын бөртекләрне кушучлап алды да, туя белмәс кешедәй, яңа уңыш ашлыгының хуш исеннән аерыла алмый торды. Автомашина кузгалып киткәч, ул, мотор тавышын басарга тырышкан төсле, кече улыннан кычкырып сорады:

— Күпме чыга? Гектардан дим?

— Беренче егерме гектардан исәпләгәч, унбиш центнердан артыграк диделәр, әткәй...

— Алай икә-ә-ән... Көйле килгән еллар өчен безнең туфрактан болай гына алу зур эш майтару түгел дә соң... Быелгы афәттә монысына да шөкер итми хәл юк. Алып житкермәгәнебезне көзгә жыештырырга кала...

Аннары алар кишәрлекнең аргы очына кадәр сөйләшми генә бардылар. Һәркайсының үз уе иде. Харис әтисенең осталыгына сокланып барды. Илфат, сафка кайтачагына ышанычы артып, күңелендә пар канат үскәнен тойды. Тик... куаныч озакка бармады, кыска гомерле булды.

Ташбуа юлында колхоз председателе Кәрим Вәлиев машинасы күренде. Район үзәгеннән кайтышы. Комбайннар янына кагылып чыгарга уйлаган.

Председательнең килеп житүе булды, Илфатны күрүе булды, аның үзен дә, улларын да утлы табага бастыра башлавы булды.

— Илфат абый! Төш, утыр минем машинага! Кайтарып яткызам урыныңа, өстеңнән биклим.— Монысы — Маннуровларның өлкәненә катгый әмер иде.— Мин синең саулыгың өчен персонально җаваплы. Ә сез,— монысы егетләргә шелтә,— этиегезне кабат аяктан егарга җыендыгызмы?

Илфат та тел тешләп каласы итмәде.

— Җикеренмә әле бик, Кәрим энем,— дип ризасызлык күрсәтте.— Мин синең сугыш кырында ятып калган этиеңнән ун яшькә генә кече. Савыктым мин басуга чыгып, бик беләсең килсә. Савыктым прәметәки...

— Беләм, Илфат абый, бәхәсләшмә! Герой механизаторыбыз әлегә берәү генә безнең. Син киләчәк еллар өчен кирәк безгә. Утыр машинага!

Илфат һаман карулаша бирде.

— Приказлама! Герой Йолдызын алганда биргән вәгъдәмне райком секретаре үзе ишетеп торды. Тоттым жалуладым булыр первыйга... Кави Салихович мине яхшы белә...

Кәрим бер мәлгә сүзсез калды. Аннары чыдамады, ихтыярсыз көлемсерәп:

— Дивана!— диде. Бу — аның яратып әйтә торган сүзе.— Мин үзем дә райком бюросы члены бит. Ә Кави Салихович синең саулыгыңны сорашып кына тора...

Председательнең «дивана»сы боларның иннәреннән таш төшергәндәй итте.

Өлкән механизатор председательнең «Волга»сына кереп утырды һәм үз алдына сукрана башлады:

— Шулчындый да авыр елда ярдәмем тимәсме дигән идем. Миңа бит ул җирнең һәр карышы, анда үскән ашлыкның һәр бөртеге газиз. Председатель дигәч тә, мине басудан сөрергә...

Хаклык хакына шунысын да әйтү кирәктер, Кәримгә рәнҗүе ничаклы зур булмасын, бүген татыган рәхәте чамасыз иде Илфатның. Күңел хозурлыгы тасвирлап бетергесез иде.

Председатель белән сүзләрен бетергәч, агалы-энеле Маннуровлар кыр корабын гөрләтеп, китеп бардылар. Табигать аяусызлыгы белән бәхәсләшеп һөҗүмгә ташланган сугышчыларны хәтерләтәләр иде алар.

«Әйе,— дип фикер йөртте уллары өчен сөенгән Илфат,— игенчемен дигән игенче җирдә кысыр чәчәк булып яши алмый, үзенең бар булдыгын, туган туфрагына мәхәббәтен, осталыгын, тәҗрибәсен бүтәннәр белән дә уртаклашмый кала алмый. Аның вөҗдане һәм киләчәккә ышанычы кулыннан килгән изге гамәлләрнең һәммәсен кылырга, күңелендәге бай хәзинәдән башкаларга да өлеш чыгарырга куша. Җиргә береккән кеше ялгызак калса, башы михнәттән чыкмаячак. Хезмәттәге батырлыкның әхлакый асылы яудагы кыюлык һәм каһарманлыкның әхлакый тамырларына бик якын...»

Соңгы сүз

«Көз — елның сагышлы фасылы, аерылышулар вакыты»,— диләр. Бәлки, бу сүзләрдә хаклык та бардыр. Шулай да Илфатның моның белән алай ук килешәсе килми.

Көзләрен очар кошлар җылы якларга юнәлә. Алар белән саубуллашу моңсу була. Көз життеме, урман-аланнарга, үлән-чәчәкләргә лимон сарысы суга. Без җәйге матурлык белән хушлашабыз. Ул кадәресе дә җанга моңсулык өсти. Көз — егетләрнең армиягә китә торган чакла-

ры. Әмма бит алар кайтмаска китмиләр. Язлар җиткәч, очар кошлар кире кайткан, табигать янә гүзәллеккә төренгән кебек, солдат егетләр дә көннәрнең берендә туган ояларына кайтып керәләр. Дөньялар гына имин торсын! Шулай икән, сагышланудан битәр көзнең муллык китерүенә сөенергә, алтын көзне шуның өчен яратырга кирәк...

Менә берсекөнгә — авыл хуҗалыгы эшчәннәре бәйрәменең иртәгәсен — Илфат та төпчек улын солдатка озатачак. Аерылышу, димәк. Әмма Маннуровлар гаиләсендә моның өчен берәү дә ут йотмый: егет бит ир-ат иңенә төшкән мактаулы бурычны үтәргә китә.

Бүген исә әле Илфат Маннуров өендә күрешүләр, танышулар көне. Иң күңелле, иң матур, иң мәгънәле көннәрнең берсе. Авыл фидакарьләренең елның-елында уздырыла торган тантанасына Казаннан герой-механизаторның кодасы Гамил, кодагые Зәйтүнә, өлкән улы Варис белән Миләүшә кайталар. Авылдагы кызы Зөбәйдә белән кияве Даниял киләсе.

Әлегәчә күз күрмәгән кунак та булачак. Рәмзиянең Себер нефтендәге улы Хәйдәрдән телеграмма алдылар. «Октябрьның тугызында сездә булам» дигән.

Телеграмманың икенчесе дә бик куанычлы. Анысын Белоруссиядән Детдом Женя, ягъни Евгений Иванович Логинов суккан. «Илфат дус! Капкаңны ачык тот, Наташа белән икәүләп кайтабыз», дип язган. Сабан туена кайту насыйп булмаган иде, соң булса да уң булсын, кичке поездны каршыларга кирәк.

Хәбиб абзый Гайсин да Гөл-Төркем якларыннан бер әйләнәм әле, дип бик җилкенгән иде дә, морадына ирешә алмады. Дөнья куйганына икенче ай китте. Хәер, гомерләрен ил-көнгә багышлаган андый кешеләр үзләренең якты истәлекләре белән гел безнең арада калалар.

Буа—Апас—Казан.
1981—1982 еллар.

Илдар Юзеев

ОЛЫ ЮЛНЫҢ КАЕНЫ

ПОЭМА

Өлкәнәйгән саен күңел һаман
Якынайта ике араны:
Синең белән очрашырга кайттым,
Саумы, туган авылым Ямады!
Юл читендә әллә аккаеннар,
Әллә кырлар шулай сузамы?—
Иске көйгә яңа җыр ишетәм,
Таныйм: «Олы юлның тузаны».
«Җилләр исә, ни өчен соң
Юк бу юлның тузаны?
Асфальт асларында калган
Хәсрәтләрнең узганы.
Тузан эченә күмелгән
Без кичергән нужалар,
Без елап узган юллардан
Яшьләр җырлап узалар.
Олы юлның тузаннарын
Онытмыйлар олылар,
Без үткән салкын юлларда
Калды безнең җылылар»...
Олы юлда төшеп, авылымның
Кече урамына узамын.
Иң беренче булып сиңа керәм:
Ач ишегең, Фәндүс туганым!
Һаман сине эшкә озатадыр
Авылымның тыныч ал таңы...
Эшләр ничек бара?
Бригадаң һаман алдамы?
Шушы җирдә сөрдең, тырмаладың,
Иген иктең, җәйләр җәйләдең...
Һәм нефтьче булып авылыбызны
Ил-йсрт, дөнья белән бәйләдең.
Ямады!
Төрле елда, төрле дошман килеп,
Туган җиребезгә янады,
Балаларың Җирнең кайсы гына
Ноктасында ятып калмады...

Бабаларым малчы игенчеләр
Булып яшәүне дан санады,
Изге һөнәрен дә югалтмады,
Нефтьче дә хәзер Ямады!
Шәҗәрәмне актарганда, Фәндүс,
Горурланам синең белән мин:
Бөтен тирә-якта ат казанган
Мастер икәнеңне беләм мин.
Ә нигә соң сирәк очрашабыз,
Ничә еллар инде — күргән юк,
Элеккечә төнге урамнарда
Икәү бергә җырлап йөргән юк.
Онытылып яткан гармуныңның
Тузаннарын кагыйк әле бер,
Өлкәнәйгән хисләр яшәрерләр —
Яшьлек кайтмаса да — барыбер...
Кире кайткан ярсу көйләребез
Ярлар сөйсен, кызлар урласын,
Гармуныңа тузан кунса кунсын,
Хисләреңә тузан кунмасын!
Узганнарның тик бер генә кичен,
Тик бер кичен гармун кайтарсын,
Ул кич яшьлек булып качып калсын,
Исеме, әйдә, картлык аталсын!
Онытылып яткан гармуннарда
Яшәрүнең сере бар сыман...
Калды яшьлек, үкереп яна-яна,
Насыйп булалмаган яр сыман.
Бер төн кунакка дип барыйк әле,
Яшьлектә — юк күптән булганым,
Аулак өйдә торып калыйк әле,
Бер сөйләшик, Фәндүс туганым...
Син нинди җыр җырлый идең әле?..

Мин уйнаган, Фәндүс җырлаган җыр

Туган якның каеннары калалар инде,
Озатыша баралар инде,
Йөрәгемдә яфракларын яралар инде,
Сагышларга салалар инде.
Каеннарым арттан калмый чабалар инде,
Ерагая аралар инде.
Киткән саен якыная баралар инде,
Сагынудан дәвалар инде.
Туган якның каеннары калалар инде,
Кемнәр сөеп карарлар инде,
Гомерем буе миңа таба чабарлар инде.
Кайтмый һич тә калалмам инде...
Бу тормышның кырыс үз көе бар:
Без дигәнчә бармый һич тә ул...
Ишегеңдә — йозак...
«Җир астында тагын авария...
Эштә ул...»

Авылдашларга культура сараенда укылган шигырь

Скважиналарга җир асты ремонты үткәрү мастеры Фәндүскә багышлыйм

Син, туганкай, үзең — җир остасы,
Җыр остасы дисең син мине...
Җырсыз-моңсыз яшәп булмагандай,
Җирсез яшәп булмый, билгеле.
Баһадирга тиң гомерең синең
Илгә күпме байлык тапшырган.
Көнен-төнен туктамыйча ага
Туган җир астыннан ташкыннар.
Әле урман, әле кырларда сез,
Давыл-буран, пычрак, тузанда.
Нефть гел тиешле җиргә аксын:
Авария кайда — сез анда.
Колакларың, бәлки, сәерсенер
Зурдан кубып әйткән сүземә:
Авария яный түгелме соң
Менә бүген Җирнең үзенә?
Миллиард еллар яшәп Җир дә тузган,
Ул игътибар сорый, онытмыйк,
Әйдә әле, Фәндүс, Җиребезне
Авариядән саклыйк, ремонтлыйк!
Шундый ремонт кирәк Җир шарына,
Белмим, хәтта ничек атарга:
Кешелеккә каршы коралларның
Шәрепләрен борып атарга!
Илле дә шәп булыр иде, Фәндүс,
Җирнең күчәрен дә майласак,
Аны, шулай итеп, гел яхшыга
Таба әйләнүгә җайласак...
Без һәммәбез бүген ремонтчылар:
Оста түгелме син, остамы...
Җиребезгә авария яный:
Ремонтчылар бар да посттамы?
Бәлки әле килгәнсеңдер диеп,
Халык арасыннан эзләдем,
Балачактан таныш, ихлас йөзләр...
Тик... күренми синең күзләрең.
Яратумы, әллә ихтираммы...
Зал, алкышлап, бердәм кул чапты.
Фәндүскәме, әллә авторгамы?
Аңлап җиткермәдем ул чакны.
Җиргә түгел, ул чак үзеңә бит —
Сиңа авария янаган...
Больницада шәфкать туташлары
Яшәү сәгатьләрен санаган.
Яшәү!
Кадереңне бер дә белмибез шул,
Үзең — көчле, төнең — нык булгач,
Тик уйлыйбыз синең турыда без
Хәлсезләнеп, авырып егылгач...
Рәхәтләрең, газапларың белән
Син барыбер матур күренгәч,

«Белер идек кадереңне!» дибез,
Тагын онытабыз... терелгәч.
Яшәү!
Күз яшедәй ачы,
Балдай татлы син...
Аңлап бетереп тә өлгермисең...
Йөз-мең катлы син!
Әле генә нинди якты иде:
Кич җиткән...
Палатага керәм... һәм Фәндүснең
«Яшәү!» дигән тавышын ишетәм.

Фәндүс белән очрашу

Синең белән менә монда түгел,
Өйдә очрашырга иде дә...
Язмыш безне күрештерде шулай
Больницада, кичке җидедә.
Сиңа багышланган шигыремдә
Кайгыртканмын бары Җир хәлен,
Ник белмәдем, нигә уйламадым
Җирне кайгыртучы ир хәлен...
Нигә еш очрашып сөйләшмәдек,
Син дә оста, мин дә оста бит...
Минутлары сзын тоелса да,
Һай, бу гомер — бигрәк кыска бит!
Синең кебек янар җаннар белән
Күпме яшәсәң дә, аз сыман...
Мин — шигырьдә, син — гел эштә яндың,
Буш янмадык факел-газ сыман!
Юк, ашыкмыйк әле кайгырырга,
Аңлашулар бар да алдадыр,
«Әлдермештән Әлмәндәр»дәгедәй,
Әҗәл кире китәр, алданыр...
Нигә иреннәреңкүм-күк көйгән?
Чак таныдым: Фәндүс идең син...
Кайнар-тирән сулышларың белән:
«Яшәү»... дидең син.

Мин

Фәндүс, нихәл?

Фәндүс

Илдар?.. Килдеңме?

Мин

Хәлең ничек?

Фәндүс

Эшкә... иртәгә...

Мин

Докторларны тыңла. Шәп дәвалан.
Бик ашыкма моннан китәргә.

Фәндүс

Һаман шулай... күктә... йөрисеңме?

Мин

Менә... төштем синең яныңа.

Фәндүс

Туры килдең... мескен чагыма...
Илле еллыгыма кайталмадың...

Мин
Шул... эш инде...
Фәндүс
Бик шәп... айда кил...
Тар урамнарны... киңәйтеп...
Икәү... җырлап... йөргән... майда кил...
Мин
Мин килермен...
Очрашырбыз, Фәндүс,
Ә вакытны төннән урларбыз.
Йокламабыз,
Урам әйләнербез,
Таң атканга кадәр җырларбыз...
Фәндүс
Заһит, синме?
Өлкән мастер
Әйе, Фәндүс абый.
Фәндүс
Киттек эшкә...
Хәзер бүрек киям...
(Кулы югарыга үрелә.)
Әнә анда... тышта... тәрәзәдә...
Подъемникмы... нәрсә... күренә...
Айрат улым... синме?..
Айрат
Мин, әткәй...
Фәндүс
Нигә... җыелдыгыз?..
Син... кайдан?
Айрат
Участоктан.
Фәндүс
Скважина ходка киттеме?
Айрат
Китте, әткәй!
Фәндүс
Аккаеннар... акмы?..
Айрат
Ак, әткәй...
(Ул күзләрен йомды, тагын тынды.)
Ах, әткәй!..

Доктор!
Бик еш мактанабыз һәм хаклы да!
Медицина дигән фән үсте!
Аның гомере күпләр өчен кирәк:
Коткарыгыз, зинһар, Фәндүсне!
«Кеше үз-үзен дә ремонтласын,
Кеше үз-үзен дә сакласын,
Үз гомерен үзе озынайтсын,
Докторлардан көтеп ятмасын...»
Әйе, доктор, сүзләрегез дөрес:
Тимер түгел ми дә, йөрәк тә...
Кеше — кирәгенчә эшләсен дә,
Ял итә дә белсен кирәктә.
Ничек ял итәргә һәм яшәргә?
Доктор иптәш, өйрәт син безгә,

Әйе, шулай, безнең ял итүләр
Куелмаган фәнни нигезгә.
Яхшы аңлый моны гомерләре
Тоташ ялдан гына торганнар,
Тик үзләрен генә саклаганнар,
Үз тормышын уңай корганнар.
Берәү Җирне тота иңнәрендә:
Бу тормышны гөл дә ал итә,
Ә берәүләр алны-гөлне алып,
Бәйрәм итә, гел-гел ял итә.
...Гомерендә бер ял йортына барган,
Качып кайткан бик тиз аннан да...
Фәндүс!
Кәккүкләрнең тавышын тыңлап кына
Ник ятмадың иркен яланда?
Әйе, Фәндүс, доктор дөрес әйтә:
«Гомер бик кыска бит болай да...»
Ник ятмадың зәңгәр күккә карап,
Су коеныл Кәшти тугайда?
Доктор дөрес әйтә...
Ник ятсын, ди, Фәндүс көннәр буе
Елга буйларында, урманда...
Айлар, еллар буе, гомер буе
Комда ятучылар булганда?!
Ник ял итсен Фәндүс, җаны түзеп,
Ник туктасын кибет янында,
«Тик йөз грамм гына!» өмет итеп,
Яшьтәшләре йөргән чагында.
«Нишләр идә микән?— дисезме сез,—
Шул гомерне бирсәң кабаттан?»
Тик... бары тик шулай яшәр идем!—
Табигате шулай яраткан.
Карточкасын эзләп табалмыйлар...
Чирләгәнме?
Бик еш чирләгән.
Бер тапкыр да ләкин, үзе теләп,
Больницага килеп кермәгән.
Менә хәзер аны дәвалагыз,
Медицина дигән фән үсте!
Тормыш өчен ул бит бик, бик кирәк:
Коткарыгыз, зинһар, Фәндүсне!
Доктәрлар да,
Шашып елаулар да,
Берни коткаралмый шул инде...
Бу тормышны өзелеп сөйгән күзләр
Иртә-таңда мәңге йомылды.

Гомер-елга.
Борылып карарга да өлгермәдем...
Актың да киттең.
Яшьлектәге татлы яшьләр сыман
Актың да киптең.
Гомер-елга,
Ник коймадың
Син мәңгелек дигән диңгезгә?
Мәңгелекнең бер мизгелен генә
Бүләк итәсең ич син безгә.

Яшәү — яшәү түгел, үткән гомерең
Саф чишмәдәй челтерәп калмаса,
Агып кипкәч, көмеш челтерәүләреңә
Йөрәкләргә күчә алмаса...

Фәндүснең рәсеме

Үзем белән бергә алып кайтам,
Бирмим сине, бирмим үлемгә...
Гәүдәң — калды, ә рәсемең — кулда,
Җанлана да инде күңелдә.
Юк, калдырмыйм салкын мәңгелектә,
Хыялларым белән терелтәм,
Терелтәм дә киләчәккә илтәм,
Каеннарга кара гел иртән...
Иреннәреңә елмаерга теләп,
Кинәт җитдиләнгән шикелле,
Кара кашлар, соры күзләреңдә
«Яшәп туймам!» дигән шикелле.
«Минем күзләр,— дигән идең бер чак,—
Ат күзләре кебек тоныклар...
Бабам аттан артык эшләгән, дип
Искә алыр, бәлки оныклар...»
Җилгә-давылларга буйсынмыйча,
Назны сирәк тойган чәчләреңә
Үзләреңчә калсын, күчермәсен
Каеннарның ап-ак бәсләрен.
Әйтсәң дә син: «Бигрәк кыска буем,
Бакчамдагы күчән төслерәк».
Юк, күчән дә, юк, күчәр дә түгел,—
Син үзеңнән хәтта көчлерәк!
Үзем белән бергә алып кайтам,
Бирмим сине, бирмим үлемгә.
Гәүдәң — калды, ә рәсемең — кулда,
Җанлана да инде күңелдә...
Аның рәсемен шулай кулдан-кулга,
Елдан-елга — чорга күчерик.
Гореф-гадәт шундый... күмеп кайттык...
Әйдә, үзен искә төшерик.
Үзенә башка, кабатланмас шәхес:
Җирдә бүтән андый кеше юк...

Беренче истәлек

Без, биш бала, өелеп ятим калдык...
Башта — әнкәй, аннан — әткәбез...
Никадәре кырыс булса да, юк,
Без тормышка ләгънәт әйтмәбез.
Ун яшеннән Фәндүс кырга китте.
Камыт киде, «авыр!» димәде,
Апалары үзен кызганганны,
Баштан сыйпаганны сөймәде.
Без балавыз сыксак, камчы тотып:
«Җитте!» диеп кенә туктатты,

Кичен кайтмый калсак, эзләп чыкты,
Иртән иртүк эшкә уятты.
Утын-салам ташый, печән чаба,
Сабан сөреп кырдан кайта да,
Үзе һич буйсынмый авырлыкка:
Ул — ана да, безгә, ата да...
Авыр чакта әле юата да:
«Нишлисең бит, кыен, сеңелләр...»
Апа дими... Каеннарга карый:
«Сез бит миңа «каен сеңелләр».
Һәр баласы туу хөрмәтенә
Әткәй утырткан ул биш каен
Бала йөрәгендә тамырланып,
Назлап торган туган йорткаен.
Ютәленнән буылып әйтте әткәй:
«Изге сугыш барган вакытта,
Авырумын дип яту һич килешмәс,
Эшкә китәм,— диде,— заводка».
Башта безгә,
Аннан каеннарга
Туган йортка карап тын калды.
Әткәй китте.
Каеннарга эленеп
Ул яраткан ядкарь-җыр калды:

«Туган якның каеннары калалар инде,
Озатыша баралар инде,
Йөрәгемдә яфракларын яралар инде,
Сагышларга салалар инде...»

Өч елдан соң кайтып керде әткәй...
Өйгә килеп җитми егылган...
Терсәкләре белән шуышып барган.
Без күтәреп алдык аны бишәү
Яшелләнеп яңа яфрак ярган,
Соңгы юлга аны озатып калган
Каенлыктан — шушы урыннан.

«Туган якның каеннары калалар инде,
Озатыша баралар инде,
Йөрәгемдә яфракларын яралар инде,
Кайтмый һич тә калалмам инде...»

...Язын күкрәп үскән биш каенның
Яфраклары карга күмелгән.
Фәндүсебез җырлап туялмаган
Шул җыр китмәс инде күңелдән.
Апаларың, сине туган күреп,
Ярдәм итмәк булсак,— үз сүзең,—
Усал гына әйтеп куя идең:
«Үзегезне караң! Мин — үзем!»
Хәзер мин кадерләп искә алам
Мәрхәмәтсез, каты чагыңны.
Тупаслык ул битлек кенә булган,
Яшерү өчен нечкә җаныңны.
Күзләреңә гел мөлдерәмә тулы...
Түгеләм-түгеләм диеп торалар.
Андый күзләр бары кеше күңелен
Аңлый торганнарда булалар.
Төче сүзләр һич тә әйттермәдең...
Ишетмисең син — үзкәебез,

Үзебез өчен генә әйтәбез тик:
Кадерлебез, Фәндүскәебез!
Үкереп-үкереп бер елар да идем
Сулкылдавын тыеп йөрәкнең:
«Җебемә!» дип усал әйтерсең күк,—
Безне һәрчак шуңа өйрәттең.

Икенче истәлек

Кырда салам тарттырабыз,
Фәндүс — унике яшьлек.
Эссе. Бөркү. Фәндүсне без
Су коенырга дәштек.
Төштек атларга атланып,
Уйламый-нитми шундук,
Атларны ярда калдырып,
Кәшти тугайга чумдык.
Фәндүс һаман ат янында,
Тыелалмый ачудан,
Кычкыра бөтен тугайга:
«Ну-ка, чыгыгыз судан!
Синнән алда кем иң авыр
Йөкләрне тартып бара?
Көн буе, атлар шикелле,
Авырлык тартып кара...
Син башта — атны коендыр,
Син башта — атны кара!»

Өченче истәлек

Бригадада унау идек,—
Бер кешегә ким калдык,
Юк, ким генә калмадык без —
Гүяки ятим калдык.
Бер сәбәпсез эшкә чыкма
Яки соң килеп кара,
Кул белән түгел, тел белән
Камчысыз-нисез яра!
Авыр хәлдә калсаң, үзе
Кайгыртып йөри, чаба,
Үз әткәңнән ишетмәгән
Иң җылы сүзләр таба.
Юлдан чыккан малайларны
Тәртәгә кертер иде,
Эт итеп тиргәр иде дә
«Улым» дип йөртер иде.
Әйбәт эшләгән һәркемнең
Урыны түрдә иде,
Бригаданың дәрәҗәсе
Һәрвакыт үрдә иде.
Бездән башка аш-су капмас
Тик бер генә йотым да...
Җырлап бара иде эшләр
Тигез, шома ритмда...

Нинди генә бәлаләргә
Үзебез чик куймаган...
Төзәлмәслек авария
Килер дип кем уйлаган?
Бригадада унау идек,
Бер кешегә ким калдык,
Юк, ким генә калмадык без,
Гүяки ятим калдык...

Дүртенче истәлек

Табигать кыштан уянып,
Сулыш алган чакларда,
Аккаеннар рәхәтләнеп
Яфрак ярган чакларда,
Урман өстенә атылды
Нефть һәм газ фонтаны.
Тирә-якны, алсу таңны
Кап-кара төс каплады.
Өстәмә ярдәмнәр сорап,
Туктаттык бу афәтне.
Күрсәгез иде шул чакта
Безнең төс-кыяфәтне:
Адәм танырлык та түгел,
Ансы әле — түзәрлек.
Эзлибез ак каеннарны...
Кая киткән гүзәллек?
Үсә иде яфракларын
Яра-яра каеннар...
Кара кайгыдан иелгән
Кара-кара каеннар...
Яшәртергә, агартырга
Нинди тылсым табыйк, әйт...
Саклап кала алмадык шул,
Кичер безне, Табигать!
Аккаеннар белән бергә
Үзебез дә каралдык.
Бер-беребезгә бер сүз дәшми,
Телсез-өнсез таралдык.
Фәндүс абый бер ялгызы
Бик яман сулый иде.
Аңламадык, әллә елый,
Әллә ул җырлый иде:

«Их!
Каеннарым яфракларын яралар иде,
Җәйгә таба баралар иде,
Туган якның каеннары карълар инде,
Йөрәгемдә яралар инде...»

Фәндүснең сөйләгәннәрен искә алу

1

Мин әйттемме, бетте,— эшлим инде:
Мактансам да, хаклы мактанам.
Орденнары булды, ул гына аз,
Герой исеме алмый туктамам.

Күкрәк тулы орден, медаль, билге...
Йолдыз? Абзац тагар ансын да.
Алтын-тимерләрне җылытырлык
Йөрәк булсын аның астында.
Герой исемен әгәр бирмәсәләр,
Үпкәләмим... Берәр әсәрдә
Җырчы энем герой ясар әле
Поэмада... яки мәсәлдә...

2

Гөнаһым бар: яшь чак.. Председатель
Галим җизни атын урладым,
«Урла» диеп лично үзе әйткәч,
Мин үземә хатын урладым.
Атны кире илттем. Сизмәделәр
Абзагызның карак икәнен.
Әллә инде мин дә яратканмын:
Апагызны кире илтмәдем.
Мин дарыны алай коры тотам:
Апагызны, бик узынып китсә,
«Кире илтәм!» диеп куркытам.

3

Кычкырмыйча һич кенә дә
Чамалар юк түзәрлек:
Капчык тулы акча... акча!
Унарлык та йөзәрлек!
«Акча бездә бер бакча»! дип
Шашып йөрисе килә,
Җиргә сибеп, көрәк белән
Кабат көрисе килә!
Бар дөньяның ятимнәрен
Киендерәсе килә,
Ни теләсә — шуны алып,
Сөендерәсе килә!
Комсызларның алларына
Тезеп саласы килә,
Тегеләр үрелгәч кенә
Кире аласы килә!
Андый-мондый малай түгел,
Мал таба торган малай,
Акчасыз да, бакчасыз да
Яр таба торган малай!
Киттек, дуслар, ресторанга!
Сыйланыгыз, мин түлим!
Оркестрмы? Мә — йөз тәңкә!
«Каеннар»ны мин телим!
«Каеннар»ны!
«Андый җыр бездә юк!» дисез?
Табыгыз! Мә — мең булсын!
Ул җыр булмаса, башкасын!
Но... безнеңчә моң булсын,
Барыбер каен булсын!
«Карурман»ны уйнадылар...
Башны идем дә... тындым...

Каеннар бит карурманда...
Бер сүзсез риза булдым.
Шул чак карурман ягыннан
Акты моң, акты болыт...
Ап-ак каеннар күренде
Ак булып, якты булып.
...Исәп-хисапны өздем дә
Эш белән, дуслар белән,
Туган якларга юнәлдем
Яз көне кошлар белән.
Шахталарда үкенмәслек
Ун еллык гомер калды.
Рекордлар куеп өелгән
Мин чапкан күмер калды...

4

Җирнең өстеннән дә, астыннан да
Без үтәсе авыр юллар бар...
Шахталарда гел-гел уйлый идем:
Җир өстендә ничек, ниләр бар?
Хәзер инде күңелем — гел тирәндә:
Анда — без белмәгән серләр бар.
Доктор сыман ятып Җирне тыңлыйм:
Хәлең ничек, җаным, ниләр бар?

5

Осталарсыз, йортны үзем салдым,
Әйдә, саран диеп көлсеннәр...
Кимлегемне минем күрмәсеннәр,
Кемлегемне минем күрсеннәр!
Юкка түгел читтә, ераклarда
Җирнең өстен-астын айкавым...
Күреп торам «әйе» дигән сыман
Каеннарның башын чайкавын.

6

Минем кайнарлыктан үрнәк
Ала күрмәгез тагын...
Сөйлим әле технологның
Килеп бәйләнгән чагын.
Белеп торам инде, каһәр,
Бик хаклы әйткәнен дә,
Инструкция буенча
Дөрес юнәлткәнен дә...
Әйтеп куймасынмы шул чак
Югары гыйлем белән:
«Мин беләмме, син наданмы —
Дүрт класс белем белән!»
Үз-үземне белештерми,
Сыйпадым берне моңа.
Үкенергә бик соң иде
Килгәндә акылыма...
Җүләрлегем үземне дә
Тәмам аяктан екты.
Куркып калдым... Но егет тә

Молодец булып чыкты:
Жалу белән дә йөрмәде.
Мин — юлыннан бүлдермим.
Үкенәм инде, билгеле,
Но үзенә белдермим.
Моны сезгә генә сөйлим,
Эчтә калмасын өчен,
Фәндүс абзагызның хәлен
Яшьләр аңласын өчен...

7

Гөл итә белмибез, егетләр,
Ал итә белмибез, егетләр...
Әйт шуны, нигә без эчәбез?!
Ял итә белмибез, егетләр!..
Сандугач таңнарда чык эчә.
Ат кебек эшләдек, егетләр...
Сандугач булырдай затлар ич,—
Без әле нишләдек, егетләр?!

8

Юк, юк, чыкмый миннән крәстиянлек,
Үзем эшче дигән ат алдым,
Машина да түгел, эт тә түгел,—
Йортта тоту өчен ат алдым.
Ямь табалмыйм,
Ат ялына ябышып,
Иркен кырлар буйлап чапмасам,
Июль таңнарында, чалгы янап,
Тирләп-пешеп печән чапмасам.
Үз-үземнән сорыйм:
«Крәстиянме,
Әллә рабочиймы?
Я, кем син?»
Эштән өйгә кайтсам, крәстиян мин,
Өйдән эшкә барсам, эшчемен.
Эшче һәм крәстиян, бик хуш килеп,
Очрашалар минем җанымда...
Эшче Фәндүс мыек бөтереп тора
Крәстиян Фәндүс янында.
Эшче Фәндүс тыя, крәстиян
Малга ябышып яткан чагында.
Кайнар бәхәсләр дә чыгып ала
Кайчак, кызып, кичке табында.
Бер-берсенең сүзен аска салып,
Башта бәхәсләшкән булалар,
Аннан кочаклашып, бер үк җырны
Җырлыйлар да... тыналар.

9

Эшләгәндә мин үземне көчле
Һәм кодрәтле тоям.
Илгә, Җиргә киряклемен диеп,
Сөенеп тә куям.
Эшнең асылын мин, ямен-тәмен
Мәгънә-гамьдә күрәм.

Көйсез, ипсез, уйсыз-хиссез көчнең
Нәтиҗәсе — түбән.
Кеше дигән олы дәрәҗәгә
Бик ят булмыйк әле,
Нәкъ Тукайча: аттан артык эшлик,
Тик ат булмыйк әле!
Уйлыйм-уйлыйм да бер хәйран калам:
Ай-һай вакыт ага...
Ни арада шулай күтәрелдек
Аттан — ракетага!
Гамьле-ямьле эшнең урыны да
Иң югары төштә.
Шатланыйк без: күккә күтәреште
Безнең гади эш тә!
Күтәрелер Кеше киләчәктә
Кояшларга кадәр,
Эш, Акыл, Хис — бергә кочаклашып,
Дус булсалар әгәр!

Бишенче истәлек

Истә: кышкы сабантуйда[1]
Ярышкан чагы,
Атның дилбегәсе — кулда,
Аякта — чаңгы.
Йөзгә бәрә кышның зәһәр
Салкын бураны.
Егылса да, дилбегәне
Ычкындырмады.
Терсәкләре белән шуып
Калган араны,
Барды финишка кадәре...
Туктап калмады.
Бу сыйфаты килгән, димәк,
Балалыгыннан,
Үсә-үсә, күчә-күчә
Җанда ныгыган.
...Бригадалар арасында
Барган алышта
«Җиңүче» исемен яулады
Күпме ярышта...
Әмма нигә алдан килдең
Соңгы финишка?
Үлем аша үтәлмәде
Хәтта Фәндүс тә...
...Скважинага барырга дип,
Өеннән чыккан.
Йөрәгендә авария —
Аяктан еккан.
Тукталмаган, шул килеш тә
Тапкан чараны:
Терсәкләре белән узган
Калган араны.
Күтәреп алыйк дигәндә,

[1] Кышкы сабантуй — Башкортстанның Яңавыл якларында март аенда үткәрелгән спорт ярышларын кышкы сабантуй дип тә йөртәләр.

Каплады йөзен:
«Эшне туктатмаң... малайлар...
Мин... үзем...»
Матросовтай, соңгы һөҗүменә
Шуышып алга барган шикелле,
Нефть-газ ташкынын үз күкрәге
Белән каплап калган шикелле,
Һәлак булды...

Алтынчы истәлек

Көтелмәгән авыр зур югалту...
Гыйбрәт бар монда, уйласаң...
Без аңардан гел-гел эш сорадык...
«Хәлең ничек?» диеп — беркайчан...
Күпме еллар авыру хәлдә йөргән.
Ул әйтмәгән, ә без — белмәгән,
Аны мактап, күп рәхмәтләр язып,
Кемнәр күпме приказ элмәгән...
Нефтьчеләр ничек ял итәләр?..
Уйланырлык хәлләр бар монда...
Менә хәзер телгә килер сыман
Уйналмыйча калган гармун да...

Җиденче истәлек

Өйдән эшкә сагынып китә торган,
Эштән өйгә сагынып кайта торган,
«Акыллым» дип сөеп әйтә торган
Фәндүс юклыгына ышанмам...
Юклыгына бер чак ышансам да,
Хәсрәтемнән мәңге бушанмам.
Гел-гел эштә, гаиләдә иде
Бөтен сөенече, бар уе...
Ана — тыныч, балалар да көйле
Өйдә булса — ата абруе.
Балаларга гел кабатлап торды:
«Ана — йөрәк, ата — баш» диеп,
Һәрбер сүзен аның үти идек
Хөрмәт белән, сөеп, баш иеп.
«Еллар авыр булды, надан калдым...
Төпчегемдә өмет — бер белем...»
Соңгы сулышында әйтәлмичә
Бүленеп калган сүзе: «Сөмбелем...»
«Балаларым үсә алырлармы
Үзем кебек көчле-гайрәтле?»
Үз янына, иң-иң авыр эшкә —
Бригадага алды Айратны...

Соңгы истәлек

«Җебемә!» дип әйтә торган идең
Күңел китсә артык нечкәреп.
Синең гомерең — нечкә шигырь сорый,
Синең гомерең — хәзер истәлек.
Акыл тезгенәрен ычкындырсам,
Артыграк ташсам хисләнеп,

Аккаеннар аңлар хәлләремне:
Алар — синнән соңгы истәлек.
Фәндүс күңеле сыман ак каен,
Беләм: бик хәсрәтле чаккаең.
Бөгелмә дә, сыгылма да җилдә,
Фәндүс кебек кал син, аккаем,
Фәндүс булып кал син, җанкаем!
Тыңлап өлгермисең кәккүкләрнең
Гомер юрап сузган тавышын...
Кай арада узган, һай бу гомер
Сизелми дә калды агышың...
Синең кебек янар җаннар белән
Күпме яшәсәң дә — аз сыман,
Мин — шигырьдә, син — гел эштә яндың,
Буш янмадык, факел-газ сыман!
Уй-хыяллар булып, уллар-кызлар
Бишекләрдән сикереп төштеләр,
Сүнгән дәртләр, җырлар, уйлар, көйләр
Инде балаларга күчтеләр.
Айрат энем, әткәң җырлый алмый,
Мин уйнамый калган бер җыр бар...
Егетләрчә бер утырыйк әле:
Без җырламый, аны кем җырлар?
Олы юлның тузаннарын кактык,
Инде кагыйк гармун тузанын...
...Сезнең өй янында биш каенга
Карый-карый эчкә узамын.
Бу тормышның кырыс үз көе бар:
Без дигәнчә бармый һич тә ул.
Ишегеңдә — йозак.
«Җир астында тагын авария...
Эштә ул...»
Ишегеңә язып җыр калдырам,
Эштән кайткач алып укырсың.
Фәндүс төсе итеп, сиңа карап,
Әнкәң тып-тын тыңлап утырсын:
«Мин — үзем!» дип янып яшәүчегә
Җайлы түгел тормыш, кыен — юл.
Әткәң нигезендә үз көең тап,
Көйсез бу тормышның җаен бел,
Аккаеннар Фәндүс кебек булсын,
Ә син, энем, үзең — каен бул!»
...Йорт янында әллә аккаеннар,
Әллә кырлар шулай сузамы,
Иске көйгә яңа җыр ишетәм,
Таныйм: «Олы юлның тузаны»...

«Олы юлның тузаннарын
Онытмыйлар олылар,
Без үткән салкын юлларда
Калды безнең җылылар...»

...Сине сагынып Җирнең астын тыңлыйм:
Анда — әллә нинди серләр бар,
Синең тавышыңны ишетәм күк:
«Анда — Җир өстендә ниләр бар?»
Уйлар, хисләр, эшләр — киеренке,
Уклы җәя кебек тартылган,
Кешелеккә каршы

Ракеталар
Берсе икенчесе артыннан
Юнәлергә тора...
Җирнең йөзе
Шомлы, борчулы һәм уяу да...
Җир гомере өчен көрәш бара,
Без — солдатлар шушы зур яуда!
Кемнәр айкый Галәм океанын,
Кемнәр актаралар тауларны,
Кемнәр иген игә, сыер сава, —
Җирне саклаучылар — саулармы?
Узган, Бүгенге дә, Киләчәк тә
Безнең башта,
иңдә,
йөрәктә...
Тормыш, Яшәү өчен зур көрәштә
Исән-саулык кирәк бигрәк тә,
Бер-беребезне саклыйк, югалтмыйк без
Һәр көрәшче Илгә кирәктә...
...Сине сагынып Җирнең астын тыңлыйм,
Анда — әллә нинди серләр бар.
Синең тавышыңны ишетәм күк:
«Анда — Җир өстендә ниләр бар?»
Урыныңны Айрат улың алды,
Постта калды, Фәндүс, тынычлан.
«Каен энеләр»ең сынатмаслар,
Синең сыман катгый, кырыслар...
Чорыбызның реаль атлантлары,
Әйтерсең, Җир — алар иңендә.
Мин дә җырым-йөрәгемне куям,—
Күтәрәсем килә минем дә!
Бу дөньяны ташлап китмәгәнсең,
Гүя аста күмер чабасың...
Җир астына ремонт ясый-ясый,
Гел киләсең безгә таба син.
Юк, сыйдыра алмый зурлыгыңны,
Җир аслары синнән тарсына.
Әнә, сине танып, сөенә-сөенә,
Аккаеннар чаба каршыңа.
Мин уйнаган, син җырлаган җырлар
Каеннарга эленеп калсыннар,
Кабатланмас якты образыңны
Киләчәккә озатып барсыннар:
«Туган якның каеннары калалар инде,
Кемнәр сөеп карарлар инде,
Гомерем буе миңа таба чабарлар инде,
Кайтмый һич тә калалмам инде...»
Без дә борынгыга әйләнербез,
Гомер мәңге түгел, чамалы...
Сау бул инде, китәм, Ямады...
Каеннарың, Фәндүсләреңнән
Җырларымда торып кал әле.
Җирне сөеп бүтән җилләр исәр,
Башкаларга безнең җыр күчәр...
Аккаеннар язын яшелләнер,
Сандугачлар таңда чык эчәр...

Март, 1983 ел.
Яңавыл — Ямады.

Солтан Шәмси

НИХӘЛ, ДУСТЫМ?!

хикәя

Вакыйф җәйге ялын диңгездә уздырды.

Диңгездән өйгә кайтышлый, бераз әйләнгечрәк булса да, башкалада яшәп яткан дусты Игорьга сугылып чыгарга уйлады. Игорь белән алар иске дуслар иде. Вакыйфның күптән инде аның белән бер күрешеп туйганчы сөйләшәсе, эчен бушатасы килеп йөри иде. Хәзер менә күрешү мөмкинлеге чыгып тора, һәм ул ялының калган бер-ике көнен Игорь белән үткәрергә булды.

... Бу дуслык армиядә башланып китте. Хәтта поездда ук диярге ярый. Армиягә алынган егетләрне көнчыгышка алып китүче поездда аларның урыннары янәшә туры килде. Танышып киттеләр. Мәктәп карталарында нокта гына булып күренгән шәһәрләрне, урман-тауларны вагон тәрәзәсеннән карап бара торгач, бер-берсенә сүз кушып, ияләшеп тә өлгерделәр. Аннан бер үк частька, бер үк ротага эләктеләр. Бер ай карантиннан соң Вакыйфны штабка күчерделәр, ә Игорьны... моңа хәтта ышануы да кыен иде — почтага билгеләделәр. Әйе, гап-гади почта бүлегенә, шушы часть егетләренә хатлар, газета-журналлар ташып, аларны сөендереп торырга тиеш иде Игорь.

Кайберәүләр егетнең җиңел эшкә эләгүенә көнләштеләр, арада аны өнәп бетермәүчеләр дә табылды. Чөнки солдатлар телендә «почтарь» дип йөртелгән Игорь, хат ташучы буларак, төрле хуҗалык эшләренә дә сирәк тартыла, автомат тотып, кырык градуслы суыкларда каравылда да сирәк тора иде... Ләкин башкарган эше, егетләрне куандырган хатлары аркасында, солдатлар арасында бик тиз үз кешегә әверелеп китте ул. Иң яхшысы: егетнең холкында масаю, эреләнү кебек нәрсәләр сизелмәде. Киресенчә, читтәрәк калуны ул кулайрак күрә, үзенең игътибар үзәгендә булуыннан тартына иде.

Игорьны почтага билгеләгән офицер кешеләрне яхшы белә торган булгандыр, күрәсең. Бу эш егеткә шулкадәр туры килә иде ки, махсус сайласаң да алай ук килеп чыкмас. Тыныч, басынкы табигатьле Игорьда яшьлеккә бигүк хас булмаган төгәллек, җаваплылык бар, әмма хәрби хезмәттә кирәкле башка сыйфатлар житенкерәми иде. Нык, таза гәүдәсенә ятышып бетмәгән аксыл чырай, салмак хәрәкәтләр. Тавышы да ничектер йомшак кына булып, артык интим чыга. Кыскасы, характеры белән Игорь тулысынча «гражданский тормыш»

кешесе, тагын да төгәлрәк әйтсәң — кабинет кешесе иде. Ул китаплар ярата, аларны инде гомере буе җыя икән...

Китаплар, язучылар турында сөйләшү аларны тагын да якынайтты, егетләр бер-берсенә тагын да тартыла төштеләр. Бушаган арада Вакыйф Игорь янына почтага килә, аның кечкенә генә җылы бүлмәсендә чәй эчеп, яңа журналлар, газеталар актарып утыра. Ә журналлар көн саен диярлек килеп кенә тора. Аларда яңадан-яңа әсәрләр басыла. Берәр журналда аерата кызыклы әйбер күренсә, Игорь белән Вакыйф укыганга, журнал адресатына бераз «соңарып» та килгәләде. Шул вакытларда Экзюпери китаплары басылып чыкты. Егетләр аның белән дә мавыгып киттеләр. Әдәбиятка мәхәббәт, культураны мөмкин кадәр күбрәк сеңдерергә тырышу теләге Игорь белән Вакыйфның дуслыгын тагын да ныгытты.

Шул дуслык, хезмәт сроғын тутырып, өйләренә әйләнеп кайткач та дәвам итте.

...Мәскәү аэропортына килеп төшкәч, Вакыйф такси алды. Автобус көтеп торасы килмәде аның. Игорь белән күрешер алдыннан аның ялгызы гына каласы, үткәннәрне искә төшерә-төшерә, хыяллана-хыяллана башкала урамнарыннан үтәсе килде. Диңгездә яхшы ял итте ул, хәзер кәефе күтәренке иде. Игорь берәр кая китеп бармасын дип, үзенең киләсен белдереп, алдан аңа телеграмма да сукты.

Машина, җил сызгыртып, башкалага ашкына. Юлның ике ягында чабылмаган болыннар, калкулыклар, ямь-яшел кырлар җәйрәп ята; каршыга йөгергән борылышларда ромашкалы ачыклыклар күзгә чалынып уза һәм, әлеге матурлыкка сокланып, син тәрәзәгә килеп капланганчы, алар инде ераклашып, югалып та өлгерә.

Уйларга бирелеп барган арада машина шәһәргә дә килеп җитте,— башкалага керделәр. Гомеренең унбиш елын Вакыйф шушында үткәрде бит! Шушында укыды, эшләде. Бу минутта уйланырлык, искә төшерерлек нәрсәләре байтак иде Вакыйфның.

Игорь хәзер «Сокольники» метросы тирәсендәрәк тора икән. Бөтен шәһәрне аркылы үтәргә кирәк. Бу Вакыйф өчен шулай ук куаныч — ул таныш проспектлар, урамнар аша узачак... Институт тәмамлаганнан соң яңадан Мәскәүдә булганы юк иде әле Вакыйфның. Ә тәмамлап чыгуына инде биш ел булды...

Ул тәрәзә аша яңа йортларны, кибет рекламаларын күзәтеп барды. Карап бара торгач, шуны аңлады Вакыйф: юк, үкенми икән ул моннан китеп баруына. Үкенми!.. Бар шундый кешеләр, алар илнең теләсә кайсы почмагында яши алалар, аларга кайда да бер — бары тик тормышлары бөтен һәм җайлы гына булсын. Ә кайберәүләрнең менә үз почмагы, үз шәһәре була. Һәм алар үз шәһәрләрендә генә бәхетле була алалар. Вакыйф та хәзер үз шәһәрен тапкан иде...

Игорьның яңа квартирасында булганы юк иде әле Вакыйфның... Өчәү торабыз, дип язган иде ул. Үзе, Зоя һәм Алешка. Беренче хатыны белән тормышлары барып чыкмагач, Зояга өйләнгән иде Игорь. Алешка — беренче иреннән туган малай икән.

Язылышкач, Игорь белән Зоя, туй сәяхәтен сылтау итеп, Вакыйф торган шәһәрдә дә булып киттеләр. Яшь хатынның сеңелесе биредә яши икән. Кунакка кайткан булганнар. Шунда Игорь, күпен дәфтәрендәге иске адрес буенча, Вакыйфны да эзләп тапты. Вакыйфның баштанаяк фәнни эшкә чумган чагы иде. Өстәвенә, йөкле Дилбәренең ризык сайлый торган, кәефсез вакыты туры килде. Әнима барыбер

кунакларны алар сөенеп кабул иттеләр. Хәтта әле юри оештырган-дай килеп чыкты — Дилбәрнең туган көненә хәзерләнеп йөриләр иде. Игорь белән Зояның көтмәгәндә килеп чыгуы гаилә бәйрәмен тагын да бизәп, ямьләндереп кенә җибәрде. Алар — ике яшь пар — туган көн табынына җыелдылар.

Зифа буйлы, җыйнак гәүдәле Зоя кара трикотин күлмәген чуклы бау белән ныгытып куйган, бу исә хатыннның сынын тагын да юкартып, җиңеләйтеп җибәрә, түшендәге бердәнбер бизәнү әйбере булган гәрәбә медальон да аңа затлылык өсти. Күз салу белән үк аның зә-выклы шәһәр кызы икәнен аңлыйсың. Яшькә дә ул Игорь тирәсе иде, ахрысы, әмма чаманы белеп, оста кулланылган косметика аны тагы да яшь күрсәтә. Зоя тиз арада Дилбәр белән уртак тел тапты, өстәл әзерләшергә ярдәм итте. Тапкырлык, сизгерлек, ситуацияне аңлый белүен күрсәтте. Хатыннар өстәл әзерләгән арада ирләр балконга чы-гып тәмәке көйрәттеләр, Вакыйф дустын яңа тормыш башлап җибә-рүе белән котлады. Игорь да, шуны гына көткәндәй, Зояны мактап алды, ул чын мәгънәсендә тормыш кешесе, ни теләсәң, шуны таба ала, минем кебек җебегәнрәк иргә нәкъ шундый хатын кирәк тә ин-де, дип шаяртты. Шул кичне Зоя белән ничек танышуын, ничек яшәү-ләрен, нинди хәлләр булып узганын сөйләде. Дустын яхшы белгәнгә, Вакыйф Игорь әйтеп бетермәгәннәрне дә сизенде, күп нәрсәне болай да чамалады.

...Аэропорттан бирле ләм-мим сүз катмый килгән таксист, Вакыйф-ның уйларын бүлдереп, сорап куйды:

— Ничәнче йорт дидегез әле?

Вакыйф кабаланып куен дәфтәренә сузылды, адреска күз салды:

— Унберенче.

Бер-ике минуттан такси кызыл кирпечтән салынган биш катлы йорт янына килеп туктады.

Ишекне Игорь үзе ачты — элекке кебек үк таза гәүдәле, өстендә кнопкага төймәләнә торган модный батник, йөзендә ихлас елмаю. Вакыйф сумкасын идәнгә куюга дуслар ирләрчә кочаклаштылар да, бе-рәр адым артка чигенеп, бер-берсен тагын күздән кичерделәр, аннары түргә уздылар. Шул вакыт кухня ягыннан Зоя килеп чыкты, сөенүен күрсәтергә теләп елмайгандай итте, тик елмаюы мәҗбүрирәк килеп чыкты шикелле. Нилектәндер бик ябык иде ул һәм, җәй уртасы булу-га карамастан, чырае аксыл иде.

Бүлмәгә кергәч, Игорь Вакыйфка затлы келәм җәелгән кушеткадан урын күрсәтте, үзе дә, урындык алып, каршына килеп утырды, елмайган карашы белән аны тагын бер күздән кичерде.

— Ну, Каспий ничек соң? — диде.

— Искиткеч! Суы да җылы, чиста, нефть дигәнең дә бөтенләй юк икән, — диде Вакыйф кулларын кушырып.

Ул монда килеп җитүенә шат, шунлыктан, бераз дулкынлана да иде. Ниһаять, килеп җитте, каршысында менә дусты утыра, сөйлә-шенмәгән күпме сүзләр, күпме бәхетле сәгатьләр көтә аларны.

Игорь тагын бер кат аның кояшта янып шоколад төсенә кергән йөзенә карап елмайды да:

— Танырлык та түгел үзеңне, тәмам чүл гарәбе булгансың, — ди-де. Шунда үзенең йөзеннән ниндидер күләгә үткәндәй тоелды. — Мин җәйне өйдә үткәрермен, ахры.

Әлегә сүз шуның белән өзелде. Бүлмәгә кереп-чыгып йөргән Зоя иренә минут саен нинди дә булса эш куша, бусы исә, кунакны ялгыз калдырып, я суыткычка йөгерә, я берәр савыт-саба алып килеп хаты-

нына тоттыра. Килеп янадан Вакыйф каршына утырганда сүзнең кызыгы киткән була.

Хуҗалар табын хәзерләп арлы-бирле йөренгән арада Вакыйф җиһазларга күз йөртеп чыкты. Стенкада бәллүр савыт-саба, ялтыравык тышлы китаплар, чит илдән алып кайтылган төрле сувенирлар, бизәнү әйберләре һәм, аерымрак куелган, «Беломор» тартмасы хәтле генә чит илдә эшләнгән телевизор тора иде. Стеналарда яшькелт обой.

Бар шундый өйләр: аларның бусагасын атлап керү белән үзеңне иркен һәм җиңел хис итәсең, гүя монда күп тапкырлар булгансың да, күнегеп китеп, үз кешегә әйләнгәнсең... Бу квартирада исә Вакыйф беренче минуттан ук үзен сәер хис итте. Беренчедән, Зояның кунакны ничектер көчәнебрәк каршы алуы гажәпләндерде. Ә бит Вакыйф, ике гаилә арасында чын дуслык башланыр, дип уйлаган иде теге чакта. Өстәвенә тагын монда аны нәрсәдер чикли, кыса да иде. Башта ул моның сәбәбен озак күрешми торудан күрде; чыннан да, күптән күрешеп сөйләшкәннәре юк, бәлки, бераз ераклаша төшкәннәрдер, үзгәргәннәрдер, ә үзгәрү, билгеле, кешене һәрвакыт сагайта, шикләндерә башлый. Башта Вакыйфның уйлары шул тирәдәрәк йөрде, бераздан ул төп сәбәпнең Зояда икәнлеген аңлады.

Өстәл янында да сүз тиз ялганып китмәде. Хәлне җиңеләйтү өчен Вакыйф үзе сүзгә кереште: башта ничек ял итүен, көньякта табигатьнең, һаваларның ниндирәк булуын сөйләде, аннары өйдә калган кечкенә кызын исенә төшерде, сагынуын әйтте. Игорь, әлбәттә, бу киренкелекне сизә, тегеләй дә, болай да итеп карый, кунакның күңелен күтәрергә тырыша, кабалана, барысын да җайларга тели. Әмма табынны кулга алырга, тел тегермәнен эшкә жигеп, бу хәлдән оста гына чыгарга, беренчедән, аңа осталык-тәҗрибә житми, икенчедән, Зояның янәшәдә утыруы комачаулый, телен бәйли иде. Шул сәбәпле, әңгәмә өзек-төлек дәвам итә, кайчакны авыр тынлык та урнашып куйгалый, һәм аны ерып чыгарга тагын кунак үзе ярдәмгә килә иде.

Зоя өстәлнең икенче ягында, Вакыйф каршында утыра. Очлы терсәкләре эскәтергә терәлгән, вакыт-вакыт ул да берәр сүз кыстыргалап куя. Шулай күпмедер утыргач, соңгы вакытта бик нык аруын, йончуын сөйләргә керешә, тормыштан зарланып ала. Бу сүзләр, бу зарлану — әле кунак белән маташа торган чак түгел, дигән кебегрәк килеп чыкса да, Вакыйф сер бирмәскә, күңелдәген сиздермәскә тырыша. Ахыр чиктә, ул Зоя янына түгел, иске дусты — Игорь янына килде бит...

Игорьның үзенә дә жиңел түгел иде. Ул үз хәлен аңлый, хатыны белән кунак арасында бәргәләнә, икесенә дә ярарга тырыша, ләкин әңгәмә тәгәрмәчен майлап жибәрергә кулыннан килми. Шулай да, эчкә кергән эчемлек тора-бара үзенекен итте — әңгәмә эзгә төште. Өстәл артыннан инде елмаешып, канәгать булып тордылар. Ачык тәрәзә каршына килеп, сөйләшүне дәвам иттерделәр. Әмма Зоя монда да онытылып киткән ирләргә үзенең барлыгын сиздереп алды:

— Игорь, стенкага кояш төшкән бит, неужели шуны күрмисең! — диде. — Яп пәрдәләрне!

Ирләр борылып стенкага карадылар. Аның бер читендә, чыннан да, кояш нурлары уйный иде. «Шуннан ни булган?» — дип уйлап куйды Вакыйф, ә Игорь, авыз эченнән нидер сөйләнеп, идәнгә кадәр төшеп торган калын пәрдәне биетергә кереште. Пәрдә бирешмәде, ул тагын тартты, пәрдә тагын ябылмады, ачу белән өченче кат йолыккандa, өске чите ычкынып китеп, божрадан чыкты. Зоя исә, шуны гына көткәндәй, ирен әрләргә, булдыксызлыкта гаепләргә кереште,— бүлмәне ярсулы авазлар басып китте. Бу авазлар Зоя кухняга чыгып киткәч тә ишетелеп торды шикелле. Игорь кунакка карамаска тырышып, күзләрен яшерде, кызарып чыкты...

Йөреп кайту өчен баскычтан төшеп барганда артларыннан кинәт ишек ачылды, анда Зояның озынча йөзе күренде.

— Бер сәгатьтән өйдә бул, син миңа кирәк булачаксың, — дип боерды ул иренә, каршы әйтергә урын калдырмыйча һәм, җавапны көтеп тә тормыйча, шапылдатып ишекне япты.

Игорь тагын уңайсызланды, кәефе кырылды. Аннары, хатыны өчен гафу үтенгәндәй, дустының иңенә кагылып алды да:

— Игътибар итмә әйдә, бу арада өянәге кузгалып тора, тырышып-тырышып мине каравыллый, — диде.

«Каравыллый?» Ни өчен икәнен Вакыйф аңламады, ә сорашырга кыймады. Шулай да бу гаилә тормышының тулысынча Зоя кулында икәне аның өчен хәзер ачык иде. Димәк, кем әйтмешли, монда Зоя патша да, алла да икән!

Беренче хатыны Лида белән аерылгач, Игорь байтак вакыт ялгызы йөри, күңеле төшенке була аның. Җимерелгән тормышы турында уйлана, кич җитте исә үзен кая куярга белмичә аптырый, көн саен диярлек үпкә белдереп, акыл өйрәтеп торучы эти-әнисе яныннан ничек чыгып качарга белми. Зоя белән ул нәкъ шушы чорда таныша. Хатын аның бер-берсенә охшаган төссез көннәренә ямь, яңалык кертә. Дөрес, башта Зоя аның өчен ялгызлыктан котылу чарасы гына була, тора-бара егет күнегә, тәм табып йөри башлый. Беренче очрашулардан ук Зоя дилбегәне үз кулына ала, ә Игорь, гадәтенчә, аңа ияреп, ул кая чакырса, шунда барып, үзен артык мәшәкатьләндермичә, ялкау гына йөри. Зоя ягыннан булган игътибар, кайгыртучанлык йөрәгенә сары май булып ята, беренче хатыннан андый хөрмәт күрмәгән ирне бу үсендерә. Ә Зояга шул гына кирәк тә. Ул аны үзенә ныграк бәйли, иркәли-иркәлиә күнектерә, алыштыргысыз хатын булачагын әкренләп ирнең аңына сеңдерә һәм тәмле теле, йомшак мөгамәләсе шушы фикерне раслый, нығыта бара. Тормыш-көнкүреш хәлләрендә тәжрибәсез Игорь тора башлауның беренче көненнән үк барысын да аңа тапшыра. Болай уңай, уйлыйсы, мәшәкатьләнәсе юк. Гомере буе ата-ана канаты астында яшәп, ул моңа инде күнеккән, шулай булырга тиеш, дип уйлый.

Яңа тормышка аларның һәрберсе ялгызлык, моң-сагыш, югалтулар аша килә. Яшьлек, аның котылгысыз ялгышлары артта кала. Хәзер икесе дә: менә, ниһаять, ныклы, чын тормыш башлана, дип ышаналар. Берсе дә үткәннәргә, артка әйләнеп карамый, яңа хисләр искәләрен күмеп китә, оныттыра, — алар инде беркайчан да баш калкытмас, искә төшмәсләр сыман тоела...

Зоя белән мавыгып китеп, Игорь вакытлыча шулай уйласа да, беренче хатыны кулында улы үсә. Лида үзе Мәскәүдә кала, ә бала башкаладан ерак түгел кечкенә генә бер шәһәрдә — әбисе тәрбиясендә яши. Зояга өйләнгәнче Игорь әле улы янына барып-кайтып йөри. Малай янына, гадәттә, атна уртасында бара. Эшендә ялны атнаның теләсәң кайсы көнендә алып булганга, шулай итә. Ял көннәре барсаң, Лиданы очратуың бар.

Зоя белән тора башлагач, малае янына йөрүләрен вакытлыча туктатырга була Игорь. Бераз күнегешик, тормыш эзгә төшсен, дип уйлый. Калган эшкә кар ява дигәндәй, бер-ике атнага гына кичерелгән нәрсә озакка сузыла. Яңа тормышта бер-бер артлы мәшәкатьләр чыгып кына тора. Шулай итеп, Зоя белән тора башлауларына алты ай тула дигәндә, аны кабат малае тарта башлый: күрешеп сөйләшәсе, алдына утыртып сөясе, җитәкләшеп урамда йөрисе килә. Бу турыда ачыктан-ачык сөйләшергә, малаен өзелеп яратуын, аны күрмичә, си-

рәк-мирәк кенә булса да, очрашмыйча түзә алмаячагын әйтергә Игорьның көче житми. Ә малайны ул торган саен ныграк сагына. Ирнең бу халәте, уйчан күзләре яшь хатынның йөрәгендә хәвеф уята, шикләндерә. Күпне күргән, тәжрибәле хатын буларак, ул нидер сизенә, бәхетемә ниндидер куркыныч яныйдыр, дип уйлый, ләкин уртага салып барысын да ачыкларга аның да йөрәге житми. Бу хәл ир белән хатынны якынайтмый, киресенчә, алар үпкәләшә, сүзгә килешә башлыйлар...

Игорь белән Вакыйф, ишегалдыннан чыгып, тупыллар утыртылган тар урам буйлап киттеләр. Монда машиналар йөрми. Теге очтагы киң проспекттан тонык кына гүләү ишетелә. Шәһәрне яхшы белсә дә, бу аулак урамда беренче тапкыр иде Вакыйф.

Тынычсызрак узган төшке аштан соң Игорь әкренләп табигый халәтенә кайтып килә иде. Бу яктан Игорь үзгәрмәгән кебек күренә. Димәк, ихлас сөйләшү булачак, дип өметләнде Вакыйф.

Урам башына житәрәк аларны саргылт чәчле, озын-арык гәүдәле, ак чырайлы унбер-унике яшьләрдәге малай куып житте. Бу — Зоянның улы Алешка булып чыкты.

— Игорь абый, сез озак йөрисезме?

— Нигә сиңа?

— Әни сезнең белән йөрергә кушты! Тик минем йөрисе килми ияреп. Тиз кайтмасагыз, кино карап чыгар идем. Ә кайтканда капка төбендә көтәрмен, өйгә бергәләп керербез.

Игорь көлемсерәп куйды, мәгънәле итеп Вакыйфка карап алды һәм малайның аркасыннан сөеп:

— Яхшы егет син, Алешка,— диде.— Бар, бар киноңа.

Ә малай китәргә жыенгач:

— Акчаң житәме соң? — дип сорады.

— Билетка житә!

— Алайса, ярар.— Игорь аңа дусларча күз кысты.— Бар, йөгер!

Ирләр паркка таба киттеләр.

— Шәп малай үстерәсең,— диде Вакыйф бераз сүзсез баргач.

— Малай ярыйсы. Сизгер күңелле, барысын да аңлый.

— Сине «Игорь абый» дип йөртә икән...

— Башкача булдыра алмыйдыр, күрәсең. Зур бит инде. Мин аның үз иркенә куйдым. Теләгәнчә атасын.

— Ятсынмыймы соң?

— Дуслар без аның белән. Бик якын итә. Аңа хәзер ирләр компаниясе кирәк. Яше шундый.

Армиядәге кебек көн саен бергә булмасалар да, Вакыйф Мәскәүдән китеп барганчы Игорь белән алар еш очрашып, уй-серләрен уртаклашып яшәделәр. Шуңа күрә Вакыйф дустының бу чор тормышын яхшы белә иде.

Лида белән Игорьны ата-аналары таныштырды. Моңа егет үзе гаепле иде. Армиядән кайтуына ел үтте, икенче ел китте, ә аның һаман йөргән кызы юк. Ялгызы да ялгызы, китаплар жыя, вузга керергә хәзерләнә. Ата-ана борчыла ук башлады, бер-ике тапкыр өйләнү турында сүз дә кузгатып карадылар — рәт чыкмады. Уллары сүзне уенга бора, йомшак кына елмая, гомумән, бу хакта сүз кузгатмаска тырыша. Болай булгач, үзебезгә кайгыртырга кирәк, дип ата-ана кыз эзләргә тотынды. Кыз тиз табылды. Күрешүне дә үзләре оештырдылар. Кызның нәкъ чәчәк аткан чагы. Пешкән алма кебек алсу битле, Мәскәү тирәсендәге кечкенә шәһәрдә үскән озын толымлы чибәр генә

кыз иде Лида. Әмма Игорьга ул әллә ни ошамады. Соңрак кызның да егетне ошатып бетермәве ачыкланды. Монысын, әлбәттә, ата-ана гына белде. Шушында нокта куйсаң да ярар иде. Әмма картлар моңа әллә ни игътибар итмәделәр. Аларның үз уе, үз тәҗрибәсе бар иде. Егет белән кызга тагын берничә очрашу оештырдылар. Һәрберсенең колагына ымсындыра торган сүзләр ишеттереп тордылар. Очрашулар ешайды, кыз белән егет бергә киноларга, концертларга йөрделәр. Акрынлап бер-берсенә күнегә дә башладылар. Олылар җай чыккан саен кызга егетне, егеткә кызны мактадылар, аларны көткән матур тормыш турында тукыдылар. Хәер, бу хакта инде тукымасаң да була иде. Яшьләр инде тәмам дуслашып, дуслыкны мәхәббәт итеп кабул иткәннәр иде. Монда кызның яшьлеге, сафлыгы, балаларча эчкерсез, беркатлы булуы да үз ролен уйнагандыр. Лида гомеренең иң матур, табигать биргән гүзәллекнең иң югары ноктасына җиткән иде. Һәм Игорь шуңа сихерләнде дә...

Картлар да моны сизенде, зур тырышлык, түземлек белән төзелгән йортка инде түбә ябарга бик вакыт иде. Ике яктан да ашыктыра башладылар. Лида өлкәннәр сүзенә, аларның тәҗрибәсенә ышанды, Игорь исә, ниндидер ялгышлык эшләргә җыенуын күңеле белән сизенсә дә, үзендә кире чигенерлек көч тапмады, егеттән шушы адымны көткән кешеләрне — бигрәк тә Лиданы — алдый алмады, өйләнергә булды.

Аларның беренче айлары матур узды. Үзенең оялчанлыгы, хатын-кыз мәсьәләсендә артык кыюсыз, саф булуы аркасында Игорь, өйләнгәнче, кызлар белән йөрмәде дә диярлек. Хатын-кызны ул бөтенләй белми иде, ахрысы. Беренче айлар егеткә яңа дөнья ачты, татлы төш күргәндәй хәтерендә калды. Кыенлыклар соңрак, дәртле ташкын үз ярларына кайта башлагач килеп чыкты. Башта буйдак тормыштан калган гадәтләр комачаулады: моңа хәтле ул тулысынча ирекле кеше булса, хәзер исә, аз гына соңга калып йөрсәң дә, хатын алдында исәп-хисап тотасы бар иде. Шулай итмәгәндә, яшь килен татлы иренәрен турсайта, сөйләшми газаплый, балаларча үпкәли. Өйләнешүдән шуны көттемени ул! Хатын иренең катлаулырак тормыш белән яшәвен күз алдына да китерә алмады. Иренең ниндидер сәер булуы аны ярсыта иде. Чит кешене аңларга, кайвакыт үзен аның урынына куя белергә, аның кайгысын үз кайгысы итеп кабул итәргә өйрәнмәгән иде Лида. Өйләнешү, ир хатыны булу аның өчен беренче айларның исерткеч ялкыныннан гына гыйбарәт, шуңа гына кайтып кала, башка мәгънә, рухи ләззәт, тәннәрнең генә түгел, җаннарның да кушыла алуын ул белми иде. Әлбәттә, бу көенчә Лида ят гаиләдә үз урынын таба алмады, гаилә дә бу көенчә киленне кабул итәргә теләмәде. Күп тә үтмәде, гаилә икегә бүленде. Бер якта яшь килен булса, икенче якта — Игорьның ата-анасы һәм кайдадыр ике арада — Игорь! Көчләр тигез түгел иде. Игорь ике арада буталды, әле теге якка (ата-ана да кадерле!), әле бу якка (хатын да якын!) ташланды. Ул да үз урынын таба, кайсы да булса якка чыга алмады. Лида аз гына сизгерлек, ышаныч күрсәтсә, Игорь, әлбәттә, аны яклап көрәшкә ташланмый калмас иде! Әмма яшь хатын ирен дә дошман күрде, көрәшү өчен аңа фикердәш, хуплау сүзе кирәген аңламады. Болай яшәү мөмкин түгел иде. Яшь гаилә таркалырга тора һәм аны саклап калу өчен бердәнбер чара — ул да булса ата-ана йортын ташлап чыгу гына калды.

...Игорь белән Лида төп йорттан аерылып чыктылар. Себергә эшкә китеп барган бер гаиләнең буш квартирасын эзләп тапканчы байтак чиләнергә туры килде. Хуҗалар ике елдан гына кайтырга тиешләр

иде, әле вакыт бар, ул көннәр җиткәнче берәр нәрсә уйлап табылыр, дип өметләнделәр. Иң мөһиме, хәзер үзләренә үзләре хужа, тормышларына кысылучы, адым саен акыл өйрәтеп торучы юк.

Тормышта гел син теләгәнчә генә булмый икән. Бераздан шул нәрсә ачыкланды: аерылып чыгып, алар тышкы, күзгә күренеп торган каршылыкны гына хәл иткәннәр икән әле. Тирәнгә яшеренгәне күнелдә һаман яши, алай гына да түгел, һаман саен үсә, баш калкыта икән. Алар бер-берсен яратмыйлар икән ләбаса! Алар арасында бер вакытта да мәхәббәт булмаган! Бер-берсенә күнеккән, шуны мәхәббәт дип кабул иткәннәр. Игорь — характерының йомшаклыгы сәбәпле, ә Лида — тәжрибәсезлеге аркасында бу адымны ясаганнар.

Читтән караганда аларның җайга салынган тормышы тыныч кына ага кебек иде. Ләкин бу тынлыкның давыл алды тынлыгы икәнен икесе дә сизеп, белеп яшәделәр. Гаилә өстендә кара болытлар куерып, гел яшеннәр яшьнәп тормаса да, һавасында киренкелек сакланды.

Урмандагы җир асты янгыны турында ишеткәне бар иде Игорьның. Мондый янгын иң четерекле һәм хәтәр янгыннардан санала. Агач төпләреннән генә барамы янгын, әллә зур тизлек белән агач башларыннан тараламы,— ут җир өстендә вакытта аны сүндереп, аның белән көрәшеп була икән әле. Ә менә ут җир астыннан, торф катламыннан барганда — көрәшү мөмкин түгел! Ул әле бер җирдә, әле икенче җирдә борын төртә, яки яшеренеп айлар буе җир астында да пыскып ятарга мөмкин. Һәм аның кайчан, кайдан дөрләп чыгасын берәү дә белә алмый, алдан искәртү дә мөмкин түгел. Шулай яшерен генә пыскып яткан ут бер заман көтмәгәндә җир өстенә бәреп чыга, күкрәп утырган урманны кара күмер итә.

Игорь белән Лида тормышы да хәзер нәкъ менә җир асты янгынын хәтерләтә иде. Тышкы яктан барысы да тәртиптә кебек, әллә ни сүзгә дә килешмиләр, тавыш та чыгармыйлар, әмма эчтә, бик тирәндә нәрсәдер пыскый, көйри, бер-береңә ризасызлык яши. Игорь да, Лида да өйләнгәнче гаилә тормышын башкачарак күз алдына китерәләр иде. Алар теләгәнчә, алар хыялланганча килеп чыкмады. Шулай да яшь гаиләнең матур киләчәккә өметләнеп, күтәренке рух белән яшәгән чаклары да булгалады. Бу бигрәк тә Игорь институтка кергәч үзен сиздерде. Югары уку йортына керү Игорь өчен яңадан туу белән бер иде. Авыр имтиханнар үтеп, студент тормышына аяк басу һәрбер кеше өчен зур шатлык, мөһим борылыш, бер баскычка югары күтәрелү булса, армиядән соң институтка керү Игорь өчен икеләтә шатлык иде.

Тормышындагы бу борылыш аны үзгәртеп җибәрде, егеттә үз-үзенә ышаныч артты, кыюрак яши башлады. Һәм, иң мөһиме, бу үзгәреш аңа күпмедер канәгатьләнү китерде. Хәзер ул үзен иркенрәк тота, җиңелрәк аралаша, елмая-көлә, тормышның гүзәл нәрсә икәнен яңа гына аңлагандай, һәр нәрсәгә сөенеп яши. Гомер буе житенкерәмәгән ниндидер җиңеллек, иркенлек сизде ул үзендә.

Лида боларны ничек кабул итте соң? Аның өчен Игорь көтмәгәндә яңа яктан ачылып китте. Хатыны теләндә «бозау» дип йөртелгән кыюсыз, йомшак табигатьле ир, бик теләсә, каршылыкларны жиңеп, үзенекен исбат итә ала икән ләбаса! Бер араны хатын ире белән горурланып йөрде. Игорьның эчке дөньясы, укуы, китаплары белән кызыксына башлады. Ә гуманитарий булырга җыенган ирнең язу өстәленнән Лида күрмәгән-ишетмәгән китаплар өзелми иде. Әмма иренең киңрәк дөньяга чыгуы, таныш-белешләренең дә ишәюе һәм шуның аркасында күзгә күренеп үзгәрә баруы хатынны борчый, шикләндерә, кайвакытта ачуын да китерә иде. Ирен әллә ни яратмаса да, аның өйдән башка да ниндидер тормышы, яңа мохите, дуслары булу хатынны көнләштерде. Игорьның тормышын үзенекенә итеп, шуна кушы-

лып китеп, сөенеп яши белмәде ул. Тагын сүзгә килүләр, үпкәләшүләр, сөйләшми йөрүләр китте. Бу хәл гаилә нигезен ныгытмый иде, әлбәттә. Игорьның өйгә кайтмыйча Вакыйф фатирында кунып калган көннәре дә булгалады, ә хатын моннан әллә нинди нәтиҗәләр чыгара, зурайта, иренең читтә берәр йөргән нәрсәсе бардыр дип уйлый иде.

Бер заман Лида аерылышу турында сөйләнгәли башлады. Игорь аңа бер сүз дә әйтмәде, әмма эчтән моңа каршы иде. Беренчедән, улын ятим итәсе килмәде, икенчедән, хәзер аның үз хәле хәл — институтта кыенлыклар чыгып тора.

Бу болай булды: Игорь, үзенең дүрт ипташе белән, институтның түбә калаен буярга килешенделәр. Договорны соңыннан төзербез, дигән сүзгә ышанып, егетләр эшкә керештеләр. Түбәне буяп ятканда фәҗига килеп чыкты — егетләрнең берсе, абынып китеп, бишенче каттан аска очты. Ярый әле, аста агачлар үсә икән, шулар коткарды. Әмма егетнең умыртка сөяге сынган булып чыкты. Операция ясадылар, егет барыбер гомерлек инвалид булып калды. Инвалидлыкны законлаштырырга кирәк булгач, аларны яллаган кешеләр, өсләренә жаваплылык аласылары килмичә, ярдәм итүдән баш тарттылар. Сүз, тарткалашу китте. Бәхәстә Игорь башлап йөрүчеләрдән иде, шуның аркасында, институттагы хәле шактый мөшкелләнде, аңа сагаеп карый башладылар. Нәкъ шулвакыт (сайлаган бит вакытын да!) институтка Лидадан хат килеп төште. Хатта ул ирennән зарланган, гаиләсенә булган мөнәсәбәтен, тәртибен тикшерүне үтенгән иде.

Институт җитәкчеләре янына чакырып алып, шушы хатны күрсәткәч, Игорь беравык исенә килә алмый аңгыраеп утырды. Башка сыймаслык эш иде бу! Арттан пычак кадау белән бер! Болай да институтта көчкә эләгеп торган чакта... Хәзер аны бу хатын янында бернәрсә дә тотып тора алмаячак — чыннан да аерылырга кирәк, дип карар кылды Игорь һәм шул көнне хатыны янынnан чыгып китте. Тиешле срок үтеп, аерылышу көннәре якынлашып килгәндә, үзе үк аерылышу турында сөйләнеп йөргән Лидадан хат алды Игорь. (Ул инде ата-анасы янында тора иде.) Лида аерылышырга теләмәвен язган иде. Әмма Игорьның йөрәге таш булып каткан, бу турыда ул ишетергә дә теләмәде...

...Игорь соңгы елларда булып үткән хәлләрне сөйли, аның менә шулай күңелен бушатыр кешесе юклыгын сизеп бара иде Вакыйф.

— Зоя синең картлар белән уртак тел таба алдымы соң?

— Ка-а-я! — диде Игорь. — Зояны күрә алмыйлар алар. Хәлләреннән килсә, аерттырып кына җибәрерләр иде.

— Авыр хәл.

— Ничек кенә әле. Шуның аркасында күпме нервы түгелә. Мин аларга барырга җыенсам, кара коела хатын, чөнки белә: килеп керүгә — аны яманлый башлаячаклар. Ә бармыйча да булмый — ата-ана бит...

Вакыйф гажәпләнеп башын чайкап куйды:

— Улыңны күрәсеңме соң?

Игорь аңа сәер карап алды да көлемсерәгәндәй итте.

— Баргалыйм болай. Үсеп бетте инде, зур малай булды.

— Аңа йөрүеңне Зоя белә торгандыр бит?

— Хәзер белә инде. Ачыктан-ачык йөрим. — Ул нәрсәнедер исенә төшергәндәй, үзалдына көлемсерәп куйды. — Безнең монда бер тавыш чыгып алды әле. Малай янына яшертен генә йөргәнне Зоя сизеп алган да каравыллап торган. Ну, кем әйтмешли, мине «жинаять» өстендә тотып алды. Җәнҗал чыкты. Атна буе өйгә кайтмадым, әтиләрдә кун-

дым. Мин кайтмагач, Зоя бөтенләй жүләрләнә язган. Бөтенләй китүем, дип уйлаган, ахры. Үзем дә курка калдым: хатын-кызны белеп булмый, мәйтәм... Кыскасы — атна тулды дигәндә кайтып керсәм, Зоямны бауга элеп киптергәннәрмени. Зәп-зәңгәр. Жылый да алмый, бичара.— Игорь беравык дәшми генә барды, аннан яшел агачларга күтәрелеп карады да: — Чыннан да ярата, ахры, — диде. — Әмма андый яратудан тын кысыла, брат...

Игорьның соңгы сүзләре Вакыйфка күп нәрсәне аңлатты. Зоянын аны салкын кабул итүе, бу йорттагы киеренкелек, низаг — барысы да, димәк, үз-үзенә һәм уртак киләчәккә ышаныч житмәүдән килә икән. Игорьның икенче арада йөрүе, яңа семьяга Зоя ышаныр дәрәҗәдә ныклап берекмәве хатын күңеленә шик сала икән. Зоя да, тормыштагы соңгы юанычы булган Игорьны югалтмас өчен, үзе дә сизмәстән, тиранга әверелә бара, ирнең гайрәтен чигерә.

— Ярар, бер эзгә төшәр әле. Син үзең дә дилбегәне артык бушатмакансың, ахры...

Игорь сүзсез генә баш какты.

— Алайса, малай янына ачыктан-ачык йөрим дисең инде?

— Ә-э, әйтергә онытканмын: теге көнне мин аңа әйттем — әгәр минем белән торырга теләсәң, малай янына йөрүем белән килешергә туры киләчәк, дидем.

— Ә ул?

— Килешүен килеште, кая барсын инде килешмичә... Шулай да, Лида белән очраша башларбыз, дип курка ахры ул... Анысы инде юкка. Инде Лидага кайту юк. Киселгән икмәк кире ябышмый ул!

Шулай катлаулы тормыш хәлләрен сөйләшеп йөргәндә, әңгәмәнең ул уйлаган, ул өмет иткән юнәлештән тайпылып, башкарак эздән китүен искәреп алды Вакыйф. Ул бит монда канатланып, ниндидер күңел күтәренкелеге белән килеп төшкән иде. Игорьны да элекке ялкынын югалтмаган килеш күрергә теләде. Элек алар гел киләчәк турында сөйләшәләр, хыялланалар, планнар коралар иде бит. Нинди бәхетле, канатлы тормыш белән яшәгәнләр икән алар ул чакта! Дөньяны да, беркатлырак булуларына карамастан, икенче төрлерәк— матуррак һәм шигъриләк итеп күрәләр иде кебек. Ә хәзер менә көндәлек мәшәкатьләргә батып, якын һәм бәләкәй максатларны гына кайгырта-кайгырта, югарырак биеклекләрне күрми башлаганнар түгелме соң? Күпме еллар фикердәшләр булып, шул дәвернең асылын тәшкил иткән сыйфатларны югалтып баралар түгелме? Ул еллар Вакыйфның хәтерендә ниндидер кабатланмас бәйрәм кебек уелып калган иде.

Монда килгәндә Вакыйф нәкъ менә шул хакта уйлады, шуны көтте, хәтерендә сакланган яшьлек елларының чагылышын гына булса да күрергә теләде ул. Игорь белән яшьлек урамнарыннан үтәсе, барысын да искә алып утырасы, бәхетле сәгатьләр кичерәсе килде аның. Тик бәйрәм юк иде. Алар, кайдадыр тоткарланып, бәйрәмгә соңарып килделәр, ахры. «Бәлки, мин артык беркатлыдыр. Бәлки, без ниндидер чикне үтеп чыгуыбызны сизми калганбыздыр, шуны аңламыйча һаман яши бирәбездер?! Ниндидер үзгәреш булгандыр да, без аны һаман белмибездер», — дип, моңсу гына уйлап куйды Вакыйф.

— Теге чакта син диссертацияне якладым дип язган идең, — диде Игорь. — Хәзер фәннәр кандидатыдыр инде.

— Әйе, кандидат,— дип чиклә нергә булды Вакыйф. Дустының хәлен аңлаганга, үзе турында жәлеп китеп сөйләргә яхшысынмады ул.

— Ә мин менә һаман очына чыга алмыйм әле. Инде үз-үземә ышанычны да югалта башладым. — Игорь кулы белән ниндидер сүлпән хәрәкәт ясап алды, беравык дәшми торгач кына дәвам итте: — Читтә

балаң үсү авыр икән ул, брат. Тегендә-монда йөреп, гомерең ике арада уза. Йөрәк яна, эчтән сызасың. Күңел тынычлыгы булмагач, эшкә дә кул бармый. Бары да таркала. Эштә дә аяк терәп үземнекен таләп итә алмыйм. Йөрәк җитми, ничектер хакым юктыр кебек. Башкалар моны сизә һәм шуннан бик оста файдалана. — Ул фикеренә йомгак ясагандай: — Менә минем хәлләр әлегә шулай... Нәрсә булыңа бетәр— билгесез... Үзем гаепле... Үзем... — диде.

Игорьның карашы аска текәлгән. Ялтырап торган киң, матур маңгаенда авыр уй күләгәсе ята, күзләре исә бу минутта беркемне күрми — алар эчкә, тирәнгә юнәлгән.

Шулвакыт Вакыйфны нәрсәдер телеп алгандай тоелды, бу — кызгану хисе иде. Әйе, Игорьны кызганып куйды ул. Әмма бу очракта кызгану аңа кирәк микән? Тормышта кеше үзе, фәкать үзе генә хәл итә торган мәсьәләләр бар. Киңәш биреп, ниндидер фикер әйтеп кенә хәлне җиңеләйтеп булмаячак. Кеше кайбер фикерләргә авырлык белән, күп газаплар аша үзе килсә, әйбәтрәк була... Дусты әле үзен табар, чуалган йомгакны сүтә алыр... Аның борчылып яшәве, хаталарын кабатламаска, яңаларын булдырмаска тырышуы шуңа өметләндерә кебек.

Күңә тә үтмәде, асфальт сукмак аларны скульптуралар куелган ямьяшел аланлыкка китереп чыгарды. Бу аланлык ачык һавадагы сыннар күргәзмәсен хәтерләтсә, аны каймап алган агачлар — стенага эленгән яшел гобеленнар кебек иде. Җил-яңгыр астында озак торганга сыннар бераз карала да төшкән, шул сәбәпле алар монда тагын да үз булып, җирдән үсеп чыккандай, табигый утыралар иде.

— Беләсеңме, Вакыйф, — Игорь дусты каршысына туктады, аның күзләренә карады, — мин сиңнән гел күпне өмет итеп, зуррак эшләр эшләрсең дип, сине үземнән өстенрәк куеп яшәдем. Бәхетлеме син дип сорамыйм, чөнки бәхет адәм баласы аңлап бетерә торган нәрсә түгел. Әйт әле дөресен: син үз тормышыңнан канәгатьме?

Вакыйф көлемсерәгәндәй итте.

— Мәсьәләгә ничек карыйсың бит. Пришвин, ахрысы, менә нәрсә дигән: кеше, дигән, телиме-теләмиме, тормышта барыбер нинди дә булса камыт сайларга мәҗбүр. Әмма сайларга калгач, муенны кырмый торганын, дигән. Миңа калса, мин үзем теләгән камытны сайладым. Шуңа күрә үкенмим. Кайберәүләр моны яраткан эш, диләр. Үзүзеңне табу, дип тә әйтергә була.

— Шат мин синең өчен, Вакыйф, аңлыйсыңмы, чын күңелдән әйтәм моны. Ичмасам синең эшләр бара.

— Синеке дә җайланыр, менә күреп тор. Үзеңне кулга алырга тырыш. Җайланыр. Мин ышанам сиңа...

Алешка аларны, килешенгәнчә, капка төбендәге карт тупыл төбендә көтеп алды. Якынлашуларын күреп, агач күләгәсеннән чыкты, каршы килде.

— Ну, ничек, бардыңмы кинога? — дип сорады Игорь.

— Әһә. — Малай баш кагып куйды.

— Нәрсә карадың соң?

— «Ак пароход» дигәнне.

— О-о! — Игорь кашларын күтәрде, гажәпләнгәндәй итте. — Әйбәтме соң?

— Әйбә-э-әт!

Алар фильм турында сөйләшә-сөйләшә подъезд ишегенә килеп җиткәнне сизми дә калдылар.

Иртәгесен Игорь аны вокзалга озата барды. Такси аларны Сөембикә манарасына охшатып салынган Казан вокзалына китереп куйды. Поезд кузгалырга ун минутлап вакыт калган иде. Әйберләрне вагонга кертеп урнаштыргач, һавага чыктылар, ыгы-зыгы килгән халыкны, күкрәкләренә номер таккан өлгер йөкчеләрне, саубуллашучыларны тамаша кылып басып тордылар.

...Инде сөйләшер сүз дә калмаган кебек иде. Берничә минуттан кузгалырга тиешле поезд Вакыйфның уйларын алга — үзенең өенә, гаиләсенә чакыра. Игорь тыныч түгел, ул ничектер сәер итеп елмаеп куйгалый, аның гүя нәрсәдер әйтәсе, нидер аңлатасы, күңелендәге авыр тойгыларны таратасы килә иде.

Саубуллашыр минут та килеп житте. Дуслар бер кочаклаштылар да, Вакыйф вагон тамбурына кереп басты.

— Язгалап тор, яме,— диде Игорь дустының күзләренә карап. Аның тагын нидер әйтәсе килә иде, тагын ниндидер сүзе бар иде шикелле...

— Язармын, Игорь, үзең дә онытма! — Аннары Вакыйф, кулын йодрыклап, «Но пасаран!» дигән рухландыргыч хәрәкәт ясады, дусларча елмайды.

— Син уйлама... Мин әле аякка басармын...— Игорьның соңгы сүзе шул булды.

Вакыйф жавап бирергә өлгермәде, вагон тартылып куйды, поезд кузгалып китте. Проводница хатын баскычка сикереп менде дә ишекне япты.

Бераздан поезд инде ачык кырлар буйлап бара иде. Шул киңлеккә карап барган Вакыйф: «Менә жәй дә үтте», — дип куйды. Аннары үз шәһәре, хезмәте искә төште. Алда аны эшләр, күп эшләр көтә иде. Дөньяда яшәвеңне бары тик матур эшләр белән генә аклап булачагын яхшы белә иде ул...

.....

Тукайның 100 еллыгына

КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

Халык җырлары — безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр...

Г. Тукай. «Халык әдәбияты». 1910 ел.

«Шәрык» клубы урнашкан бина. (Хәзерге Татарстан урамы, 8 йорт.) 1910 елның 15 апрелендә Г. Тукай үзенең «Халык әдәбияты» дигән лекциясен шушы клубта укыган.

Татьяна Зуева рәсеме.

Зәкия Рәсулева

ТУКАЙ ЭЗЛӘРЕННӘН

Мотыйгулла Төхвәтуллин

Татарстанның халык артисткасы Галия ханым Кайбицкая сөйләгәннәрдән.

Минем әтием Мотыйгулла Төхвәтуллин Казан губернасы, Кече Кайбыч авылында (хәзерге Апас районы) 1845 елда туа.

Әтисе шул авылның мулласы Төхвәтулла, бабасы Нигъмәтулла, аның атасы Комач дигән кеше була.

Мотыйгулла туу белән әнисе үлә, ә ике яшь тулганда әтисе дә үлеп, Мотыйгулла дөм ятим рәвешендә ике апасы тәрбиясендә кала. Мотыйгулла яшьтән үк бик зирәк, зиһенле була, бик иртә укырга өйрәнә. Инде 5 яшьтә кешеләрне таңга калдырырлык итеп бөтен коръәнне укый. Шуңа күрә аны «могҗиза бала» дип атаганнар.

Әтисе урынына килгән мулла, Мотыйгулланы тыңлап караганнан соң исе китеп, аны ул заманда данлыклы саналган Кышкар мәдрәсәсенә укырга җибәрә.

Кышкар мәдрәсәсендә Кушлавычтан килгән, киләчәктә Габдулла Тукайның әтисе булачак Мөхәммәтгариф дигән шәкерт тә укый. Мотыйгулла белән Мөхәммәтгариф тиз арада дуслашып китәләр, Мотыйгулла ятим бала булганлыктан, Мөхәммәтгариф аны үз химаясенә ала, алар бергә яшиләр, бергә укыйлар. Укып бетергәч тә аерылмаска сүз куешалар.

Мәдрәсәне бетерүгә, Мөхәммәтгарифны Кушлавычка мулла итеп билгелиләр. Ә Мотыйгулланы, укуын тагын да дәвам иттерү өчен, Мисырдагы Каһирә мәдрәсәсенә җибәрәләр.

Мисырдан укуын тәмамлап кайтканда, Мотыйгулла Уральскига — кияүгә чыккан апасында туктала, Уральскиның данлыклы Тау Гани бае салдырган мәчеткә намазга бара. Намазга килүчеләр Каһирәнең үзендә укып кайткан бу кешенең коръән укуын үтенәләр. Аның укымышлылыгына исләре китә һәм үзләренә Түбән оч мәхәлләсенә мулла итеп калдыралар. Мәчетне салдыручы Тау Гани бай Мотыйгуллага үзенең Гыйзеназ исемле 16 яшьлек асрау кызын кияүгә бирә һәм Татарский тыкрыгындагы кечкенә генә бер өйгә урнаштыра: Мотыйгулланың 15 баласының 8 е шул кечкенә өйдә туалар. Аларның күбесе яшьли үлеп бетә.

Еллар үтеп, Мөхәммәтгариф вафат була. Аның ятим калган улы Габдулла Тукаев апа-жизнәләре тарафыннан Уральскига алдырыла. Ул «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укый башлагач та, Мотыйгулла хәзрәт аны үз өенә алып кайта. Тукайга әтисе Мөхәммәтгариф турында сөйли. «Синең әтиең Мөхәммәтгариф мәдрәсәдә мине бик карады, якын итте. Бәйрәмнәрдә мине үзе белән гел Кушлавычка алып кайта иде. Синең дәүәниең безнең кайтуыбызны тәмле кыстыбыйлар пешереп көтеп тора иде»,— дип сөйли.

Мотыйгулла үзенең хатыны Гыйзеназга: «Габдулла ятим бала, аны кара. Аның әтисе, әби-бабасы мине бик тәрбия иттеләр»,— ди. Мотый-

---

Дәвамы. Башы журналыбызның 1 санында.

гулла, кече улы тугач, үзенең мәрхүм дусты истәлегенә улына Мөхәммәтгариф дип исем куша.

Тау Гани бай мәчеттән ерак түгел ике катлы таш пулатта яши. Үзе үлгәндә, йортын Мотыйгуллага васыять итеп калдыра. Мотыйгуллалар шунда күчеп яши башлыйлар. (Хәзерге Орджоникидзе урамындагы 57 нче йорт.)

Мотыйгулла Түбән оч мәхәлләсенең мәдрәсәсендә мөдәррис (өлкән укытучы) була. Мәдрәсә аның исеме белән «Мотыйгыя» мәдрәсәсе дип атала.

Габдулла Кариев үзенең истәлегендә: «Габдулла әфәнде дәрескә Мотыйгулла хәзрәткә утырадыр иде. Габдулла мәдрәсәдә иң галим, иң үткен, зирәк шәкертләрдән хисаплана иде. Дамелла Мотыйгулла хәзрәт Мисырда укыган бер галим фазыль (башкалардан аерылып торучы) кеше иде»,—дип яза. («Тукай турында истәлекләр», 1976).

Мотыйгулла хәзрәтнең улы Камил Мотыйгый да үзенең истәлегендә мәдрәсәдә Мотыйгулла хәзрәтнең гыйльме гаруз (шигырь төзелеше турындагы белем) дәресләре алып баруын яза. Габдулла Тукай бу дәресләргә бик иҗтиһат белән йөрде, ди.

Шулай итеп, Габдулла Тукай шигырь турындагы белемне иң беренче булып остазы Мотыйгулла Төхвәтуллиннан ала.

Әхмәтша учитель

Халитова Бибинур Әхмәтовна истәлеге, китапханәче.

Габдулла Тукайны русча укыткан Әхмәтша учительдә мин дә укыдым. Мин башта Мотыйгулла Төхвәтуллинның татар кызлары өчен булган мәктәбендә укыдым. Ләкин минем русча да бик укыйсым килә иде. Тик уку өчен түләрлек мөмкинлегебез юк иде. Әтием электростанциядә машинист булып эшли, эше авыр, шунда эшләп чахоткадан үлде. Әни кешеләргә кер уа, укуга түләрлек акча юк. Шуннан мин Әхмәтша абыйларга кердем дә: «Әхмәтша абый, мин сезгә кер уармын, өй җыярмын, мичләрегезне ягармын, тик мине урысча укытыгыз»,— дидем. Шулай мин русча укый башладым.

Русча укытучыларның белемнәрен хөкүмәт комиссиясе тикшергән икән, Әхмәтша абый рус телен хәтта рус укытучыларыннан да яхшырак белә торган булып чыккан. Шуның өчен патшаның аерым указы белән аңа Алтын медаль биргәннәр.

Алтын медаль сары лентага тагылган иде. Мин аны өй җыйганда кулыма алып карый идем. Әхмәтша абый медальне тартмага гына салып тота, һәр көн мәктәпкә шул медальне тагып керә, шуның белән дәрес башлый иде.

Габдулла Тукайга яшьтән бөек рус культурасын үзләштерергә мөмкинлек биргән, рус телен беренче булып өйрәтүче кеше шушы Әхмәтша учитель була.

Уральск — Дәвана — Льбищин

Габдулла Тукайны Кырлайдан Уральскига алып килгән Бәдри абзый (ул Галиасгар җизнәсенең сеңлесенең ире булса кирәк) озакламый

үзе дә гаиләсе белән Кырлайдан Уральскига күчә. Аның Тукайдан (үрт яшькә олы Камалетдин исемле улы казахлар арасына чыгып вак-төяк нәрсәләр сатып та, туры килгәндә балта эшләре эшләп тә көн күрә. Шундый бер чыгуында, Габдулла Тукайның үтенече буенча, казах даласына кымыз эчәргә аны да үзе белән ала.

Яз көне Урал елгасы ташып, су белән тулган тугайлык, суы кипкәннән соң гөрләп үскән яшеллек белән каплана. Камалетдин белән Тукайның юлы Уральскидан чыгуга бер җиде чакрым чамасы әнә шул куе таллык, шаулап торган камышлык, мөлдерәп пешкән бөрлегән, чәнечкеле кыргый слива — күгәнлек һәм алсу чәчәкле аю камыры (гөләп) куаклары арасыннан үтә. Аннан инде Алкан ягы — дала башлана.

Урал елгасының халыкта «Бохара ягы» дип йөртелгән сул як далаларында эреле-ваклы казах авыллары — балчык өйләрдән торган кышлаулар күренгәли. Казахлар кышны шунда уздырып, бу вакытта инде сусыл үлән белән капланган киң далага — терлек көтү өчен җәйләүләргә чыгалар.

Болар шул дала буйлап баралар. Юлда Тукай үзенең ике китап язуы, шуларны Казанга бастырырга җибәрүе хакында сөйли. Барганда бер елга янында тукталып, Тукай үзе алган кармак белән балык тотарга утыра. Камалетдин ат ашата. Шулай бара торгач, ике көн дигәндә, Дәвана дигән җәйләүгә килеп җитәләр, шунда урнашалар. Казах хатыннарыннан сатып алып, һәркөнне май белән кайнар нан ашап кымыз эчәләр. Монда казахларның ир балалары 6—7 яшькә хәтле бөтенләй ялангач йөриләр икән. Камалетдиннең («Тукай турында хатирәләр», 1976) истәлегенә караганда, Тукай бу хәлне күргәч: «Балаларның зурысына күлмәк, кечесенә ыштан тегеп киерт!»— дип, казах хатынына үзенең сөлгесе белән тастымалын бирә.

Биш-алты көннән Тукайның кире кайтасы килә башлый. Кайтырга атлы юлдаш эзләп карыйлар — тапмыйлар. Юлдаш эзләп «Льбищин» дигән җиргә китәләр. Льбищин — 1919 елда гражданнар сугышы герое Чапаев һәлак булган урын. Ул хәзер Чапаев шәһәре дип атала.

Льбищин ул вакытта Урал елгасының уң ягын биләгән һәм елга буена урнашкан рус казачестволарының Бударено, Кожахарск кебек станицасы була. Анда һәркайда кызыл балчыктан өелгән тәбәнәк өйләр, тузанлы урамнар. Анда-санда бүрәнәдән салынган кулак һәм бай йортлары һәм алар тирәсендә бер зур чиркәү, арырак — манарасыз гына итеп салынган бер мәчет күренеп кала. Станицаның төп халкы рус казачествосы, аннан кала — казах, украин, татарлар. Руслар — хәрби хезмәт, татарлар һөнәрчелек һәм сәүдә итү белән көн күрәләр.

Менә шул Льбищинга килеп, Тукай белән Камалетдин тузанлы урамнарда озак йөриләр, кайтырга юлдаш эзлиләр. Монда да таба алмагач, тагын Уральскига икәүләп кайтып китәләр.

Бу сәяхәт 15 көн дәвам итә.

Габдулла абый эшкә керә

Тукай апасының улы Хөсәен ага Зәбировның икенче истәлеге.

Уральск— минем туган шәһәрем. Мине әни: «Габдулла абыең укыган мәктәпкә бирәм»,— дип, Әхмәтша учитель мәктәбенә укырга бирде.

Учитель Әхмәтша абзыйның мәктәптәге зур горурлыгы— китап тутырылган пыялалы өч шкаф иде. Мин шкаф янына туктап, пыяла аша күренгән, матур итеп тезеп куелган, төрле калынлыктагы, тышлары алтын

белән язылган китапларны кызыгып карап тора идем. Тырыша-тырыша исемнәрен укыйм: «Крылов», «Пушкин», «Лермонтов», һ. б. Китапларның алтын белән язылганнарын учитель безгә бирми иде, ә Габдулла абыйга бирә торган булган. Мин өйдә дәреслектән Крылов, Пушкин шигырьләрен кычкырып укып утырганда, әни килеп китапның тышлыгын карый иде дә: «Габдулла да шул шигырьләрне укый иде. Аңа Әхмәтша алтын белән язган тышлы китапны бирә иде. Габдулла бик саклап кына тотып укыды аларны», — дип сөйли иде.

Габдулла абый мәдрәсәдә укыганда 1905 елда «Уралец» типографиясенә эшкә дә керә, шул ук вакытта шигырьләр дә яза.

Ул туган тиешле Сафи абзый белән Фатыйма апаларга баргалап йөри. Аларның тормышы турында «Кечкенә генә бер көйле хикәя» дигән шигырь язып, әнигә килеп укый. Үз туганың турында шулай язмыйлар инде дип, әни аның бу шигырен яратып бетерми. Бу шигырьдән тыш Габдулла абый инде ул вакытта ук «Мужик йокысы», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр», «Теләнче», «Сорыкортларга» шигырьләрен язып газетада бастырган була.

Габдулла абый типографиядә дә бик күп эшли.

Типография хуҗасы Камил Мотыйгый үзенең истәлегендә Габдулла абыйның башта наборщик булып керсә дә, яхшы эшләгәне өчен, гадәттән тыш тырыш булганы өчен корректорлыкка күтәрелүен яза. Ул матбаганың иң көчле шагыйре вә мөхәррире дәрәҗәсенә иреште, ди. («Тукай турында хатирәләр», 1976.)

Габдулла безгә килгәндә күп вакыт бик талчыгып килеп керә иде. Эшләгәнен дә яраталар, акча да түлиләр иде үзенә, дип искә ала иде әни. Ул вакытта типографиядә ниләр булганын әни белмәгән, билгеле. Бервакытны әни, гадәте буенча, аш хәзерләп Габдулла абыйны көтә икән. «Көтәм, көтәм, ул кайтмый да кайтмый. Байтак вакыт үткәч кенә бик борчылып, кәефсезләнеп килеп керде. «Ник болай соңга калдың?» — дигәч: «Әй, карточкага төшерделәр. Үзем һич теләмәгәнчә итеп, кул тоттырып төшерделәр», — дип күңелсезләнеп сөйләде. Бик ярата дип, хәсиятләп пешергән ризыгымны да рәтләп ашамыйча китеп тә барды Габдулла», — дип сөйләде әни. Сүз монда аның Қ. Мотыйгый белән кул бирешеп төшкән рәсеме турында баргандыр, күрәсең.

Безнең гаилә белән якын туганнарча йөрешә торган Кальтиев абыйлар гаиләсе бар иде. Кальтиев Гариф абый үзе Тукай эшләгән типография эшчесе. Андагы хезмәтнең авырлыгын, эшләү шартларының начарлыгын ул әнигә килеп сөйли торган була.

Беркөнне әни бер мәҗлескә ашка чакырыла. Анда шәһәрдән күп хатын-кызлар җыела һәм Габдулла абый эшләгән типография хуҗасының анасы да була. Мәҗлестә, сүз артыннан сүз чыгып, Габдулла абыйның типографиядән эштән куылуы турында сөйли башлаганнар. «Нигә аны эштән чыгардылар икән?»— дип сорагач, әлеге абыстай: «Ул эшен алып бара алмады, шуның өчен чыгарылды», — дип җавап биргән. Әни бу хәлгә бик борчылган. «Нишләргә дә белмәдем, кайтканчы күз яшемне көчкә тыеп утырдым», — дип сөйли иде.

Ә Камил Мотыйгый үзенең шул ук истәлегендә Габдулла абый турында: «Ул, эшчеләрне забастовкаларга котыртучылар мәзһәбенә кереп китеп, минем матбагада булган барча эшчеләрне дә миннән жалунье арттыруны сорап, эш ташларга котыртты. Шуның өчен... аны матбагадан бөтенләй хезмәттән чыгарырга туры килде»,— дип яза.

Шул хәлләрдән ике атна үтүгә, 1907 елның февраль аенда, Камил Мотыйгыйның матбагасы хөкүмәт тарафыннан ябыла. Ә Габдулла абыйга солдатка алынырга комиссия тору вакыты килеп житә. Комиссиягә каралу өчен ул туган ягына, Казанга кайтып китә.

Тукайны дуслары якын иткәннәр

Кәримова Зәйнәп Габдулловна истәлеге. Уральск өлкә архивының фәнни хезмәткәре.

Минем эти Габдулла Кәримов Уральск шәһәрендә туып үскән, сәүдә белән көн күргән. Заманына күрә алдынгы карашта булган. Безгә: «Балалар, сез русча укыгыз, русчаны бик яхшы белегез, ләкин туган телегезне онытмагыз», — ди торган иде.

Эти Габдулла Тукай белән күрешеп, очрашып, аралашып яшәгән. Этиемнең сөйләвенчә, 1906 еллар иде, ахрысы, Тукай безгә килгән көннәрнең берсендә этиемә: «Мин татарча журнал чыгарырга уйлыйм. Ярдәм итәрсеңме?!» — дип туп-туры сорау биргән. «Шунда ук сорагаңы кадәр акча чыгарып бирдем. Минем булышуым шул булды Габдуллага», — дип канәгатьләнеп искә ала иде эти Тукай турында сөйләгәндә.

Типографиядә

Валентина Александровна Гладышева сөйләгәннәрдән.
Уральск эшчесе.

Этием Гладышев Александр Кузьмич озак еллар Уральск шәһәрендә типографиядә эшләгән кеше. 13 яшендә «Уралец» типографиясенә эшкә керә, наборщиклыкка өйрәнә. Шунда ук бер татар малае Апуш та типографиягә өйрәнчек булып керә. (Этием сөйләве буенча, мин Габдулла Тукай белән яхшы таныш. Аның турында язылганнарны тапсам, хәтта Тукайның туган көнен билгеләгән календарь битләрен дә кадерләп жыеп барам.)

Апушны өйрәтүне этиемә тапшыралар. Этием әле үзе исән вакытта, мин аның янына типографиягә баргач, эш урынында, нәкъ Апушны өйрәткән шикелле, мине дә өйрәтә, төрле хәрефләр салынган зур касса янына ничек килеп басарга, шул озынча кургашын хәрефләрне бәсыман чыбык белән ничек итеп, тиз-тиз генә эләктереп алып, сай тартмаларга тезәргә өйрәтә иде.

Яшь аралары шактый булса да (этиемә ул вакытта 14 яшь, Габдуллага 18—19 яшь), бу ике яшь кеше бик тиз дуслашып китәләр. Тукай этиемне «Шияпка» дип, этием Тукайны «Апуш» дип йөртә.

Үзенең язмаларында этием болай ди: «Тукай русча дөрес сөйләшергә өйрәнү өчен мине, урыс малаен, бик үз итте», — ди. «Тукай табигатьне бик ярата иде. Аның теләге белән без икәүләп Урал елгасының яр буйларын буйлыйбыз, шәһәрнең икенче очындагы зиратка барабыз, яисә шәһәр читенә ат чабышлары кararга баргалый идек. Шулай йөргәндә Тукай күп сөйләшми, ә кайвакытларда аеруча житдиләнә. Монысы инде нинди дә булса көлке нәрсә сөйләгәндә була. Ничаклы гына көлкене сөйләсә дә, үзе һич көлмәс иде. Ул халык әкиятләрен бик ярата иде. Кайбер көннәрдә Апуш минем квартирама (һәм шулай ук башка таныш-белешләренә) куна да килгәли иде. Чөнки аның яшәү өчен үзенең бүлмәсе дә юк иде. Ләкин Тукай үзен бик олы

тота, аның үз-үзенә ышанычы бик көчле иде. Яшәү өчен иң кирәкле булган нәрсәләрдән тыш аның башка һичнәрсәсе юк. Һәм ул, һичнинди купшылыкка, байлыкка кызыкмыйча, күп эшли. Ул халык файдасы өчен эшли иде. Ул миңа тормышны аңларга өйрәтте».

Типографиядә ул татар эшчеләре белән (Кальтиев, Насыйбуллин һәм башкалар) бик күп сөйләшә. Әгәр ул сөйләгәннәрне китап итеп язып барсаң, әллә ничә том чыгар иде.

«1905 елны безнең типография эшчеләре, 8 сәгатьлек эш көне таләп итеп, демонстрациягә чыктылар. Ул митинг белән тәмамланды. 1906 елда типографиядә «Печатниклар союзы» төзелде. Типографиядә студентлар да эшли иде. Мәсәлән, Бараев М. И., үзе студент булса да, типографиядә корректор да булып эшли иде. Шул Бараев «Печатниклар союзы»ның председателе булды.

Типографиядә студент Шилов һәм Шилова тарафыннан яшерен түгәрәк оештырылган иде. Анда шулай ук Бараев та, эшчеләрдән Коканов, Сенькин, Зуев, Сафоновлар да бар иде. Бу түгәрәкнең атнага бер мәртәбә занятиесе була. Аның конспиратив квартирасы элеккеге «Караван» складлары янында иде. Мин шул яшерен квартирага өлкән иптәшләрнең кушкан йомышын үтәргә бара идем. Анда миңа революцион җырлар язган листовкалар, прокламацияләр бирәләр. Без Апуш белән кичен ул кәгазьләрне шәһәрнең үзәк урамы Большая Михайловскаяга һәм башка урамнарга ябыштырып чыга идек. «Смело, товарищи, в ногу», «Вихри враждебные веют над нами» дигән һәм тагын башка җырларны Апуш татарчага тәрҗемә итеп, татарларга шуларны җырларга өйрәтте.

РСДРП(б) ячейкасы җитәкчелегендә 1906 елны шәһәрдә 1 Май демонстрациясе оештырылды. Анда тимер юл эшчесе Николай Покатилов башлап йөрде. Халык башта духовное училище янына җыелды, Аннан Ханская роща ягына юнәлделәр. Апуш белән икәү без дә аларга кушылдык. Апуш миңа революциянең әһәмияте турында аңлата иде. Иске собор янында тукталган арада металлистлардан берәү кызыл полотно җәеп җибәрде. Аны бер колгага беркеттеләр, шуны күтәреп халык Ханская рощага китте. Ләкин андагы аланлыкта безне атлы казаклар чолгап алды. Демонстрация таралды.

Шул көнне үк кичен Покатилов, Коканов халыкны Урал елгасының аръягында җыелырга чакырдылар. Эшчеләр анда шәһәрдән берәм-берәм генә чыгып бардылар. Кешеләр җыелып бетеп, студент Шилов Май бәйрәменең әһәмиятен сөйләп торганда, көтмәгәндә тагын атлы казаклар килеп чыкты, демонстрантларны камчы белән кыйный башладылар. Безнең типография наборщигы Воронцов Павел Николаевичны кабыргаларын сындырганчы кыйнап ташладылар. Ул озак вакытлар больницада авырып ятты. Ул елларны эшчеләр хәле менә шулай иде», дип сөйләде әти.

Әтием Гладышев Александр Кузьмич гражданнар сугышы чорында үзе теләп фронтка китте, элегрәк В. И. Чапаев җитәкчелек иткән 22 дивизиядә Уральск шәһәрен аклардан азат итү сугышларында катнаша. Сугышлар беткәч, партия аны 25 меңчеләр сафында авыл хуҗалыгын күтәрергә җибәрә. Авыл хәлләре рәтләнгәч, әтием яңадан Уральскига кайта, типографиядә үз эшендә эшли башлый, типографиянең директоры да булып тора. Бөек Ватан сугышы чорында, карт булса да, хезмәт армиясендә катнаша. Ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр «Землячка» исемендәге фабрикада хезмәт итте.

КАЗАНГА КАЙТКАЧ

Булачак дуслар очрашкан йорт

Казанның Яңа бистәсендәге Мәҗит Гафури урамы, 35 номерлы йортта яшәүче Шәрәфетдинов Әгъзам бабай сөйләгәннәрдән.

Казан шәһәренең Яңа бистәсендә элеккеге Малая Симбирская, хәзерге Мәҗит Гафури исемендәге урамындагы 35 номерлы йорт — Фатих Әмирхан әтисенең йорты булган. Йорт хәзер берничә гаиләгә бүлгәләп бирелгән. Шунда яшәүче 91 яшьлек, ләкин әле әйбәт хәтерле, житез хәрәкәтле, матур итеп тезеп сөйли торган мөлаем йөзле Әгъзам бабай, бүлмә саен кереп, бүлмәнең һәрбер деталенә игътибар итеп, өйнең тарихын сөйли: менә бу парадный сыман зур ишектән керүгә, сул як — Фатих Әмирхан ягы булган. Менә Фатихның йоклы бүлмәсе. Ә менә монысы — ике тәрәзәле бүлмә — аның эш кабинеты: Фатих ягының аерым ишеге дә булган. Теләгән чакта Фатих шуннан файдаланган. Менә бу икенче ишек күрше тарафка, Фатих Әмирханның әтиәнисе яши торган якка алып чыга. Анда тагын әнисенең кызлар укыта торган бүлмәсе дә булган. Бу йортта халкыбызның ике бөек әдибе — Фатих Әмирхан белән Габдулла Тукай беренче мәртәбә очрашалар.

Бу хәл 1907 ел ахырында, Тукай туган якларыннан әйләнеп кайткач була. Беренче очрашуда (Фатих Әмирханның истәлегенә караганда) гади генә киенгән, кешегә алай ук ачылып китми торган, сөйләшкәндә кыска җаваплар белән генә канәгатьләнүче яшь шагыйрь Фатих Әмирханда бернинди дә тәэсир калдырмый. Ләкин инде «Әльислах» газетасы редакциясендә очрашып бергә эшли башлагач, Фатих Әмирхан белән Габдулла Тукай зур сердәш, дуслар булып китәләр, һәм бу дуслык гомер буе дәвам итә.

Сөләйман Аитов йортында

Казандагы Ләбибә Хөсәения мәктәбе укучысы, соңыннан шул ук мәктәпнең укыту эшендә булышчысы Төфахелҗинан Гыйльметдинова истәлеге (1892 елда туган).

Без Фатиха апа Аитовалардан ерак тормый идек. Фатиха Аитова — Сөләйман байның хатыны, Казанда кызлар мәктәбе, соңыннан кызлар гимназиясе булып киткән данлыклы мәктәпне оештыручы. Фатиха апа әни белән мине якын күрә, сезгә генә ышанам дип, өйләрен карауны безгә тапшыра иде. Үзләре дачага киткәндә, без аларның шәһәрдәге өйләрендә калабыз, ә алар өйдә торганда, дачада яши идек.

Фатиха апаның өч үсмер ир баласы бар. Шуларны тәрбияләп, ашлар әзерләп, шул ук вакытта аларга күз-колак булырга да Фатиха апа безне җибәрә иде. (Бу 1908 елларда булып, миңа ул вакытта 15—16 яшьләр тирәсе иде.) Фатиха апаларның дачалары шәһәр читендә, Ботан бакчасы (Ботанический сад) каршында иде.

Олылар шәһәрдә булганда, бу дачага яшьләр җыела: Фатиха апаның Исмәгыйль, Ибраһим исемле уллары (Йосыфлары ул вакытта әле кечкенә малай иде), аннан абыйлы-энеле Фатих Әмирхан белән Ибраһим Әмирханнар, Габдулла Тукаев та килә иде.

Габдулла Тукаев ап-ак йөзле, яңа гына чыгып килә торган мыеклы, аягында кайчак ботинка, кайчак читек, өстенә я җилән, я кәзәки кигән була. Килү белән миңа: «Кая, щетка бир әле, шушы чалбарны бераз чистартыйм әле», — дигәч, мин: «Кая, үзем чистартып бирим», — дия идем. Ул идәндә одеял ябынып утырып тора, мин чалбарны әйбәтләп чистартып бирә идем.

Кайчакта бик киенеп, галстуклар тагып килә дә, бераздан муенындагы галстугын йолкып ала: «Тагын шушы камытны тактым инде», — дип әйтә иде. Аның тавышы көчле түгел, үзе һәркемгә бик йомшак мөгамәләдә. Йөзе гел моңлы була иде. Үзе күп вакыт эченнән генә шыңшып җырлап йөри иде. Мин аңа: «Ник син өйләнмисең, Габдулла абый?» — ди идем. «Минем кесәм алтын белән тулы түгел шул, шунлыктан миңа кияүгә чыкмыйлар», — дия иде. Үзе ара-тирә:

Нигә мин кечкенә Апуш түгел,
Зуп-зур Тукай булдым?

— дип әйтеп куя иде.

Фатиха апалар дачага киткәч, яшьләр шәһәрдәге өйгә җыелалар. Фатиха апа уллары янына Тукай килә. Берничә мәртәбә Хөсәен абый Ямашев та килде. Яшьләр шаулашып бик күп сөйләшәләр, нәрсәләрдер язалар, шау килеп көлешәләр. Уку-укыту турында, русча укыту кирәклеген, кыз балаларга да русча укыту кирәк, дип сөйләшәләр.

Ямашев Хөсәен абый сөйкемле ак йөзле, бик пөхтә киенеп йөри торган бик матур кеше иде. Миңа йомыш кушканда «алмакаем» дип дәшә иде. Аннан: «Син соң үзеңнең алма икәнеңне беләсеңме?» — дип сорый да: «Синең исемең Төфахелҗинан — җәннәт алмасы дигән сүз бит», — дип миңа аңлата иде.

Яшьләр шулай җыйналып, сөйләшеп, кайчак бәхәсләшеп шау килеп утыралар иде.

Шундый ук истәлекне Сөләйман Аитовның килене Мәрьям апа Аитова да сөйли:

«Сөләйман абзыйларның (кайнаталарымның) йорты хәзерге Татарстан һәм Нариман урамнары чатында иде. Өйнең уң як өлеше «Әти ягы» дип йөртелә иде. Ә шул өйгә кушылып урам чатына салынган сул як өлеше Фатиха апаның (кайнанамның) әнисе, ягъни Сөләйман байның кайнанасы Мәмдүдә абыстайга дип салдырылган. Ул якны һәркем «Дәү әни ягы» дип йөри иде.

Дәү әни үзе бик ачык йөзле һәм кеше яратучан. Шуңа күрә безгә килүче барлык яшьләр аны «Дәүәни» дип йөриләр, килү белән гел аның ягына җыелалар. Беренче булып Фатих абый Әмирхан килә. Аяклары параличлы булганга, ул кайтып йөри алмый, безгә куна килә. Хас аның өчен билгеләнгән аерым бүлмә дә бар иде. Ул бүлмә икенче катта, тәрәзәләре нәкъ почмакта, икесе ике урамга карый.

Фатих абыйдан соң башкалар җыела. Мин, бу өйгә яңа гына төшкән яшь килен булганга, аларга катнашырга ояла идем. Дәү әни аларны мич ашлары белән, чәй белән сыйлый иде. Яшьләр озаклап, шау килеп сөйләшеп утыралар. Аннан «әти ягы»на залга чыгалар.

Солтан абый Габәши рояльдә уйнарга тотына. Ибраһим абый бик матур итеп җырлый. Ибраһим абый үзе дә рояльдә уйнарга, җырга, биюгә бик оста иде. Башкалар аңа кушыла. Шулай итеп, эткәй өйдә булмаганда яшьләр безгә җыелалар иде.

Кайнагам Исмәгыйль Габдулла Тукай белән якын таныш булганнар. Сәламәтлеге яхшы чагында Габдулла Тукай әнә шул яшьләр арасына килә торган булган. Шул күңел ачуларда катнашкан. Ул музыканы, җырны бик яраткан.

Истәлекне Мәрьям Аитованың кызы Диләрә ханым дәвам итә:

Ибраһим абый Аитов Ростов-Дон шәһәрендә яши һәм озак еллар Виноградчылык институты белән бәйләнештә булып, виноградның яңа сортларын булдыру өчен тырыша.

Норвегия галиме, сәяхәтче Тур Хейердалның 1969—1970 елларда камыштан ясалган «Ра», аннан соң «Ра-2» көймәләрендә Атлантик океан аша сәяхәте уңышлы тәмамлану уңае белән, Ибраһим абый үзенең китереп чыгарган яңа сорт виноградына «Хейердал» дигән исем бирә.

Тур Хейердал Советлар Союзына килгәч, Ибраһим абыйларда улы белән кунак булып китә. Улы ялын Ибраһим абыйларда уздыра.

Кунак булган чакта татарча итеп, пар бөрки-бөрки шаулап утырган самовардан тәмләп чәй эчү Хейердалга бик ошый һәм киткәндә сувенир итеп аңа әлеге самовар бүләк ителә, хатлар язышалар. Хейердал «Ра» көймәләреннең һәм ганләсе белән төшкән рәсемнәрне, шулай ук Тын океандагы Пасха утравына сәяхәте вакытында төшкәннәрен дә җибәрә.

Шулай итеп, дөньякүләм атаклы сәяхәтче галим белән якташыбыз арасында дуслык урнаша. Ибраһим абый берничә телдә яхшы сөйләшә.

Ибраһим абый, туган якларыннан ерак торса да, туган җиргә зур мәхәббәт белән яши. Ул үзе китереп чыгарган беренче сорт виноградларның иң яхшыларына «Әмирхан» һәм «Тукай» исемен бирә.

Тукай абый биргән конфет

Мөхәммәт Әхмәдиев, укытучы.
Саба районы, Керәнле авылыннан.

Мин малай чакта Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый торган Хуҗа Бәдигый абыема кунакка килдем. Без, Габдулла Тукай, Хуҗа абый, Хөсәен абыйлар белән, кемнәрдәдер кунакта булдык. Габдулла абый кара хәтфә кәләпүштән, җилән шикелле озын кәзәкидән, балагы төшерелгән чалбар, аягында штиблет. Үзе бик көләч иде. Урамга чыктык. Урам Екатеринская дип атала иде (хәзерге Тукай урамы). Шул урам буйлап киттек. Тукай абыйлар алдан бик кызык сүзләр сөйләшеп, көлешеп бардылар. Мин алар артыннан бардым. Бер чатта конфет саталар иде. Шунда Габдулла абый туктады да: «Тукта, бу егеткә конфет алып бирмичә булмас бит инде»,— дип, миңа очлайтып төрелгән кәгазьгә салынган конфетлар тоттырды. Шунда ук бер конфетны алып каптым. Минем гомеремдә беренче мәртәбә мондый ләззәтле нәрсәне тәмләп каравым иде. Тукай абый биргән конфетның тәме әле дә авызымда тора кебек.

Ахыры бар

Гомәр Саттаров,
филология фәннәре докторы, профессор

МУЛИЛЕ — МУЛЛЫК ИЛЕ

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫНА КИЛГӘН ОЧЕРКЛАРДАН

Татарстанның Тау ягы мәйданын икегә аерып, борыла-сырыла агып ятучы алкын сулы Зөя елгасы буена утырган авыллар байтак. Туган авылым Мулиле — шуларның берсе.

Республикабызның Зеленодольск районына кергән Мулиленең шактый кызыклы һәм игътибарга лаеклы тарихы бар. Мондагы авылларның күбесенең юл башы болгар чорына барып тоташа. XI—XII йөзләрдә Иделнең уң ягы Идел-Камә буендагы Болгар территориясенең көнбатыш өлешен тәшкил иткән. Бу төбәктә яртысыннан артыгы Зөя елгасы бассейнында булган 250 гә якын болгар авылларының калдыклары мәгълүм. Тарих галиме Х. Г. Гыймади: «Казан артына һәм Идел уңъягына болгарларның беренче башлап күпләп күчеп утырулары XIII гасырның 30—40 нчы елларына (ягъни 1236 нчы елдан соң, Болгар дәүләте Алтын Урда гаскәрләре тарафыннан җимерелгәннән соң — Г. С.) туры килә»,— дип яза һәм бу җирлектәге күп кенә татар авылларына шул заманда нигез салынуын әйтә.

Мөхтәрәм якташыбыз Каюм Насыйри «Зөя өязе авыллары» дигән хезмәтендә Мулиле авылының тарихына караган кыйммәтле мәгълүматлар бирә. «Бу Мулла иленең асылы бик күптәндер. Монда бер Муллагол дигән кеше Болгардан килеп утыргандыр. Алар әүвәл килгәндә берничә кеше булып килгәннәр. Бәгъзәсенең исемнәре мәгълүм түгел. Аларның берсе Муллагол дигән кеше. Янә алар белән берәү бар икән, Шәехби дигән адәм. Ул үзенең бер углы белән килгән. Углы Теләш исемле галим кеше булгандыр; Мулла иленда дәрес әйткән, мәдрәсә ихъя кылган (салган — Г. С.). Бу Шәехбинең атасы Тәмте дигән кеше... 1660 нчы елларда Хуҗаштан байтак халык күчеп Мулла иленә кушылгандыр вә һәм Өҗемнән күп мөселманнар анда күчкәннәрдер. Өҗем дигән авыл (хәзер Мәҗем дип йөртәләр) Зөядән ерак түгел авылдыр»,— дип яза.

Бу өзектән яхшы аңлашылганча, Мулиле авылына Болгар шәһәрен монгол яулары 1240 елда тар-мар иткәннән соң күчеп килсәләр кирәк. Шулай булганда, Мулиле авылының нигезләнүе XIII гасыр урталарыннан саналырга хаклы, һәм аның чал тарихы 700 елларга җитә булып чыга.

Туган авылы Мулиленең тарихы белән кызыксынган һәм аны өйрәнеп авыл тарихын язган Габдрахман бабам Саттаровның (Габдрахман Күкенең) мәгълүматлары да (мәсәлән, авылның Җүкәсәр, Әрә эче дигән урам; Маматау, Алып бабай чабата каккан җир кебек таулы-калкулыклы кыр-басу; Шики ермагы, Чиркәлше ермагы, Нәркә сазы, Дуңгыз аткан күпере, Үзәнсигез болыны, Сөенечкә басуы, Чана чыгышы кебек җирле атамаларының бик борынгы булуы; авылда болгар төленә нисбәтле: Болгарый, Канак, Кондыр, Тапай, Күке, Чупак, Ызай кебек борынгыдан килә торган нәсел-ыру кушаматларының саклануы; авыл зиратында

Рәҗәп-Солтан исемле хатын каберенә куелган, 1493 ел белән даталанган кабер ташы, шәҗәрәләр һ. б.) авылның борынгылыгы турында сөйлиләр.

Билгеле булганча, хәзерге татар телендә, сүз тәртибе таләбе буенча, сан исемнән алда килә һәм исемне ачыклау вазифасын башкара: **өч китап, җиде таш** һ. б. Мулиле микротопонимиясендә Үзәнсигез (сигез үзән түгел). Ярасалты (яр асты алты) — болын исемнәре; Кыекбиш (биш кыек түгел) — басу атамасы кебек конструкцияләр дә урын ала. Бу — телебездәге иң борынгы формалы сүз тәртибе.

Мулиле халкы арасында бу авылның борынгылыгын раслардай ривәятьләр дә йөри. Хөрмәтле Хәяли бабай Әхтәмов (ул 90 яшькә җитеп, 1976 елда вафат булды) болай сөйли иде:

«Безнең авыл — бик борынгы авыл ул. Моннан 7 гасыр элек, урманнар белән капланган «Әрә эче» исемле бу урынга берничә гаилә килеп урнаша. Арада Муллагол дигән кеше дә була. Аның хуҗалыгы Әрә елгасыннан 30—40 метр ераклыкта гына була һәм ул балык тоту белән шөгыльләнә башлый. Соңрак килеп утырган халык урманнарны арчып, чәчүлек җиргә әйләндерә. Басу исемнәрен генә кара: Шомыртлык, Каенлык, Каенлык асты, Наратлы чокыры, Карама турысы, Чишмә эче...»

Бүгенге көндә Мулиледә, Хәяли бабай сөйләвенчә, 26 нчы буын кешеләре яши. 500 гә якын хуҗалыгы булган бу авыл халкының дүрттән өч өлеше — Муллагол нәселе кешеләре.

Авыл исеменең килеп чыгышы Муллагол дигән борынгы болгардагы кеше исеменә нисбәтле. Муллагол исеме элекке «мулла» һәм «гол» (кол) дигән сословие терминнарыннан тора: «мулла» сүзе рухани сан төшенчәсен генә белдерми, «укымышлы, белемле кеше, гыйлем иясе; укый-яза белүче; укытучы, остаз» мәгънәсендә дә кулланылган. Борынгы кеше исемнәребез составында шулай ук еш очрый торган төрки чыгышлы «кол (гол)» сословие титулы шәхеснең чыгышы ягыннан кол булуын билгеләү-күрсәтүдән тыш, аның «алла колы», «алла бәндәсе» булуын да белдергән.

Муллагол иле атамасы тора-бара лексик-фонетик үзгәрешләр кичергән. Болгар-татар теленә хас булганча, кеше исемен кыскарту нәтиҗәсендә, «гол» сүзе төшеп калып, «Мулла иле» барлыкка килгән. Мулла сүзенең «ла» иҗеген төшерү нәтиҗәсендә, атаманың «Мулиле» варианты ясалган һәм «муллык иле, байлык иле» дигән мәгънә аңлата башлаган.

Мулиле исеме составындагы «иле» географик термины да авылның борынгылыгы турында сөйли. Ил сүзе төрки телләрдә хәзер дә кулланылышта йөри торган «туган ил, ватан, дәүләт, мәмләкәт» төшенчәсен белдерүдән тыш, борынгы төрки телдә тагын: «кабиләләр берләшмәсе», «халык» мәгънәләрен бәян итү өчен дә кулланылган. Болгар-татар телендә ил сүзе «авыл» төшенчәсен белдерү өчен дә хезмәт иткән. Татарстанда уннан артык авыл шушындый исемне йөртә: Тау иле, Күл иле, Кар иле, Ялаг иле, Чүриле, Чуваш иле һ. б.

Мулиле авылының рәсми исеме — Молвино. Ул «мул/мол»га тирә-юньдәге рус авыллары исеме составында урын алган — вино (мәсәлән, Бритвино һ. б.) кушымчасын ялгау юлы белән ясалган.

Тарихтан билгеле булганча, Идел буенда яшәүче халыклар, шул исәптән татарлар, бик борынгы заманнардан бирле игенчелек белән шөгыльләнеп көн күргәннәр. Мулиле авылы халкының да төп кәсебе игенчелек булган. Терлекчелек тә хуҗалыкның шактый мөһим тармагын тәшкил иткән. Идел буе халкы, игенчелектән кала, сәүдә белән дә шөгыльләнгән, татарлар бу өлкәдә өстенлек иткәннәр.

Мулиле авылы да сәүдә өчен уңайлы урын сайлаган. Бу турыда Каюм Насыйри менә нәрсә яза: «Ул заманда Мулла иледә иген белән сату итүчеләр күп булган. Ә һәм Мулла иледә зур пристань булган; ә һәм Борындыкта пристань булган. Бәрле сулары, Гөбенә сулары бик зур су булган; ә һәм Зәя суында судноллар, баржалар йөридер икән. Бу авыллар Үтәк каласы тирәсендәге авыллар булганга күрә, Үтәк каласында игендер ә һәм башка төрле малдыр җыеп илтүчеләр, байлар күп булгандыр».

Авыл хуҗалыгының борын-борыннан төп тармаклары булып саналган игенчелек һәм терлекчелек һөнәренә Мулиле халкы бүгенге көндә дә тугрылыклы, бү-

генге көндә дә авылдашларымның төп кәсебе — игенчелек һәм терлекчелек. Мулиле һәм аның күршесендәге Өтәк авыллары халкы, «Искра» исемендәге күмәк хуҗалыкка берләшеп, заманчыл көчле техника, ныклы материаль база һәм фән казанышлары белән коралланган игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә.

Мин, һәр елны диярлек, җәйге ялымның бер аенда — август башында туган авылыма ашкынып, сагынып кайтам. Мулиледә — минем туган йортым, туган туфрагым, туган нигезем. Анда минем газиз әнием һәм сеңелем яши. Әти ягыннан да, әни ягыннан да, тормыш иптәшем Әлфия ягыннан да күпләгән туганнарым, нәсел-нәсәбем анда. Әтием ягыннан ишле нәселем—күкеләр, әнием ягыннан борынгыдан килә торган нәселем — чупчыклар, хатыным ягыннан — майурлар. Анда — минем тәпи йөри башлаганнан бирле бергә уйнап үскән иптәшләрем, яшьтәшләрем, сабакташларым, беренче укытучыларым, авылымның мөхтәрәм аксакаллары. Анда — минем үсмер елларда, тагын Казан университетында студент булып һәм аспирантурада укыган елларда хуш исле печән чапкан, чүмәлә куйган, кибән койган Яр асты алты, Куян атавы, Ишми чалуы, Олысаз, Бүре сазы, Тире кырган, Арыслан кыягы, Комаяк, Тустаган күле, Ирмышык, Әйдүч, Үзәнсигез болыннары; урак урган, зурат куйган Олтамак, Сөенечкә, Закар алды, Әптәл, Торна сазы кашы, Нарәтлык чокыры, Зират асты, Карама турысы, Әрә буе басулары. Су кергән, балык тоткан Комсу, Кукмар, Әҗәл, Биктимер, Мулла, Кыз, Паровой, Чупак күлләре, безнең йорт янындагы Урта күл; Чиркәлше, Шөлдермә, Шики ермаклары; ярлары җиләк-җимешле тал-әрәмәләр белән капланган Әрә һәм Зөя елгалары...

Кызыксынган иптәшләргә Мулиле авылының нәсел-нәсәп исемнәре һәм җирле географик атамалары турында тулырак мәгълүматларны Татарстан китап нәшриятында 1984 нче елда басылып чыгачак «Мәктәптә туган як ономастикасы» дигән китабыбыздан алырга мөмкин булачак. Биредә шуларның бер-икесенә генә тукталабыз.

Казаклар юл ярган басу. XIX гасыр башларында, авылның Олы кырында, язын чәчүлек җирләре — имана пае бүлгәндә, Мулиленең ярлы крестьяннары белән байлары арасында уңдырышлы басу өчен зур низаг чыга. Байлар, уңдырышлы басуны үзләренә алып, ярлы-ябагайларга уңдырышсыз кырны калдырмакчы булалар. Ярлы крестьяннар бунт күтәрәләр, берничә байны һәм куштанны авыз-борыннары җимерелгәнче кыйныйлар. Ыгы-зыгы арасында, бай куштаннарыннан берәү, яхшы чаптар атка атланып, волость үзәгенә чаба һәм Чакаудан, бер төркем атлы казак ияртеп, әйләнеп тә кайта. Казаклар, атлары белән ямь-яшел булып үсеп утырган арыш басуын таптатып, кара юл ярып, баш күтәргән халык янына ашыгалар. Ярсыган ярлы крестьяннарны казак камчысы белән кыйнап тараталар. Өч агайны волость үзәге Чакау төрмәсенә алып китәләр. Уңдырышлы басу байларга бирелә. Шушы вакыйгадан соң, басу «Казаклар юл ярган басу» дип атала башлый.

Сәгъди сөргән басу. Электә безнең авылда Сәгъди исемле бик ярлы бер кеше яшәгән. Үзе тырыш, уңган булса да, карчыгы һәм җиде кыз белән бик фәкыйрь көн иткән. Ир баласы да булмаганга, аның җире бер генә иманадан торган. Бер иманалык җир белән тугыз кешене ашату-киендерү бик авыр-кыен була аңа. Сәгъди абзый бер елны язын авылыбызның Торна сазы дип атала торган кырының аръягындагы (Кече Өтәк ягындагы) зур бер сазлыклы урынын, көрәк белән канау казып, суын Торна сазына агызып киптерә. Кипкән торфлы сазлыкны сөреп, тырмалап-йомшартып иген чәчә. Торфлы яңа җир мул уңыш бирә. Авыл халкы басуны «Сәгъди сөргән басу» дип йөртә башлый.

Болар турында миңа авылыбызда күп еллар колхоз председателе булып эшләгән, РСФСР Верховный Советының беренче чакырылыш депутаты булган, Мулиленең тарихи үткәннәре һәм хәзергесе белән тирәннән кызыксынып яшәүче авылдашым Габдрахман ага Фәзлыев сөйләде.

Һәр авылның, Габдрахман ага кебек аяклы тарихка әверелгән мөхтәрәм карт-ларында, хөрмәтле аксакалларында күпме мөһим җирле топонимик мәгълүматлар, кызыклы фактлар саклана. Безгә аларны теркәп калырга ашыгырга кирәк. Алар — туган телебезнең ифрат зур байлыгы, кыйммәтле хәзинәсе.

Атамаларыбызны җыйнап, аларны фәнни принциплар нигезендә берничә томлык сүзлек итеп төзеп, бастыру зарур.

Хәзерге вакытта безнең тарафтан, «Татар теленең топонимик сүзлеге»н төзү өчен, Татарстандагы торак пунктларның җирле географик атамаларын һәм Идел-Урал җирлегендәге өлкә һәм автономияле республикаларның татар яшь торган районнарындагы топоним һәм микротопонимиарны җыйнау-туплау, анализлау алып барыла. Сүзлек шулар нигезендә төзеләчәк. «Татар теленең топонимик сүзлеге»н чыгару лексикографиябез тарихында яңа бер адым булачак.

Туган авылым исә, шушы фәнни эзләнүләрдә зур ярдәм күрсәтүе белән бергә, хуҗалыгындагы уңышлары ягыннан да мине чиксез шатландыра. Бүгенге Мулиле — чын мәгънәсендә муллык иле, муллык авылы. Аның халкы һәрьяктан җитеш, таза-мул тормышта яши. Байлыгының икономик асылын аның Зеленодольск районы «Искра» колхозының алдынгы хуҗалык булуы тәшкил итә.

«Искра» колхозы — күп тармаклы хуҗалык. Анда игенчелек, терлекчелек, яшелчәчелек кебек мөһим тармаклар шактый нык үсеш алган. Колхозыбызның соңгы ике-өч ел эчендә аеруча күтәрелүендә хезмәт сөючән авылдашларымның, атап әйткәндә, күп санлы механизаторларның, савымчыларның, белгеч-кадрларның, энергиясе ташып торган колхоз председателе Әгъзам Гобәйдуллинның өлеше зур.

Әгъзам Саматовичның «Искра» колхозы председателе булып сайлануына өченче ел гына әле. Ул безнең колхозга районыбызның «Комсомолец» колхозыннан, андагы тәҗрибәле председатель Хәмит Хәлилович Хәйруллинның остәлык мәктәбен үтеп килде. Әгъзам Саматович «Комсомолец»та баш зоотехник була. Үзен тырыш, фәнчә эшләүче белгеч итеп күрсәтә. Егерме җиде яшендә аңа районның шактый зур хуҗалыгыннан саналган «Искра» колхозын җитәкләүне ышанып тапшыралар. Район җитәкчеләре һәм колхозчыларының ышанычын аклый Әгъзам Саматович. Эшкә ул бөтен көчен, белемен, сәләтен бирә. Киләчәккә карап, авыл хуҗалыгы, зоотехниария һәм экономика фәннәре казанышларына таянып җитәкли колхозны. Белгеч-кадрларның, колхоз парторгы Рәшит Хәйретдинович Садыйковның сүзләренә колак сала, алар белән киңәш тота, кешеләр белән уртак тел таба белә.

Тагын шунысы куанычлы: колхозның барлык тармакларында төп белгечләре махсус югары белемле авылдашлар: баш агроном Галимҗан Сәлахиев, баш инженер Рөстәм Нуруллин, баш экономист Тәлгать Бакиров, баш механик Равил Шәкүров, баш бухгалтер ярдәмчесе Фәридә Нуруллина, завхоз Самат Гыйззәтуллин; махсус урта белемле Зөфәр Зиннуров, Дамирә Фәйзуллина, Гөлсинә Сәлахиева, Фәрит Сафин, Хәлим Әнвәров. Барысы да туган авылларын, аның кешеләрен һәм үз эшләрен яхшы белүче сәләтле хезмәткәрләр.

4500 гектар җире булган «Искра» колхозы дүрт-биш ел элек кенә өле гектардан 12—13 центнер ашлык алуга канәгать иде. Билгеле булганча, авыл тормышының икономик нигезе игенчелеккә бәйле. Игенчелекне күтәрмичә торып, терлекчелекне дә алга җибәреп булмый.

Яңа председатель менә шуны бик яхшы аңлап эш итә. Җирне ашлау, аңа кадер-хөрмәт күрсәтү, терлекләрне яхшы нәселле итү хакында даими кайгырта. Бу чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә, «Искра» колхозында 1981 елда уңыш, табигать шартлары кыен булса да, һәр гектардан 14 центнер чыкты. 1982 елда инде ул 28,1 центнер тәшкил итте.

Бодайның гектарыннан 45 әр центнер чыккан урыннары да бар. Казаклар юл ярган басудан гектар саен 41 әр центнер солы чыкты.

Шунысы аерата сөенечле: Зеленодольск районы хезмәт ияләре дәүләткә ашлык сату буенча унберенче бишьеллыкның өченче елы планын Татарстан АССРда беренче булып үтәделәр. Бу уңышка ирешүдә «Искра» колхозы хезмәтчәннәренең дә өлеше шактый зур.

«Искра» колхозында төзелешкә бик зур игътибар бирелә. Төзелешнең әйдәп баручысы — колхоз рәисе Ә. С. Гобәйдуллин үзе.

Ул председатель булып эшләгән вакыт эчендә колхозда хуҗалык ысулы белән байтак кыча төзелеш эшләре башкарылган. 800 баш савым сыерга исәпләнгән

комплекс сафка басты. Комплекста бөтен эшләр дә механикалаштырылган. Буфет һәм кибет бар. Ашханә ачу көздә тотыла. Расписание буенча медпункт һәм парикмахерский эшли.

Комплексқа керә торган юлларга асфальт җәелгән. Ындыр табаклары да асфальт белән капланган.

Менә шуңа күрә пенсиягә чыккан Мәдинә Садыйкова, Нурания Гыйззәтуллина, Сәлимә Сәйфетдинова кебек үз эшләренең осталары булган тәҗрибәле терлекчеләр комплекста эшләүләрен һаман дәвам иттерәләр. Яшьләрчә дәртләнеп эшлиләр.

— Һаман фермада сыер савасызмы әле? — дип сорагач, күршем Мәдинә апа Садыйковa:

— Нигә эшләмәскә, Гомәр энем, хәзерге эшне машиналар башкара, сыерларны машина белән савабыз, азык мул, үзем сау-таза!..— дип җавап бирде.

Терлек азыгы дигәннән, быел колхоз терлекләренә ике елга җитәрлек запас булдырылган. Колхозларның үз ишегалларында да яки янбакчаларында печән эскертләре утыра.

800 баш сыерга җәйге лагерь төзелгән. Монда да терлекчеләр өчен бөтен шартлар бар. Барлык эшләр механикалаштырылган, терлекчеләр йортында ял бүлмәсе һәм буфет көйләнгән.

Колхоз төзүчеләре, яңа биналар салдык, дип, искеләрен дә җимереп ташламыйлар. Алары колхоз көче белән төзәтелә, яңартыла бара. Шулар янына ук 160 баш бозауга һәм 200 баш сыерга яңа абзар салганнар. Иске ферма да, үзенә күрә, заманчыл төс алган. Монда да сөт блогы, терлекчеләр йорты, ясалма орлыклandыру пункты бар. Җылы абзарларда, биналарда терлекләр яхшы кышлыйлар, мул продукция һәм үрчем бирәләр. Менә шуңа КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, Профессиональ Союзларның Бөтенсоюз Үзәк Советы һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты 1982—83 еллардагы кышлату чорында терлекләрне кышлатуны уңышлы үткәрү, терлекчелек продуктлары җитештерү һәм хәзерләүне арттыру буенча барган Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп чыгучылар һәм Почет грамоталары белән бүләкләнүчеләр арасында туган колхозым — Зеленодольск районының «Искра» колхозы да бар. Мондый зур җиңү, зур уңыш белән ничек горурланмыйсың?!

Соңгы елларда «Искра» колхозында игенчелектә дә күп кенә яңа объектлар салынды. Ындыр табакларында 5 мең тонна ашлык сыйдырышлы дүрт һәм 500 тонналык суган саклау складлары корылды. Саный китсәң, колхозыбызда төзелеп беткән яки төзелеп ята торган объектлар шактый хәзер. 900 әр тонналы ике сенаж башнясы, 4 траншея, АВМ-0,65 агрегаты, колонкалары белән 2 мең метрдан артып киткән сууткәргеч, комбайн депосы, 25 автомашиналык җылы гараж, 100 санлы автомат телефон станциясе... Унберенче бишьеллыкка кергәч кенә дә «Искра» колхозы төзелешкә 3 миллион сумга якын акча тоткан. Сигезьеллык мәктәп, балалар комбинаты, культура йорты, ашханә, колхоз идарәсенең яңа бинасы, торак йортлар салу планлаштырылган.

Туган авылыбызда һәм колхозыбызда хәл ителәсе мәсьәләләр дә байтак әле: Зөя елгасыннан торбалар аша Олы кырга су китереп, ясалма сусаклагычлар булдыру, көтүлекләрне генә түгел, бәлки суган, чөгендер, кукуруз басуларын, иген кырларын да ясалма сугару белән тәэмин итү, сусаклагычларда балык үрчетү...

500 йортлы Мулиле авылының урамнары чокыр-чакырлы. Яз-көз тракторлар һәм автомашиналар авыл урамнарын бозып бетерәләр. Авыл урамнарын төзекләндерәсе, күтәртеп, вак таш сибәсе бар. Культура йорты бакчасының рәшәткәләрен яңартып, бакчасында агачлар, чәчәкләр үстерәсе иде. Мулиледә пекарня салганда да шәп буласы! Күрше Норлат авылыннан машина белән икмәк кайтканын көтеп, чират торып, авыл халкы ике-өч сәгать вакытын кибет янында исраф итмәс иде.

Авыл һәм колхоз музее булдыру турында да кайгыртырга вакыт. Аның яшь буында туган авылны, туган колхозны, авыл хуҗалыгы хезмәтен ярату хисләре тәрбияләүдә роле ифрат зур булачак.

Мулиледә мәктәп сигезьеллык кына. Анда, 320 урынлы яңа мәктәп төзелгәнәнсоң, урта мәктәп ачасы иде. Моның өчен югары белемле укытучылар бар, укучылар саны да җитәрлек. Мулиленең үзендә урта мәктәп булса, аны тәмамлаучыларның күбесе туган колхозларында эшкә калыр иде. Кызларга — савымчы, егетләргә киң профильле механизатор һөнәрен үзләштерү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Мәктәп янында гына колхозның машина-трактор паркы, мәктәптән ерак түгел терлекчелек комплексы. Укучыларга белем бирүне җитештерүчән хезмәт белән, һөнәргә өйрәтү белән тыгыз бәйләргә була.

Мулиле мәктәбе укытучыларының барысы да диярлек — шушы авыл кешеләре, югары белемле кадрлар. Мәктәп директоры Равил Сәйфетдинов татар теле һәм әдәбиятын укыта, укучыларга туган телгә, сүз сәнгатенә, әдәбиятка тирән мәхәббәт тәрбияли. Үзе дә шигырьләр яза. Матбугат битләрендә шигырьләре, фәнни-методик мәкаләләре белән шактый еш күренә. Уку-укыту эшләре мөдире Сания Фазлыева укучыларга физика һәм математика фәннәреннән төпле белем бирә. Рус теле һәм әдәбияты укытучысы Рәмзия Шәкүрова, биология һәм химия укытучысы Роза Сәйфетдинова, тарих укытучысы Фирдәүсә Зәйнуллина, математика укытучысы Әлмира Сабирова иптәшләр балаларга тирән белем һәм коммунистик тәрбия бирүдә көчләрен һәм сәләтләрен кызганмыйлар. Мулиле мәктәбен тәмамлаучылардан Фәридә Фәйзерахманова, Фәрзия Саттарова Казан дәүләт педагогия институтында укыйлар. Икесенең дә, институтны тәмамлагач, туган авыллары Мулиле мәктәбенә кайтып эшләргә исәпләре. Мәктәпкә шул авылда туып-үскән яшь укытучылар килү — бик сөенечле күренеш. Югары белемле яшь укытучылар, яшь көчләр, яшь белгечләр — авылның культуралы якты киләчәгә, ышанычлы өмете.

Туган авылым Мулиле кешеләре — кадерле авылдашларым — батыр эшли, матур уйлый. Туган авылымның киләчәгә якты, яулыйсы үрләре биек, үсеш мәйданнары киң. Аның тарихи үткәннәре гыйбрәтле, хәзергесе муллык белән тәэмин ителгән, киләчәгә ышанычлы.

Туган авылыма үткән җәйдә кайткач, туган тәэсирләрдән чыгып, шушы шигъри юлларны да өстисем килә:

Зур илемнең бер почмагы, шаулап үскән гөлбакчалы,
Туган авылым Мулиле, йөрәк түрендә йөртәм мин
Кайда булсам да сине, кайда барсам да сине.
Кат-кат төшләремә кереп, әниемдәй газиз күреп,
Яратып кайтам сине, сагынып кайтам сине,
Туган авылым Мулиле.

Самат Шакир

ХӘЙРУЛЛИН УТРАВЫ

Без сугыш һәм хезмәт ветераннары белән бергә Төньяк ярымшардагы Боз океаны башланган урынга — Диксон поселогына — 1942 елда немец крейсеры «Адмирал Шеер»га каршы сугышта һәлак булучылар күмелгән җиргә килдек. Ветераннар Советы председателе дулкынланып сүз башлады:

— Монда 1942 елның август ахырында, төньяк диңгезләрне үтеп килгән фашист крейсеры «Адмирал Шеер» ныгып калырга исәп тотты. Ләкин безнең яр буе батареясы һәм «Дежнев» бозваткычы диңгезчеләре крейсерны алга барудан туктаттылар. Без бүген бу бәрелештә батырларча һәлак булган сугышчыларны хөрмәтләп искә алырга килдек. Менә алар: Павел Григорьевич Ульянов, Василий Иванович Давыдов, Александр Михайлович Карагаев, Фәхрулла Хәйруллин... Җиде каһарман: рус, украин, белорус, татар. Алар барысы да фашист пиратларына каршы соңгы сулышларына хәтле сугышып һәлак булдылар! Мәңгелек дан аларга!

Без, баш киемнәребезне салып, бер минутка тын калдык. Кыя-таулы Диксон ярына эшләнгән обелиск — өч гигант штык янына килеп чәчәк бәйләмнәре куйдык.

Героик Диксон оборонасының 40 еллыгын уздыру өчен Советлар Союзының төрле якларыннан адмираллар, генераллар, ветеран диңгезчеләр, диңгез хәрби училищесы курсантлары, мәктәп укучылары килгән иде.

Мин «Дежнев» корабының рулевое булган, хәзер судно капитаны И. Г. Шнейдердан һәм ераккка йөзүче кораб капитаны В. И. Дерябиннан халкыбызның батыр улы Фәхрулла Хәйруллин турында сөйләүләрен үтендем. Алар батырны яхшы хәтерлиләр.

Фәхрулла «Дежнев» корабында тырыш, үзенә йөкләнгән эшне төгәл үтәүчән кызыл флотчы була. Аны корабның туп расчетына куялар. Бу эшкә ул үзе теләп бара. Чөнки балачагыннан ул төз атарга өйрәнә, сунарчылык белән шөгыльләнә.

Көннәрнең берендә фашист самолетларының Баренц диңгезендәге корабларны бомбага тотуын хәбәр итәләр. Разведка «Юнкерс»ларның бу тирәгә дә килеп чыгу мөмкинлеген белдерә. 1941 елның 17 июлендә свастикалы самолетлар «Дежнев» корабы өстеннән әйләнеп узалар. Менә бер «Юнкерс» якын үк килә. Бомба ташлый. Аңа каршы зенит тубыннан ут ачалар. Икенче самолет бомбасын ташларга өлгермәи, аны тупчылар атып диңгезгә мәтәлдерәләр. Кораб капитаны шатлыктан кычкырып җибәрә:

— Молодцы, егетләр!

Кызыл флотчы Фәхрулла Хәйруллин зенит тупчыларына снаряд ташый-ташый хәлдән тая. Биттәге тирне сөртеп алырга да вакыт юк.

Фашист пиратлары күп илләрне басып алуда катнашканлыктан, шактый оста сугышалар иде. Ләкин безнең тупчылар аларның атакаларын батырларча кире кайтаралар.

Корабка ясалган беренче һөҗүмнән соң да байтак кына бәрелешләр була. Һава пиратлары «Дежнев»ка тагын ике-өч мәртәбә һөҗүм ясыйлар. 13 нче августта свастикалы козгыннар тагын кораб өстенә ябырылалар. Бер «Юнкерс», бомбасын ташлагач, югары күтәрелгәндә кыяга бәрелеп челпәрәмә килә. Ул ташлаган бомба

ярчыкларыннан ике диңгезче каты яралана һәм алар госпитальдә һәлак булалар. Берничә кеше контузия ала. Фәхрулла да җиңелчә яралана. Күктә совет самолетлары күренә. Алар фашист очкычларына якынлашалар... ике арада һава сугышы башлана.

Дошман тизрәк качу ягын карый.

Бу хәлне күреп торган совет диңгезчеләре шатлыкларыннан берсен-берсе кочаклап алалар һәм «ура!» кычкыралар.

Тупчы Фәхрулла Хәйруллин җиңелчә яраланган хәлдә иптәшләре белән яр буе госпиталенә барганда парашют белән төшкән немец очучысын күрә. Күп илләрнең шәһәрләрен бомбага тоткан, Европаны канга батыруда катнашкан бу палач күкрәгенә ике тимер төре таккан. Гитлерның ышанычлы илбасары Советлар Союзын бик тиз генә буйсындыру максаты белән килгәндер. Ләкин аның самолеты туп һәм пулемет утына эләгеп суга кадалды, үзе парашют белән сикерергә мәҗбүр булды... Фәхрулла аңа җирәнеп карый. Әйе, бу фашист хәзер җиңүче булып түгел, әсир булып, хурлыклы рәвештә атлый. «Бер генә фашистны да Совет җиренә иркенләп йөртмәскә кирәк! Бу — безнең изге ант!» Әнә шулай уйлый диңгезче Хәйруллин.

* * *

«Вундерланд» планы гитлерчылар тарафыннан 1942 елны төзелә. «Вундерланд» — «Могҗизалар иле» дигән мәгънәне аңлата. Арктиканы тикшерергә өлгермәгән фашист белгечләре аны Могҗизалар иле дип уйлаганнар. Гитлер әлеге план буенча Арктикага үзенең иң яхшы сугышчан корабларын, линкор «Тирпица», авыр крейсер «Адмирал Шеер», крейсерлар «Кельн», «Адмирал Хоппер»ны һәм су асты кәймәләре җибәрә.

«Адмирал Шеер» крейсеры 1942 елның 16 августында Норвегия портыннан кузгалып китә.

Японнарның хәбәр итүенә караганда, көнчыгыштан килә торган совет кораблары 1 августта Беринг бугазыннан үткәннәр, августның икенче яртысында алар Вилькицки бугазында булырга тиешләр. Шуның өчен дә Карский диңгезенә фашистлар үзләренең крейсерларын һәм су асты кәймәләрен җибәрәләр. Күзәтүче немец самолеты совет кораблары караванын таба, бу турыда «Адмирал Шеер» крейсерына хәбәр итә. Ләкин һава бозылу, көчле томан булу нәтиҗәсендә «Адмирал Шеер» капитаны Мендсен-Болькен аларны югалта. Томан таралганнан соң фашист крейсерындагылар совет корабларын тапсалар да, якын килә алмыйлар. Калын боз таулары алга барырга мөмкинлек бирми, «Адмирал Шеер» үзе чак кына бозлар арасында әсирлектә калмый. Шуның өчен Мендсен-Болькен безнең кораблар артыннан күзәтүне туктатырга һәм Карский диңгезенең көнбатышына китәргә мәҗбүр була. Менә шул вакытта аңа совет бозваткыч корабы «А. Сибиряков» очрый. Фашистлар аңа ут ачалар һәм кораб яна. Пиратлар кайбер совет диңгезчеләрен әсирлеккә төшерәләр, әмма алардан бер генә кирәкле мәгълүмат та ала алмаганнар.

«Адмирал Шеер» крейсеры Теньяк диңгезләренә кереп Диксон утравына юнәлә. Крейсер яңа техника белән коралланган. Анық экипажында барлыгы 926 кеше, ул 14 авыр туп белән коралланган. Кечерәк туплар да байтак. Анық йөзү тизлеге дә башка корабларга караганда зуррак икән. Бу турыда разведка Советлар Союзы ставкасына белдерә.

«Дежнев» корабы Диксон утравы янында якорьда тора. Аңа «А. Сибиряков» бозваткычын батырган крейсер турында яңадан-яңа мәгълүматлар килеп тора. Шуның өчен пират-крейсерны сугышчан әзерлек белән көтәләр.

* * *

27 нче август таңы... Степин каршыга килүче зур крейсерны күреп ала. Капитан урынына калган Кротов оптик прибор аша карый. Лейтенант Степин кычкырып җибәрә:

— Бу — «Адмирал Шеер» крейсеры!

Диңгезчеләр, боерык көтеп, тынып калалар. Командир ярдәмчесе Кротов кискен тавыш белән:

— Фашист крейсерына төзәп — ут! — дигән команданы бирә.

«Дежнев» корабындагы туплар телгә киләләр. Снарядлар крейсер өстендә ярылалар. Яр буе батареясы да ут ача. Крейсер үзе дә туплардан ата башлый. Ике арада бәрелеш шулкадәр көчле була, «Дежнев» өзлексез чайкала. Тупчы Карагаев Фәхрулла Хәйруллинга кычкырып кына гора:

— Снаряд кирәк! Снаряд! Тизрәк!

Яңадан тупны коралар. Яңадан аталар. Крейсер, авыр туплардан атып, «Дежнев» корабын батырырга тели. Өч-дүрт снаряд палубага төшә һәм корабка ут каба. Диңгезчеләр дошман крейсерына атуны дәвам итәләр. Снаряд ярчыгы тиеп Карагаев каты яралана. Ләкин туп янының китми. Немецларның бер снаряды мачтаны җимерә, машина бүлегендә янгын чыга. Бәрелеш коточкыч төс ала. Тупчы Карагаев һәлак була. Туптан атуны Василий Андреев һәм Фәхрулла Хәйруллин дәвам итәләр. Фәхрулла янына гына дошман снаряды килеп төшә һәм ярчык аның бер аягын өзә. Икенче снаряд ярчыклары Фәхрулланың кабыргасын, маңгаен яралыйлар... Туп янына егылган Фәхрулла, соңгы көчен җыеп, кулларын йодрыклый һәм гитлерчылар ягына карап кычкыра:

— Фашистларга үлем! Туганнар, кыйнагыз шул этләрне! — Ул күзләрен зур итеп ачып як-ягына карый. Бу минутларда аның күз алдына, мәгаен, туган җире, шау чәчәкле болын, печән чабучы авылдашлары килеп баскандыр. Ераста, бик ераста җыр тавышы ишетелгәндәй булгандыр...

«Адмирал Шеер»га каршы яр буе батареясы атуын дәвам итә. Дошман крейсеры кире борылырга мәҗбүр була... Соңга таба ул утрауның икенче ягыннан килеп һөҗүм итә, ләкин, яр буе батареясы өзлексез атып торганлыктан, кире чигенә.

Корабта җиде диңгезче һәлак булган, утызга якын кеше яраланган. Иртәгесен аларны Диксон утравына алып чыгалар. Кайгы митингы оештырыла. Полк комиссары Бабинцев һәлак булучы диңгезчеләрнең батырлыклары турында сөйли. Яшь диңгезче Фәхрулла Хәйруллин турында да бик җылы сүзләр әйтелә.

* * *

Фашист крейсеры «Адмирал Шеер» Карский диңгезеннән китәргә мәҗбүр була. «Дежнев» корабындагы диңгезчеләр үзләренең шундый зур крейсерны чигендерүләрен күреп торсалар да, крейсерда нәрсә булганын белмәгәннәр. Алар Гитлернының мактанычыннан саналган сугыш крейсерын батыра алмауларына борчылганнар.

Сугыштан соң бу крейсерның командиры Мендсен-Болькен бу операция турында болай дип белдерде:

«Адмирал Шеер» совет диңгезләрендә озак йөзә алмады, чөнки яр буе батареясыннан һәм корабтан безгә көчле ут ачтылар. Бу хәл безнең арада курку, каушау тудырды. Без, билгеләнгән урынга бернинди каршылыксыз гына килербез, дип ышанган идек. Әмма бик нык ялгышканбыз икән. Совет диңгезчеләре көчле ут ачкач, крейсер кире китү ягын карады. Ставка тарафыннан совет җиренә 180 автоматчыдан торган десант төшерергә боерык бирелгән иде. Без бу боерыкны, аның бик катгый булуына да карамастан, җиренә җиткереп үти алмадык. 180 кешелек десантны кире үзебезнең базага алып кайтырга мәҗбүр булдык...»

Төньяк диңгезләрдә немец корабларына һәм «Адмирал Шеер» крейсерына каршы үз-үзләрен аямыйча сугышкан диңгезчеләр турында ул вакытта Төньяк флотның командующее, адмирал А. Г. Головко болай дип яза:

«Мин котыпчыларның — «Сибиряков» борты экипажы һәм фәнни станция персоналы, «Дежнев» һәм «Революционер» экипажлары, Диксондагы тупчылар һәм портта эшләүчеләр каһарманлыгы алдында баш иям. Алар барысы да совет патриотына йөкләнгән изге бурычны үтәп чыктылар. Фашист рейдерына алар биргән отпор гитлерчыларның планын эзде»...

Бу сүзләр, һичшиксез, безнең тугандаш Фәхруллага да кагыла. Яңа-яшь килеш фашист пиратларына каршы сугышып, туган җирдән ераста башын салган баһадир Фәхрулланың исемен совет диңгезчеләре һәм галимнәре мәңгеләштерделәр. Карский диңгезендәге бер утрауга 1962 елны Хәйруллин исеме бирелде. «Диңгез картасы сөйли» дигән китапта болай дип язылган: «Хәйруллин Ф. Утрау исеме. Карский диңгезендә, Диксон утравына якын. 1962 елны совет гидрографлары тарафыннан Диксон оборонасы вакытында һәлак булган кызылфлотчы Фәхрулла Хәйруллинга

бағышлап бирелде. Хәйруллин Ф. Бөек Ватан сугышы вакытында «Дежнев» корабында тупчы иде. 1942 елны Диксон оборонасы вакытында немец крейсеры «Адмирал Шеер»гә каршы сугышта һәлак булды».

Диксон утравына һәр елны Советлар Союзының төрле якларыннан туристлар, мәктәп балалары һәм кызыл эзтабарлар килә. Алар «Адмирал Шеер» крейсерына каршы сугышта һәлак булучыларның каберләренә чәчәкләр куялар.

Илебезнең кинотеатр экраннарында «Бөек Ватан сугышы» дигән күп серияле документаль фильм күрсәтелде. Киноэпопеяның «Арктикада сугыш» исемле алтынчы сериясендә «Адмирал Шеер»гә каршы көрәш тә телгә алына.

* * *

Башкортстан республикасының Дүртөйле яклары... Агыйдел буена утырган матур өйле авыллар, зәңгәр рәшәткәле бакчалар, асфальт юллы урамнар. Барасы юлыбыз — районның «Чишмә» колхозы. Мин колхоз идарәсе янында машинадан төшеп калдым. Тирә-ягыма каранып торганда бер апа эндәште:

— Кем кирәк сезгә, энем?

Бу апага сугыш вакытында зур батырлык күрсәткән авылдашлары Фәхруллә Хәйруллин турында мөмкин кадәр күбрәк белү ниятe белән килүемне әйттем.

Апа уйланып торды да авыл башындагы бер өйгә күрсәтте:

— Фәхруллә әнә шул йортка — Әхияровларга кунакка кайта иде, сез шуларга барыгыз.

Капкадан керүемә, урта яшьләрдәге хатын каршы алды. Әкълимә Әхиярова Фәхрулланы күреп белә икән. Мин аның фашист крейсеры «Адмирал Шеер»гә каршы сугышта батырларча һәлак булуын, Диксон утравында күмелүен, үлгәннән соң Карский диңгезендәге бер утрауга «Хәйруллин» исеме бирелүен сөйләдем.

— Дөнья бәясе кеше иде ул Фәхруллә абый,— диде Әкълимә бераз тынлап торгач.— Сугышка хәтле, диңгезче формасын киеп, авылга кайткан иде. Туган якларын өзелеп сагынуын сөйләде. Аннары капка төбендә матур итеп гармун уйный-уйный җырлавын бөтен күрше-күлән яратып тыңлады. Укырга, шигырь сөйләргә ярата иде. Аның телөге диңгезче булу иде. «Мин зур кораблькә утырып диңгезләр гизәчәкмен»,— ди торган иде ул. Әнием дә аны бик яхшы белә, алар безгә күрше генә торды.

Мин Сәхипкамал ападан Фәхрулланың буй-сынын, төс-кыяфәтен сорашам.

— Урта буйлы, таза гәүдәле иде, түгәрәк йөзле... Фәхруллә үсеп буйга җиткәч, авылдан Мурманск якларына китте. Җырга оста иде ул. Гармунчы булуы белән дә танылды. Үзебездә башлангыч мәктәпне тәмамлаганнан соң күрше авылда укыды. Фәхрулланың әнисе Фатыйма: «Улым үскәч, артист булыр әле»,— ди торган иде.

Шактый сөйләшеп утырганнан соң Фәхруллә туган йортка киттем. Йорт хуҗасы Мәгъруф Шәмсиев кин күңел белән каршы алды.

— Фәхрулланың туган нигезе шушы инде,— диде ул.— Без аның белән бер мәктәптә укыдык. Дөрес, ул өлкен класста иде. Атлар сакларга аның белән бергә йөри идек. Әтиләр дә бик дус булды. Фәхруллә абыйның атны яратуын, ат өстендә Агыйдел буйларына баруын әле дә хәтерлим. Базы елгасында су коенганда ул бик оста йөзә, безне дә йөзәргә өйрәтә иде.

Фәхруллә белән бергә укыган Әхмәт Кәшфуллин да аның турында күңеленда якты истәлекләр саклый. Ул да сугышта катнашкан, орденнар һәм медальләр белән бүләкләнгән, батыр сабакташының яшь чаклары турында кызыклы мисаллар китерде. Фәхруллә үзе скрипка ясаган һәм уйнарга өйрәнгән, авыл сәхнәләрендә чыгыш ясаган. Икесе дә мәктәптә алдынгы укучылар булганнар.

Көннәрнең берендә ул Базы елгасында батып барган кечкенә малайны коткарып калган һәм авылга күтәреп алып кайткан. Үсә төшкәч, сабан туйларында көрәшкән, ат чабышларында һәм йөгерү ярышларында катнашкан. Еш кына, Агыйделнең аръягына йөзеп чыга да, бнек ярга күтәрелеп, моңлы итеп җырлый торган булган.

Иртәгесен мәктәптә батыр авылдашларының якты истәлегенә багышланган очрашу булды. Укучылар Фәхруллә абыйларының батырлыгы турында зур игътибар белән тыңладылар, киләчәктә бер пионер отрядына аның исемен бирергә булдылар.

Азат Әхмәдуллин

УҢАЙ ГЕРОЙ—ТӨП ЮНӘЛЕШ!

Проза турында барган җитди бәхәскә катнашыргамы, юкмы дип, шактый икеләнеп йөрдем. Бу сөйләшүгә кушылу драматургияне өйрәнә торган кешегә бик үк уңай түгел кебек исәпләдем. Әнә бит: әдәбиятта специальләшү булырга тиеш дигән фикер тагын яңгырады. Ләкин мин бит әле, иң беренче чиратта — укучы. Роман-повестьларны өметләнеп көтеп алучы, яхшы хикәягә очраганда, авторы өчен сөенеп бетә алмаучы. Әнә шундый кеше буларак, прозабызның бүгенге хәле, аерым язучылар һәм әсәрләр хакында миндә дә фикерләр бар, алар белән минем дә уртаклашасым килә. Икенче яктан (һәм бусы төп сәбәп булса кирәк), әдәби жанрлар элек-электән үзбашка яшәмәгәннәр, мөстәкыйль хәлдә генә үсмәгәннәр, «әдәби процесс» дип аталган Иделдә бергә йөзгәннәр. Алар тегеләйме-болаймы бер-берсенә ярдәмләшкәннәр дә, тәэсир дә итешкәннәр, ярышканнар да. Шуңа күрә бүгенге драматургия һәм, гомумән, әдәбиятның барлык жанр-төрләренә карый торган законнар ноктасыннан торып фикер йөртү проза турындагы иҗади бәхәскә катнашуны аклый һәм мәҗбүриятка әйләндерә дип уйлыйм.

Иң әүвәл, бу сөйләшүнең оештырылуы һәм барышыннан үземнең асылда канәгатьлек хисе кичерүемне әйтеп китәргә тиеш табам. Анда кызыклы чыгышлар булды, оригиналь фикерләр очрады. Кыскасы, сөйләшү ярыйсы ук профессиональ югарылыкта бара. Моннан парадоксаль дип әйтерлек бер әйбер килеп чыга: тәнкыйть, җае килсә дә, килмәсә дә сүгелә торган тәнкыйть, шактый ук җитлеккәнлеген күрсәтә түгелме соң?! Сөйләшүнең төп пафосын тәнкыйтьчедән дә бигрәк прозаик үзе, язучы А. Гыйләҗев билгеләде, алга таба да язучыларның үз сүзләре бәхәснең тонусын югары тотарга ярдәм итә, диярләр бәлки кайберәүләр. Моңа минем җавабым болай. Гәрчә әдәби тәнкыйть үзен махсус шул өлкәгә генә багышлаган иҗатчылар тарафыннан тудырыла дип карарга күнегелгән булса да, ул — күмәк эш. Тәнкыйтьне элек-электән тәнкыйтьчеләр генә түгел, язучылар үзләре үк тудыралар. Г. Тукай һәм Г. Ибраһимовлар үз чорының иң үткен тәнкыйтьчеләре булганнар; шул заман әдәби тәнкыйтенең сыйфатын билгеләгәндә бу исемнәр алдан йөри. Без һәрвакыт сагынып һәм сокланып искә ала торган 20—30 еллар тәнкыйтен Г. Нигъмәти һәм Г. Галиләр генә түгел, нәкъ менә Г. Ибраһимов, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, К. Нәҗми, Ә. Фәйзи, М. Җәлилләр дә тудырган. Әйтәсе килгәнем шул, бүгенге тәнкыйть киемендә ертык-ямаулар бар икән инде, аның өчен тәнкыйтьчеләргә генә үпкәләргә кирәкми. Аның каравы, уңышларыбыз да уртак лабаса,— сөйләшү шуны күрсәтә. Бәхәсне башлап җибәргән А. Гыйләҗев тә, эчтәлекле чыгыш ясаган Ә. Баянов, Т. Миңнуллин һәм Л. Ихсанова да аның казанышларын, шулай ук кимчелекле, җитешмәгән якларын да бердәй билгеләшәләр.

Шулай да, әлбәттә, сөйләшүнең үзәгендә тәнкыйтьче сүзе ята. Прозаны белгән, аны махсус өйрәнгән тәнкыйтьче, яки хикәя-романнарны даими укып барган, әдәби иҗат белән азмы-күпме таныш булган тәҗрибәле һәм бу очракта тәнкыйтьче буларак чыгыш ясаучы укучы сүзе. Бәхәснең фәнни дәрәҗәсен дә,

объективлыгын һәм эзлеклелеген дә билгеләүче җитди фикер-сүзләр хәзергә тәнкыйтьчеләр Т. Галиуллин һәм Р. Мостафин, И. Ахунҗанов, Ф. Хатипов, Ф. Зөлкарнәев һ. б. лардан чыкты. Кыскасы, хәзерге тәнкыйть мәсьәләне зурдан куеп, югары критерийлар белән эш йөртеп сөйләшерлек дәрәҗәдә тора,— бүген бара торган дискуссиядән мин иң әүвәл менә шундый бер нәтиҗә ясыйм.

Әлбәттә, бу әле һич тә арба гел тигез юлдан гына тәгәри дигән сүз түгел. Чатаклыклар да шактый, фикер тарлыгы да, субъективлык та җитәрлек.

Миңа калса, сөйләшү хәзергә ике яссылыкта бара. Берсе — прозабызның, гомүмән әдәбиятыбызның бәя-критерийларын ничек билгеләргә, ни-нәрсәне әлге итеп куярга дигән характерда. Бу темага сөйләшү актив, чыгыш ясаганнарның һәрберсе дип әйтерлек моңа кагылмый калмый. Прозабызны бәяләгәндә Союз күләмендә, күпмилләтле совет әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре югарылыгында торып эш йөртергә кирәк дигән, бераүдә дә шик тудырмый торган фикер өстенлек итә. Монда дискуссияне башлап җибәргән А. Гыйләҗев тә, Р. Мостафин да, башкалар да хаклы. Ә инде менә әсәр шул биеклеккә ирешкәнме-юкмы икәнен ачыклау мәсьәләсе исә үзе ачыклауны сорый. Монда бер төрле генә җавап әлегә табылмады, аны, бәлкем, табуы да читендер. Тәнкыйтьчеләрнең бер өлеше өчен ул ачык кебек: рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрне Ч. Айтматовлар кебек алдынгы язучылар әсәрләре белән чагыштырып карыйсың да — вәссәлам! Болай карау — мәсьәләне артык гадиләштерү булыр кебек. Чөнки беренче карашка артык әһәмиятле булып күренмәгән «ваклыклар» исәпкә алынмый. Әйтик, тәрҗемәнең сыйфаты, яңа әсәрне анализлауда, аның новаторлыгын билгеләүдә, Бөтенсоюз укучысы өчен әһәмиятен ачыклауда тәнкыйтьнең (гафу итегез!) үшәнлеге, оештыру эшләренең җитешмәве һ. б., һ. б. Хәлбуки, сәнгатьтә ваклыклар юк. Бәхәстә катнашучылар «Сарут», «Җомга көн, кич белән» кебек аерым мисалларны күрсәттеләр инде. Монда «Туган ягым — яшел бишек» әсәрен дә искә алырга мөмкин булыр иде. Р. Мостафин аны бик хаклы рәвештә «Әдәбиятыбыз өчен этап булган әсәр» дип атады. Повестьның исемендә үк чагылган теманы сәнгатьчә югары итеп эшкәртә башлауда Гомәр Бәширов,— Бөтенсоюз күләмендә үк дип расламыйм,— төрки халыклар әдәбиятларында беренчеләрдән иде, новатор булды. Миңа бу мәсьәләдә Ә. Баянов хаклырак булып күренә. Әйе, без бит үзебез дә күпмилләтле совет әдәбиятыннан яхшы ук хәбәрдар кешеләр, иң яхшы әсәрләрне укып барабыз, Бөтенсоюз әдәби тәнкыйтьне кулланган иң югары критерийлар белән дә танышабыз. Үз әсәрләребезне бәяләгәндә без шул югарылыктан торып, шул сыйфат таләпләреннән чыгып эш йөртмибезмени? Рус һәм башка милләт укучылары өчен бу әсәр ни дәрәҗәдә кызыклы һәм яңа — без аны үзебез бәяли алмыйбызмыни? Боларны эшләү өчен безнең Р. Мостафин кебек Бөтенсоюз әдәби процессын яхшы белгән тәнкыйтьчеләребез юкмыни? Һәм бу тәнкыйтьчеләр, әйтик, «Дружба народов» журналы өчен теге я бу әсәрнең бару-бармавын үзләре белеп, үзләре тәкъдим итә алмыймы? Үз вакытында тиешле оператив белән һәм югары сыйфатлы төстә тәрҗемә ителгәндә «Сарут» хикәясенең, Ә. Еники әсәрләренең үзәк журналларның һәм нәшриятларның кайсына да яраРлык булуын без үзебез дә чамалый алабыздыр бит.

Сөйләшүдә ачык әзгә төшкән икенче яссылык — прозабызның сыйфатын күтәрергә комачаулый торган җитешсезлекләрне ачыкларга, прозаның үсеш тенденцияләрен билгеләргә, прогноз ясарга омтылудан туган уйланулар рәвешендә оешты. Бусы — тагын да мөһимрәк мәсьәлә, дәресрәге, иң мөһиме! (Беренче яссылыктагы сүзләр, гәрчә әһәмиятле булса да, проза сыйфатын билгеләшүнең бер ягын гына тәшкил итәләр.). Монда йөзләгән сораулар һәм специфик мәсьәләләр калкып чыга, концепцияләр формалаша. Сөйләшү барышында без шуны күрәбез дә. Ф. Зөлкарнәев өчен, әйтик, бездәге укучылар контингентының үзенчәлекле булуы алгы планда торса, Р. Мостафин прозадагы кимчелекләренең сәбәпләреннән берсен традицияләр һәм новаторлык яссылыгында күрә. А. Гыйләҗев урта кул әсәрләргә һәм прозаны басып бара торган урталыкка, кәсепчелеккә нәфрәтләнеп гашлана; аныңча, татар прозасының биеклеген билгеләүдә өч багана гына булуында шул урта куллык һәм кәсепчелек, тәнкыйтьнең җебегәнлеге сәбәпче булса

кирәк. Т. Галиуллин (һәм Р. Мостафин да) прозаның сыйфат үзгәрешләрен эре уңай геройлар үлчәве белән үлчи, бүгенге роман һәм хикәяләрдә Нәфисәләр булмавына өфтәнә. Прозада «тарихилык рухы көчәю», «психологик анализның функциясе киңәю», сюжет сызыгын үстерүнең башка юлларын эзләү кебек тенденцияләрне ачыклый. Ф. Галимуллин язучыларның иҗат көчләрен «рациональ файдалануның магистраль юлын» тематик тарлыктан таба. И. Ахунҗанов, Ф. Хатипов, Л. Ихсанова һ. б. һәрберсе үзе мөһим дип санаган, яки башкалар күзе төшеп җитмәгән якларга игътибарын юнәлтә. Нәтиҗәдә шактый тулы картина ачыла, аерым уңай күренешләр билгеләнә, прозабызга хас кимчелекләр, тиешле һәм тиешсез мавыгулар күрсәтелә. Шуның белән бергә кабат әйләнеп кайтып уйланасы, ачып бетерәсе фикерләр дә, артык кискен яңгыраган раслаулар да очрый.

Нинди генә авырлыклары һәм кимчелекләре булса да, без бүгенге әдәбиятыбызга гомумән хас булган бер әйбернең проза өчен дә характерлы булуын ачык төстә әйтергә тиешбез: ул тормышка якыная бара. Проза сәнгатьнең төп критерийларыннан берсе булган дөреслеккә ирешә бара. Димәк, прозабыз иҗтимагый функциясен торган саен тулырак үти.

Моны прозаның тематикасы һәм проблематикасы ноктасыннан карап та әйтергә мөмкин. Хәзергә сөйләшүдә бу мәсьәләгә игътибар җитеп бетми, прозаның торышы гомумән алып карап бәяләнә. Ә бит бу — гаять мөһим! Роман-повестьларыбызның, хикәяләребезнең проблематикасы аша гына прозада җәмгыятебезнең тарихи-социаль җирлегендәге үзгәрешләр һәм яңалыклар ни дәрәҗәдә тулы чагыла икәнен билгели алабыз. Мисал өчен, әсәрләрдә яңа тормыш шартларында каушап-аптырап калган, үз-үзен эзләгән яшь кешеләр образлары активлашты. Нидән бу, моның иҗтимагый-политик сәбәпләре бардыр бит (урбанизация, туган туфрактан аерылу борчылулары, тук һәм рәхәт тормыш, мещанлыкның бу шартларда һәлакәтле һөҗүме һ. б.)? Аларның нигезе кайларга барып тоташа?

Без бүген гомер буе килгән каршылык — дәүләт үсеше белән шәхес үсеше арасындагы антагонизм алып ташланган шартларда яшибез. Һәм язучылар бу үзенчәлекне асылда дөрес аңлап эш йөртәләр. Моны түбәндәге дәлил дә ачык раслый: әсәрләрдә асылда җәмгыять интәреслары һәм шәхси мәнфәгатьләр берлегенә омтылу чагыла. Ләкин моннан һич тә шәхес һәм җәмгыять конфликты хәзер гомумән дә яшәми икән дигән нәтиҗә чыгарып булмый, әлбәттә. Ул яши, әсәрләргә дә үтеп керә. Ләкин аның чагылышы да, хәл ителеше дә хәзер бөтенләй башкача. Электә бу конфликтның асылын уңай геройның тискәре җәмгыятькә каршы торуы һәм көрәше тәшкил итә иде. Хәзер исә, шәхеснең үз-үзен расләвы, иң югары идеалларын да тормышка ашыру өчен бөтен мөмкинлекләр туган шартларда уңай җәмгыятькә тискәре тип каршы чыга. «Сарут», «Әтәч менгән читәнгә», «Һәлакәт», «Хәсән Вагыйзович» кебек әсәрләрдәге тискәре геройлар кыяфәтендә каршы чыга ул.

Ләкин әдәбиятның, шул исәптән прозаның да өлгергәнлек дәрәҗәсен, иң беренче чиратта, уңай герой билгели. Уңай геройда әдәбиятның активлыгы да, җитлеккәнлеге дә, сәнгатьчә камиллеге дә чагылыш таба. Ә югарыда әйтелгән җәмгыять һәм шәхес конфликты андый геройны сурәтләү мөмкинлеге бирәме соң? Һичшиксез, бирә. Мондый конфликт ярдәмендә иҗтимагый-политик мәсьәләләрне дә, әхлак һәм этика проблемаларын да куеп хәл итәргә мөмкин, гуманлы җәмгыятьне дә, уңай геройлар образларын да тулы чагылдырырга мөмкинлек бар анда. Шулай булса да андый конфликт уңай геройны художестволы гәүдәләндерүнең бердәнбер дә, үзәк юлы да булмаса кирәк. Ни өчен дигәндә, мондый конфликт уртасында, кагыйдә буларак, без күрергә теләгән уңай герой түгел, тискәре персонаж тора. Һәм еш кына андый персонаж дөньяга карашы, характеры төзәлә барган кешене чагылдыра.

Шуңа күрә дә язучыларыбызга тормыштагы башка төсле конфликтларга да игътибарларын көчәйтергә кирәк. Үзәгендә гүзәл замандашларыбыз торган, җәмгыятебезнең тоткасы булган, яшәү көчен тәшкил иткән кешеләр — эшчеләр һәм колхозчылар, галимнәр һәм башка интеллигенция вәкилләре хәлиткеч рольне уйнаган конфликтлар тормышта бихисап ич. Аларга игътибарның җитмәве югары

идеалларын, дөрес тормыш сукмакларын капшанып табучы яшьләр, хәтта олы яшьтәге кешеләр образлары күбәюдә дә чагыла.

Заманында Көнбатыштагы капиталистик илләр әдәбиятларында «ачулы яшь кешеләр» образлары шактый шау-шу тудырган иде. Инглиз әдәбиятында, мәсәлән, мондый яшьләрнең ачуларын мәгънәле идеаллары булмау чыгара. Италиядә аларның икенче төрлеләре барлыкка килде. Яшәү идеаллары булмау түгел, ә гамьсез рәхәт тормышта, кәеф-сафада яшәү өчен акчалары булмау боларның эчләрен пошыра һәм саруларын кайната. Тормыш хуҗаларына ачуланып түгел, ә аларның байлыгына кызыгу нәтиҗәсендә алар дөньяга каш җыерып карыйлар.

Безнең прозада, бигрәк тә яшьләр иҗатында активлашкан геройлар образлары болардан тамырдан аерыла, билгеле. Мондый яшь геройның иң пассив, йомшак буынлы дигәне дә бөтенләй башка, файдалы уй-ният белән дәртләнә. Һәрхәлдә, шул юнәлештә тора.

Мәсәлән, Ә. Баянов мондый геройның төрле вариантларын иҗат итте. Ул нәкъ менә тынчу гамьсезлеккә, акчага һәм байлыкка табынуга, намуссызлыкка һәм мәнсезлеккә каршы чыга. Җәмгыятьнең перспективалы идеалы яктылыгындагы шәхси идеалын эзләү һәм табу процессын сурәтләгәнгә күрә дә, аның әсәрләре актуаль яңгырыйлар. Үз-үзен раслау, иҗтимагый мәгънәле үз идеалын эзләү яшь прозаиклар өчен әле дә актив булып калуында дәвам итә. Озаккарак китте, күпкәрәк китте. Аның әдәби процесстагы башка мөһим тенденцияләргә (бигрәк тә уңай герой тенденциясенә) комачаулык китерү ихтималы борчый. Икенче төрле әйткәндә, яшь авторларыбыз үрнәк уңай герой эзләүне һаман да шул үз хисләрен тәртипкә китерү белән мәшгуль булган геройларга алыштыру куркынычы алдында торалар. Чөнки һәр нәрсәнең чамасы булырга тиеш. Актив, хәрәкәтчән, алга омтылган, шул заряд белән коралланган геройларны һаман уйлана, газаплана, нидер эзли торган геройлар күмеп китү мөмкинлегә борчый.

Фикер һавада асылынып калмасын,— менә сезгә мисал. «Идел» альманахының 1976—1980 еллар саннарында 6 повесть һәм 14 хикәя басылган. Барысы да яшь авторларныкы. Боларда бүгенге яшьләр прозасына хас булган уңай яклар да, кимчелекләр дә, бер тамчы суда бөтен күк йөзе чагылган кебек, чагылышын таба. Идея-художество җәһәтеннән алар төрле характерда, билгеле. Асылда барысы да басылырга яраклы, укылырлык әсәрләр. Бүгенге яшьләрнең тормышы, аларны җилкендергән омтылышлар һәм интересләр, борчыган сораулар чагыла аларда. М. Галиев, Р. Вәлиев кебек авторларга яшь замандашка хас булган катлаулы рухи дөньяны, интеллектуаль байлыкны шактый үзенчәлекле төстә чагылдыру хас. Нәбирә Гыйматдинова, Марат Ганиев шикелле яшьләр сурәтләнә торган геройларның һәм вакыйгаларның реальлегенә омтылып, чынлыкка ирешүне беренче планга куялар. Художестволылык ягыннан иң яхшы дип әйтергә мөмкин булган әсәрләр — шушы саналган авторларныкы. Болардан чыгып: яшьләр прозасына үткен сюжетлылыкка, образлы фикерләүгә, тасвирлана торган тормыш ситуацияләренең һәм характерларның чынлыгына омтылу хас, дип әйтергә дә мөмкин булыр иде.

Ләкин, гомумән алып караганда һәм барлык калган әсәрләрне дә күздә тотып әйткәндә, яшь авторларның артык чуклы-бизәкле итәргә тырышулары, мәхәббәт мәҗараларын, геройларның шәхси кичерешләре белән чамадан тыш мавыгулары күренә. Бары тик ике повесть кына (К. Кәримов — «Кыңгыр эш», 12 сан; С. Хафизов — «Яшьтәшләр», 9 сан) бу яктан чыгарма булып тора. Боларында вакыйгаларның гражданлык яңгырашына ирешергә омтылу, тормышның киң катламнарын күтәрергә, актив заман героен, кыйбласы иҗтимагый яктан файдалы хезмәткә каратып куелган геройны сурәтләргә тырышу хас. Бу ике повестьта шулай ук яшьлек темасы, мәхәббәткә тугрылык проблемасы алынган. Әмма бу авторлар башка проза әсәрләренә хас булган тарлыктан котыла алганнар. Болай дигәндә мин күпчелек яшьләрнең әсәрләренә хас булган мәхәббәт коллизияләрен төп урынга куюны, бәргәләнүче яшьләрне, тормышта үз позицияләрен ачыклый алмыйча чәбәләнүче геройларны күздә тотам.

Кызганычка каршы, «ләкин» диярга туры килә. К. Кәримовның бу беренче зур күләмле әсәренә дә, С. Хафизовның кызыклы уйланылган повестена да тәж-

рибәсезлек әлегә нык кына тәэсир ясаган: сәнгатьчә төгәлләнгәнлек, ягъни художество бөтенлеге җитеп бетми. Шуңа күрә «Идел»дәге яшьләр прозасының төп пафосын әлегә безнең җәмгыятебезнең асылын билгели торган хезмәткә, иҗади һәм фидакарьлек сыйфатлары белән характерлана торган хезмәткә мәнәсәбәттән читтәрәк йөргән геройлар билгели, дип әйтергә туры килә. Иң аянычы шунда, яшь прозада күзәтелгән бу хәл гомумән татар прозасының бүгенгесен төгәл үк чагылдыра.

Ә. Баяновка әйләнеп кайтсак исә, ул үз иҗатында хезмәт процессында чыныга һәм үсә барган кешеләр образларын, бүгенгенең уңай геройлары образларын сурәтләүгә торган саен күбрәк игътибар бирә. Бу язучы иң беренче шул ягы белән кадерле. Аның «Ут һәм су», «Таш китап» романнары, аларның үзәгендә торган Фәез образы язучының бу юнәлештәге иң зур казанышларыннан берсе хисапланырга тиеш. Ә. Баянов өчен поэтик алымнарга ирешергә омтылу, шартлы-метафорик образ һәм детальләргә актив мөрәҗәгать итү хас. Шул яктан аның повесть һәм романнары прозабызда үзгә бер урын били. Бардык очракта да дип расларга җыенмыйм, ләкин күп вакытта мондый үзенчәлек оригинальлек бирә, укучыга барып җитә. Кайбер мәкалә һәм чыгышларда бу иҗатка карата сизелгән, йомшак кына итеп әйткәндә, илтифатсызлыкны мин аңламыйм да, хупламыйм да,— үтә субъектив һәм беръяклы дип саныйм. Һәрбер ординар булмаган күренеш кебек үк, Әхсән Баянов иҗаты да катлаулы. Аның да кимчелекләре бар: вакыты белән стиленә ачыклык җитми, тел-сурәтләү чаралары тиз генә аңлашылып бетми, җөмләләрендә чатак конструкцияләр урын алгалый һ. б. Ләкин аның тирән фәлсәфи гомумиләштерүләргә омтылган, тормышны катлаулы яклары белән, мәгънәле эчтәлеге белән, үзенчәлекле чагылдырган, күңел сафлыгына һәм бөтенлеккә, рухи гармониягә баш игән, акыл һәм физик хезмәткә карата иң алдынгы карашларга һәм шөгыль-хәрәкәтләргә тугрылык саклаган геройларны сурәтләгән иҗат булуын берәү дә инкарь итә алмас. Менә шул якларны алга чыгарып бу иҗатны өйрәнү, кимчелекләрнең конкрет урынын һәм мөмкин булганда, сәбәпләрен дә ачыклау әлегә эшләнми килә икән инде, аның өчен без дә гаепле. Чөнки ул кимчелекләрне бетерү өчен иң башта авторның үзен «аякландырырга» кирәк, иң беренче, шул максаттан чыгып көрәшергә, әсәрләрендәге яңалык орлыгын күрә белергә кирәк. Әнә, М. Мәһдиев прозасының укучыга гаҗәеп көч белән тәэсир ясавын аңларга, моның эчке сәбәпләрен ачыкларга тырышабыз бит: хәтта әдәбият кануннары белән ныгытылган, гомер-гомергә иҗатчылар тарафыннан раслана килгән сюжет теориясенә дә кизәнәбез бит. Ә ни өчен шул ук метод Ә. Баяновның асылда кызыклы һәм егәрлекле иҗатына карата кулланылырга тиеш түгел. Яки, Әхәт Гаффарның гаять үзенчәлекле прозасына карата. Тыгыз яза бу автор, хәтта артык тыгыз, дияр идем мин.

Кабатлап әйтәм, боларны өйрәнергә, анализларга кирәк; яңалыкларны күрергә, шуларны тагын да камилрәк үстерү өчен мондый авторларга ярдәм итәргә кирәк. Әгәр дә бүгенге прозабыз тиешенчә үсми дип әйтәбез икән, анда тулы бер стиль юнәлешен тәшкил итә торган авторларны һәм аларның әсәрләрен санга сукмау ярамас. Ә. Баян, Ә. Гаффар, М. Галиев һ. б. берничә яшьләр алып бара торган эзләнүләр дә, шиксез, Г. Бәширов, А. Расих, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Н. Фәттах, М. Юныс, Ш. Бикчурин һ. б. ш. язучыларның иҗади табышлары янына уңышлы кушылып китәр һәм алга сыйфат сикереше ясар өчен мөмкинлек бирер.

Сөйләшүдә кузгатылган тагын бер-ике мәсьәләгә кагылып үтәсе килә.

Әһәмиятле теоретик мәсьәләләрдән берсе — традицияләр һәм новаторлык, аларның бүгенге проза үсешендәге роле мәсьәләсе. Ул үткен итеп Р. Мостафин мәкаләсендә куела. Аның төп фикере шуңа кайтып кала: революциягә кадәр хәтта үз әлифбалары да булмаган яшь республикалар (кыргыз, казах) әдәбиятларының гаять зур тизлек белән үсеп китеп, алдынгы әдәбиятларны еш кына узып китүләрендә төп сәбәпләрдән берсе — («берсе» дип әйтик, гәрчә автор алай әйтмәсә дә!) — аларның үткәндәге традицияләргә ябышып ятмауларында. Ә ни өчен — чөнки «яшь республикаларның язучылары үткәндәге традицияләр белән азрак бәйләнгән»; авторның тел төбен аңлау җиңел,— чөнки, димәкче, ул әдәбиятларда

традицияләр көчле түгел. Ә без традицияләргә ябышып ятабыз, башка әдәбиятлардагы яңалыкларга сизгерлегебез юк. Автор бу карашын чыгышларында күптән үткәреп килә инде. Димәк, ул аңар чын күңелдән ышана, дәреслегенә шикләнми. Абруйлы тәнкыйтьче белән мин бу хакта бәхәс кылыр идем.

Беренчедән, «яшь республикалар язучылары үткәндәге традицияләр белән азрак бәйләнгән» дигән фикер турында. Моны бу язучыларның үзләренә әйтсәң, алар бер дә куанмаслар иде, дип уйлыйм. «Ә Абай, ә «Манас» традицияләре?!» диячәкләр. Әдәбият галимнәре кыргыз һәм казах язма әдәбиятларының буш җирдә үсмәгәннәре, бик бай халык авыз иҗаты, аерым алганда, героик эпос традицияләренә нык тамырланган булулары турында кат-кат әйтәләр. Мәсәлән, ул әдәбиятларда роман жанрының соңгы вакытларда тизлек белән алга китүләренең сәбәпләреннән берсен дә аларда эпос традицияләре белән бәйләнеш көчле булуда күрәләр. Бу очракта мин К. Зелинский, З. Кедрина, З. Османова, Э. Габбасов кебек әдәбият галимнәренә таянып әйтәм.

Новаторлык «инде урнашкан традицияләрне инкяр итүдән, күнегелгән, озакка сузылган карашларны җиңүдән башка мөмкин түгел» дигән фразада әйтелеп бетмәү, хаталыкка сәйрәү мөмкинлеге бар. Югыйсә, новаторлык гел кире кагудан гына туа булып чыга. Новаторлык ул, уңай, алдынгы традицияләрне үстерүдән дә гыйбарәт.

Үзебездән мисал алыйк. Нигә, мәсәлән, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, И. Гази, К. Нәҗми прозалары гел инкяр ителергә тиешледән генә торамыни? Ш. Камалның «Акчарлаклар» повесте, мәсәлән, бүген дә кыю новаторларча язылган әсәр булуын саклаган хәлдә кала. Андагы тәэсир көче, андагы нәкышларның гаҗәеп сихрилеге, андагы хисләр байлыгы, гадилек һәм табигыйлек, ниһаять, андагы фикер тирәнлеге — социаль анализның үткенлеге! Минем тәҗрибә үткәргәнем бар: олы язучылардан да, студентлардан да «ничек уйлыйсыз, повестьның күләме ничә битләр чамасы?» дип сораганым бар. Җавап саннары машинкада басылган битләр белән 100—150 тирәсендә чайкала. Ә чынлыкта повесть машинкада барлыгы 48 бит, ике басма табак!! Шундый кечкенә мәйданда олы фикер һәм художество күәтен шулкадәр дә тыгыз җыя алу традицияләре бүген уңышлы үстерелми икән, моңар үкенергә генә кирәк. Хәзергә, кайберсе биш-алты басма табакка сузылган, фикере чыпчык борыны кадәр генә булган повестьларны укыйсың да, кыска язу традициясенең онытыла баруына офтанасың...

Новаторлык җитмәүне, башкалардагы яңалыкка сәңгыраулыкны традицияләр белән бәйләргә ярамый, һич тә ярамый. Алайга китсә, рус, белорус, грузин һ. б. әдәбиятлар искиткеч гүзәл һәм бай традицияләргә таянып үсә бит. Ә аларны башкалардагы яңалыкка «ябык» торуда кем гаепли алыр икән, аларның прозада бүгенге бөтендөнья әдәбиятларының иң алгы сафларында булуын кем инкяр итәр?! Югыйсә, рус язучылары традицияләргә яхшы таяналар, бүтәннәрдәге яңалыкларны да тиз үзләштерәләр, ә безнең язучылар бары тик инде комачауга әйләнгән традицияләргә генә ябышып яталар булып чыга. Тулы бер әдәбият гел консерваторлардан гына тора аламы? Кай яклары беләндер Ф. Әмирханның проза стилен яңа бер югарылыкка күтәргән Ә. Еники өчен дә, сюжет төзүдә Г. Әпсәләмов принципларына тугрылык сакларга тырышкан Г. Ахунов өчен дә мин традицияләр бары тик тышауга гына әверелгән дип әйтмәс идем. Ә М. Мәһдиевнең татар прозасы өчен бөтенләй дә оригиналь күренеш булган прозасына нинди традицияләр тышау инде?

Киресенчә, без язучыларны һәм бигрәк тә яшь иҗатчыларны үз традицияләребезне дә, алдынгы әдәбиятлар традицияләрен дә ныграк үзләштерергә өндәргә тиешбез. Новаторлык традицияләрдән башка була алмый, алар үзара диалектик мөнәсәбәттә.

Ә менә бүгенге прозада драматизм кимүне һәм детальләр тирәнлеге җитмәү турында Р. Мостафин бик дөрес яза. Без моны, бигрәк тә беренчесен, бүгенге драматургия жанрында да күзәтәбез. Драматизм җитмәү әсәрнең эмоциональ тәэсир көчен, ягъни укучыны дулкынландыра алу күәтен кимәтә. Ә эмоциональ тәэсир — сәнгать әсәренең асыл билгеләреннән берсе. Драматизм саранлыгы табигый төстә сюжет ярлылыгын китереп чыгара, һәм — киресенчә. Замандашлар

образларын сурәтләүдә героизм сызыгы көчсезләнүенең сәбәбе дә күпмедер дәрәҗәдә драматизм җитмәүдән туа, болар шулай ук үзара тыгыз бәйле төшенчә-күренешләр. Ә бит бу — татар прозасындагы көчле традицияләрдән берсе һәм аларның бүген тиешенчә үстерелмәве әдәбиятның алга баруын тоткарлый. Бүгенге прозада намусны әлли-бәлли иттереп тирбәтүче әсәрләрнең күбәеп баруында, ә намусны тетрәндереп җибәреп уятучы әсәрләрнең җитәрлек булмавында драматизмның йомшаруы да сәбәпче.

Бүгенге прозада эре художестволы гомумиләштерү алган детальләр белән эш итү җитәрлек түгел. Бу шулай ук басым ясап сөйләрлек бер мөһим мәсьәлә булып тора. «Төп хикмәт детальләрдә»,— дигән И. С. Тургенев. Чын мәгънәсендәге художник кайвакытта бер уңышлы деталь ярдәмендә кешенең рухи дөньясын актарып ташлый ала. М. Шолоховның «Тын Дон»ында кояшның каралуы, яки «Күтәрелгән чирәм»дә Нагульновның элекке хатыны Лушкадан калган чиккән яулыкны яшерен төстә саклап йөртүе, мәсәлән. Күптән түгел генә М. Маликованың «Ак давылда тал бөресе» исемле романын укыдык. Шундагы бер деталь үзенең тормышчан җирлеге, мәгънә йөгенең зурлыгы һәм художестволы төгәллеге белән истә калды. Ул — мәхәббәт агачы, бергә үрелеп-укмашып үскән каен һәм усак. Агачларны, аларның оятсыз мәгънә бирә торган булып сарышып үскәнлекләрен беренче булып Әнвәр күрә. Киләчәктә хатынына хыянәт итәчәк, инде шул җәһәттән тәмам иләсләнгән Әнвәр. Һәм ул агачларны хатыны Зәйтүнәгә, булачак яшерен сөяркәсе Ларисага күрсәтә. Автор мондый аморальле күренешләргә үз карашын да, аларның тормыштагы бәясен дә үткен итеп әйтеп бирә. «Оятсыз ләззәттән башы иелгәндәй бөгелеп төшкән каенның кәүсәсе гадәттәгечә ак түгел, күгелҗем иде. Аның каен икәнен дә яфракларыннан гына белеп була. Аклыгын югалткан иде каен».

Менә шулай, әдәби әсәрдәге деталь — гади чынбарлыктагы деталь түгел, бәлки үзендә типиклык һәм индивидуальлек хосусиятләрен җыйган художестволы деталь. Мондый детальләрдән файдалану җәһәтеннән бүгенге авторлар арасында Мөхәммәт Мәһдиев аерылып тора. Тормышта, табигатьтә, кеше характерында, психологик халәт күчешләрендә, аерым төркемнәрнең, урынчалыкларның тормыш-көнкүрешләрендә, яшәү рәвешләрендә чагылган үзенчәлекләрне ул үткен күзәтүләр, кискен фикри бәяләр, тапкыр чагыштырулар һәм тап килә торган хәкем чыгарулар ярдәмендә — боларның барысын да художестволылык дәрәҗәсенә күтәреп тасвирлый белә. М. Мәһдиев прозасының көче дә, иң беренче, шунда: художестволы детальләр байлыгында, ул детальләрнең ясалма булмавында, иркен сулыш белән сулавында, халыкчан җирлегендә. Аның һәр повесте кешеләрнең яшәү шартлары, характер, геройлар психологиясе һәм аларның туктаусыз үзгәреп торуына, үсешенә бәйле хисапсыз күп санлы детальләр җыелмасыннан гыйбарәт.

Ф. Энгельс реализмның көче турында сүз алып барганда юкка гына детальнең роле зур булуын үзеннән-үзе аңлашыла торган бер төшенчә итеп карамаган, әлбәттә. Бик мәгълүм булса да, аның сүзләрен китерергә уйлыйм: «...реализм,— ди ул,— детальләрнең дөреслегеннән тыш, типик шартларда типик характерларны дөрес итеп сурәтләүне күздә тота».

Сөйләшү барышында кузгатылган тагын да бер мәсьәлә турында. Ул Фоат Галимуллин мәкаләсендә күтәрелде. Нигездә әйбәт кенә, дөрес мәкалә. Ләкин мин авторның бер тезисы белән килешмәс идем. Ул язучыларны «диапазонны тарайту исәбенә тирәнлеккә» омтылырга чакыра, алай гына да түгел, моны «талантларыбызны файдалануның магистраль юлы» дип игълан итә. Әдәбият һәм сәнгать кебек, иҗат эше кебек нечкә өлкәдә регламентлау гаять җаваплы һәм бәрәкәтсез шөгыль ул. Прогноз ясарга мөмкин, әлбәттә, хәтта кирәк тә, ләкин фәнни нигезләнгән булырга тиеш. Чын талантны мондый чикләр эченә киртәләп куярга ярамый. В. Шукшин иҗатының үзенчәлеге (тематика ягыннан, тормыш материалына мөрәҗәгать итү ягыннан, ә инде индивидуаль стильне әйткән дә юк!), әйтик, Ч. Айтматов иҗаты өчен дә норма була алмый. Әйе, Шукшин башлыча Себер һәм аның кешеләре турында язган (хәлбуки ул башка, мәсәлән, тарихи темаларны да чит күрмәгән). Әйбәт язган. Ә Айтматов кыргызлар турында гына да, колхозчылар яки укытучы турында гына да, балалар дөньясы турында гына

дә, тагын да әллә нәрсәләр турында гына да язмый,— барысы да бар, төрле өлкә, төрле профессия кешеләре аның иҗатында. Һәм барысы турында да шәп яза,— менә бит хикмәт кайда! Талантны чикләргә ярамый, мөмкин түгел. Шуңа күрә дә ул талант! Ф. Галимуллин хөрмәтле язучыбыз С. Хәким сүзләренә таяна. Белмим, алар нинди уңай белән әйтелгәндер. Мин дә таяна алам андый абруйларга. Мәсәлән, Юрий Нагибинга, шулай ук танылган сүз остасына. Ул болай дигән: «Кайвакыт шундый фикер яши: әгәр дә син «авыл язучысы» икәнсең, авыл турында яз инде, ә шәһәр темасы белән бүтән берәү шөгыльләнер; әгәр дә сине завод кызыксындырса, «производство» темасын үстер, бер әйбердән икенчесенә ташлануның, чәчелүнең кирәге юк, имеш. Мин андый рекомендацияләргә, бигрәк тә алар хикәячегә бирелсә, категорически каршы. Шундый күрсәтмәләрдән чыгып эш итсә, ул үз иҗатын фәкыйрьләндерергә, үзен дә, укучыны да кызыклы ниятләрдән (замысел) мәхрүм итәргә мөмкин» («Литературная газета», 1975, 18 октябрь).

...Инде сүзне очлар вакыт җитте. Сүземне драматургия белән уртак моментлар, гомуми проблемалар, барлык жанрлар өчен дә кызыклы булган мәсьәләләр тирәсендә генә оештырырга ниятләгән идем. Алай гына килеп чыкмады. Хәер, иҗат кебек җаваплы һәм катлаулы эштә проблемаларны теге жанр яки бу жанр өчен генә дип тә, бусы уртак, бусы уртак түгел дип тә чикләве кыен бит...

Рим Салихов

ПОЭТИКАГА ИГЪТИБАР КИРӘК!

Сүз дә юк, прозабызның казанышлары бәхәссез. Аны бизәп торган әсәрләр дә күп, урта кул дәрәҗәсендәгеләре дә шактый. Ләкин Мирсәй ага Әмир сүзләре белән әйткәндә, андыйлары да безнең китап киштәбезне тулыландыра.

Әдәбиятның төп максатларыннан берсе: яганнарыңа кешене ышандыра белүдәдер. Бу хәтта кечкенә генә детальләрдә дә ачык күренә. Ихластан башкарылган әсәргә, музыкантлар әйтмешли, бер фальшь нота килеп керсә, бу инде балга бер кашык дегет тамызгандай була. Укучының әсәргә, геройга булган имаңы какшый башлый. Кем белә, шушы иман какшау шаукымы вакыты белән авторга да килеп бәрелергә мөмкин. Мондый мисаллар танылган сүз сәнгате осталары иҗатына да үтеп керә. Мәсәлән, А. Гыйләҗевнең оста һәм матур итеп язылган «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят»е бар. Бәхәссез, әйбәт әсәр. Әмма автор, чаманы узып, геройлар настроениесенә кайчакта үзе дә ияреп китә. Укучы хәтерли торгандыр, анда хаксызга кулга алынган Хәбибрахман абзый янына күршесе Рәхимҗан бабай керә. Шунда ук тәнгә дежурга килгән өлкән класс малайлары. (Даими дежурлык мәктәп тирәсендә караклар няләшә башлагач укытучылардан һәм өлкән класс укучыларыннан оештырылган була.) Озакка сузмастан, сүзне авторга бирик: «Картларның бәхилләшкәнен күрүем беренче мәртәбә иде минем, алар аягүрә басуга, түзмәдем, без дә аларга якынрак килдек, дүртәүләшеп кочаклаштык, керфекләр чыланды...» Бәлки мондый хәл булгандыр да, ләкин психологик яктан, хикәяләү агымыннан килеп повестьта ышандырмый.

Язучының «Язгы кәрваннар» повесте тәнкыйтьтә хаклы, уңай бәя алды инде. Ләкин анда да укучыны сагайта торган эпизод бар. Хәтерегездәдер, әсәрнең герое Ибраһим тракторчылар курсыннан олы хыяллар белән кайта. Колхозда эшләр

шәптән түгел, атлар үлә башлаган. Председатель Хәкимҗан абзыйның үз-үзен дә күралмаган чагы. Шундый чакта Ибраһим аңа үпкәли башлый. Кул кысып котламадың, янәсе. Кәгазьдәге билгеләргә күз салмадың. Кем әйтмешли, ат дәгәләганда...

Бүгенге кайбер әсәрләрдәге персонажларның теленә генә игътибар итик. Мисаллар артыннан ерак барып йөрисе юк. Кул астында булган теләсә нинди уртакул әсәрне генә укып карарга кирәк. Кайчакта диалог афоризмнар, мәкаль-әйтемнәр баганасын хәтерләтеп куя. Менә М. Хәбибуллинның «Хәтер ярлары»нда Нәүфәл җиңгәчәсе белән сөйләшеп утыра. Җиңгәчәсе яшьлегендә фаҗигагә очрап, гарип калган егетне өйләнергә үгетли. Барысын да язып тормастан, аның сөйләвеннән мисаллар гына китереп китәбез. «Ир кешегә гариплек — бәхеткә, хатын-кызга — ләхеткә», «Ду килеп йөрдек, Хәлил белән Галиябану диярсең», «Башкалар— күмер, ә бу миңа алмаз инде менә», «Хискә төренгән — җилгә очкан, данга төренгән — канга төшкән». Нәүфәлнең өч кенә юллык җавабы китерелгән: «Мин алай уйламыйм, җиңгәчәй. Беренче мәхәббәт ул — мәңгелек истәлек, мәңгелек хатирә яры. Ярсыз кеше яши алмый. Елга кебек, яры юк елга — елга түгел инде ул, күл, черек күл». (М. Хәбибуллин. «Хәтер ярлары», Казан, 1981, 203—204 битләр.)

Б. Камалов әсәрләрендә дә без шундый ук күренешкә тап булабыз.

Әдәби телебездә газета теле элементлары еш күренә башлады. Чөнки хәзерге язучыларның күбесе — журналистлар. Ләкин алай дип акланып булмый, телгә бераз саграк булырга кирәктер. Менә Б. Камаловның «Актуган Габсаттары»ннан Габсаттар абзый сөйләп җибәрә. «Безнең буын үзенчә бәхетле, улым. Яңа дөнья коруны башлап җибәрүе белән бәхетле. Ә без усубый. Яңа дөньяны гел камилләштерә барачаксыз». Менә тәрҗемә итеп кара инде моны! Аннан соң әдәбиятыбыз бөтенсоюз аренасына кыенлык белән чыга дип зарланабыз...

Хисләрен тышка чыгармауда гадәттә тотанаклы булган геройларыбыз хәзер мәхәббәт турында дискуссиягә бик еш кереп китәләр. Хәтта мәхәббәт сүзе таушала, асыл мәгънәсен югалта башлый. Ул гына да түгел, картлар ике сүзнең берендә мәхәббәт дип җибәрәләр. Геройга, бигрәк тә өлкән яшьтәгесенә ятышып бетми болар.

Мәхәббәт, мәхәббәт дип авыз суын корытмасын иде геройлар. Мәхәббәтне аны тасвирларга кирәк. Моннан образ-характерлар да отар иде, әсәрнең яшәндыру көче дә артыр иде.

А. Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән...», «Әтәч менгән читәнгә» повестларын дискуссиядә катнашучылар бертавыштан хаклы рәвештә уңай бәяләделәр.

Дөрестән дә, «Әтәч менгән читәнгә» повесте сиксәненче еллар татар әдәбияты өчен темасы белән яңа. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, аңарчы бездә Зөфәр Сәбитов та бар иде. Язучы заманның тискәре тенденциясен дөрес тотып алган. Тагын «ләкин» сүзен кулланырга туры килә. Сәләхетдиннәрнең һәм Мирфатыйхларның бәлеп китү процессын автор бик җентекләп тасвирлый. Әмма аларның байлыкка омтылуларын бары тик көнчелеккә генә кайтарып калдыра. Ярый ла, заманның мондый тискәре тенденциясе көнчелектән генә килеп чыкса. Аның белән көрәшү дә бермә-бер җиңел булыр иде. Болай килеп чыга: Сәләхетдиннең дә, Мирфатыйхның да күңелендә әйбер җыю (вещизм) корты булмаган, алар бары тик берберсеннән калышмау өчен генә тырышалар.

Кабатлап әйтергә кирәк, мондый гына кимчелекләр асылда әйбәт булган әсәрләрнең төп бәясен төшерми, әлбәттә. Зур сүз осталарының моңа юл куюлары гына борчылу хисе тудыра.

Әхсән Баянов ижаты турында дискуссия вакытында да, аңарчы да күп фикерләр әйтелде. Ижаты бәхәс куптара торган язучы үзенә күрә бер бәхетле кешедер инде ул. Ә. Баяновның язучы буларак бер уңай ягы шунда, ул гадәттә әсәрнең поэтикасына үзеннән нинди дә булса яңалык, оригинальлек кертергә тырыша. Хуплый торган сыйфат. Ләкин экспериментлар артык озакка сузылмады микән дигән шик тә уяна. Без кайчандыр Кама-Камиләне күрдек, язгы ташу белән бакчасына килеп кергән бозны ватучы Татаны беләбез. «Тавыш — табигать бүләге» турында да сүзләр күп булды. Әлбәттә, символларның әдәбиятта яшәргә тулы

хокукы бар. Ләкин алар әсәр тукымасына органик рәвештә үрелеп керергә тиештер инде. Тата айсберг кадәрле боз ватып йөри (кайдан килгәндер ул безнең җирлектә андый боз?). Күрәсең, ул кеше күңелендәге салкынлык белән көрәшә. Язгы кояшка бөтенләй диярлек эш калмый. Э. Баянов, дискуссиядә катнашып, «Замандашларым» дигән мәкаләсендә чын күңелдән мондый сүзләр әйтеп ташлады! «Ни өчен болай дим, чөнки безгә еш кына сәер сүзләр ишетергә туры килә:

— Социалистик реализм әсәрләре өчен шартлы алымнар куллану гөнаһлы — тормыштагы хәл нәкъ булган рәвешендә генә әсәргә кереп утырырга тиеш».

Әдәбият булгач, шартлылыктан ничек кенә теләсәң дә качып булмый инде. Әмма дөньяда чама дигән нәрсә дә бар бит әле.

Заманында бәхәсләрдә күпме сөңгеләр сындырган Әнис Бадигин бар иде. Еллар үткәч «Аязучан болытлы һава» повестенда без аның белән тагын бер кат очраштык. Заманында М. Маликова куйган «Кем ул Әнис Бадигин?» дигән сорау тагын килеп басты. Чыннан да, кем соң ул? Ул һаман да шул акыл өйрәтергә, үгет-нәсихәт бирергә яратучы Әнис Бадигин. Тик ул бераз олыгайган, сабырланган. Әмма элекке кебек үк дөнья язмышын бер үзе хәл итәрдәй кеше булып йөри. Бу аңа бик ошый. Аңа хатлар язалар, чакыралар, киңәш сорыйлар — гомумән, Әнис Бадигин әле дә дөньяның тоткасы. Авылда никадәр кеше яши, акыллылар, укымышлылар, әмма үзләре чуалтып бетергән мөнәсәбәтләрне үзләре аралый алмыйча азапланалар. Ярдәмгә әллә кайдагы Әнис Бадигинны чакыралар. Ул яшь чагында үзен рәнҗеткән кешеләрне берәм-берәм йөреп чыга, аларның мескен хәлгә калуларына эчтән генә сөенә дә кебек.

Эшче темасына язылган әсәрләрдә, тел-стиль мәсьәләсенә дә әдипләрнең әле ныклап тотынасылары бар. Күпме тырышсак та, әллә ни алга китә алган юк безнең бу өлкәләрдә.

Мәсәлән, эшче темасына багышланган, соңгы елларның яхшы әсәреннән саналган «Каты токым»да да кешене ышандырмый торган наив урыннар тулып ята. Укучы әсәргә иң элек бәя биргәндә ышандыру-ышандырмау позициясеннән чыга. Ул тормышны яхшы белә. «Ышанмыйм, тормышта алай булмый ул»,— дисә, укучы йөз тапкыр хаклы. Шуннан чыгып, тагын бер моментка тукталу кирәктер. Безнең әсәрләрдәге күпчелек җитәкче персонажларның семья хәле начар. Кайсысыннан хатыны киткән, кайсы үзе качкан, кайсы соңарган мәхәббәт белән интегә, кайсының баласы тайгак юлдан киткән. Э бит алар җитәкчеләр. Аларның кулында цех, завод, колхоз, тагын да югарырак урында утырганнары бар. Көн саен алар дистәләрчә кешеләр белән очрашалар, дистәләрчә боерык бирәләр, карар кабул итәләр. Шундый мәңгегә боялган рухи халәт белән эш итсәләр, аның нәтиҗәләре куанырлык булмас иде. Әгәр дә авторның башына үзе тасвирлаган бу бәлаләрнең бер генә проценты төшсә дә, үзе җүнләп бер абзац та яза алмас иде. Бик күп җитәкчеләр матур тормыш белән, кул астындагыларга үрнәк булырлык яшиләр бит. Алар кая китте соң безнең әсәрләрдән?

АЯЗ КҮКТӘ КАРЛЫГАЧЛАР

Чех халкының патриот-шагыйре Ю. Фучикның шундый сүзләре бар: «Бу чордан исән котылганнардан мин бер генә нәрсә сорыйм: онытмагыз! Яхшыларны да, яманнарны да онытмагыз! Үзе өчен, сезнең өчен һәлак булганнар турында түземлек белән мәгълүмат җыегыз. Бүгенгеләр үткән көн булып калган вакыт килер, ул чакта бу бөек чор һәм тарихны тудырган исемсез геройлар турында сөйләячәкләр. Мин бөтен кешеләрнең дә анык белүен теләр идем: исемсез геройлар булмады...»

Ватан сугышы геройларының якты истәлеген мәңгеләштерүгә бөтен иҗатын багышлаган Шамил Рәкыйпов — бу васыятькә тугры язучыларның берсе. Әдәбият сөючеләргә сугыш батырлыгы турындагы документаль әсәрләре белән күптәннән таныш булган бу язучының яңа китабы[1] басылып чыкты.

Соңгы елларда язылган очерклар, документаль хикәяләр тупланган бу җыентыкта. Ул «Аяз күктә карлыгачлар» исемле очерк белән ачыла. Советлар Союзы Герое Закир Әсфәндияров, авырып китеп, больницага эләгә, һәм батырның тынгысыз уйлары аның үткән тормыш юлын айкый башлый. Аның данлы үткәне бүгенге көн белән бик тыгыз бәйләнгән. Беренчедән, уллары, оныклары үзенә лаек булып үсәләр, аның рухи варислары буларак, эшен дәвам иттерәләр. Икенчедән, авырып яткан да ул фронтташ дусты Вася Сторублевцевның атисе Федот Никитичның исәнлеге хакында ишетә. Ветеран, сагыну белән, Васяның каберен барып табарга, аннан соң Федот Никитичны күрергә карар итә, оныгын да үзе белән ала. Тормыш турында яңабаштан уйлана ул. Әлегә соң түгел— каберләрне табарга да, лаеклы кешеләрне искә төшерергә дә... Оныгын да бу эшкә җәлеп итәргә мөмкин....

Герой үзенең иптәшләре хакында сөйли. Шул вакытта аның үзенең дә иң гүзәл әхлак, характер сыйфатлары ачылып китә.

Әсәрнең исеме исә, корбаннар, авырлыклар, кан, күз яшьләре аша яуланган аяз тыныч күкнең, тормышның бәясен онытмаска, бүгенге рәхәткә изрәп, кешелеккә янаган куркыныч хакында истән чыгармаска киреклеген тагын бер кат искәртә.

«Комбат истәлеге» очеркы да ретроспектив сурәтләүгә корылган. Автор биредә комбат турында сөйләгәнче, аның хакында хикәяләүчә кеше — бакча каравылчысы Михаил Максимыч белән таныштыра. Чәчкәләр үстерүче, беренче карашка сәер генә характерлы бу картның образы аша язучы үткәннәргә күпер сала, вакыйгаларның ышандыру көчен арттыра, очеркның чынлыгын раслый. Гөлчәчәк куаклары үстерүче Максим Максимычның сәер гадәтенең дә сере очеркның үзәк герое комбат Баталовның истәлегенә тугрылыктан килә икән.

Дәһшәтле 1941 елның җәендә Федор Алексеевич Баталовның ординарецы була Михаил Максимыч. Баталов сугышның 22 нче көнендә контрһөҗүм оештыру киреклеген ышандырып инициатива күрсәтә. Аны хуплыйлар, 63 нче корпуска караган 21 нче армия һөҗүмгә күчә, Жлобин, Рогачев шәһәрләрен ала. Һөҗүмдә иң алда Баталов батальоны бара. Әлбәттә, фашистларның стратегик һөҗүме туктатылмаса да, мораль җиңү зур була... Шушы кырыс комбатның землянкасында, тәрәзә төбендә — роза чәчәкләре... Образ шул деталь белән яктырып, ачылып китә.

Автор Баталовның тәҗрибәле командир булуына басым ясый, аның хәрби талантын оста сурәтли. Полк командиры Федор Баталовка 1941 елның 9 августында Советлар Союзы Герое исеме бирелә, ә үзе ул

[1] Шамил Рәкыйпов. Аяз күктә карлыгачлар. Казан, 1982.

18 июльдә һәлак була. Һәркемгә мәгълүм: сугышның беренче көнендә үк герой исеменә тәкъдим ителүчеләр күп булмый. Баталов — шул беренчеләр тоқымыннан.

Очерк бүгенге тормыш, яшьләрне дөрес тәрбияләү, кешелек бурычы, хәтер турында уйландыра, сугышның төрле шаһитлары Николай Владимирович, Мария Васильевна образлары аша дәһшәтле чорның атмосферасын, кеше язмышы лабиринтларын ача.

«Сагынулы очрашу» әсәрендә автор япончарга, финнарга, фашистларга каршы сугышларда унбиш тапкыр яраланып, үлгән дип исемләнгән кешене — Советлар Союзы Герое Фәррах Камалетдиновны эзләп табу тарихын сөйли. Эзләнүләр уңышлы тәмамлана — герой үсенек югалган улы Альберт белән очраша. Бу — эзләнүченең фидакарьлегенә иң зур бәһа түгелмени! Ш. Рәкыйпов хезмәтенең әхлакый изгелеген дә күрсәтүче факт бит бу!

«Мәхәббәт тарихы» очеркында автор сугышта сыналган, дөнья вакыйгаларыннан, хәтта үлемнән дә көчлерәк булган Маруся һәм Мишаның гыйбрәтле мәхәббәт тарихын хикәяләүче сугыш герое Фәйзулла Хаҗиевич Әһлетдинов образын үзәккә куйган. Геройның сугышчан батырлыгы мәхәббәт һәм әхлак проблемаларын яктыртып җибәрә.

Альбина Муратовнаның да мәхәббәте, семья тарихын сөйләп, автор саф мәхәббәт өчен көрәшергә чакыра. Еш кына автор сөйләме персонаж сөйләме белән кушылып китә. «Тормыш дәвам итә. Ил дә, ир дә, хатын да оттырмасын өчен, ил тирәгә булган гаиләдә бер-береңне гомер буе газаплап яшәмәс өчен, безгә иртәгә тагын нилләр эшләргә соң?» (52 бит.)

«Солдат биштәре» әсәре кече сержант Садыйк Әбелхановның уйланулары формасында язылган. «Сакланганны саклармын»га охшаш үз фәлсәфәсе булган бу 30 яшьлек мишәр агае Николай Нещадим, Чебоксар егете Федяның фидакарьлекләре үрнәгендә, фронт тәҗрибәсе йогынтысында үзе дә батыр сугышчы булып формалаша. Батырларның яшәү философиясен, рухи кыйбланаларын аңларга аңа художник Миколадан калган Пушкин томы, шул китапка мәкибә киткән каһарман Федя ярдәм итә. Гүзәллек һәм поэзия яраткан бу кеше егет кирәк булганда гомерләрен дә кызганмыйлар. Автор Садыйкның кыска вакыттагы рухи үсешен ышандырырлык итеп күрсәтә алган.

Китаптагы «Сәнгечегә — алтын сәгать» очеркы Ш. Рәкыйповның юҗат лабораториясе үзенчәлеген тагын да ныграк ача кебек. Әсәр Ватан сугышы геройлары эзеннән баруның, батырларны ачыклау эшенең никадәр авыр һәм четерекле икәнен күрсәтә. Эзләнүче вәҗданының, аның әхлак позициясенең әһәмиятен күтәрә. Дәгъвә Вәлиевнең Герой исеменә лаек язмышын ачыклау бушка китми. Бу эш катлаулы язмышларны чишүдә ориентирлар да бирә. Ул — дөреслек, хакыйкать! Әсәрдәге факт — халкыбыз батырлыгының сугышта массовый төстә булуы хакында да сөйли.

Белоруссиядәге партизан хәрәкәте материалларына нигезләнеп язылган «Иярләнгән атлар» драматик повестенда да автор билгесез геройларны эзләү эшен, «Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый!» дигән лозунгның тормышка ашырылуын сурәтли. Ш. Рәкыйпов әсәрен партизаннар хәрәкәте, Плещиницыны азат итү сугышлары турында мәгълүматлар эзләнүгә нигезләнеп язган. Кем белә, бәлки, повесть Иван Кабушкин турындагы материаллардан да тугандыр? Ничек кенә булмасын, бу драматик повесть авторның яңадан-яңа форма, сурәтләү чараларына ия була баруы хакында сөйли. Һәм ул киносценарийны да хәтерләтә.

Плещеницы районын азат итү сугышларында безнең якка чыккан бер немец офицеры фидакарьлек күрсәтә. «Ул машинасы өстенә басып, бүрәнкәне рупор итеп, листовка укырга кереште. Кызу сугыш барганда, шулай югарыга менеп кычкыру зур саксызлык иде, әлбәттә. Ләкин шул ук вакытта бу — каһарманлык та иде. Листовкада язылган хакыйкатьне үз җанының өстен күрмәсә, кабинада гына чүмәшеп утырыр иде ул. Үз эшенең хак булуын аңлау кешене күркусыз итә»,— ди Алексей Максимович. (209—210 битләр.)

Отто язмышы аша Ш. Рәкыйпов азатлык сугышына өлеш керткән, игелек күрсәткән, гомерен кызганмаганнардан беркем дә онытылырга тиеш түгеллегенә басым ясый, ченки лаеклыларны оныту, дөреслекне белмәү үзе үк буыннарга, кешелеккә каршы эшли, дошманга хезмәт итә. Мәсәлән, Көнбатыш Германия армиясендә Оттоны фюрер өчен үлде дип, милли герой ясыйлар, яшь солдатларның аңын агулыйлар икән. Өлкән пионервожатыйның Дрезденнан килгән хатка игътибарсызлыгы аркасында Отто турындагы хакыйкать тулысын-

ча ачыкланмый кала. Эзләнү озаккарак сузыла, ул вакыт эчендә элекке рота писаре лейтенант Зайцев вафат була.

«Бөек Ватан сугышы тарихында күзне чагылдырырлык шәхесләрнең батырлыгы турында яңадан-яңа сәхифәләр табыла гына тора. Күңел күзе белән карап эзли бел дә нәтиҗә ясый бел.

Чын тарих бервакытта да мәһабәт таш кыя рәвешендә тормый, ул төрле зурлыктагы кисәкчәләрдән тора. Шушы кисәкчәләр билгесезлек тузаны булып калмасын, юкка чыкмасын өчен, кеше, тирә-юньгә үтә игътибарлы булып, үз вазифасын һәрвакыт төгәл башкарырга тиеш». (217 бит.) Авторның бу ремаркасында әсәрләрнең төп пафосы чагыла. Сугыш чоры һәм документаль, һәм матур әдәбият өчен бетмәс-төкәнмәс материал ул. Әлегә соң түгел — анда булган вакыйгаларны җыярга кирәк! Бигрәк тә тере шаһитлар бар чагында...

Китапның ахырына урнаштырылган бу повесть очеркларның логик дәвамы булып кына тормый, ә Ш. Рәкыйповның бөтен иҗат кыйбласын да ачып бирә кебек. Бу фикер Александр Максимович уйларында тирән чагыла: «Үлгәннәр истәлеге тереләр өчен кирәк. Тереләрнең және тыныч түгел. Дөнья тыныч түгел. Үлгәннәр турында даими сөйләргә кирәк. Вакытсыз үлгәннәр турында. Ир-егетләр турында. Алар онытылмаска тиеш. Алар хакы — изге». (220 бит.)

Әсәрнең исеме «Иярләнгән атлар», бердән, сугышчыга тугрылыклы булган атны («ир-егеткәй белән ат башы») гәүдәләндерсә, икенче яклап, ул вакытның үтүен, җилүен белдерә, заманны иярләп калырга чакыра. Киләчәк өчен үткәннең сабакларын мөмкин кадәр тулырак, күбрәк алырга кирәклегенә дә ишарә ясый әсәрнең исеме.

Китап — Ватан сугышының вакытлыча игътибардан читтә калган батырлыгы хакында тагын бер яңа сәхифә. Ул батырлык, изгелекләрне онытмаска, вакытында халыкка җиткерергә ашыгырга чакыра. Кулыннан килгән кешеләр моны эшләргә тиешләр. Чөнки алар киләчәк буыннар һәм заман алдында, һәлак булган полкташлары, үз вөжданнары алдында җаваплылар. «Йөзең ак, намусың пакь булуын теләсәң — эзлән, уйлан, укучым, ихлас күңелдән эшләнгән эш бушка китми ул»,— ди кебек автор. Әйе, үткән буыннар белән рухи бердәмлектә һәм аларга лаек булып яшәргә чакыра бу китап.

Рәүф ИДРИСОВ.
Уфа.

ЯКТЫ МОҢ...

Китапның тышлыгында шундый рәсем: адәм баласы, кулына балкып янган кояш тотып, кешеләр янына бара. Туганлык, дуслык, бәхет, мәхәббәт хисләре — ташып торган күңеленең хәзинәләрен кояшка әйләндереп, ул шулай кешеләргә таба ашыга. Гасырдан-гасырга кешегә мирас булып күчеп килгән бу рухи халәтне — яшәешнең нигез сыйфатын — хыял белән чынбарлык арасында тирбәлеш хәлендә торган иң саф, иң самими тойгыларны рәссам әнә шулай итеп чагылдырган...

Шагыйрь Гәрәй Рәхимнең «Мәхәббәтем турында җыр» исемле җыентыгына[1] тупланган шигырьләр белән әлеге күренеш арасында гади күзгә ташланып тормаган бер эчке бәйләнеш, рухи кардәшлек бар. Аларны якынайткан, туганлаштырган хасиятләр, мөгаен, җиребезне бизәп торган әйбәт кешеләргә карата булган Мәхәббәт хисенең зурлыгында һәм кайнарлыгында, бу дөньяда рухи гармония булдырырга омтылуында, кешелекнең барыр юлын өмет һәм ышаныч уты белән һәрдаим яктыртып торуындадыр...

Шагыйрьнең китабы үзенчәлекле бер шигырь белән ачылып китә. «Туган илем Татарстан» дип аталган бу шигырьдә күпмедер дәрәҗәдә шагыйрьнең иҗат кредосы да чагыла. Чөнки биредә язмышын иле һәм туган халкы белән бәйләгән шагыйрь-патриотның және ачыла, заман гамен сыйдыра алган тынгысыз йөрәк тибеше сизелә.

Син бит мине шундый көчле иттең,
Өстәп бирдең тагын изгелек.
Рәхмәт, илем! Инде үзем сине
Күтәрергә көчем бар кебек.

Лирик герой Ватан-анага игелекләр һәм шуңа өстәп биргән игелекләре өчен чын

[1] Гәрәй Рәхим. Мәхәббәтем турында җыр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1982 ел.

күңеленнән рәхмәт үкый, үзендәге барлык яхшы сыйфатларның башлангычы туган илдә булуын тирән аңлый.

Бары азат, ирекле ил генә адәм баласын күтәрә, кеше итә ала. Ә инде тернәкләнгәч, тау-таш актарырлык булып җитешкәч, кеше үзе Ватаны турында кайгыртырга, аның язмышын уртаклашырга, нигез ташы һәм тәрәге булырга тиеш, ди шагыйрь. Ил-көнебез алдындагы изге бурычны шулай искәртеп, Гәрәй Рәхим намус активлыгына, ил-көн намына хәрәкәткә чакыра.

Туган җиргә багышланган шигырьләрендә Гәрәй Рәхимнең поэтик характеры аеруча кыю ачыла, шагыйрьнең үз йөзе тагын да ачыграк сизеләнә. Әйтик, шагыйрьнең «Иген өчен, илең өчен», «Юлың якты», «Туган ягым» дигән шигырьләре әлеге фикерне куәтли. Биредә лирик герой халык күңелендә, халык җанында бөреләнгән уй-хисләр белән янып-көеп яши. Тамырлары җиргә нык береккән үсентеләр генә яшәү бәхетенә ирешә алган кебек, йорты, җире-суы, гүзәл Ватаны, матур киләчәгә булган кеше генә бәхетле була ала. Бары Ватан гына кеше күңелендә өмет чаткысы һәм бәхет йолдызы кабыза, иҗат шатлыгы һәм яшәү дәрте бүләк итә. Менә шуңа күрә, азат Ватаныбызның кадерен белеп кенә яшәргә, хезмәт итәргә чакыра шагыйрь, Ватан дигән якты йолдызны сүрелдермәскә өнди.

Кеше шул йолдыз өчен, гомерен
Кабергә кадәр озата ала.
Үзе мәңгегә җирдән югала —
Тик туган иле исән-сау кала.

Гәрәй Рәхим баллада жанрына да кыю мөрәҗәгать итә. «Игенче турында баллада» әсәрендә игенче образы матур сурәтләнгән. Ел саен аның иленә яңа `килә дә бар нәрсәне кырып-жимереп китә. Ә игенче исә, зур сабырлык күрсәтеп, басуны маңгай тире белән сугарып эшкәртә, иген игә— тереклек чишмәсенә кибәргә юл куймый. Киләчәк хакына тырышып хезмәт итә. Игенченең фидакарь хезмәтенә дан жырлаган бу баллада фикер агышының тирәнлеге белән җәлеп итә. Туган иленә зур игелек эшләп тә, үзе тыйнак булып кала алган энәк игенченең жан матурлыгы, күңел сафлыгы сокландыра, рухи деньябызны ниндидер бер эчке гүзәллеге белән җылыта:

Болытлар озакка
Киткәндә ераккa,
Кайнар җил тәннәрне пешерә.
Кешеләр көченә
Буйсынды бу чүл дә,—
Дан жырлый басулар кешегә.

Шагыйрь жаны жир шарында барган бер генә үзгәреш-яңарышка да битараф түгел. Аның гражданлык йөзен көчәйтүче төп сыйфатларның берсе — поэтик характерының тынгысызлыгы, туктаусыз эзләнүчәнлеге. Жирдә яшәгән һәр төре жан, һәр жисем шагыйрьнең сизгер карашыннан читтә калмый. Шагыйрь йөрәгенең җылысын һәркемгә тигез бүлеп бирә. Аның жаны кешелек, тереклек белән бергә күшылган. Шигъри әсәрләрендә халыклар дуслыгына мөрәҗәгать итәме ул, яки халыкара сугыш чукмарларына кискен нәфрәт хисләрен белдерәме, шагыйрь-гражданин авазы яшәешнең, тереклекнең нигез ташын какшатырга омтылучыларның пычрак ниятләренә каршы чыга, үлем уты белән шаяручыларны нык итеп кисәтә.

Крематорийларны күрмәдем мин —
Әмма яндым.
Бу таш белән беркемгә дә сукмадым мин—
Әмма кулга алдым.

Шагыйрь кешеләрнең нхлас булмаган мөнәсәбәтләре аркасында кайчак таркала, жуела башлаган гармонияне, мәхәббәтне тергезергә ашкына. Тик жирдә бәхет, шатлык һәм мәхәббәт хакимлеге урнаштыру жиңел түгел. Чөнки, табылдыклар өстәлендә хәсәтлек бар, кеше, намус, ил, тән сатып тамак туйдыручы инәнеч затлар бар. Югалган атом бомбасы, фашист чокып чыгарган күзләр, ярасы саркып торган хәтер бар...

Кешелек сыйфатларын — моңнарын, телләрен, илләрен, иманнарын, намусларын, мәхәббәтләрен югалткан бәндәләргә табылдыклар өстәленә юл бикле.

Кешелек һәм шигърият алдында зур жаваплылык тоеп иҗат итә шагыйрь. Әсәрләренең көчен, җегәрен исемнәре халык намусына, ил вәжданына әверелгән Тукай, Такташ, Җәлил кебек затларның шигырьләре белән чагыштырып карый, үлчи, сыный.

Уйлыйм бүген бөек Тукайларны,
Бөек Пушкин, Такташ, Җәлилне.
Язганнарым шушы бөекләрне
Дәвам итүемә дәлилме?

Гәрәй Рәхимнең сәю лирикасы үзе бер якты моң! «Мәхәббәтем турында жыр», «Карама син көзгеләргә», «Мәхәббәт хаты» һәм башка әсәрләрендә шагыйрь жан сафлыгына, хисләрнең пакьлегенә, чисталыгына, мәхәббәтнең илаһи көченә соклана. Мәхәббәтнең тылсымлы сихри көче белән канатланган лирик геройның рухы бәхеткә

йөз төбәп оча. Табигать, тереклек бу халәтнең бер мизгеле алдында әсәрләнеп калган. Күкләр, таулар, урманнар, сулар хозурланып тамаша кыла. Бу хиснең — мәхәббәт хисенең кеше җанына үтеп керүен бар тараф әнә шулай таң калып күзәтә. Төкле аягы белән атлап, мәхәббәт килә. Сөю килә, яну килә... Лирик герой сөйгәненә тугрылыклы, вәгъдәле. Шулай булмаса, сөеклесе өчен шәрран ачык булган йөрәге кайнар хисләр әсире булмас, олы хиснең «ялкыннары тәннәрендә, каннарында уйнап тормас» иде.

Гәрәй Рәхим үзенең көчен четерекле жанрда — опера либреттосы өлкәсендә дә сынап карады. Мәҗит Гафуриның «Кара йөзләр» повестена нигезләнеп «Кәһәрләнгән мәхәббәт» исемле либретто язды. Сәхнә өчен поэма Г. Рәхим иҗатының офыкларын шактый киңәйтте. Поэма — мул фикерле, киң полотнолы әсәр. Халкыбызның ул чордагы яшәешен, әхлакый гадәтләрен тасвирларга омтылган әсәр. Халыкның акрынлап дини хорафат сәременнән арына баруын, якты киләчәк өчен көрәшүчеләр сафына якынаю процессын Гәрәй Рәхим оста күрсәтә. Мәхәббәт өчен, намус өчен, вөҗдан азатлыгы өчен көрәштә һәлак булган Галимә белән кара йөзле кешеләр тарафыннан мәсхәрәләнгән Закир образлары трагик эчтәлекләр, драматик пафос белән истә кала.

Шагыйрь Галимәне мескен, кызганыч итеп түгел, бәлки көчле характерлы, бай натуралы, социаль хокуксызлыкка каршы көрәшүче алдынгы хатын-кыз итеп тасвирлый. Закир да алдынгы фикерле егет. Авыл яшьләрен оештырып йөрүче, байларга һәм аларның куштаннарына каршы чыгучы кыю йөрәкле гаярь көрәшче. Галимә белән Закирның мәхәббәте — ул дингә, томаналыкка, наданлыкка — димәк, тормышның социаль нигезенә каршы бунт дигән сүз. Шуңа күрә, кара көчләр — өстен сыйныф вәкилләре — мәхәббәтне кәһәрләп, кара ягып, яшьләр бунтын тизрәк бастырырга ашыгалар. Шагыйрь шуны драматик фонда, Галимә белән Закирның трагик язмышларын, үзенчәлекле образларын ышандырырлык итеп күрсәтә. Мәхәббәт каргалып мыскылланса да, кара көчләрнең вәхшилеге, җинаятьчел йөзе авыл халкының йокымсырап яткан намусын уята, аңын томалап торган караңгылык пәрдәсен ертып ташлый. Поэма ахырында «Кара йөзләр! Галимәне сез үтердегез!»— дип, халык үзе үк өстен сыйныфның битенә төкерә. Димәк, мәхәббәтнең тылсымлы көче жиңеп чыга!

Революциягә кадәрге татар халкының этнографиясенә мөрәҗәгать итү, печән өсте, кичке уен күренешләрен кертү, халык авыз иҗатының кайбер үрнәкләрен мул куллану поэманы тагын да җанландырып җибәргән, аның тәэсир итү көчен арттырган. Бу поэма Гәрәй Рәхимнең зур планлы эпик әсәрләр язарга сәләтле шагыйрь булуына да ышандыра.

Әхмәт СӘХАПОВ.

СОВЕТ ТАТАРСТАНЫНЫҢ СЫНЛЫ СӘНГАТЕ

(Альбом)

Халык үзенең хисләрен-тойгыларын җырда, бәеттә, яратып башкарган күл эшендә чагылдыра, деньяга мөнәсәбәтен үзе иҗат иткән әсәрләргә тәрендерә, чигү чигәме яшь кыз бала, көләпүш кайыймы — һичшиксез мәхәббәт хисен катнаштырып башкара. Дуга бизиме авыл агае, каралты-кура шикелле әйбер корыштырамы — ул, әлбәттә, һәр эшенә хисен сала, дәртен өсти.

Гасырлар чиген җимереп үткән үлемсез поэма «Кыйссаи Йосыф»ны иҗат итүче бөек шагыйрь бабабызга үткән ел 800 ел тулганын моңарчы да белә идек. Карап баксаң, безнең сәнгатебез дә борын-борыннан килә икән, ләбаса. Күптән түгел генә Мәскәүнең «Советский художник» нәшриятында рус телендә басылып чыккан «Совет Татарстанында сынлы сәнгать» дигән зур күләмле, иланһи матур альбом халкыбызның борынгы сәнгать үрнәкләрен дә күрсәтә. Борынгыдан алып бүгенге көнгәчә! Альбомның иң зур кыйммәте әнә шунда.

XII гасырда яшәүче Биләр һәм Болгар осталары амальгама белән каплаган көзгенең икенче ягына кош сурәтләре төшерергә оста булганнар: әнә мәсәлән Абу-Бәкер исемле оста каллиграфик матур хәрефләр белән бакырдан ясалган әйбергә сүзләр уйган; икенче бераүләр исә атлар, сыерлар һ. б. хайваннарның, күбесенчә йорт хайваннарының сурәтен төшергән. Һәм бу сурәтләр 800 елдан артык яшәп, бүгенге көндә борынгы заман сәнгать әсәрләренең әлгеләренә әверелгән. Болгардагы мәчет дивар-лары да (XIII гасыр) сәнгатьчә бизәлгән булган. Ә соң кабер ташлары! Ул ташларда халыкның яшәеше-көнкүреше дә, хисләре-тойгылары да чагыла килгән.

Альбомда халык иҗатына олуг игътибар күрсәтелгән. Нинди генә челтәрле-бизәкле, оста кулы белән эшләнгән беләзек һәм чулпылар, нинди генә зиннәтле бизәкләр төшереп яки асыл ташлар куеп ясалган хәситә һәм изүләр, нинди генә чигешле-челтәрле эскәтер һәм сәлгеләр юк монда! Ә соң энҗе-мәрҗәнле янсә көмеш тәңкәле, гажәеп затлы, күзнең явын алырлык, карап туймаслык, хәтта бераз охшашлык булган очракта да һичбер вакыт кабатлануны белмәгән, һәркайсы уникаль булып сакланган калфаклар үзләре генә дә нн тора бит! Алтын куллы осталарның күпме көч сарыф итеп, күз нурларын түгел, күңел тойгыларын салып чиккән калфаклары бүгенге көндә искиткеч зур хәзинә. Денья бәясе торырлык ул осталарның изге ният-ләре гамәлгә ашкан: алар кулы белән чигелгән-каелган бинһая затлы әйберләр пәхтә-пакь кәенче гасырлар аша үтеп, ничәмә-ничә буын вәкилләрен сөендереп, аларның рухын баетып, безнең көннәргә имин генә килеп җиткән. Сәнгать нәсел яки әдип өчен — иҗат иткән әсәренең үзе деньядан киткәч тә яшәвеннән дә зур бәхет, шундый илаһилыкка ирешү, дәрәҗәгә лаек булу бәхетеннән дә өстен нәрсә, гомуман, бармы икән?! Әйе, альбомдагы шикелле үк зиннәтле әйберләрне без бәләкәй чактан үк күреп үстек, һәм безнең күңелебездә төс һәм бизәкләргә, илаһи матурлыкка иң беренче мәхәббәтне, һичшиксез, әнә шулар уятты, гүзәллекне таный һәм сокланырга өйрәтте, гомумән сәнгатькә безнең күзебезне ачты. Хәзер инде ул гүзәллек үрнәкләре музей экспонатларына әверелде һәм әлеге альбом битләрендә меңнәрчә кешенең күңелен сөендерәчәк.

Альбомда шулай ук татар китапларының, газета-журналларының кайбер үрнәкләре китерелгән. Бу хәл бүген китап һәм журнал тышлыклары, эчке рәсемнәр ясау-

чы рәссамнарыбызны уйланырга мәҗбүр итә: димәк ки халыкка аң-белем чишмәсе алып килгән басма сүзне сәнгать әсәре буларак та бәяләргә, бу эшкә күп көч салырга тиеш икәнбез!

Халкыбыз культурасының үткәне белән таныштырганнан соң бу альбомны төзүче һәм кереш сүз язучы — сәнгать белгече, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Светлана Червонная иң төп өлешкә күчә. Автономияле республикада чәчәк аткан сынлы сәнгатьне ул жанрларга бүлеп тәкъдим итә.

Нәкыш бүлеге РСФСРның халык художнигы Бакый Урманченың «Салтык болыны» исемле мәшһүр картинасыннан алынган фрагмент белән ачылып китә. Һәм шушы хәл генә дә төзүченең күпме уйлануын, борынгыны бүгенге белән ничек итеп оста бәйләвен күрсәтә. Бакый ага бу полотносында үзе сабый чакта күргәннәрне гәүдәләндерә: авыл халкы болында печән чаба, чүмәлә куя; алгы планда зифа буйлы ике кыз тырма белән печән җыештыра; аларның башларына кигән эшләпәләре дә, өсләрендәге күлмәк-алъяпкычлары да, аякларына кигән тула оек белән чабаталары да, әлбәттә, бүгенге көндә тарихка әйләнгән нәрсәләр; шул чаклы да бай чигешле алъяпкычлар бу ике чибәрне тагын да ныграк ямьләндерә һәм күркәмлек өсти; һәм бер үк вакытта алдагы бүлеккә искиткеч оста бәйли.

Гәрчә рәссамнарның фамилиясен алфавит тәртибендә алу тематик бердәмлекне саклауга бик нык комачауласа да, янәшә килгән кайбер битләрдә төзүче азмы-күпме бердәмлеккә ирешә алган. Шундыйлардан РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Илдар Зариповның «Әти» һәм «Куаныч!» дигән картиналары икесе дә хезмәт кешесенең киләчәккә өметен, нәниләренә сөенүен гәүдәләндерә. Талантлы рәссамның бу эшләрендә аның иң әйбәт сыйфаты — гуманизм — аермачык чагыла һәм бөтен иҗатын күз алдына китерергә мөмкинлек бирә; альбомны караучыда рәссамга теләктәшлек хисе уяна. В. И. Куделькинның да ике хезмәте («М. И. Калинин Татарстан крестьяннарында кунакта» һәм «Советлар Союзы Герое Н. А. Якупов»), шулай үк Н. Д. Кузнецовның «Казан — биш диңгез порты» һәм «Бүгенге Иделнең ярлары» дигән картиналары да тематик яктан аваздашлар. Ә инде Татарстанның халык художнигы Мәхмүт Усмановның зур күләмле ике картинасы Кама буендагы бөек төзелешләрне чагылдыра.

Соңгы еллардагы күргәзмәләрне йөзек кашыдай бизәгән картина — ул да булса Мәснәви Хәертдиновның «Ана тойгысы (Наз)» дигән әсәре альбомда аерым бер урын алып тора: гүя ул рәссам ирешкән осталык алдында сокланырга һәм бер үк вакытта нәкъ менә таланты ачылып килгән чакны дөнья куюы белән һәркайсыбызны моңаергә, сагышланырга мәҗбүр итә...

РСФСРның халык художнигы Лотфулла Фәттахов милли сәнгатебездә һичбер вакыт юылмас эз, гаҗәеп бай мирас калдырды. Аның олы жанрлы кеше булганлыгы «Яңа буралар» һәм «Сабантуй» дип исемләнгән зур күләмле картиналарында — төсләрнең искиткеч уңышлы сайлануында, геройларының кабатланмас позаларында, хәрәкәттә бирелүендә, жанрлылыгында, милли колоритында — ярылып ята. Хәер, бу останың 1967 елда Бөек Октябрьның 50 еллыгын котлап ясаган картинасы альбомның тышлыгында бирелү үзе генә дә күпне аңлата булса кирәк. Ә инде Харис Якупов белән бергәләп эшләгән һәм «В. И. Ленин Татарстан АССР төзелү Декретына кул куя» дип аталган картинаның ил күләмендә шөһрәт казанып, СССРның Дәүләт премиясенә лаек табылганы һәркайсыбызның хәтерендә.

СССР халык художнигы Харис Якуповның Муса Җәлилгә багышлап язылган картинасы зур игътибарга лаек: гәрчә тоткын булса да, гәрчә үлемгә дучар ителгән булса да, халкыбызның горурлыгы булуга ирешкән әдип йөзендә өркү ише нәрсә һич тә сизелми — ул күп милләтле совет халкының Олуг Җиңүне яулап аласына чын күңелдән ышана; ә инде креслоларга җәелеп, масаеп утырган фашист илбасарларның күзләрендә хәвеф, киләчәккә бер дә ышанмау чагыла. СССР художество академиясенең член-корреспонденты Харис Якуповның башка хезмәтләре дә бу альбомда лаеклы урын алган.

Альбомны төзүче үткән белән хәзерге арасындагы бәйланышны ярыйсы ук оста күрсәтүгә ирешкән. Дөнья күләмендә мәшһүрлек казанган Н. И. Фешинның күп санлы картиналары Сынлы сәнгать музеебызның үзәген тәшкил итә һәм бизәп тора. Шулардан альбомга «В. И. Ленин портреты», «А. В. Луначарский портреты» һәм

«Т. А. Попова портреты» урнаштырылган. Фешин белән бер үк заманда диярлек Казандагы сәнгать училищесында озак еллар дәверендә бик күпләрне тәрбияләгән-белем биргән, шәкертләрен гомер буе сәнгатькә турылыклы булырга, көч кызганмый эшләргә өйрәткән һәм үз иҗатларында камиллекнең үрнәкләрен күрсәткән П. П. Беньков, В. К. Тимофеев, Г. А. Медведев һәм Н. М. Сокольскийларның да гаҗәеп үзенчәлекле әсәрләре альбомны баета.

Кайсыбер таланты ияләренең, шул исәптән Нәбиулла Вәлиуллин белән Әмир Мәҗитовның фәкать берәр генә эшләрен күрәбез. Бөек Ватан сугышында һәлак булган Вәлиуллинның сакланып калган бердәнбер күләмле әсәре («Татар хатыны») да, шулай ук Мәҗитовның әле моннан биш-ун ел элек кенә иҗат ителгән һәм «Партия ветераны Н. Т. Мәҗитов оныгы Кәринә белән» дип исемләнгән хезмәте дә бу рәссамнарның гаҗәеп зур осталыкка ирешкәнлеген, сәнгатебездә зур урын алып торганлыгын раслый.

Бу бүлекнең азагындарак урын алган ике яшь рәссамның — Шамил Шәйдуллин белән Фәрит Якуповның — әсәрләре символик яңгыраш алган диярсе килә. Шамил дә ике-өч буын вәкилләрен гәүдәләндерә һәм яшьләрнең тынгысызлыгы алдында баш июен исбатлый: «Карт алмагач төбендә»— тормышның дәвам итүен күрсәтә. Фәритнең геройлары исә кайчандыр, моннан күп еллар элек, яшь чакларында үзләре очраша торган чишмәне сагынып килгәннәр. Инде «Онытылган чишмә» янына бүтән килүче дә күренми, су авыл халкының өенә торбадан килә, әмма яшьлекне оныту һич мөмкин түгел. Тормышның дәвам итүен без аларның бәп-бәләкәй оныкларында — алтын яфраклар күтәреп, елмаеп-көлеп торучы сабыйның кыяфәтендә күрәбез һәм олылардан эстафетаны кабул итеп алган бу рәссамнарның сәләте киләчәктә бөтен тулылыгы белән ачылып китәр, аларның геройлары, әлеге сабыйдай, хәрәкәткә килер, йөреп китәр дигән өмет уяна.

Графика бүлеге Кол Галинең «Йосыф вә Зөләйха» китабына Тәвил Хаҗиәхмәтов ясаган рәсем белән ачыла. Талантлы һәм гаҗәеп үзенчәлекле рәссам үлемсез поэманы мәхәббәткә мәдхия уку дип кабул итә һәм шулай тасвирлый да. Укучыны бик борынгы заманнарга алып китәргә сәләтле рәсемдә гүзәллек тә, сафлык та, геройларның олы һәм изге хисе дә төсмерләнә. Татарстан китап нәшриятында бу әсәр Кол Галинең 800 еллыгына багышлап чыгарыла. Узган ел, нәкъ шул дата уңае белән бөек татар шагыйренең Хаҗиәхмәтов эшләгән портреты һәм тарих фәннәре докторы Миркасыйм Госманов язган мәгълүмат ЮНЕСКОның «Яңалыклар» бюллетененда шулай ук дөнья күрде. Халкыбыз өчен гаҗәеп зур вакыйганы чагылдырган шушы гүзәл рәсем белән бөтен бер бүлекне ачып җибәрүе яңа да төзүченең татар сәнгате, татар әдәбиятына булган мәхәббәтен, игътибарлы, мәгълүматлы булуын исбатлый.

Бу бүлектәге төрле стильдә эшләнгән рәсемнәр арасында акварель осталары Валентин Карамышев белән Рәшит Госмановның ике эше күңелне җәлеп итә. «Әмин тавы»— Казан каласының авылны хәтерләткән иске бер почмагы; урамнарны да, өй түбәләрен дә кар баскан; поселокта тормышның үз көенчә агылуын рәссам җиңелчә көлемсерәп, тыныч тонда тасвирлый. Иделне чын-чынлап яратучы Рәшит исә иртәнге бер мизгелне шундый да саф, шундый да пакь итеп суратлы ки, иректән үзеңне Идел киңлегендә күреп хыяллана башлыйсың, күңелләреңә рәхәт булып китә... Мәнә ни сәбәпле тиз генә аерыла алмыйсың бу акварельләрдән.

Әле быел гына Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә лаек булган Эмиль Ситдыйковның да «Бәхет басты» дип аталган линогравюрасы һәркемне сәер бер хәлгә китерә: гүя син әлеге картина геройларын рәсемдә генә түгел, бәлки тормышта күрәсең, яңа туган сабыеннан күзең дә алмыйча елмаеп торучы ананың куанычын уртаклашасың, сөенәсең, елмаясың.

Э инде Иван Язынинның бер рәсемен күрү белән Идел батыры Степан Разин образын гәүдәләндергән, байларга-патшаларга каршы Россия халкын аяусыз көрешкә күтәргән бәһадирны суратларча хезмәте күз алдына килеп баса. Графика жанрына зур әлеш керткән һәм иҗатында бәхәссез бер камиллекка ирешкән, ихлас кече күңелле рәссамның арабызда булмавы бәгырьне тырнап уза.

Театр декорациясе үрнәкләрен күрсәткән бүлектә исә контраст кую билгеле бер эффект китереп чыгарган: Нәҗип Жиһановның «Алтынчәч» операсы күп тапкырлар сәхнәгә куелды, һәм альбомда без 50 нче елларда П. Т. Сперанский ясаган эскиз

белән бер рәттән 70 нче елларда Хәнәфи Нәфиков эшләгән декорацияне күрәбез. Бер-берсенә һич тә охшамаган, икесе ике төрле алым. Петр Тихонович борынгы Болгар дәүләтен биек манараларда, мәгърурлыкта күрсә, бүгенге көн театр сәнгатен алга этәрүче Хәнәфи — сәхнәне җанландырып җибәрү юлын сайлый. Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясенә дә икесе ике стильдә эшләүче Әнәс Тумашев белән Э. Б. Гельмсның эскизлары китерелгән. Алар да мәсьәләне үзләренчә, дөресрәге һәркайсы үзенчә хәл итә. Алай гына да түгел, бер үк әсәр (Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» хикәясе) буенча төрле вакытта бер үк рәссам (Ә. Тумашев) тарафыннан эшләнгән декорацияләр дә төрле тональностьта, әдәби әсәрне төрлечә уку һәм төрлечә аңлау, ягъни героиняның язмышын һәр очракта башкача аңлау-күзаллау (бичара-мескен; дәһшәтле-дәртле) нәтиҗәсендә әнә шулай хәл ителгән.

Скульптура бүлегендә Бакый Урманченың Сәнгать музеендагы «Сагыш» исемле хезмәте күркәм урын алып тора. Агачтан уеп ясалган бу скульптурада гүя оста үзенең автопортретын бирергә теләгән. Һәрхәлдә, күпне күргән әлеге картның образында бары бер сагыш кына түгел, бәлки зирәк акыл да, уйга калу да, илаһи кодрәт тә, бертөрле моң да чагыла... Рада Нигъмәтуллинаның тынычлыкны саклау темасына ясалган скульптурасы, әлбәттә, һәркайсыбызда теләктәшлек тудыра. Әхсән Фәтхезмәте күркәм урын алып тора. Агачтан уеп ясалган бу скульптурада гүя оста үзебелән, алтын туйларын җиткергән карт белән карчык образын китереп чыгарган. Әхсәннең «Шүрәле»се игътибарга лаек. Әмма бу бүлеккә ямь биреп торган иң гүзәл сын — ул да булса Георгий Зяблицевның «Гөлчәчәге». Шул тикле нәфислек, шул тикле матурлыкны скульпторның балчыкны яндырып ясый алуына ышануы да авыр.

Монументаль сәнгать белән декоратив сәнгатьне альбом бәргә берләштереп тәкъдим итә. Бу бүлек Виктор Федоровның Төзүчеләр сараен ямьләндереп-бизәп торган монументаль рәсеменнән алынган фрагмент белән ачыла. Н. Ершов урамыннан көне буе халык агыла. Фасадны бизәгән әлеге паннога һәркемнең күзе төшә, һәм аны күргән саен һәркемнең күңеленә җылы керә, сәнгатькә, матурлыкка омтылышы арта бара. Ә соң тимер юл вокзалында күпме кеше була! Анда шул ук монументалистның Сергей Бубеннов белән бергәләшеп иҗат иткән Сәембикәсенә сокланмый узган кеше бар микән!

Бизәү әйберләре белән башланып киткән альбом икенче төрлерәк бизәү әйберләре (В. Ковалевскийның «Беләзеге» һәм С. Кузьминыхның читек-кәвеш, сумка һәм перчаткасы) белән тәмамлана да.

200 дән артык сәнгать әсәренең репродукциясен бергә туплаган мондый зур күләмле альбомның, гомумән, булганы юк иде әле. Төзүченең чал тарихны телгә китерүе, үзебез дә күреп җиткермәгән, кыйммәтен-кадерен белмәгән зиннәтле әйберләрне, сәнгать әсәрләрен чын күңелдән яратып, кайсын-каян берәмтекләп җыеп, шундый да затлы альбом чыгаруы олуг хөрмәткә лаек. Мондый альбомнар ел саен чыгып торса, күзгә ешрак чалынса, халык сынлы сәнгатькә дә ныграк һәм тизрәк ияләшер иде. Ә безнең инде иҗатына махсус альбом яки монография багышлардай көчле һәм сәләтле рәссамнарыбыз да аз түгел.

Бүгенге көндә, тугандаш халыкларның СССРны төшкил итеп, бергә оешып яши башлаганына 60 ел тулып узганда, татар әдәбияты, татар сәнгате искиткеч нык алга китте. Әмма һәркайсыбызга моны күрә-таный белергә — симфоник музыка башкарылган концертларга да, музейларда оештырылган күргәзмәләргә дә ешрак йөрү зарур. Шунда ишетергә, шунда күрергә мөмкин хәзинәгә тиң әсәрләрне! Безнең халык 80 ел буена театр спектакльләрен яратып карый. Һәр спектакльгә билет алуы кыенлашканнан-кыенлаша бара. Тик инде сәнгатьнең бер театр белән генә чикләнмәгәнен, аның колачы һәм мөмкинлекләре чиксез киң икәнен һәркемгә аңларга кирәк. Көчле симфоник оркестрның концертларына, шулай ук кече күләмле яисә бөтенләй ялгыз пианист, скрипкачы, органчы һ. б. концертына йөрергә вакыт табуы алай ук читен нәрсә түгел. Әнә шундый концерт залында яки музейда гына алып була торган рухи байлыкны һәркем алсын иде! Анда гына мөмкин булган рәхәтне һәм ләззәтне һәркем татысын иде! Сәнгать — халык байлыгы!

Кыям МИҢЛЕБАЕВ,
РСФСРның атказанган культура хезмәткәре.

Әхәт Нигъмәтуллин,
Башкортстан дәүләт университеты доценты

ӘДИПНЕҢ ҮСҮ ЮЛЫ

Мәгълүм булуынча, социалистик реализм методы эшчеләр хәрәкәтенең күтәрелә һәм үсә баруын чагылдырудан башланды. Икенче төрле итеп әйткәндә, эшче темасы яңа тип әдәбиятны нигезләде һәм үстерүдә хәлиткеч роль уйнады. Эшче тормышын чагылдыручы әдипләр революциягә кадәр каршылыкларга, авырлыкларга, очрадылар. Әмма үз язмышын хезмәт ияләре язмышы белән бәйләгән, халыкка хезмәт итү идеалына тугры булган әдипләр, каршылыкларны җиңә барып, ару-талусыз көрәшеп, әдәбияттә зур үрләр яуладылар. Шундыйларның бер күренекле вәкиле — Шәриф Камал.

Әлбәттә, аңа үзенең язучылык йөзен билгеләгәнче, эшчеләр темасын сайлап, аны ничек яктырту серләренә төшенгәнче шактый бормалы һәм газаплы тормыш юлы, иҗади эзләнү чоры үтәргә туры килде. Патша Россиясендә вак милләтләрнең хезмәт ияләре самодержавие тарафыннан да, үз милли байлары һәм руханилары тарафыннан да каты изелә — бөлгенлектә-хәерчелектә яши иде. Мондый кешеләр тормышында үткен проблемалар күп булды. Бер ише язучылар, шул исәптән Ш. Камал да, аларны гомумиләштереп «бәхет һәм бәхетсезлек» яки «бәхет эзләү» дип атарга яратты. Шәриф мәдрәсәләрдә укып йөргәндә, дөньяви белем алырлык уку йортлары һәм төшемлерәк эш эзләп Россия, Төркия, Мисыр буйлап сәяхәт иткәндә (1896—1905 еллар) «Хәерчелек хәленнән котылу, бәхетле булу өчен нәрсә эшләргә?» дигән традицион тарихи сорау тагы да үткенрәк рәвештә миллионнарча эшчеләр күңелен биләгән иде.

Мулла гаиләсендә туып-үскән, иске мәдрәсәләренең дини-схоластик «белеме» белән тәрбияләнгән яшь Шәриф өчен бу сорауга дөрес җавап табуы җиңел булмады. Җитмәсә, башкалар тарафыннан бирелгән җаваплар да башын әйләндерерлек дәрәҗәдә чуар һәм күп төрле иде. Әтисе Камалетдин абзый мулла булуны иң зур бәхетләрдән санаган. Шуңа күрә аның җавабы да — улы Шәрифне мулла итәргә тырышудан гыйбарәт булган. Икенчеләр, өченче-дүртенчеләр бәхеткә ирешүне төшемле эш табуда, яки һәртөрле эшне тырышып башкаруда, дөньяви белемгә ия

булуда, явызлыкка каршы көрәшүдә, яңача тормыш коруда күргәннәр. Шәриф, әлбәттә, бу карашларга да игътибар итмичә калмагандыр. Ә менә аның әтисе һәм муллалыкка фатиха биргән мәдрәсә хәзрәте йогынтысыннан котылуы, чыннан да, соклану уята. Ни өчен дисәң, бу — заман стихиясенә каршы бару дигән сүз, бу — җиңел түгел. Шәриф Ләбәҗә мәдрәсәсендә укыганда ук, бүтән фанатик шәкертләр кебек, кешеләргә аятьләр күчерү кәсебе, мулла-мәзин иярченнәре сыйфатында ашка йөреп хәер җыюлар белән кызыксынмаган. Биредә укыганда ул (1900 елның җәйге каникулында) Рузаевка белән Голицын арасындагы тимер юлында гади эшче сыйфатында үз көнен үзе күреп, үз бәхетен үзе сынап карарга була. Эшчеләр белән аралашу, иңгә-иң торып эшләү аның дини укудан бизүенә, мулла булудан баш тартуына, халык мәнфәгатен якларлык һөнәр үзләштерергә теләвенә җитди этәргеч бирә.

Әйе, Ш. Камал бик яшьли үз көчең белән тапканны кадерлерәк дип исәпләде, халык мәнфәгатен яклап намус белән хезмәт итүне артыграк санады. Әлеге сорауга җавапны да ул менә шушы караш күзлегеннән чыгып, үзе өчен генә түгел, ә барлык хезмәт ияләре өчен дә файдалы булырлык итеп бирергә, шунлыктан киңрәк аудиториягә мөрәҗәгать итеп эшләргә омтылды. Үзендә әдиплек сәләте сизгәнлектән, мондый омтылышны гамәлгә ашыру мөмкинлеген ул матбугат битләрендә иҗади әсәрләр белән чыгышлар ясауда күрде. Аның Екатеринослав күмер шахталарында эшләвен ташлап, 1905 елда революцион хәрәкәтнең иң нык кызган үзәгенә — Петербургка килүе, монда мөгаллим булып эшләве белән дә канәгатьләнмичә — яңа гына ачылган «Нур» газетасы редакциясенә эшкә керүе һәм мәкаләләр, шигырьләр белән газетада катнашуы да әнә шул турыда сөйли булса кирәк. «Нур» газетасында «Әфгале милләтә бер имган» («Милләт хәленә бер караш») исеме белән бастырган беренче мәкаләсендә (1905) ук эшчеләрнең — хезмәт ияләренең бәхетсезлеге, эш башында торучыларның кешелексезлеге, икейөзлелеге, дини укуларның файдасызлыгы, кешене наданлыкта тотуга сәбәпче булуы турында тирән борчылуын белдерә. Бу инде шул чордагы татар мәгърифәтчелеге позициясендә тору дигән сүз. Ш. Камалның поэтик әсәрләре дә мәгърифәтчелек күзлегеннән язылган. Аның шигырьләренең лирик геройлары да «Халыкларның кара каны, мазлумнарның күз яше зур диңгез тәшкил» итүдән тирән әрни («Инде» —1906); гөнаһсызларны арттыручы, Ватанны кайгы йорты ясаучы палачларга, самодержавиегә ләгънәт укый («Халык тавышы» —1906); искелекне, наданлыкны, кешелексезлекне, явызлыкны, ерткычлыкны ләгънәтли, яктылыкка, яхшылыкка, мәгърифәтчелеккә, бәхеткә омтыла, башкаларны да мәгърифәтле һәм кешелекле булырга өнди («Садә» —1906).

Шулай итеп, 1905—1906 елларда Ш. Камал тормышны яхшырту юлын, бәхеткә ирешүне кешеләрнең үзләренең кешелекле һәм мәгърифәтле булуларында күрде. Шуның өчен дә ул халыкны кичекмәстән «Кирәкләрне кулга алырга» — мәгърифәтчелек эшен юлга салу һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрне гуманизм принципларына кору өчен көрәшергә өндәде, бәхетле булуны шушы көрәшнең җиңүендә күрде. Икенче төрле итеп әйткәндә, ул иҗатының башлангыч чорында ук үзенең идея-эстетик карашлары белән Г. Тукай, М. Гафури кебек язучыларга якын торды. Нәкъ менә шундый позициядә торганлыгын раслап аз гына соңрак ул «Нишләргә» исемле шигырендә үзе дә ачыктан-ачык «Тукай кебек буласым килә» дип язды.

Ләкин поэзия Ш. Камалның төп юлы түгел, ә барыннан да элек иҗади эзләнү юлында оперативлыкка бирелү, үз фикере — сүз көче белән мәгърифәтчелекне Тукайча яклап, революцион хәрәкәттә тизрәк катнашырга ашыгу күренеше иде. Аның реакция өстенлек алгач та Петербургтан китүе, шигырьләр язуын туктатуы, туган авылына кайтып балалар укытырга тотынуы нәкъ менә шуны раслаучы бер дәлил булып тора.

Шулай да Ш. Камал язучылык талантының потенциал көченә ия иде. Тик бу көч, нинди генә зурлыкта булмасын, шартлар җитешмәсә — үсми, талантның үзенә әверелә алмый. Ниһаять, 1909 елда Ш. Камал проза әсәре язу ниятә белән кулына яңадан каләм ала. Аңа мондый адымны ясауда М. Горький әсәрләре остазлык ролен үти. Күрүебезчә, Ш. Камал үзенең мәкаләләрендә һәм

шигырьләрендә бәхетсезлекнең сәбәпләрен, башка бик күп мәгърифәтчеләр кебек үк, наданлыктан, ерткычлык инстинктларына юл куелудан дип уйлый иде. Наданлыкның, ерткычлык инстинктларының үзләреннең нәрсә аркасында булуларын исә аныкламаган иде. М. Горький әсәрләре аны менә шулар турында җитди уйландыручы чыганакларның берсе булды. Бөек рус әдибенең «Челкаш», «Извозчик», «Бер йолкыш», «Архип бабай һәм Ленька» кебек хикәяләрдә, «Коновалов», «Макар Чудра», «Элекке кешеләр» исемле повестьларда капитализм тәртипләренең, хосусый милекчелекнең хезмәт ияләрен ничек тормыш төбенә төшерүләрен һәм зәгыйфьләтүләрен, ничек ерткыч һәм хосусый милекче рухында агулауларын җанны тетрәтерлек картиналарда хөкем итүе аңа үрнәк күрсәтте. Ш. Камал да әнә шундый идея-эстетик юлдан китте. Бу юл аның талантының иң көчле ягы да иде. Нәкъ менә шуңа күрә дә ул үзенең «Уяну» исемле беренче хикәясе белән үк укучыларның, әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә тартты.

К. Маркс һәм Ф. Энгельс «Коммунистик манифест»та пролетариатның стихияле тормыш белән яшәгән — каты изелү сәбәпләрен аңламаган, сыйнфый ачуын кемнән алырга белми газапланган, станокларны ватып, үзара кыйнашып ачуын чыгарган чорын «сыйныф үз эчендә» дип, ә изелүе сәбәпләрен аңлап, изүчеләргә каршы бердәм көрәшүе дәверен «сыйныф үзе өчен» дип билгелиләр. М. Горький «Ана» романында пролетариатның «сыйныф үз эчендә» дәверен Михаил Власов образында, ә «сыйныф үзе өчен» чорына күтәрелүен Павел Власов, аның иптәшләре һәм анасы Пелагея Ниловна образларында зур чынлык-художестволылык көче белән сурәтләде. Ш. Камалның мондый киң диапазонлы гомумиләштерүләр ясарга әзерлеге юк иде әле, аның тормыштан туплаган материалы да Михаил Власов образы белән аваздаш иде, шунлыктан әдип Михаил образына салынган идея йогынтысы белән чикләнде (ә романның революционер образларыннан алган тәэсире буенча соңыннан «Тау атканда» романын язды).

«Уяну» хикәясенең герое Муса яшьлегендә, егет чагында һәм Гафифә белән никахлашуының беренче елларында йомшак табигатьле, нечкә күңелле булган, Гафифәгә карата яхшылык кына эшләгән. Әмма тегермән эшчесе булып эшләгәндә ул каты изелә, кимсетелә. Шул җирлектә туып торган сыйнфый ачуын кая куярга белми газаплана башлый һәм... кайгысын, җан ачуын басу ниятe белән хәмер эчеп исергәч, үз-үзен белешмичә күңелендә кайнаган сыйнфый ачуын сәкләле хатыны Гафифәне кыйнауга чыгара. «Уяну» дигән исем исереклектән айну мәгънәсендә генә түгел, геройның үз хатасын аңлавы (гуманистик асылына кайтуы) мәгънәсендә дә алынган. Хикәянең умыртка сөяген тәшкил итүче бу момент психологик планда гаять тәэсирле итеп бирелә!

«Гафифәнең кан эчендә сыланып ятуы, шунда да Мусага якын итеп эндәшүе, Мусаның йөрәген тагын да тирәнрәк дулкынландыра, телгәли. Анда вакытлыча туган вәхшилек инстинкты юкка чыга, аның күңеле нечкәрә, кешелеклелек һәм кечелеклелек тойгылары белән тулып таша башлый:

— Гафифә, ни өчен минем битемә төкермисең? Ни өчен миңа карыйсың? Үзеңне бу хәлгә китергән залимга эркәң белән әйләнмисең? Мин бит сине золым иттем, хаксызга рәнҗеттем, башыңны ярдым, миңа булган мәхәббәтеңне хакламадым, аяк астына бастым, бән — залим, бән — вәхши, бән — явыз... бән...» диде Муса, артык сүз әйтә алмады, үксеп-үксеп елый иде... үбеп-кочып, җан сулышы илән аның кулларын җылытмакчы була иде» («Шура» журналы, 1909 ел, 12 сан, 383 бит).

Табигате белән кыргый, ерткыч кешеләр үзләреннең эшләгән явызлыклары өчен үкенми, киресенчә, аңардан тәм таба, ерткычлыкны өзлексез рәвештә эшләп торучан була. Муса ерткычлыкны бер генә тапкыр эшли, шунда да үзен-үзе гафу итә алмыйча чиксез газапланып акылыннан яза.

Димәк, ул кешелекле. Гафифә дә шундый. Ш. Камалның шигырьләр язгандагы карашы буенча, алар бәхетле булырга тиеш иде, ләкин бәхетсезлекнең дә иң соңгы хәленә — фаҗигагә очрадылар. Капитализм чынбарлыгының мәлкәтсез шәхесне җимерүчән сыйфатын аңлау һәм М. Горькийга иярү аркасында Ш. Камал иске карашы белән каршылыкка керде, дәресрәге — идея-эстетик яктан бер баскычка югары күтәрелде. Нәтиҗәдә, ул «Бәхетле булу өчен нишләргә?» дигән әлеге сорауга түгел, ә «Капитализм җәмгыятендә төшемле эш табып, намус белән

хезмәт итеп тормышны рәтләп, бәхеткә ирешеп буламы?» дигән сорауга җавап эзли башлады. (Аның «Әүвәл-әүвәл заманда», «Бәхет эзләгәндә» дигән хикәяләрен карагыз.) Бу сорауга җавапны Ш. Камалга үз күргәннәреннән һәм кичергәннәреннән дә табарга мөмкин иде. Ул үзе дә 1900 елдан алып бу хикәяләрне язуга керешкән арада бик күп, бик газаплы нужа күреп өлгерде. 1900 елда тимер юлда эшләгәннән соң Ләбәҗә мәдрәсәсендә дини-схоластик укудан сүрелеп, патша Россиясендә бәхет табуына өметен өзеп, бәхетне чит илләрдән — Төркиядән, Мисырдан да эзләп карады. Стамбулда ул «Дарельмөгаллимин» исемле мөгаллимнәр әзерли торган мәдрәсәдә, ә Каһирә шәһәрендә пансионда укыды. Ләкин аларда бирелгән белемнең дә тормыш өчен яраксыз булуын аңлап, Россиядә революция хәрәкәте башлануын ишетеп, 1902 елда туган иленә кайтты; яңа шартлар тудырган өмет белән бәхетне Россия буйлап яңадан эзләде. Каспий диңгезе буенда балык тотучы, Днепропетровскийның күмер шахтасында шахтер-забойщик булып эшләде. Эшчеләрнең тормыш-көнкүрешләре белән якыннан танышты, моң-зарларын ишетте, эшчеләр, шул исәптән үзе белән шахта хуҗалары арасындагы социаль аермалыкларны, байлык белән хәерчелек арасындагы капма-каршылыкны күрде. Эксплуатацияләнүнең авыр газабын җилкәсендә кичерде. Аннан Петербургта, туган авылында эшләү... Кайда гына булмасын, нинди эшләрне генә башкармасын — бәхет аны читләп үтте. Икенче төрле итеп әйткәндә, ул үзе мәгърифәтле, дә, гуманлы да иде, җитмәсә, типсә — тимер өзәрдәй ир буларак, еш кына тәүлегенә хәтта ундүртәр сәгать тырышып эшләде, ләкин барыбер тормышын матурайта, ярлылыктан котыла алмады. Ш. Камалга сыйнфый аермалык турындагы карашын киңәйтә төшәр, бәхетне социаль тигезсезлектән чыгып бәяләр, үз кичергәннәрен башка хезмәт ияләре язмышына кушып нәтиҗә ясар өчен җитәрлек фактлар инде болар. Художник карашында бәхет реаль мөмкинлеген югалта, хезмәт ияләре өчен тормышта була торган нәрсә рәвешендә түгел, ә хыял иткән нәрсә рәвешендә генә күренә башлый. «Әүвәл-әүвәл заманда» дигән хикәя (1910 ел) язучының, Оренбургка күчеп, «Вакыт» газетасында бераз эшләгәч, шундый бер тойгы кичергән, шундый бер карашка килгән булуын бик ачык күрсәтә. Бу хикәядә Ш. Камал хезмәт халкы өчен чын бәхетнең булмавын сурәтли һәм шуның белән ул иске Россиядә тормышны яхшырта алырлык хаклы хезмәтнең булмавын раслый: «Алар икәү иделәр. Берсе озынча буйлы, сирәк сакаллы, урта яшьле ябык бер кеше, икенчесе егерме яшьләрендә таза гына гәүдәле бер егет иде. Көймәче карт күбрәк аңарга карап сөйли иде:

— Хәзер инде, энем, ул бәхет дигән нәрсәне эзләп маташырга да ярамый: ул инде юк,— диде көймәче».

Менә шул рәвешчә, димәк бәхет һәм бәхетсезлек проблемасы язучы иҗатында, турыдан-туры һәм аңлы рәвештә, капиталистик хезмәт шартларының нәтиҗәсе итеп яктыртылу баскычына күтәрелә.

Хезмәт халкы өчен бәхетнең булмавында капиталистик хезмәт шартлары һәм эксплуататорлар гаепле. Мондый фикергә килү язучыда хезмәт ияләрен кирәгеннән артык эшләүләре, ә эш хакын гаять аз алулары аркасында бәхетсезлектә яшәүчеләр итеп күрсәтү теләгең уятты. Бу теләгең ничек тәмәлгә ашыру алымнарын һәм осталыгын ул М. Горькийдан өйрәнде.

Әмма шуны да әйтергә кирәк: Ш. Камал М. Горький иҗатын өйрәнгәндә механик юл тотмады, ә иҗади рәвештә эш итте. Горький чагылдырган аерым мотивларны икенче яктан үстереп, оригиналькә омтылды.

«Козгыннар оясында» повесте эшчеләрнең аң ягыннан үсә баруларын чагылдыру белән әһәмиятле. Менә, мәсәлән, образ буларак Насрый. Ул Мусадан шактый аерыла. Ләкин анда да каты изелүдән туган ачу бар. Ул да, Муса кебек үк, кайгысын басу, күңелен ачу ниятә белән исерткеч эчә. Ләкин инде ул, исерек хәлдә дә изелүдән туган ачуын теләсә кемгә карата чыгармый, киресенчә, Госманга яхшылык эшләргә йөри; забой астында калган иптәшләрен җылы сүзләр һәм хисләр белән искә ала. Ул — дусны дошманнан аера белүче кеше. Насрый кемнәрнең көч түгеп, кемнәрнең көч түкмичә акча алуларын да бик яхшы аңлый: димәк, ул «Сукбай»дагы үз бәхетсезлеге өчен кемнәрне сүгәргә белми баш ватучы Гали дә түгел инде. Шулай да язучы биредә дә әле, тормышның авырлыгы,

геройларының бәхетсезлеге турында тиешле гомумиләштерүләр ясый алмады, ничек бәхеткә ирешергә мөмкин булуын күрсәтә алмады.

Революцион хәрәкәт яңадан күтәрелә башлагач, аның тәэсирендә Ш. Камал эшчеләрнең эш хакы түбән булуга, тормышларының начарлыгына зарлануларын, ризасызлык белдерүләрен ачыктан-ачык һәм кыюрак әйтә башлады. Шуның белән бергә, анда сюжетларны эшчеләрнең бәхетсезлегендә капиталистик хезмәт шартлары гаепле булуын аңлата алырлык рәвештә оештыру, образларны типик хәлләргә куеп сурәтләү осталыгы үсә төште. Менә аның «Бәхет эзләгәндә», «Чит илдә» дигән хикәяләре. Боларда автор уңай эшче геройларының аянычлы хәлдә яшәүләрен дә, трагик үлемнәрен дә капиталистик хезмәт шартларының коточкыч авыр булуы белән аңлата. Шул ук вакытта бу әсәрләрдә инде без уңай геройларның капиталистик хезмәт шартларына ризасызлык белдерүләрен, ягъни бик әһәмиятле яңа сыйфатлар үзләштергәнлекләрен күрәбез. Язучы бәхетсезлекнең төп сәбәбе итеп хезмәтнең авыр һәм гаять түбән бәяле булуын ала, шуны геройларының өметләренә капма-каршы торган бер нәрсә итеп һәм зур осталык белән, психологик аспектта тасвирлап күрсәтә.

«Чит илдә» хикәясенең геройлары көрәкне комга батырган саен үзләрен бәхеткә бер адым якынайган кебек хис итәләр. Бу оптимизм аларны «Уяну»дагы Муса, «Сукбай»дагы Гали, «Әүвәл-әүвәл заманда»гы ишкәкче һәм хәтта «Козгыннар оясында»гы Насрый образларыннан да шактый ныклы аера.

«Эшлибез! Өмет эшләтә... шатланып эшлибез. Гүя җәй башына акчабыз да була... хәтта инде ул вакыт бер дә җитешмәгән җир булмый, бар сәгадәт безне каршы алырга гына көтә...» — дип хыялланалар алар.

Димәк, «Чит илдә» хикәясендә, бер яктан, уңай геройларның, икенче яктан, Ш. Камалның үзенең тормышка һәм язмышка газап белән караудан өмет һәм шатлык белән карауга күчә башлавы билгеләнә.

«Бәхет эзләгәндә» һәм «Чит илдә» хикәяләреннән соң инде Ш. Камал, билгеле бер эзләнү дәвере үтеп, революция хәрәкәтенең шифалы җиле астында, бәхетнең барлыгын, ләкин аны табу өчен төрле милләт эшчеләренең үзара берләшергә, туганлашырга, гомуми мәнфәгать өчен көрәшергә тиешлеген аңлый һәм шул җирлектә «Акчарлаклар» повестен иҗат итеп, моңа кадәр күрелмәгән уңышка ирешә.

Әгәр моңа кадәр Ш. Камалның күп кенә хикәяләрендә бәхет һәм бәхетсезлек проблемасы хезмәткә, гуманизм идеяләренә бәйләнешле рәвештә яктыртылса, «Акчарлаклар» повестенда инде хезмәт шартларының, бергәләшеп эшләүнең һәм үзара ярдәмләшүнең эшчеләрдәге иҗтимагый мәнәсәбәтне, сыйнфый карашны һәм яшьләр арасындагы мәхәббәтне билгеләүдәге рольләре сурәтләнә. Монда эшчеләр хезмәт процессында, тормышның ыгы-зыгысы эчендә бердәм коллектив булып чыныгучылар итеп тасвирлана. Повесть геройлары үзләренең уй-тойгылары, омтылышлары белән дә, художестволы бирелешләре ягыннан да Ш. Камалның моңа кадәрге хикәяләрендәге, шул исәптән «Чит илдә» хикәясендәге геройлардан да байтак югары торалар. «Чит илдә» хикәясе геройларының бәхеткә өметләре үзара ярдәмләшеп, ат кебек эшләгәндә генә нәтиҗәле булыр дип ышанудан туган тойгы иде. «Акчарлаклар» повесте геройларының бәхеткә өметләре исә үзара ярдәмләшүгә һәм бергәләшеп гомуми мәнфәгать өчен явызлыкка каршы көрәшүгә әзер торудан туган актив һәм сыйнфый тойгы.

Бердәм коллективны төшкил итүчеләрдән Шәрәфине, Гарифны һәм Газизәне язучы игътибар үзәгенә куя. Бу образларда автор үзара аралашу һәм бергәләшеп, ярдәмләшеп эшләү җирлегендә эшчеләрдә сыйнфый аң һәм дуслык тойгыларының ничек үсә баруын, эшчәнлек һәм батырлык, тыйнаклык һәм гаделлек кебек сыйфатларның ничек формалашуын шактый калку һәм истә калырлык итеп ача.

Әгәр язучы Шәрәфинең эшчеләр арасындагы гаделлекне, татулыкны үстерү турында кайгыртуын, сыйнфый аң ягыннан формалашу процессы кичерүен, милекчелек психологиясеннән арыну ягына таба юл тота башлавын чагылдыруга басым ясаса; Гарифның инде йөзгә-буйга матур, эштә арысландай батыр, бал корты кебек эшлекле, ә мәхәббәттә кристалл шикелле саф һәм гаять тыйнак булуын һәм, шундый булып та, капитализм шартларында бәхеткә ирешә алмавын күрсәтүгә басым ясый. Газизәне исә автор матур, үтә тыйнак, акыллы, кешелек-

ле, эшлекле һәм «Уяну»дагы Гафифәгә, «Сулган гөл»дәге Камәргә, «Козгыннар оясында»гы Мәрьямгә караганда аңлырак, булдыклырак бер кыз итеп сурәтли. Газизәнең Гарифка мәхәббәте капитализм шартларында тормышка ашмый, татлы хыял, үкенечле хәл генә булып калган тойгы рәвешендә укучыны тирән дулкынландырырлык, җилкендереп куярлык итеп бирелә. Гомумән, повестьта геройларның художестволы бирелеше бик матур. Монда сюжет гадилеге белән дә, үтә табигыйлеге ягыннан да игътибарны үзенә тарта. Табигать күренешләрен, аеруча диңгез стихиясен язучы үз геройларының уй-тойгыларын һәм бер-берләренә мөнәсәбәтләрен ачуда тәэсирле картина итеп файдалана.

Шулай итеп, язучының күп кенә уңай геройларындагы кешелеклелек һәм явызлык, бәхетлелек һәм бәхетсезлек, мәгърифәтчелек һәм мәхәббәт мотивлары «Акчарлаклар» повестендагы уңай геройларда да дәвам ителә. Ләкин повестьта инде бу мотивларның хәл ителеше, хикәяләрдә хәл ителешенә караганда, бик күпкә уңышлы. Әгәр Ш. Камал үзенең хикәяләрендә: гуманлылык, мәгърифәтчелек кешегә бәхет китерә, ә явызлык һәм наданлык кешене бәхетсезлеккә төшерә дигән карашын образлар аша җәмгыятьнең барлык кешеләре өчен дә яраклы бер нәрсә итеп аңлатырга тырышса, «Акчарлак»лар повестенда инде ул моңа омтылмый. Киресенчә, ул монда һәр геройны, типик шартларга куеп, аның сыйнфый хәле, дөньяга карашы һәм характер үзенчәлеге белән конкрет гәүдәләндерә, явызлыкны-гуманлыкны, бәхетсезлекне һәм бәхетлелекне сыйнфый аермалыктан һәм мөнәсәбәтләрдән чыгып билгели.

Димәк, Ш. Камалның хикәяләрендә аерым-аерым чагылып киткән күп кенә мотивлар «Акчарлаклар»да билгеле бер дәрәҗәдә тупланып, яңа мотивлар белән баетылып һәм үстерелеп бирелә ләр. Монда бәхет материаль яктан да, рухи яктан да берлектә карала. Ә инде эшчеләрнең сыйнфый аермалыкны социаль тигезсезлекне аңлаучылар һәм үзара бер гаилә кешесе кебек дуслашып китүчеләр рәвешендә бирелүе повестька тагын бер нур өсти.

Әгәр Ш. Камал «Акчарлаклар» повестенда уңай эшчеләр образларын тудыруда зур уңыш казанса, «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясендә ул сатирик кире типларны эшчеләр әхлагы күзлегеннән фәш итүдә зур иҗади уңышка иреште. Бу комедиясенә кадәр Ш. Камал әле эксплуататорларның хезмәт кешеләре бәхетен урларга маташканда хезмәт кешесе тарафыннан җиңелүен, хурлыкка калдырылуын бер әсәрендә дә яктыртмаган иде. «Хаҗи әфәнде өйләнә»дә инде ул менә шул нәрсәне эшләде. Атап әйткәндә, бу комедиядә карт бер кадимче татар сәүдәгәренең, байлыгын һәм динне файдаланып, япь-яшь бер кызны икенче хатынлыкка алырга маташуында кызның туган-тумачалары тарафыннан адәм мәсхәрәсенә калуы — үз карчыгына «өйләнүе» гаять зур осталык белән күз алдына бастырыла.

Шулай да... Ш. Камалның революциягә кадәрге әсәрләре аның үзенең шул чордагы идея-эстетик карашларын тулысынча чагылдырып бетерә алмыйлар. Революцион хәрәкәтнең яңадан күтәрелеше чорында, аеруча февраль буржуаз һәм Октябрь социалистик революцияләренә әзерлек елларында язучының идея-эстетик карашларында зур уңай үзгәрешләр булды. Мәсәлән, 1916 елда Ш. Камал үзенең «Кечкенә фельетон» дигән фельетонында («Вакыт» газетасы, 31 январь, 1916 ел) «Бөтен дөнья пролетарлары, берләшегез!» дигән революцион лозунгны цитата итеп китерде һәм аның мәгънәсен кайнар яклады.

Әмма аның үзендәге шундый яңалыкка, белем казанышына таянып эшчеләрнең үз хәлләрен яхшырту, политик азатлыкка ирешү өчен эксплуататорларга, капиталистик төзелешкә каршы ничек көрәшүен художество әсәрләрендә күрсәтә алмавы, аның гаебе генә түгел, ә бәлки бәласе дә иде. Икенче төрле итеп әйткәндә, Ш. Камал яшәгән мөхитнең революцион мөхит булмавы, анда каты цензураның хөкем сөрүе, марксистик әсәрләрне укырга, революцион хәрәкәтне өйрәнергә мөмкинлек булмау сәбәпче иде. Ә революцион хәрәкәт Ш. Камал яшәгән мөхиткә барып җиткәч һәм тәэсир ясагач, Ш. Камал бернинди икеләнүсез, революциягә хезмәт итүгә күчте, типография эшчеләре белән бергәләшеп, типография хуҗаларына каршы көрәш алып барды.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң инде Ш. Камалның идея-эстетик карашлары марксизм-ленинизм фәне һәм социалистик төзелеш уңышлары яктылыгында үсте. Ләкин бу үсеш тә иҗади эзләнүләрсез генә бармады.

Ш. Камал, җиң сызганып, яңа тормышны өйрәнергә тотынды. Шунысы характерлы, ул тормышны, башка берәүләр кебек, читтән күзәтү юлы белән генә түгел, ә башлыча, производствода, социалистик төзелештә нинди дә булса бер эш башкару юлы белән өйрәнде. Ул Чебенле авылы коммунасында коммунар, «Юл», «Сабан», «Кызыл Татарстан» газеталары редакцияләрендә әдәби сотрудник, Оренбург балалар йортында мөдир һәм тәрбияче булып эшләде. Болай эшләү белән тормышка бик тиз һәм тирәнрәк үтеп керергә мөмкин. Шуның өстенә Ш. Камал революциядән соң марксизм-ленинизм әдәбиятын, күренекле художество әсәрләрен укый-укый эстетик карашларына яңалыклар өсти барды, көннең кадагына сугa, массаны социалистик төзелештә актив катнашырга өнди торган бик күп ялкынлы мәкаләләр язды. Әнә шул формада материал туплаганнан соң, ул әдәби әсәрләр язу эшен дәвам итәргә кереште. Язучылык осталыгын үстерү буенча тәҗрибә туплаганда, ул революциягә кадәрге үзенең һәм, гомумән, күренекле классик язучыларның уңай традицияләрен дә бик нык исәпкә алды һәм иҗади файдаланды. Әнә шулай эзләнүе һәм хәзерлек булдыруы аркасында, ул совет чоры тематикасын үзләштерүдә һәм әсәрләрендә гәүдәләндерүдә революциягә кадәрге демократик әдәбияттан килеп кергән язучылар арасында алдынгылар сафына чыкты. Ул чагыштырмача тиз арада революциягә кадәр үк кызыксына килгән бик күп сорауларына дөрес җавәплар тапты, яңа тип әсәрләрнең эчтәлеге һәм формасы, иске культура мирасы буенча төпле караш булдыру, башкаларга файдалы киңәшләр бирә алу югарылыгына күтәрелде. Берничә хикәя язып, калэмен үткенләндерә төшкәч, партиянең әдәбият турындагы 1925 елгы карарыннан соң, татар әдәбияты тарихында беренче буларак социалистик революция темасына роман язып, зур гына уңыш казанды. Бу романда Ш. Камал татар эшчеләренең һәм большевикларының партия комитеты җитәкчелегендә социалистик революцияне хәзерләүгә ничек катнашуларын сурәтли.

Романның «Таң атканда» дип аталуы да, анда «Акчарлаклар» повестендагы берничә геройның үстерелеп бирелүе дә — берсе дә очраклы түгел. Повестьта Гариф һәм Шәрәфи бәхетле булуны берләшүдә, эштә бер-береңне яклауда күрүчеләр итеп бирелгән иде. Ләкин әле алар бәхет өчен актив көрәшүчеләр — революционерлар түгел иде. Романда инде без аларның бәхеткә ирешү өчен забастовкаларда катнашуларын, социалистик революциягә хезмәт итүләрен күрәбез. Димәк, бу образларны язучы романга үзенең революциягә кадәрге иҗатында күтәргән җитди бер мәсьәләсен чишеп төгәллəү өчен керткән һәм аны уңышлы төгәлләгән дә. Ш. Камал монда Шәрәфи, Гариф образларында крестьяннарның промышленность тармакларында эшләү процессында хосусый милекчелек психологиясеннән арынып пролетарлашуларын, революционлашуларын һәм большевиклашуларын тарихи закончалыклы һәм әһәмиятле күренеш дип карауга, художестволы хәл итүгә күтәрелде. Шулай итеп, Ш. Камалның XX йөз башларындагы шигырьләрендә һәм хикәяләрендә чагылган мәгърифәтчелек карашлары революциядән соң «Таң атканда» романында фәнни карашка үстерелде. Монда инде язучының гуманизмы да сыйфатый тенденциялелек һәм ялкынлы революционлык белән сугарылган. Мохтар образына салынган идея-эстетик карашларны гына күздә тотканда да «Таң атканда»да Ш. Камалның идея-эстетик яктан никадәр нык үскәнлеген, революцион сикереш ясаганлыгын бик ачык күрергә мөмкин.

...Кыздырма мыскыл итеп йөрәкне,
Яндырырмын, дошман, дөньяңны!
Сыкранып, елап өзмә үзәкне,
Дустым, төзәтермен ояңны.

Эксплуататорларга карата ачы нәфрәт, хезмәт халкына карата кайнар мәхәббәт бу шигырьдә бик матур гәүдәләндерелгән. Нәкъ менә шуңа күрә дә Габдулла ул шигырьне сөйләгәндә, Мохтар рәхәтләнеп утыра, шигырьне кайнар хуплый. Бу очраклы эпизод түгел. Үзенең тормыш максатын чагылдырганга күрә әнә шу-

лай кайнар хуплый Мохтар бу шигырьне. Ул үзе көрәшкәндә нәкъ менә дошманның дөньясын туздыру, дусының — хезмәт иясенең тормышын яхшырту өчен көрәшә.

Большевик өчен революция эшенә бөтен барлыгы белән бирелгән, революцион максатлар өчен үз-үзен аямый торган булу хас. Мохтарны шундый батыр йөрәкле итеп тасвирлауда Ш. Камал үрнәкне үзенең остазы М. Горькийдан ала. «Ана» романында Павел Власов, төрмәдә ятканда Рыбин һәм башкалар белән бергә качып китәргә мөмкинлеге булса да, судта революция дошманнарын фаш итәргә, большевикларның халык бәхете өчен көрәшүчеләр икәнлеген үз урнәгендә күрсәтергә уйлаганлыктан — качмый. Мохтар да, полиция тарафыннан кулга алыну ихтималын белгәндә дә, билгеләнгән забастовкага сигнал ролен үтәү максаты белән, качып китми. Шуның белән ул да Павел Власов шикелле гомуми эш өчен үз-үзен аямый торган большевик булып күз алдына килә. Бу эпизод үзе генә дә Ш. Камалның революция юлында батырлык күрсәтүне, үз-үзеңне аямауны матурлык итеп аңлавы турында сөйли.

Әйе, хәзер инде Ш. Камал өчен матурлыкның асылы — иске дөньяны җимереп, эксплуататорларны бетереп, яңа тормыш төзүдә, халыкны бәхетле итә торган яңа шартлар тудыруда. Хәзер инде язучы карашында халыкның якты киләчәге өчен сыйнфый дошманга каршы көрәшүләр, бу көрәштә кайгы-шатлык кичерүләр, авырлыкка түзүләр, үлем куркынычын җиңүләр — барысы да үзләре бер гүзәллек, үзләре иң зур кешелеклелек һәм бәхет.

Мохтар, образ буларак, шактый тәэсирле итеп бирелгән. Укучыны дулкынландыруга ирешү өчен Ш. Камал аның я бер төркем милләтчеләр белән бәхәсен контраст буяуларда кискен көрәш дәрәҗәсенә күтәреп, урыны-урыны белән юмор кыстырып тасвирлый; я кайгысын шатлык, шатлыгын кайгы белән чиратлаштырып сурәтли.

Ә «Таң атканда» әсәреннән соң язган «Ут» пьесасында язучы сыйнфый сизгер булырга, гомуми мәнфәгать өчен интим тойгыларны йөгәнли белергә кирәклеген әйтергә теләде. Сыйнфый гамьсезлекнең җитәкчене күңелсез хәлгә төшерүен, матур гаилә төзү өчен дөньяга караш берлеге, максатлар уртаклыгы булырга тиешлеген гәүдәләндереп, көчле һәм тәэсирле картиналар тудырды.

Ләкин яңа шартларга җавап булырлык әдәби осталык әдипкә тулаем гына килмәде. Менә «Тәулар» пьесасы. Биредә геройларның сыйнфый сизгер булулары, алдынгы эшчеләр инициативасына таянып җитәкчелек итү игътибар үзәгенә куеп сурәтләнә. Ләкин бу пьесада завод драмасы үзенең яктыртылышында нинди дә булса уңай герой драмасы белән үрелми. Һәм тагын «Козгыннар оясында»гы шикелле, башта киң итеп алынган мәсьәләнең соңга таба тарайтылу, үстерелмәү һәм чишелмәү күренеше дә бар. Атап әйткәндә, монда заводның югары сыйфатлы продукция эшләп чыгаруга сәләтле булуын эш белән исбат итү мәсьәләсе уңай герой язмышына бәйләнешле һәм эзлекле рәвештә художестволы чагылышын тапмый, схематик рәвештә генә бирелә.

Ләкин шуны да әйтергә кирәк, болар егерменче елларда һәм утызынчы елларның башларында «Козгыннар оясында», «Тәулар» драмалары өчен генә характерлы кимчелек тә түгел иде.

Партиянең бөтен ил язучыларын бер оешмага берләштерү турындагы 1932 нче елгы карарыннан соң тирән идеялелек һәм югары художестволылык өчен схематизмга, декларативлыкка, тормышны лаклап күрсәтүгә каршы көрәш гомуми төс алды.

Ә илебез язучыларының Беренче съезды бу көрәшне нәтиҗәле итәрлек чаралар билгеләде, социалистик реализм методының төп принципларын теоретик нигезләде. Менә шуңа күрә дә Ш. Камал язучыларның бу съездын «яктырткыч эз» дип атавы белән бик хаклы иде.

Бу истәлекле һәм әһәмиятле вакыйгалар тәэсирендә әдәбиятта бик күп уңышлы әсәрләр иҗат ителде.

Ш. Камалның «Габбас Галин» драмасы да, «Матур туганда» романы да партиянең 1932 нче елгы карары, илебез язучыларының Беренче съезды яктылыгында кат-кат эшкәртелгән уңышлы әсәрләрдән булды.

«Матур туганда»ның халык тарафыннан яратылып укылуы очраклы хәл түгел. Ул — укучыларны тирән дулкынландырырлык югары художестволы әсәр.

Бу романның укучыларны тирән дулкынландыру көче, барыннан да элек, аның искиткеч реалистик булуында. Ш. Камал бары тик дөреслеккә генә таяна. Монда бер нәрсә дә шик тудырмый, геройлар да, сюжет та, эпизодлар да, хәтта вак-төяк детальләр дә — бөтенесе дә ышандыра. Шуның белән бергә аларның үзара органик бәйләнеше дә, каршылыклар көрәшен тәшкил итеп, үстерелеше дә шулкадәр тормышчан ки, әйтерсең, анда язучы фантазиясенең һәм эшчәнлегенең һичбер төрле катнашлыгы булмаган, әйтерсең, язучы тормышның үзеннән үзе бер вакыйганы күчереп кенә алган. Әсәрнең шундый тәэсир калдыруы ул, һичшиксез, язучының зур осталыгы турында сөйли.

Каршылыклар көрәше күпчелек художество әсәрләренә хас нәрсә. Аның контрастлык белән бирелү очраклары да аз түгел. Әмма «Матур туганда» романында каршылыклар көрәшенең контрастлык белән бирелүе система тәшкил итә. Монда бик күп эпизодлар һәм хәтта детальләр дә бер-берсенә каршы куелып сурәтләнә һәм шул юл белән сюжетның мәгънәви һәм тәэсир көче куертыла, көчәйтелә, экспрессив төсмер ала.

Каршылыклар көрәшенә карата язучының мөнәсәбәте дә контраст буяулы. Автор кулаклар көрәшен я ачы ирония, я көчле сарказм астына ала; ә коммунистлар, коммунарлар көрәшенә исә я хуплавын, я теләктәшлеген белдереп бара.

«Матур туганда» романы тәрбияви яктан да, язучының үзенең иҗади үсешен билгеләү, татар әдәбияты тарихын, аеруча прозасы үсешен ачыклау ягыннан да зур әһәмияткә ия булып тора.

Шулай итеп, Ш. Камал үзенең иҗади эшчәнлеге дәверендә тормышны чикләнгән карашлы мәгърифәтчеләрчә аңлаудан большевикларча, марксистларча аңлауга, коммунистик мораль күзлегеннән бәяләп, фикер йөртүгә кадәр күтәрелде.

Мусадан — Насрый, Насрыйдан — Фәтхулла, Фәтхулладан — Гариф һәм Шәрәфи, Гариф һәм Шәрәфидән — Мохтар Булатов, Мохтар Булатовтан — Габбас Галин, Габбас Галиннан — Каюм, Мәдинә һәм Мостафа. Ш. Камалның идея-эстетик яктан үсешен билгеләүче төп уңай образлар галереясе менә шулар. Бу образлар аша Ш. Камал тормышны газаплы кичереш белән кире кагудан шатлыклы кичереш белән хуплау, бәхетне «юк» дип раслаудан «бар» дип раслау, кешеләрнең бәхетне хезмәт итү юлы белән табарга тырышуларын күрсәтүдән революцион юл белән яулауларын күрсәтү юнәлешендә үсте һәм остарды.

Шулай итеп, Ш. Камалның Рузаевка тимер юлында башланган мөстәкыйль хезмәт биографиясе әлеге тимер юл кебек, Россиянең бик күп почмакларын иңләп, халык биографиясенә тоташты. Бу чагыштыру аның иҗатына да туры килә. Аның мәгърифәтчелек идеяләре белән чикләнгән баштагы иҗади адымнары Эшче темасын, халык тормышын киңрәк, тирәнрәк, бәхет өчен көрәшне төгәлрәк чагылдыра барып үсте. Бу үсеш, җитди иҗади казаныш булып, татар совет әдәбиятының нигез ташларын тәшкил итте, гомумән, совет әдәбиятының бер органик элементы, халыкларның яраткан әдәби хәзинәсе булып китте. Ә мондый иҗат искерүне, тарихтан төшеп калуны белми. Ул халык белән бергә гел алга, гел киләчәккә атлый.

ШӘРИФ КАМАЛ ХАТЛАРЫ

Ш. Камалның Татарстан Дәүләт музеенда саклана торган архивы зур һәм тематик яктан бай. Анда без укучыларга яхшы таныш булган барлык әсәрләрнең кулъязмаларын, аларның вариантларын һәм әдипнең матбугатта басылмаган әсәрләрен дә очратабыз. Шундыйлардан «Алтынчы башня», «Шик», «Ыңгырчак», «Эшләпә» кебек кыска күләмле сатирик сәхнә әсәрләрен, «Хаҗи әфәнде өйләнә» пьесасы нигезендә иҗат ителгән балет либреттосын, Гогольнең «Ревизор»ы тәрҗемәсен күрсәтергә мөмкин.

Боларга тагын әдәбият мәсьәләләренә багышлап төрле елларда язылган мәкаләләрне, күп кенә новелла, хикәяләрнең нигезенә яткан фикерләр тупланган блокнотларны, сирәк кенә булса да язылган көндәлекләрне, нигъмәтьле хатларны кушарга була.

«Вакыт килер, һәр язучыны эчсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле»,— дигән Тукай. Ш. Камал архивы да җитди өйрәнүгә мохтаҗ. Әлхәзергә без укучыларга Ш. Камал архивыннан алынган берничә хатны тәкъдим итәбез.

Дания БАҺАУТДИНОВА.

Хөрмәтле Зәйнәп иптәш Хәмитова! [1]

Хатыгызга шактый кичегеп җавап язам, гафу итегез. Китапны игътибар белән укуыгыз, шуның өстәвенә, язучы белән үзегезнең кайбер килешеп бетмәгән урыннар турында күрсәтмәләр ясап хат язарга вакыт аеруыгыз өчен сезгә чын рәхмәттән башка сүзем юк. Укучы тарафыннан әсәрнең игътибар белән укылуы һәм аның турында яхшы теләк белән фикер белдерелүе һәрбер язучы өчен дә бик күңелле хәл.

Сезнең фикерләрегез, нигездә, дөрес. Матур әдәбият өлкәсендә эшләүче кеше үзенең әдәби әсәрендә сүзләр сайлау һәм җөмләләр төзүдә бик нык игътибар белән эш итәргә тиеш.

Шулай да минем «гөнаһлар» саксызлык-игътибарсызлыктан бигрәк, күбесенчә, үземнең кайбер моментларда аерым фикердә булуыма нигезләнгәннәр дип уйлыйм. Мәсәлән, Казанда басылган әсәрләргә бары Казан тирәсенә хас булган сүзләр генә керергә тиеш дигән фикергә мин кушылып җитмим. Шулай ук кайбер сүзләрне иске булганлыклары өчен генә ташлауны да мин урынсыз дип беләм. Тик бары аларның массага аңлаешлы булулары шарт. «Иҗтиһа» сүзе турында Сез хаклы. Аның урынына башка сүз кулланганда яхшырак буласы. «Тана үгез» — «тәкә бәрән»гә охшашлы кулланыла. «Текте» белән «текәде» — берсе ныграк, икенчесе йомшаграк ике урында кулланылалар. «Биргәнне алмый ди бит кеше!», «Биргәнне алмый диме кеше». Бу ике җөмлә икәүсе ике төрле мәгънә аңлаталар ич.

Инде мин дә Сезне (үзегез әйтмешли, миңа ачуланмагыз тагын) чак кына тәнкыйть итмәкче булам. Сез үзегезнең хатыгызда китапны тышкы форма ягыннан гына тикшереп, эчке ягына кагылмагансыз. Ә ул кирәк иде. Мәсәлән, шундагы вакыйгалар, кешеләр һәм аларның кыланыш, характерлары турында аз гына булса да кайбер фикерләрегезне язсагыз әйбәт булган булыр иде. Сез бәлки икенче бер вакыт табып аны эшли алырсыз?

Мин хәзер «Матур туганда»ның икенче бүлеген язам. Матур әдәбият әсәрләрен игътибар белән укучы, Сезнең кебек культуралы иптәшләрдән миңа ярдәм кирәк. Бу хатыгыз өчен тагын бер кабат зур рәхмәт.

Хөрмәт белән Ш. Камал.

Казань, Островский ул. д. № 15. кв. 2

Хөрмәтле дус Фәрит һәм Гайшә ханым! [2]

Бик кайнар сәламнәр җибәрәм. Минем китү көтелмәгәндәрәк һәм ашыгычрак та булды. Чөнки мин сораган җиргә путевка булмагач башта бармаска чамалаган идем. Ә соңыннан икенче төрле карашка килдем. Шул сәбәптән, киткән чагында күрешеп булмады. Берничә тапкыр телефон шалтыратсам да туры китерә алмадым.

Апрельнең 7 сендә ял йорты Белорус-Балтика тимер юлы белән, Мәскәүдән ике сәгатьлек җирдә. Дорохово дигән станциядән ярты сәгать чамасы автомобильдә килергә. Нарат урманы эчендә матур гына урын. Тормыш бик тын. Эшләү һәм ял итү өчен уңайлы. Теләгән вакытта Мәскәүгә бару да бик җиңел. Ләкин еш йөрергә исәп юк. Шулай да май бәйрәменә барырмын чамасы: күңел вәсвәсәсенә каршы торып булмас төсле. Мин бирегә килгән чакта һава җылы, карлар беткән иде диярлек. Ә тугызынчы төштән соң буран кузгалып, төне буе һәм икенче көн кичкә хәтле күз ачырмаслык карлы давыл дәвам итте. Шулай итеп чирек чамасы кар төшеп, актыгында ник кына катырып җибәрде һәм шул килеш бара. Шулкөйгә икенче кыш ялганып китмәсә ярар дип чак кына куркыбрак торабыз әле әкият.

Хушыгыз хәзергә. Хөрмәт һәм сәлам белән кулларыгызны кысам.

Шәриф.

12/IV-39 ел.

Хат языгыз. Июньнең башына хәтле ял йортында булам. Адрес болай:

Ст. Дорохово Б/Б ж. д.
п/о Ст. Руза.
Дом отдыха писателей
Шариф Камал Байгильдеев.

Асиягә, Сәгыйтькә һәм иптәш Абрамовка бик күп сәлам [3].

Кави дус! [4]

Унҗидесендә җибәрелгән 55 сум гонорар акчасын алдым. Рәхмәт. Яхшы гына поддержка булды. Оятсызлык димәсәң, бер өстәмә альманах җибәрүеңне дә үтенәм. Җае булса гына әлбәттә. Юкса общее положениега карарсың.

Үземнең монда тормыш ярыйсы. Бондюгны бик яратып торам. Көндезләрен цехларда булам. Иртә кичләрен язу белән шөгыльләнәм. Хәзергә әле электән яза башлаган әйберләремне дәвам иттереп, Бондюг турында материал җыйнау белән канәгатьләнәм. Син кайчан отпуска аласың? Кайларга барырга уйлыйсың? Сәрвәр [5] нишли? Гомәрдән [6] ике открытка алдым, «Атака»ның исеменә бәләкәй «возражение» ясап язган идем. «Соңлагансың, агай-эне» дигән. Шулай дигәч килештем. Болай үзе матур исем.

Коммунистлар сәламе белән: Шәриф Камал.

23/VII-30 ел.

Хөрмәтле иптәш Маннапов! [7]

18 нче мартта язган хатыгызны 24 нче мартта алган идем. Ләкин ике айдан артык вакыт үтте — җавап яза алмадым. Гафу итәрсез дип уйлыйм. Чөнки мин сезгә, үткән 37 нче елны Әстерхан газетына язган хатыма елдан артык вакыт эчендә җавап ала алмаган идем... Бу үпкәләү түгел, әлбәттә. Тик бары бәләкәй шаяру дип кара. Чынында озак җавап яза алмавыма башка вак-төяк сәбәпләр булды. Гафу ит, яме?!

«Забойчы Булат» пьесалар җыентыгының баш өлешенә кертелү зур гына уңышлы хәл. Тагын да матур һәм көчле әйберләр бирергә тырыш. Син аны булдыра аласың. «Машинист» дигән әсәреңә үткән ел Мәскәү адресы белән рецензия җибәргәннәр (Разин), «Шаулы ташкын» турында 8/V ндә җавап язганнар.

«Дулкыннар арасында» чират көтә диләр. Кыскасы, журналда «Совет әдәбияты» редакциясенең («Сиваш» авторы Разин) бәя бирүе бик уртача. Ләкин аңар карап син рухыңны һич тә төшермә. Киресенчә, алга үрмәлә. М. Горькийны, Чеховны, Л. Толстойны һәм башка классикларны мөмкин кадәр күбрәк һәм дикъкать белән укырга тырыш. Иҗат эше, бигрәк тә социалистик реализм нигезендә үтә җитди (серьезный) хезмәт икәнлеген исеңдә тот. Берничә әсәреңә басылып чыгу гына әле матур әдәбият өлкәсендә һәм, гомумән, матур сәнгать мәйданында зур художник исемен күтәрергә хокук бирмәгәнлекне онытма күрмә.

Ш. Камал.

Татарстан совет язучылары союзы правлениесенә язган хаттан өзек

Иң элек Татарстан совет язучылар союзы правлениесенә минем ижат эшем буенча зур әдәби юбилей үткәргәнлеге өчен чын күңелдән рәхмәтләр белдерәм.

Киң совет җәмәгатьчелеге катнашы белән үткәрелгән ул зур әдәби санлау бәйрәмен, әлбәттә, мин үз хисабыма гына алмадым. Ул санлауны мин бөтен совет әдәбиятына карата бирелгән игътибар һәм аны санлау дип аңладым. Шуның белән бергә бу факт миңа бик нык тәэсир ясады, совет җәмәгатьчелеге каршында үз ижатым турындагы җаваплылык тойгыларын тагын да арттырды.

Әйбер өстендә күбрәк эшләү, аның турында тагын да күбрәк уйлану түземлеген тагын да ныгыта төште. Конкрет алганда бу минем яңа әсәремә («Матур туганда»ның 2 китабына) кагыла. Ул нигездә беткән булуына карамастан мин әле һаман аның өстендә эшлим, һаман да үземә охшамаган урыннарын төзәтәм, яхшыртырга тырышам. Инде, миңа белдерүләренә караганда, елның өченче кварталында Татгосиздатның китапны производствога җибәрүгә мөмкинлеге бар шикелле (кәгазь ягыннан). Шуны күздә тотып мин бу әсәрне июньнең икенче ярты-сында тапшырачакмын...

Ш. Камал.
1940.

Искәрмәләр

1 — Зәйнәп Хәмитова — Ш. Камалга хат язган әдәбият сөюче.
2 — Гайшә һәм Фәрит Хәсәновлар — Ш. Камалның Казандагы якын танышлары.
3 — Асия, Сәгыйть, Абрамов — Хәсәновларның гаилә члennары.
4 — Кави — язучы Кави Нәҗми.
5 — Сәрвәр — язучы Сәрвәр Әдһәмова.
6 — Гомәр — язучы Гомәр Гали.
7 — Маннапов — Донецкида татар телендә чыга торган «Пролетар» газетасының җаваплы секретаре. Әдәби әсәрләр дә язган кеше.

ЛЕНИННЫҢ ТУГРЫЛЫКЛЫ ШӘКЕРТЕ

Сәхибгәрәй Сәетгалиевнең тууына 90 ел

Ялкынлы революционер, Татарстан Халык Комиссарлары Советының беренче председателе Сәхибгәрәй Сәетгалиевнең тууына бу елның февраль аенда 90 ел тула. Аның күп тармаклы эшчәнлеге Казанга гына түгел, Уфа, Екатеринбург (Свердловск), Чиләбе, Златоуст, Самара (Куйбышев), Бәләбәй, Симферополь, Саратов кебек башка шәһәрләр белән дә, Мәскәү белән дә нык бәйләнгән.

Эшче гаиләсендә туып үскән Сәхибгәрәй әле унике яшьлек малай чагында ук, Уфадагы социал-демократлар белән элемтәгә керә. Бу — Россиядә беренче революцион күтәрелеш чоры. 1906 елда, тыелган политик әдәбият саклаганы өчен, яшүсмер Сәетгалиев беренче тапкыр кулга алына. Соңрак, революцион эшкә катнашып киткәч, аны Самарада һәм Златоуст шәһәрләрендә дә берничә мәртәбә кулга алалар.

1916 елның маеннан, патша армиясендә хезмәт итә башлагач, Сәхибгәрәй Екатеринбургтагы солдатлар арасында Ленин идеяләрен таратуда даими эш алып бара. Бусы инде егеткә шәһәрнең яшерен большевистик оешмасы тапшырган бурычны үтәү төсендә башкарыла.

Февральдәге буржуаз-демократик революция җиңгәннән соң, солдатлар унтер-офицер Сәетгалиевне башта — полк Советына, аннары Екатеринбург шәһәренең эшче һәм солдат депутатлары Советына член итеп сайлыйлар. Бу чорда солдатларга партия Үзәк Комитетының һәм Владимир Ильич Ленинның күрсәтмәләрен аңлату, алга куелган бурычларны тормышка ашыру буенча киеренке эш җәелдерелә. Аңлашыла ки: армиянең политик позициясе, солдатларның кайсы якта торып көрәшәчәге социалистик революциянең җиңү-җиңмәвендә хәлиткеч роль уйный. РСДРП(б)ның Екатеринбург комитеты большевик Сәетгалиевкә Уралдагы хәрби частьларда, яңа оештырылган татар-башкорт роталарында агитация һәм пропаганда эшләрен тапшыра. Бу роталар большевиклар белән буржуаз милләтчеләр арасында, мәселмән солдатларының күңелен яулау өчен, бик кискен төстә алып барыла торган көрәш мәйданына әйләнә.

1917 елның августында Екатеринбургта Урал мәселмән сугышчыларының эшчеләр катнашындагы I съезды ачыла. Сәетгалиев съездда РСДРП(б)ның Урал өлкә комитеты исеменнән доклад ясый. Ул үзенең чыгышында татар-башкорт роталары оештырылуның төп максатын аңлата. Мондый роталарның башка милләттәге солдатлардан

һичнинди аерымлыклары булмавына, аларның агитация-масса эшләрен туган телдә алып бару өчен генә кирәклегенә төшендерә. Съезд, бу юнәлештә үзәкләштерелгән җитәкчелек тәэмин итү өчен, Урал өлкә мөселман хәрби Советын сайлый. Сәхибгәрәй Сәетгалиев аның председателе була. Бу Совет Урал буендагы сигез гарнизонның татар-башкортларын берләштерә. Корниловның революциягә каршы оештырылган һөҗүме башлангач, Сәетгалиев татар-башкорт солдатларына мондый сүзләр язылган өндәмә тарата: «...Барыгыз да, моңарчы күрелмәганчә, турыдан-туры яки хәрби милли оешмалар аша, эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Советлары тирәсенә тупланыгыз; аларның чакыруын ишетү белән үк революцияне контрреволюцион элементләр һөҗүменнән саклап калырга әзер торыгыз! Генерал Корнилов яки аның ярченнәреннән ишетелгән бер генә күрсәтмәне дә үтәмәгез!..»

Өлкәдәге мөселман хәрби Советы членнары һәм большевиклар җитәкчелегендәге татар-башкорт роталары Екатеринбургта Октябрь кораллы восстаниесен әзерләүдә зур активлык күрсәтәләр. Власть тулысынча Советлар кулына күчкәч, шәһәрнең Югары Исет районында оештырылган митингта Сәетгалиев ялкынлы сүзләр белән чыгыш ясый. Ул эшчеләрне һәм солдатларны башында бөек Ленин торган Совет хөкүмәтен, һичсүзсез, хупларга, азат тормышны яклауда җаннарны аямый көрәшергә чакыра.

Сәхибгәрәй Сәетгалиев — гомере буе ленинчыл милли политиканы, пролетар интернационализм принципларын тормышка ашыру өчен тырышкан революционер. Аның эшчәнлегендәге бу сыйфат 1918 елда Казанда контрреволюционер милләтче татар буржуазиясе тарафыннан оештырылган Икенче Бөтенроссия мөселман хәрби съездында бигрәк тә ачык чагылыш таба. Сәхибгәрәй бу съездга Урал ягы татар-башкорт эшчеләре һәм солдатларының делегаты буларак катнаша. «Хәрби шура» җитәкчеләре «Идел—Урал штаты» дигән буржуаз дәүләтне законлаштырырга азапланалар. «Хәрби шура»ның бу юнәлештәге «эшчәнлеге» Совет властена шактый җитди куркыныч тудыра. Аның карамагына Идел буе һәм Урал ягының төрле шәһәрләренә урнашкан 65 меңләп кораллы солдаты булган татар полклары керә. Өстәвенә, ул Украинадагы, башкортлардагы, Төркестандагы, чуваш, мари, удмурт якларындагы кара көчләр белән тыгыз элемтәдә тора. Рус буржуазиясенең урындагы контрреволюцион элементлары да «Хәрби шура» тирәсенә елышалар. Алар: «Большевиклар патшалыгы булганчы, татар ханлыгы гына булсачы!» — дип тәкърарлыйлар.

Сәхибгәрәй Сәетгалиев, Камил Якубов һәм Хәсән Урманов җитәкчелегендәге аз санлы большевик делегатлар бу съезднең трибунасын буржуаз милләтчеләрне фаш итүдә файдаланалар. Милләтчеләр, илдәге бөтен мөселманнарны берләштерергә, дигән максат белән чыккач, Сәетгалиев ленинчыл партия карашын ачыктан-ачык аңлатып бирә:

— Без,— ди ул,— кешеләрне русларга да, татарларга да бүлеп карамыйбыз. Без — большевиклар!

Халыкны милләтчелек баткаклыгына сөйрәргә азапланган съезд, эшчеләрнең актив катнашлыгы белән, куып таратыла, «Хәрби шура» бетерелә. Сәетгалиев бу кискен көрәштә дә үзен социалистик революциягә тугрылыклы, сугышчан рухлы интернационалист итеп таныта. Партиянең Казан губкомы аны Казанда калдырырга карар кыла һәм аңа милли эшләр буенча комиссарлык вазифасын тапшыра.

Ул чор газеталарында, архив документлары арасында Сәхибгәрәй Сәетгалиевнең күп санлы чыгышлары саклана. Алар барысы да бу большевикның барыннан да бигрәк халыклар дуслыгын ныгыту өчен җан аямый көрәшкәнлеген дәлилләр. 1918 елның мартында Казан губернасы крестьяннарының IV съездында да Сәетгалиев күп милләтле крестьян халкын бердәмлеккә, дуслыкка өнди:

— Без бер-беребезгә, бу — мөселман, монысы — урыс, бусы — яһүд, дип карамыйк! Эшчеләр, русмы ул, татар баласымы — бервакытта да бер-берсенә каршы сугышмаячак, чөнки аларның төп мәнфәгатьләре уртак,— дип аңлата.

Гражданнар сугышы елларында Сәетгалиев халыкны акгвардиячеләргә һәм чит ил басып алучыларына каршы көрәшкә өндәп, күп көч куя. 1918 елда ул партиянең Уфа, Бәләбәй, Аксаков, Самара шәһәрләрендәге мөһим эшләренә катнаша. 1918 елның октябренда Сәетгалиев, РКП(б)ның татар-башкорт оешмалары Уфа губернасы бюро председателенең урынбасары буларак, Көнчыгыш халыклары коммунистик оешма-

ларының II Бөтенроссия съездына делегат итеп сайлана. Бу съездда аны РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы председателе дәрәҗәсенә күтәрәләр.

Шул чордан башлап, Сәхибгәрәй Сәетгалиев илкүләм мәшәкатьләрнең үзәгендә кайный һәм турыдан-туры партиянең В. И. Ленин җитәкчелегендәге Үзәк Комитетында эшли башлый. Владимир Ильич аның хезмәтләренә ифрат дәрәҗәдә игътибарлы була, кирәк чакларда, ярдәм дә итә. Сәетгалиев исә, үз чиратында, юлбашчының Көнчыгыш халыклары белән эшләгәндә, гомумкоммунистик теориягә һәм практикага таянырга, шул ук вакытта, әлеге халыклар аңында һәм тормышында сакланып калган урта гасыр артта калганлыгын да истә тотарга кирәк, дигән тәгълиматына таяна.

Сәхибгәрәй Сәетгалиев — Татарстан АССРның иң актив оештыручысы. Ул, бөек Ленинның тәкъдиме буенча, РКП(б) Үзәк Комитетының һәм Халык Комиссарлары Советының Татарстан республикасын оештыру турындагы декрет проектын төзү комиссиясе составына кертелә. Эшчәнлегенең бу чорында Сәхибгәрәй Сәетгалиев Татарстанда ленинчыл милли политиканы тормышка ашыру өчен аеруча тырыша. 1920 елның 20 мартында В. И. Ленинга тапшырган бер язмасында Сәетгалиев Бөек Октябрь революциясе аркасында татар халкы ирешкән хәрлекнең әһәмиятен, татар халкы үзенең артталыгын, руслар белән кулга-кул тотынып көрәшкәндә генә җиңеп чыгачагын ассызыклап күрсәтә.

1920 елның 27 маенда Татарстан АССР төзелү турындагы декрет кабул ителә, һәм 8 июньдә РКП(б) Үзәк Комитетының Политбюросы карары нигезендә Сәхибгәрәй Сәетгалиев Татарстан ревкомының председателе постына билгеләнә. 1920 елның сентябрендә ул Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советының беренче Председателе итеп сайлана. Үзенең бу җаваплы вазифасын үтәгәндә Сәхибгәрәй Сәетгалиев яшь республиканы гражданнар сугышы китергән җимереклекләрдән арындыруда, халык хуҗалыгын күтәрүдә, культурасын үстерүдә күп эшли. Татарстанда тар карашлы милләтчеләрнең корткычлыгын фаш итүдә, Солтангалиев җитәкчелегендәге дошманы агымга каршы көрәштә ул зур роль уйный, аларга отпор бирә.

Ленинчыл милли политиканы тирәннән аңлаган хәлдә, пролетар интернационализм принципларына таянып эшләү нәтиҗәсендә Сәетгалиев, чагыштырмача тиз арада, үзен киң колачлы партия-совет эшлеклесе итеп таныта. РКП(б)ның XII съездындагы, РКП(б) каршындагы милли хезмәткәрләр турындагы IV киңәшмәдәге, Татарстанда һәм Кырымда үздырылган төрле җыелышлардагы чыгышлары, В. И. Ленинга язган хатлары, Ленинның, Сәетгалиев белән сөйләшкәннән соң, татар коммунистларына җибәргән язмасы — барысы да шуны раслый.

Партиянең XIII съезды булып үзгач, Сәетгалиев Үзәк Контроль Комиссиясендә һәм СССР Халык Хезмәт Комиссариаты аппаратында эшли. Ул монда М. Калинин, Н. Крупская, И. Сталин, М. Фрунзе, Г. Орджоникидзе, В. Куйбышев, Ф. Дзержинский, А. Цурюпа, Н. Семашко, Н. Шверник кебек, Совет дәүләтенең һәм партиянең күренекле эшлеклеләре белән иңгә-иң хезмәт итә.

Бу елларда аңа ил буйлап күп йөрергә, халык хуҗалыгын өйрәнергә һәм, күргәннәреннән чыгып, нәтиҗәләр ясарга, тәкъдимнәр кертергә туры килә. Аның коммунистлар һәм комсомоллар җаваплылыгына, югары оешмаларда чыгарылган карарларның үтәлешен тикшерүгә, хуҗалыкта исәп-хисапны төгәл алып баруга кагылышлы һәм башка тәкъдимнәре бүген дә кыйммәтен югалтмаган.

Хезмәт няләренең һәм партиянең ышанычын, ихлас хөрмәтен казанганлыктан Сәхибгәрәй Сәетгалиев РКП(б)ның IX, X, XII, XIII, XIV съездларына һәм XIV конференциясенә делегат итеп сайлана, III Интернационалның II конгрессына делегат булып катнаша, Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитетында күп мәртәбәләр членлыкта тора.

Үзен чын интернационалист итеп таныткан Сәхибгәрәй Сәетгалиев РСФСР делегациясе составында Советларның I Учредительный съездында да катнаша һәм ул СССР оештырылу турындагы Килешүгә, Декларациягә кул куя. РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросының 1923 ел 24 маенда кабул ителгән карары нигезендә ул СССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумының СССР Конституциясен төзү комиссиясенә кертелә. 1933 елдан 1937 елның сентябренә кадәр ул Саратовның тимер юл идарәсендә политбүлек начальнигы булып эшли.

Кайда гына, нинди генә вазифаны башкарса да, Сәетгалиев һәр эшен җиренә җиткереп үти, принципиаль таләпчәнлеген һич киметми. Шул ук вакытта ул кешеләргә карата ифрат шәфкатьле һәм игътибарлы да була белгән. Аның киләчәккә юнәлдерелгән якты өметләре башкалар күңелендә дә оптимизм уяткан, яшәргә көч өстәгән.

1920 елның җәендә III Интернационалның II конгрессы делегатларының бер төркеме Казанга килә. Алар арасында Марсель Кашен, Жак Садуль, Джон Маклин кебек халыкара эшчеләр хәрәкәтенең күренекле вәкилләре дә була. Шул кадерле кунаклар алдында чыгыш ясаганда Сәхибгәрәй Сәетгалиев:

— Татарстан хезмәт ияләренең экономик хәлен һәм культурасын яхшырту — безнең алда торган иң беренче бурыч,— дип сөйли.— ...Без шуңа омтылабыз, без моңа ирешәчәкбез, һәм бу җиңү тарих битләренә кызыл хәрефләр белән языльр.

Без бүген, Ленинның турылыклы көрәштәше безнең киләчәкне күз алдына бик дөрес сурәттә китергән, дип әйтә алабыз. Өч ордены булган Татарстан бүген СССР халыкларының бердәм семьясында экономик яктан да көчле, югары культуралы республикага әйләнде. Татарстан хезмәт ияләре ирешкән җиңүләрдә ялкынлы революционер, партиянең күренекле эшлеклесе Сәхибгәрәй Сәетгалиевнең дә өлеше зур. Нәкъ шуңа күрә аның якты образы халык күңелендә мәңге яшәр.

Мөнирә СӘЙДӘШЕВА.

СӘХНӘ ЙОЛДЫЗЫ

Хөсәен Уразиковның тууына 90 ел

Татар совет театр культурасының күренекле эшлеклеләре исемлегендә Ленин ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Хөсәен Уразиков мактаулы урыннарның берсен алып тора. Аның илле еллык сәхнә эшчәнлеге — милли театр сәнгатебез үткән юлның көзгедәгедәй чагылышы. Ул — сәләтле актер, үзенчәлекле режиссер, драматург һәм педагог буларак та татар театр тарихында зур урын алып тора.

Х. Уразиков сәнгатькә Октябрь белән бергә килә. Совет чоры актеры, барыннан да элек, үз хезмәтенә партиячел мөнәсәбәттә булырга, илебез, халкыбыз интересларын алга куеп яшәргә, зур җаваплылык хисе тоярга тиеш. Бу сыйфатлар Х. Уразиковка да хас. Тормыш дөреслегенә омтылышы аның бөтен сәхнә эшчәнлеге юнәлешен билгели. Ярты гасыр дәвердә Уразиков сәхнәдә йөз алтмыш роль башкара. Аларда актерның күпкырлы таланты ачыла.

Ул башта «Г. Кариев истәлеге», Дүртенче татар бригадасы, Алма-Атадагы Г. Тукай исемендәге труппаларда, Кызыл Октябрь исемендәге Татар дәүләт театры, Астрахань татар театрлары сәхнәләрен ә уйный. Ләкин беренче рольләре аңа уңыш китермиләр.

Уразиковның актер булып формалашуында К. Тинчурин драматургиясенең тәэсире зур була. Беренче тапкыр башкарган Җиһанша роле («Зәңгәр шәл», 1926 ел) актерга популярлык алып килә. Шул ук вакытта бу роль аңа шушы ук пьесадагы икенче сәхнә образын тудыруда хәзерлек эше дә була. Ишан роле (1929 ел) аның иҗат биографиясендә чынлап та иң яхшылардан санала. «Җилкәнсезләр»дәге (1933 ел) Мисбах хаҗи да үзенең фикер масштаблыгы, сурәтләү чаралары һәм социаль яңгырашы белән Ишан образына охшаш. Х. Уразиков, «Сакла, шартламасын» спектакленнән (1928 ел) Шакирҗан бай ролен башкарып, Тинчурин сәнгатенең уен манерасын үзләштерә.

Уразиковның сәхнә остасы булып китүендә рус һәм чит ил классикларының да өлеше шактый. Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» спектаклендәге (1933 ел) Вурм образы аерым бер социаль катлауның барлыкка килүен күрсәтә. Мәкер тантана иткән дөньяда мәхәббәт кебек гүзәл хисләргә урын юк. Яңа тормыш төзү өчен барлык вурмнарны, президент һәм герцогларны юк итәргә кирәк. Х. Уразиков образ тудырганда менә шушы төп фикергә таяна.

Х. Уразиковның сәхнә осталыгы артканнан-арта бара. Ул Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», «Зифа» пьесаларыннан Колый Тархан, Бикәмәт, Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы» пьесасыннан Сәмигулла, М. Горькийның «Дошманнар»ыннан Печенегов кебек тормышчан һәм бер-берсенә охшамаган образлар тудыра.

Х. Уразиков образларын тормышчан, халыкның көнкүрешен һәм культурасын, милли үзенчәлекләрен тирән белеп иҗат итә. Актер, теге яки бу рольне әзерләгәндә кием, сөйләм, жест үзенчәлекләрен дә җентекләп өйрәнә. Бу очракта аны үз роленең режиссеры дисәк тә ялгышмабыз. Ул комик һәм драматик рольләрне дә тигез дәрәҗәдә башкаручы оста була.

Х. Уразиков шулай ук үзеннән соң тирән реалистик сәхнә әсәрләре калдырган талантлы режиссер да. Г. Карнеев режиссурасы мәктәбенең реалистик традицияләрен кабул итеп, үстереп, милли театрның яңа буынына тапшыруы Х. Уразиковның мактауга лаек казанышы ул. Тормыш дөреслеге исә, аңа юл күрсәтүче якты маяк була.

Татар дәүләт академия театрында Т. Гыйззәтнең «Даулы көннәр» пьесасы буенча куелган спектакль Х. Уразиковка режиссер буларак та дан алып килә.

«Даулы көннәр» пьесасын сәхнәгә әзерләгәндә режиссер әсәрнең төп фикерен төшенергә, аны үзенең тормыш белеме һәм актерлар коллективы тәҗрибәсе белән баетырга тырышкан. Бу очракта режиссерның төп максаты — социалистик идеяләрнең халык аңына үтеп керү, хезмәткә яңа караш һәм социалистик җәмгыятьнең яңа кешесе формалашу процессларын чагылдыру. Спектакльнең тулы яңгырашына катлаулы куелыш алымнары, декорацияләр белән түгел, бәлки пьеса геройлары характерларын тирән ачлап, сәхнәдә аларны реалистик, тормышчан дөрес чагылдыру юлы белән ирешелә.

Утызынчы еллар уртасыннан Х. Уразиковның иҗат юлы Уразиков-артист, Уразиков-режиссер юнәлешләренә бүленә. Аның күпьеллык иҗат эшчәнлегенең төрле чорында әле бер, әле икенче юнәлеш өстенлек ала. Кем генә булса да — актермы, режиссермы, театр җитәкчесеме, педагогмы — Х. Уразиков туктаусыз эзләнүчән, үзүзенә таләпчән була.

Утызынчы елларда куелган сәхнә әсәрләрендә аның заман сулышын тоюы, татар халкының көнкүрешен һәм культура байлыкларын, милли театрның иҗади мирасын, тарихын һәм традицияләрен белүе ачык күренә.

Бөек Ватан сугышының беренче елларында шул чор героен сурәтләү проблемасы алга килеп баса. Бу мәсьәлә тиз генә хәл ителми. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының М. Әмирнең «Миңлекамал» пьесасы буенча режиссер Х. Уразиков әзерләгән спектакле — идея-художество ягыннан югары, сугыш еллары тормышын артык бизәмичә, кырыс сурәтләгән сәхнә әсәре. Драматургия законнарын белү бу юлы да режиссерга авторның иҗат лабораториясенә үтеп керергә мөмкинлек бирә.

Кырыгынчы елларда татар театры режиссерлары тарихи һәм героик-революцион спектакльләр булдыру өчен шактый эзләнәләр. Х. Уразиков бу чорда М. Гали һәм Н. Исәнбәтнең «Каюм Насыйри», «Мулланур Вахитов» әсәрләре буенча спектакльләр куя.

Х. Уразиковның режиссерлык композицияләрендә артистлар үзе төп урын алып тора. Шунлыктан артист аның спектакльләрендә сәхнә әсәренең төп идеясен чагылдыручы булып тора. Югары профессиональ культура, артист эшенә мәхәббәт, аның белән яхшы мөгамәлә, эрудиция — бу сыйфатлар Уразиков-режиссерга күп ярдәм итәләр.

Уразиков спектакльләренең үзәгендә һәрчак кеше тора. Аны тарихи конкрет, аерым бер җәмгыять, тирәлек кешесе, аның көнкүреш шартлары кызыксындыра. Режиссерның спектакльләре идея ягыннан төгәлләнгән, аларда заман кешесен дулкынландыручы проблемалар карала, чорның актуаль идея бурычлары чагыла. Болар

хәтта театр практикасында «конфликтсызлык теориясе» өстенлек иткән елларда спектакльләрендә дә ачык күренә. Ул елларда Х. Уразиков куйган «Мулланур Вахитов», «Ялгыз каен», «Зифа» кебек спектакльләр тирән идеялелек, кискен проблематика белән аерылып тораллар. Уразиковны режиссер буларак көнкүреш темасы кызыксындыра. Ләкин көнкүреш аның өчен үзмаксат булмый, ә кеше күңеленең тирәнлеген ачу чарасы булып тора. Режиссер тормыш дөреслеген сәхнә поэзиясе дәрәҗәсенә күтәрә. Ул тирәлектә барган вакыйгаларны күрә, аңлый һәм тормышта яңаны тотып ала, анализлый.

Х. Уразиковның режиссерлык мирасы чагыштырмача зур түгел. Ул, тулаем алганда, утыз бер спектакль куйган. Аларның кайберләре берничә тапкыр яңадан куела. Уразиковның һәр спектакле диярлек республикабызда вакыйга була, тамашачының игътибар үзәгендә тора, тәнкыйтьчеләр тарафыннан уңай бәяләнә.

Уразиковның педагоглык эшчәнлеге дә әһәмияткә ия. Аның күп санлы шәкертләре бүген дә республикабыз театрларында эшлиләр, остазларыннан алган реалистик традицияләрне дәвам итәләр, үстерәләр.

Аның драматургия мирасы да игътибарга лаек. Артист Г. Капкаев һәм прозаик М. Гали белән берлектә ул «Кара тап» (1928 ел), «Каюм Насыйри» (1945 ел) драмаларын яза, рус һәм үзбәк телләреннән пьесалар тәрҗемә итә.

Х. Уразиковның бай, күпкырлы эшчәнлеген партия һәм хөкүмәтебез югары бәяләде. 1938 елда аңа Татарстанның атказанган, 1945 елда — Татарстанның халык артисты, ә биш елдан соң РСФСРның атказанган артисты дигән исемнәр бирелә, 1957 елда Х. Уразиков илебезнең югары бүләге — Ленин орденына лаек була.

Гали АРСЛАНОВ.

МОҢЛЫ ЯКТАШЫБЫЗ

Композитор Хөснул Вәлиуллинга 70 яшь

Яшьлегебез тайгага тоташып киткән бер үк урманда үткәнгәме, Саба егете Хөснул ага Вәлиуллинның иҗаты миңа аеруча якын һәм кадерле. Уйчан йөзле, тыйнак табигатьле якташыбызның бөтен иҗаты да туган якны сагыну, ярату хисе белән сугарылган төсле...

Җырга-моңга бай, уен-көлкегә юмарт як ул Саба яклары. Фатих Хөснинең җор теле, Хәй Вахитның комедия-водевильләре, Тавил Хаҗиәхмәтовның шаян Шәвәли рәсеменнән алып, җитди, уйчан Кол Галие дә шуны раслый.

Моннан күп еллар элек, тимерче алачыгыннан кайткач, яшь Хөснул да клубка тынлы оркестрда уйнарга ашыга. Сәләтле егет уен коралларында уйнарга тиз өйрәнә. Көндез кулда чүкеч, ә кичләрен скрипка һәм кларнет була. Ә күңелдә туган як, аның матур кешеләре, чибәр кызлары турында моң шыта...

1935 елда Казан музыка училищесының бер төркем укытучылары Татарстан районнарында сәләтле яшьләрне барлап йөриләр. Сабада аларны кечкенә буйлы, чандыр егет үзенә җәлеп итә.

Шулай итеп, Саба суының нәни чишмәсе татар музыкасының киң Иделенә килеп кушыла, 1940 елга чаклы Х. Вәлиуллин музыка училищесының теория-композиторлык бүлегендә Ю. В. Виноградов классында укый. Илһамлы студент еллары бәрәкәтле дә була — яшь егет егермегә якын җыр, тынлы оркестр өчен ике марш, фортепиано өчен «Сүзсез җыр» пьесасын иҗат итә. Бу әсәрләрнең кайберләре әле бүген дә яңгырый. Ә. Ерикәй сүзләренә язылган «Онытырга мөмкин түгел» җыры исә сәнгатебезнең алтын фондында лаеклы урын алды.

Яшьлек сафлыгы, ихласлык, хис тирәнлеге, эчкерсезлек... Бу җыр шул яклары белән ота. Яшь кешегә җилбәзәк җил дә, салкын чишмә дә, җырчы былбыл белән күктәге йолдызлар да сөйгән ярыңны оныт инде дип үгет бирәләр. Әмма «йөрәк җа-

вап бирә: онытырга һичбер вакыт мөмкин түгел»,— дип. Композиторның беренче иҗат җимешләре үк татар музыкасына кабатланмас моңлы һәм аһәңле иҗат кешесе килүен раслыйлар. Аларда композиторның табигатьне һәм шигъриятьне бик нечкә тоеп-сиземләүче художник булуы ачыклана. Шул ук вакытта композиторга гражданлык тематикасы да ят түгел — ул колхоз тормышының үзенә күптән таныш күренешләрен моңга сала, музыкаль образлылык ярдәмендә авыл яшьләренең күңелле, матур тормышын тасвирлый («Яз җыры» — Х. Вахит сүзләре, «Тракторчы кыз» — Ә. Ерикәй сүзләре һ. б.). Халык моңына нык береккәнлеге, милли музыка үзенчәлекләрен яхшы белүе дә композитор иҗатында бик иртә билгеләнә.

Укуын тәмамлагач үк башланып киткән бөек Ватан сугышы композиторның тормышында да, иҗатында да зур сынау, рухи чыныгу чоры булды. Сугыш фаҗигаләрен ул үз җилкәсендә татыды.

1945 елның сентябрендә ул үзенең күптәнге хыялын тормышка ашыра — Казан дәүләт консерваториясенең композиторлык факультетына укырга керә. Анда күренекле педагог һәм композитор А. С. Леман җитәкләгән композиция классында укый.

Инде кырыкны куып барган, чәченә чал кереп, йөзенә авыр юл эзләре төшкән композитор өчен яңадан мавыктыргыч иҗат дөньясына сәяхәт башлана. Күңелендәге сагыш, хәсрәт юшкыннарын акрынлап җиңүле язларның кар сулары әрчи. Куанычка каршы, аның белән бергә консерваториядә якын дусты, иҗатташы драматург Хәй Вахит та укый. Алар икесе дә язларга гашыйк, музыкага, шигъриятка, тормыш гүзәллегенә гашыйк. Ике дус «Ватаным», «Яз айлары», «Саба», «Күңелкәем» дигән җырлар иҗат итәләр.

Яз нурында, яз нурында
Чәчәк ата үрмә гөл.
Яз айлары сагынуымны
Тирәнәйтә бермә-бер.

Композиторны халык җырлары да үзенә җәлеп итә. Ул бернича татар халык көен эшкәртеп кенә калмый, үзе дә халык сүзләренә җырлар яза.

Композитор үзен шулай үк инструменталь музыкада сынап карый — фортепиано өчен сонатина һәм прелюдия, виолончель өчен «Романс» яза. Соңгысы аеруча популярлык казанып, бүген дә радиодан һәм концерт эстрадасыннан еш яңгырый. Консерваториядә укыганда Хөснул Вәлиуллин Хәй Вахит белән берлектә «Самат» операсының беренче пәрдәсен тәмамлый. Тулысынча опера 1956 елда төгәлләнә һәм Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында куела. Ул Мәскәүдә уздырылган татар сәнгате һәм әдәбияты декадасында зур уңыш белән бара. «Самат» — заман темасына багышланган опера. Әсәрнең төп идеясен кыскача гына: кешенең тормыш мәгънәсе һәм чын бәхете — туган илең, туган халкың тугрылык белән хезмәт итүендә, дип билгеләргә мөмкин.

Ут белән чолганган танктан дустын коткарганда Самат каты яралана һәм акрынлап сукырая. Фаҗига котылгысыз. Самат Корчагиннар, Мересьевлар башыннан узган иң кыен ситуациядә кала. Ә авылда аны сөекле Әлфиясе көтә. Егет аны бәхетсез итәргә теләмим дип, Әлфиягә куешкан вәгъдәләрен онытырга куша. Әмма саф күңелле, батыр йөрәкле Әлфия моңа риза булмый. Алар кавышалар. Мәхәббәт канатландырган Самат гариплеген җиңәр өчен көч таба, социализм төзүчеләр сафына басып, туган илең хезмәт итә — колхозда электростанция планын төзеп, аны тормышка ашыра...

Менә шул сюжет композиторга опера сәнгатендә хәзерге заманда сирәгрәк очрый торган лирико-психологик драма тудырырга мөмкинлек бирә. Авторның төп игътибары геройларның рухи дөньясын ачуга юнәлдерелә. Композитор бу катлаулы бурычны уңышлы хәл итә.

Опера мелодик байлыгы, милли бизәкләрнең муллыгы белән аерылып тора. Художник кулланган халык көйләре аның музыкаль тукымасына органик төстә бәйләнеп китәләр, еш кына авторның үз мелодиясен алардан аерып алу да кыен. Бу, һичшиксез, композиторның осталыгы, музыкаль сизгерлеге турында сөйли. Шул ук вакытта композитор халык көе интонацияләрен файдаланып кына калмый, ул салмак, тыйнак, басынкы, тоелган халык көенең эчке киренкелеген, драматизмын ачып бирә белә.

Х. Вәлиуллинның соңгы еллар иҗатында җыр, романс жанры өстенлек итә дисәк, ялгыш булмас. Шул уңайдан аның тагын бер күркәм сыйфатын әйтеп китик — ул шигъриятне тирән тоеп иҗат итүче композитор. Бу ягы аны Р. Яхинга якынайта. Аларның һәркайсы билгеле бер автор шигырьләренә җыр иҗат итәргә яраталар. Бу даимилек куанычлы нәтиҗәләр бирә. Композиторның Хәй Вахит белән иҗат дуслыгы турында әйттек инде. Әмма драматургның «Соңгы хат» драмасына язылган музыкасын һәм бигрәк тә романтик рухлы «Зөһрә җыры»н атамасак, татар совет җыр сәнгатенең соңгы еллардагы иң гүзәл казанышларыннан берсен читтә калдыру булыр иде. Сүз уңаеннан, гомумән, Хөснул аганың спектакльләргә музыка язу осталыгын ассызыклап үтәргә кирәктер. Бүген инде Ш. Камалның якты рухлы «Акчарлак»ын да Х. Вәлиуллинның Рәшит Әхмәтҗанов сүзләренә язган «Акчарлаклар» җырыннан башка күзаллавы кыен.

Композиторның Сибгат Хәким белән иҗат дуслыгы да игътибарга лаек. Бу дуслык сугыштан соң ук башланып хәзер дә дәвам итә. «Урал суы буенда», «Иртәнге сихри юллар» һәм бигрәк тә «Күңелем Ленин белән сөйләшә» исемле җыр-романслар моны ачык раслый.

Гаҗәп тыйнак, аз сүзле, уйчан Хөснулла ага яшьләрчә елмаеп-көлеп алуга да каршы түгел. Һәрхәлдә Шәүкәт Галиев белән ул менә дигән «Көлү гимны»н, «Бар икән күрәселәр» җырын язды, ә шагыйрьнең табигый агылышлы лирикасы аны «Шомырт чәчәкләре ак кына» кебек гүзәл җыр язарга рухландырды.

Композитор әдәбиятыбызның аксакаллары Нәкый Исәнбәт сүзләренә «Сабан туе» Әхмәт Исхак сүзләренә «Тагын җитте язлар» кебек җырлар иҗат итү белән бергә, хәзерге яшь шагыйрьләрнең әсәрләренә дә еш күз сала.

Әйе, Саба егетенең Казанга аяк басканына да инде 50 еллап гомер узган. Якташыбызның канатлы җырлары да инде күптән туган якка юл тапкан... Ул үзе дә Саба якларын сагынып, якташлары белән әледән-әле күрешеп яши.

Вакыт тик тормый. Язларга, яшьләргә гашыйк композиторга да 70 яшь тулды... Әмма ул һаман яшьләрчә җитез һәм хәрәкәтчән. Күксел-зәңгәр күзләре һаман да жете һәм күпне күрүчән, күңеле һаман җыр-моң тулы, мөлдерәп тора. Карт фронтовик һәрвакыт сак һәм уяу. Җыры-моңы белән ул тынычлык, иминлек өчен көрәшә.

Фасил ӘХМӘТОВ,
композитор, РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе,
М. Глинка исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты.

Рафаэль Мостафин

ҖӘЛИЛ — ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬЧЕ

Муса Җәлил каләмә белән язылган һәм әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышланган йөздән артык мәкалә, рецензия, политик чыгышлар, шулай ук башка язмалар авторның профессиональ дәрәҗәдәге тәнкыйтьче булуын да раслыйлар. Мәскәү дәүләт университетында укыганда ук ул әдәби тәнкыйть белгечлеген үз мәсләге итеп сайлый. Аның югары белем турындагы таныклыгында да белгечлеге — тәнкыйтьче, матур әдәбият редакторы диелә.

Университетны тәмамлаганнан соң Җәлил бернича ел Мәскәүдә тәнкыйть һәм библиография институты белән тыгыз бәйләнештә тора. Институт тәкъдиме белән ул китапларга рецензияләр яза, институт хезмәткәрләре белән үзенең һәм башка авторларның рецензияләрен тикшерә, әдәби тәнкыйть осталыгын системалы рәвештә камилләштерә. Мәскәүдә татар телендә чыгучы «Коммунист» газетасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшләгәндә актив тәнкыйтьче һәм рецензент булу белән бергә әдәби тәнкыйть процессын оештыручы да, аңа дөрес юнәлеш бирүче дә, әдәбияттә иҗади климатны билгеләүче дә Җәлил була.

Гадәттә Җәлилнең әдәби тәнкыйть мәкаләләрен шигырьләренә күзәтү ясаганда, сүз уңаеннан гына искә алалар. Ә бит шагыйрьнең тәнкыйть мирасы авторның иҗат позициясен ачыклауда мөһим роль уйный. Безнеңчә, тәнкыйтьче Җәлил эшчәнлегенең төп әһәмияте үз заманының агымдагы әдәби процессына йогынтысында, татар әдәбиятындагы дөрес, тормышчан башлангычларны яклавында, иҗади климатны яхшыртуда һәм, иң мөһиме, яңа метод-социалистик реализм методы өчен көрәштә. Кызганычка каршы, Җәлил эшчәнлегенең бу өлкәсе нигездә әле өйрәнелмәгән.

Муса Җәлилнең тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге әдәбиятта РАПП[1] карашлары үсеш алган һәм вульгар социологик юнәлеш киң таралган чорга туры килә.

Бу елларда ул МАПП члены, соңрак татар секциясенең җаваплы секретаре һәм МАППның милли секция секретарьларыннан берсе була. Җәлилнең РАПП карашлары белән мавыгуы озакка бармый (1929—1932 еллар). Шагыйрьнең поэзия һәм тәнкыйть өлкәсендәге үсеше — илебездәге һәм республикабыздагы тарихи-әдәби процесс диалектикасының ачык чагылышы. Вакыт һәм заман белән бергә атларга омтылучы Җәлилгә милли тарихи үсешнең кайбер тайпылышлары да хас. Шунлыктан аның әдәби тәнкыйть карашларын һәм эстетик идеалын үсештә карау зарури. Аны РАПП карашларына әдәби мода түгел, бәлки шул заманның алдынгы идеалларына, партия эшенә, халыкка хезмәт итү теләге якынайта. «Без партия һәм комсомол чакырган фронтта»[2] исемле мәкаләсе моңа ачык мисал. Бу үзенә күрә МАППның татар секциясе исеменнән Җәлил раслаган әдәби манифест. Манифест кайнар, кыю комсомол рухы белән язылган. Җәлил киң катлау хезмәт ияләрен идеологик яктан тәрбияләүдә матур әдәбиятның роле чиксез зур булуын күрсәтә. Ул язучыларны «идеология фронтындагы ышанычлы гаскәрләр» дип атый һәм пролетар язучылар исеменнән

[1] РАПП — Российская ассоциация пролетарских писателей. Аның Татарстандагы бүлекчәсе ТАПП (Татарская ассоциация пролетарских писателей. Мәскәүдәгесе исә — МАПП (Московская ассоциация пролетарских писателей) дип атала.

[2] «Эшче» газетасы, 9 июнь, 1929 ел.

партия һәм комсомолның югары ышанычын акларга әзерлекне белдерә. Бу мәкалә теоретик яктан да әһәмиятле. Ул елларда әдәби метод төп мәсьәләләрнең берсе була. Яңа метод — социалистик реализм методы — әдәби бәхәсләрдә, дискуссияләрдә, капма-каршы фикерләр көрәшендә туа. Аны төрлечә: марксистик, пролетар, диалектик һ. б. дип атыйлар. Җәлил исә «революцион метод» ди һәм татар язучылары иҗатында аның мөмкинлекләрен һәрьяклап сурәтләүне яклый.

Ләкин ул әдәбият алдына революцион метод куйган максатлар һәм бурычларны, шул вакыттагы экономик һәм гомум политик бурычлар белән үтә якынайтып, бернигадәр утилитар аңлата. Бу — эшләп чыгару көчен күтәрү, продукциянең сыйфатын яхшырту, яңа техниканы үзләштерү, прогулларга чик кую, вак крестьян хуҗалыкларын күмәкләштерү өчен көрәштән гыйбарәт,— дип яза Җәлил. Ләкин шушы актуаль бурычлар исемлегендә яңа кеше характерының формалашуы, кеше рухи дөньясының байлыгын сурәтләү мәсьәләләре хәтта телгә дә алынмый.

Җәлил «күк күлмәкләр» хәрәкәтен киң җәелдерергә өнди, аларга кичәләр һәм театр сәхнәсендә кую өчен тиешле репертуар бирергә, агиткалар һәм рифмага салынган лозунглар язарга чакыра. Бу РАПП күрсәтмәсе Җәлилнең шул чор иҗатында да шактый сизелә.

Өч айдан соң Җәлил яңа, программа характерындагы «Революцион әдәбият өчен киң походка» исемле мәкаләсе («Эшче», 1929, 13 сентябрь) белән чыга. Биредә югарыда күрсәтелгән мәкаләдәге фикерләр үстерелә. Шагыйрь барлык татар язучыларын яңа революцион әдәбият өчен зур походка чакыра. «Поход ул шәп нәрсә,— дип яза Җәлил.— Син үзең дә сизмисең: колагыңны ярып, көчле тревога сигналы яңгырый. Уянып киткән буласың да бөтен көчеңне, коралыңны кулыңа җыйнап, чакырылган фронтка ыргыласың.

Походта бөтен көч бергә оеша. Коточкыч биек бер тау була. Походтан соң артыңа әйләнеп карасаң, өр-яңа позицияләрнең үз кул астында калганын, бик күп яңа адымнарның алга атлаганын күреп исең китәр. Гражданнар сугышыннан походларга катнашкан көрәшчеләр моны яхшы беләләр. Комсомол инициативасы белән күтәрелгән урожай походы, культпоход, социализм ярышы, теория өчен поход эчендә кайнаучылар да моны ачык сынаганнар» («Эшче» газетасы, 1929, 13 сентябрь).

Җәлил революцион әдәбият өчен булган походның төп максатларын болай билгели:

1. Әдәбиятта марксистик методны үзләштерү.

Шагыйрь барлык совет язучыларына марксистик методны үзләштерергә һәм эшче-крестьян массалары эшенә хезмәт итәргә чакырып мөрәҗәгать итә.

2. Иҗат көчләрен марксистик рухта тәрбияләү. Җәлил марксистик тәрбияне теоретик хәзерлек кенә дип түгел, бигрәк тә тормыш белән тыгыз бәйләнеш итеп аңлый. Ул язучыларны «тормыш казанында кайнарга» өнди.

3. Барлык татар язучыларының иҗатын тиешле юлга бору, идеологик яктан тотрыклы итү.

Бу пунктта Җәлил югары идеялелек һәм әдәби осталык бер берсенә тыгыз үрелергә тиеш дигән фикер әйтә. Шуның белән ул РАПП билгеләгән чикне уза.

Җәлил бу чорда язган мәкаләләрендә һәм чыгышларында методка, дөньяга карашка, юнәлешкә кагылышлы гаять зур мәсьәләләр күтәрә. Аерым әсәрне бәяләү, «технология», әдәби осталык мәсьәләләрен һәм шигырь «техникасы»н ул икенче урынга куя, аларга кагылмый да диярлек.

Егерменче еллар ахыры — утызынчы еллар башында РАПП оешмалары өчен яңа этап башлана. Ул бу оешмалар эшчәнлегендәге уңай якларны күмеп китәрлек теоретик ялгышлар, сектантларга хас тар карашлылык белән характерлана.

Бу 1929 елның сентябрендә татар әдәбияты үсеше мәсьәләләре буенча үткәрелгән РАПП пленумында ачык чагыла. Җәлил, татар секциясе җитәкчеләренең берсе буларак, кайбер мәсьәләләрдә РАПП идеологлары белән килешмәсә дә, пленум карарларын игътибарсыз калдыра алмый. Ул «Эшче» газетасында РАПП пленумы карарларына җавап итеп язылган «Матур әдәбиятыбыз алдындагы үзәк проблемалар» исемле мәкаләсе белән чыга. Анда шагыйрь пролетариат әдәбияты гегемонлыгы өчен көрәш турындагы РАПП лозунгысын эзлекле рәвештә алып бара. Шагыйрь аны пролетариат һәм, киңрәк — марксистик идеология гегемонлыгы өчен көрәш дип аң-

лата. Чынлыкта исә бу лозунг әдәбиятта бер группаның башкалардан өстенлек дәгъва итүен белдерә.

Җәлил пролетар әдәбиятның үз стилен булдыру өчен көрәш турындагы РАПП тезисын күтәреп ала. Бу чор иҗатында шагыйрь шундый стиль табар өчен күп эзләнә. Ул «производство»ча метафора һәм чагыштырулар эзли, завод тематикасын өйрәнергә, мәхәббәт белән производство планнарының үтәлешен бергә бәйләргә тырыша. Ләкин болар нәтиҗәсез калалар.

Җәлил мәкаләсендә РАПП пленумы карарларында аерып әйтелгән һәр әсәрдә язучының сыйнфый идеологиясе чагыла дигән фикер үткәрелә. Бу тезис пролетар чыгыштан булмаган язучыларны аеруны күздә тота. Бу исә теоретик аңлашылмаучылыкка китерә. РАППчылар һәр сыйныфның үз әдәбияты бар, антогонистик сыйныфлар җәмгыятендә аерым «сыйнфый әдәбиятлар» барлыкка килә һәм алар бер-берсе белән туктаусыз көрәшәчәкләр дип уйлыйлар, РАПП идеологлары, бу фикерне дәвам итеп, әдәбияттә килешмәүчән сыйнфый көрәш лозунгысы игълан итәләр.

Җәлил әдәбиятны сыйнфый көрәшнең үткен коралы дип дөрес бәяли. Ләкин соңрак, РАПП пленумы резолюциясе йогынтысында «Комсомольская правда» газетасында дөнья күргән мәкаләсендә татар әдәбиятында сыйнфый көрәш гәүдәләнешен күрмәгәне өчен профессор И. Н. Бороздинны кискен тәнкыйтьли. РАПП фикерләрен яклап, ул татар тәнкыйтьчеләре һәм әдәбият белгечләре Г. Сәгъди, Х. Вәли белән дә бәхәскә керә.

Бу мәкаләсендә Җәлил метод турында башкачарак аңлатма бирә. Ул әдәбияттә диалектик материализм методы турындагы РАПП тезисын игълан итә. Алдагы чыгышларында шагыйрь марксистик метод төшенчәсенә якынрак тора. РАППчылар марксистик философия төшенчәләрен һәм аның категорияләрен матур әдәбиятка механик рәвештә күчерәләр. Алар материализм белән реализмны, романтизм белән идеализмны тәңгәл куялар. Алар XIX гасыр француз язучылары Бальзак, Флобер, Золя һәм башкаларны реалист-материалист, әмма метафизик дип уйлыйлар. Алар фикеренчә, диалектик материализм методы кыска вакытта чит ил әдәбияты классикларын куып җитәргә һәм узып китәргә мөмкинлек бирә.

Җәлил метод проблемаларын 1931 елда МАППның татар секциясендә укыган докладында да искә алып үтә. Шагыйрь архивында сакланган тезислардан чыгып бәя биргәндә, кайбер мәсьәләләрдә фикер башкалыклары булса да, бу мәсьәләдә РАПП теоретиклары белән килешүен күрәбез. Дискуссия ахырында ул берсүзсез ВЛКСМ Үзәк Комитеты работниклары ягында кала. Шагыйрь группачылыкны һәм кайбер РАПП җитәкчеләрен мин-минлектә гаепли, дискуссия барышында фаш ителгән вульгар социологик хаталар турында да әйтеп уза.

Ул Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Толымбайский, Г. Сәгъди, Х. Вәли кебек татар тәнкыйтьчеләре һәм әдәбият галимнәре белән бәхәстә үз стиле һәм методы булган пролетар әдәбият киреклеген таный. Бу Җәлилгә дөрес нәтиҗәләр ясарга ярдәм итә. Татар әдәби тәнкыйтенең түбән дәрәҗәсе һәм начар методологик коралланыу турында яза, формалистик характердагы хаталарны күрсәтә, идеологияне политикадан аерып карауны тәнкыйть итә. Тезислар шагыйрьнең теоретик хәзерлек дәрәҗәсе нинди югарылыкта булуын раслый. Җәлил, кайбер мәсьәләләрдә ялгышса да, бөтен совет әдәбият белеме белән бергә ялгыша.

Җәлил үзе кабул иткән РАПП карашларын игълан итү белән генә чикләнеп калмый, практикада конкрет әсәрләрне анализлаганда кулланырга тырыша. Яшь язучы Л. Гомәровның «Соңгы сугыш»[1] исемле китабының кереш сүзендә шагыйрь конкрет мисалларда диалектик материализм методы турында фикерен дәвам итә. Ул методның язучы өчен ят нәрсә булмавын һәм аны читтән алу мөмкин түгеллеген әйтә. Метод — ул язучының дөньяга карашы һәм тормышны белүенең конкрет чагылышы. Чынлыкта метод язучының нәрсә һәм ничек күрүен, тере яки бу тормыш күренешләрен ничек аңлый һәм бәяли, иң мөһиме нәрсәгә өнди, тормышта нәрсәне һәм ничек үзгәртергә теләвен билгели дип яза Җәлил. Ул сәнгать әсәре иҗат итүчедә билгеле бер сыйныф вәкилен күрергә чакыра. Л. Гомәров әсәренең яхшы якларын аның пролетар чыгыштан булуы белән аңлата. Бу урында авторның Гражданнар

[1] Л. Гомәров. Соңгы сугыш. Мәскәү. Центриздат, 1931 ел, татар телендә.

сугышында катнашып, кызыклы материал туплавы турында әйтү урынлы булыр иде. Авторга материалын файдалану өчен талант һәм осталык җитенкерәми. Бу әсәреннән соң Л. Гомәровның игътибарга лаек бер әсәр дә иҗат итмәве һәм әдәбияттан китүе очраклы түгел.

Г. Төхфи һәм Альфади белән берлектә язылган «Әдәбиятта контрреволюцион троцкизмга каршы» исемле мәкаләдә («Ударниклар», 1932, 4—5 саннар) Г. Ильясның «Штык» романы тәнкыйть ителә. Авторлар механик рәвештә диалектик материализм методы принципларыннан чыгып, бу романны философик категорияләр белән тикшерәләр. Чынбарлыкны сурәтләүдәге субъектив моментларны күреп, авторлар язучыны фәлсәфи субъективизмда, икенче төрле итеп әйткәндә, идеализмда гаеплиләр. Сюжет төзелешендәге һәм образларны ачып бирүдәге схематизм язучыга метафизик һәм механицист дигән исем тагуга китерә. Дөрес, Г. Ильяс романында җитешсезлекләр шактый. Ләкин алар авторның таланты җитәрлек дәрәҗәдә булмау белән аңлатыла.

Шагыйрь башка мәкалә һәм рецензияләрендә дә аерым әсәрләргә бәя биргәндә диалектик материализм методын кулланырга тырыша. Ләкин ул тәнкыйтьчегә уңыш китерми. Соңрак исә, шактый вакыттан соң, Җәлил партия активында ясаган чыгышында әдәбиятта диалектик материализм методы турындагы РАПП положениесеннән көлә. «Диалектик материализм методыннан чыгып атны ничек сурәтләргә соң?»— дип сорый ул, аларның теоретик дәгъваларының мәгънәсезлеген күрсәтеп. Аның чыгышы үз-үзенә тәнкыйть тә булып яңгырый. Чөнки Җәлил вакытында үзе дә бөтен татар тәнкыйте белән бергә РАПП тайпылышларын башыннан кичерә.

Җәлилнең тәнкыйтьче буларак иҗат юлы шагыйрьнең әдәби-тәнкыйть принциплары үсеш юлы никадәр каршылыклы һәм катлаулы булуын, эстетик идеалының нинди шартларда формалашуын ачык күз алдына китерә. Шуңа күрә дә аның тәнкыйть мирасын тулаем алып карарга, тулаем алып бәяләргә кирәк.

* *
*

ВКП(б) Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать оешмаларын яңабаштан кору турында»гы 1934 ел карары республикабыз һәм илебез әдәби тәнкыйть фикере үсешендә зур борылыш ясады. Карарда «Советлар власте платформасын яклаучы һәм социалистик төзелешкә актив катнашырга омтылган барлык язучыларны бердәм оешмага — совет язучылары союзына тупларга!» тәкъдим ителә.

Карар Җәлилнең әдәби тәнкыйть эшчәнлегендә дә яңа этап башлануын белдерә. Карарны төшенү, оештыру һәм идеологик әһәмиятен аңлау өчен шактый вакыт сорала. РАПП идеологларына чын күңелдән ышанган, күп кенә фикерләрен һәм терминнарын йөрәге белән кабул иткән шагыйрьгә хаталарыннан арыну бик авыр була. 1934—35 елларда да аның мәкаләләрендә вульгар социологик фикерләр очрый. Җәлил аларны бөтен совет әдәбияты белән бергә җиңә.

Җәлил күренекле рус шагыйрьләре һәм язучылары белән аралашып яши, диспутларда һәм фикер алышуларда катнаша, үзәк матбугатны даими күзәтеп бара. Болар аны теоретик яктан ныгыталар.

Социалистик реализм термины бөтен совет тәнкыйтендә, шул мисалдан татар әдәбиятында да, совет язучыларының беренче съездыннан һәм А. М. Горькийның съездда ясаган чыгышыннан соң гына (август-сентябрь 1934 ел) кулланыла башлый дип исәплибез. Муса Җәлил исә бу терминны 1933 елда ук кулланган. Кулланып кына калмыйча, аның мәгънәсен һәм әһәмиятен тирәннән, теоретик яктан нигезләп аңлаткан. Принципиаль әһәмияткә ия булганлыктан бу мәсьәләгә киңрәк тукталу урынлы булыр. Социалистик реализм термины беренче тапкыр «Литературная газета»ның 1932 ел 23 май санында кулланыла. Тиз арада ул гражданлык хокукы да ала. Беренче съездда кабул ителгән Совет Язучылар союзы Уставында совет әдәбиятының төп иҗат методы итеп социалистик реализм билгеләнә. Социалистик реализм, «художниктан чынбарлыкны дөрес итеп, тарихи-конкрет сурәтләү белән бергә, революцион үсешендә күрсәтүне таләп итә. Сәнгатьчә таасвирлаудагы дөреслек һәм

тарихи-конкретлык хезмәт кешеләрен идея ягыннан үстерү һәм социализм рухында тәрбияләү бурычы белән кушылырга тиеш»[1].

Устав кабул итәргә ел ярым алдан (1933 ел 12—19 февраль) язучылар союзы оештыру комитетында совет әдәбияты, аерым алганда, драматургия үсеше мәсьәләләренә багышланган II пленумда яңа метод турында нигезле теоретик сөйләшү була. Жәлил, пленум киңәшмәләрендә катнашып, шуның тәэсирендә «Совет драматургиясе яңа чорда» исемле мәкаләсен («Коммунист», 1933 ел, 16 март) яза. Бу теоретик мәкалә шактый зур проблемалар күтәрә. Шулар арасында метод проблемасы иң әһәмиятлесе. Мәкаләнең бер бүлеге шушы мәсьәләгә багышлана.

Пленум һәм чыгыш ясаучылар (бигрәк тә А. В. Луначарский) материалларына таянып Жәлил татар матбугатында беренче булып яңа терминга теоретик нигез сала. «Безнең реализмны төп стиль итеп алуыбыз очраклы хәл түгел,— дип яза шагыйрь.— Реализм чынлыкны (әйләнә тормышны) бар көенчә дөрес итеп чагылдыруны шарт итә. Шунлыктан әдәбият тарихында реализм һәрвакыт кайсы да булса сыйныфның алга табан үскән, прогресс чорында урын алды».

Жәлил эксплуататорлар строе шартларында барлыкка килгән критик реализмның чикләнгән булуы турында сөйли һәм социалистик реализм турындагы фикерен дәвам итә, «Социализм реализмы стиле (биредә стиль метод мәгънәсендә. Р. М.) безнең әдәбиятка социализм чорының бөтен дөреслеген, бөтен катлаулылыгын ачып күрсәтергә ярдәм итәчәк. Бу стиль безгә социализм турында бөтен дөресне ярып салырга куша. Чөнки социализм — хәзер ул коры идея генә түгел, ә ул — факт. Менә шул фактны бөтен дөреслеге белән жанландыру — бердәнбер иҗат методы булачак».

Яңа метод, үзеннән алда килгән реализмнан аермалы буларак, бүгенге көнне һәм тарихи үткәнне социализм идеаллары яктылыгында сурәтләүне бурыч итеп куя. Бу бурыч эчтәлек һәм идея юнәлеше белән бергә сәнгать төзелеше (структурасы) принципларын да билгели. Жәлил яңа методны бер генә яклы итеп карамаска өнди. Тыгыз бәйләнештәге һәм форма, һәм эчтәлек, һәм идея юнәлеше ди ул.

Жәлил бу мәкаләсендә татар әдәбият белемендә беренче тапкыр яңа методның партиялелек һәм халыкчанлык принципларына нигез сала. «Чынлыкны дөрес чагылдыруда ике моментны онытырга ярамый. Бер яктан, безнең әсәрләрдә партиялелек, сыйнфый юнәлешлелек бик кискен торырга тиеш. Партиясез әсәр безгә кирәкми. Мәнә шул партиячелек үзе чынлыкны дөрес чагылдыруны тәэмин итә. Бары партия юлына ышанмаган, партия һәм эшчеләр сыйныфы идеаллары белән нык сугарылмаган язучы гына чынлыкны бозып, буяп күрсәтәчәк. Икенче яктан, безнең әсәрләр художество ягыннан югары сыйфатлы булырга тиешләр. Ул коры өндәү методын кораль итмәскә тиеш. Ул җанлы сурәтләр, җанлы характерлар аша чынлыкны бирергә тиеш».

Ярты гасыр элек Жәлил тәкъдим иткән бу фикерләр татар совет әдәбиятына нигез булып яттылар. Алар бүгенге көн тәнкыйтьчеләре өчен дә актуаль. Мәкалә үзе дә Жәлилнең әдәби тәнкыйть эшчәнлегендә яңа чор башлануын күрсәтә.

Мәкаләдәге күп кенә карашлар «Съезднық көн тәртибенә» исемле икенче бер мәкаләдә тагын да тулыландырылганнар. Ул шул ук «Коммунист» газетасында, совет язучыларының I съезды ачылган көннәрдә басылып чыга. Анда социалистик реализм лозунгысына төгәл аңлатма бирелә. Жәлилчә яңа методның асылы — яңа кешене дөрес, сәнгатьчә ышандырырлык итеп сурәтләү. Шагыйрьне әдәбиятыбызда бүгенге көнгә кадәр тирән, катлаулы һәм тулы жанлы итеп сурәтләнгән яңа кеше образы юклыгы борчый. «Безнең практикада еш очрый торган хаталар, минемчә, шулардан гыйбарәт: без яңа кешене сурәтләндергәндә, аның чорга характерлы булган тулай типик сыйфатлары белән аерым кешенең үзенә генә хас, индивидуаль сызыкларын берләштереп бирә алмыйбыз. Күбесенчә безнең иҗади типларда соңгы як төшеп кала».

Мәнә шушы — әдәбияттә кеше шәхес буларак сурәтләнергә тиеш дигән фикере белән Жәлил инде РАПП концепциясе чикләрен уза. Ул шәхеснең җәмгыять һәм

---

[1] Совет язучыларының I Бөтенсоюз съезды. Стенографик отчет. 1934, 716 б.

вакыт белән бәйләнешен кире какмый, күңелдә озак саклана торган җанлы, тирән образлар иҗат итүне яклый.

«Икенчедән,— дип дәвам итә шагыйрь,— безнең әсәрләрдәге җитәкче большевик типлар ясалма рәвештә артык серьез, гел агитацион фразалар кабатлап йөрүче, бөтен тормышы белән җәмәгать кешесе, «ашамый» да, «эчми» дә, «уйнамый» да, «көлми» дә торган, тойгысыз итеп биреләләр».

Бигрәк тә ул шартларда бу мәсьәләнең шундый куелышы никадәр әһәмиятле булуы турында әйтеп тору кирәк микән. Җәлил, гомуми кисәтүләр белән генә чикләнеп калмый, кимчелекләре күзгә ташланып торган аерым әсәрләрне искә алып үтә. «Ул сурәт ясалма рәвештә дөньядагы бөтен яхшы сыйфатлар, яхшы холыклар белән тутырыла, шунлыктан ул беркатлы, схематик булып чыга».

Әдәби герой характеры я гел уңай, я гел тискәре генә була алмый. Бер-берсен төссезләндерә яки тулыландыра торган арадаш төсләр дә бар, аларның бердәмлеге образны баета, тормышчан итә, дип яза Җәлил.

Шагыйрь «тормыш эчендә кайнарга кирәклек» турындагы фикерен дә дәвам итә. «Бу дөрес һәм иң мөһим шарт,— ди ул.— Ләкин надан көенчә күпме кайнасаң да, аны тирән төшенеп булмый. Шуның өчен укырга кирәк. Партия, хөкүмәтнең бөтен карар, чараларыннан башлап, тарих, фәлсәфә, психология һәм башкаларга хәтле белергә кирәк. Бу безнең чынлыкны һәм кешеләрне дөрес бирергә ярдәм итәр».

Бу фикерләр бүген дә актуаль... 1933—1934 еллар — Җәлилнең әдәби тәнкыйть эшчәнлеге чәчәк аткан чор. Бу елларда аның иҗатында поэзия түгел, ә тәнкыйть өстенлек ала. Кайбер айларда ул ун-унбишәр мәкалә һәм рецензия яза — ике елда гына да әдәбият мәсьәләләренә караган барлык материалларының яртысы диярлек язылган. Моны ничек аңларга?

Беренчедән, Җәлил «Коммунист» газетасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире буларак, хезмәте кушуы буенча да күзәтүләр, мәкаләләр, рецензияләр язарга тиеш.

Икенчедән, нәкъ шушы елларда Җәлил әдәби тәнкыйтьне иң алгы планга куя. Өченчедән, ВКП(б) Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать оешмаларын яңабаштан кору турында»гы карарыннан соң элеккеге күп кенә карашлар яңадан карала, тәнкыйть РАПП ялгышларын инкяр итә һәм яңа эстетик платформасын булдыра. Җәлил бу эштә һәрьяклап ярдәм итүне үзенең бурычы дип саный.

Җәлилнең 1932 елдан соң язылган материаллары теоретик яктан җитди булулары, анализ тирәнлеге, эстетик критерийларының таләпчәнлеге белән аерылып тораллар. Үзенең иҗат практикасында да, язучыларның әсәрләренә бәя биргәндә дә социалистик реализм методы художниктан дөрес итеп, тарихи-конкрет сурәтләүне таләп итә дигән принциптан чыгып эшли. Ул социалистик реализм әдәбиятында стиль һәм жанрлар, иҗат алымнары төрлелеген яклый.

Бу фикерләр, аерым алганда, «Безнең үсеш юлларыбыз» («Коммунист», 1933 ел, 6 ноябрь) «1933 ел өчен «Совет әдәбияты» журналына күзәтү, (шул ук газета, 1934 ел, 27—28 июль) исемле мәкаләләрендә тагын да баетылалар. Шагыйрь Сәхап Урайскийның шигырь һәм хикәяләр җыентыгына «Таныш елмаю» рецензиясендә һәм башкорт язучысы Һадия Дәүләтшинаның хикәяләр җыентыгына Мәскәү дәүләт матур әдәбият нәшрияты өчен язылган эчке рецензиясендә һ. б. чыгышларында, әдәби әсәрләрне анализлаганда эчтәлек һәм форма, идея пафосы һәм әдәби осталык бердәмлегенә ирешә. Әдәби әсәрнең һәр компонентын, авторның төп фикере контекстында, хезмәт ияләрен социалистик рухта тәрбияләүне төп максат итеп карый ул.

Җәлил, тәнкыйтьче буларак, татар совет әдәбиятының идея-художество дәрәҗәсен күтәрүгә күп көч куя. Биредә кызыклы эволюция күзәтергә мөмкин. Җәлил РАПП идеяләре белән мавыккан чорда күбрәк декларация, өндәмә характерындагы мәкаләләр, манифестлар язса, хәзер исә конкрет әсәрләргә бәя бирүче, теге яки бу жанрны үстерү өчен мөһим мәсьәләләр күтәргән рецензия һәм мәкаләләр аның әдәби тәнкыйтьтә төп жанрларына әвереләләр. Җәлил барлык алдынгыны, талантны, тормышчан әсәрләрне яклау белән бергә әдәби җитешсезлекләр белән дә аяусыз көрәшә. Мәсәлән, Башкортстанның Дүртөйле районы яшь язучыларының «Атака» исемле әдәби җыентыгына, Казан татар эшче театрының Мәскәүдәге гастроль спек-

тәкыльләренә, М. Әмирнең «Безнең авыл кешесе» исемле китабына рецензияләрдә уңай яклар белән бергә әдәби ялгышларны да тирән һәм ышандырырлык итеп күрсәтә, теге яки бу таланттың үсеш перспективасын билгели. Җәлил язучыларны тәнкыйть буе җитмәстәй, дан казанганнар һәм гадиләр төркемена аерып карамый. Авторның кем булуы аның өчен артык әһәмиятле түгел, әсәрне ул лаеклы якларыннан чыгып бәяли. Җәлил тәнкыйттә принципиаль һәм таләпчән була. Ул хезмәтнең бөеклегенә һәм зур көченә ышана, хезмәт кешесенә дан җырлый. Ул бөтен әдәби хезмәтләргә дә республика һәм илебездә барган гаять зур тарихи үзгәрешләр биеклегеннән, укучы мәнфәгатен алга куеп карый.

Аның мәкаләләрендә социалистик реализм методы турындагы карашларның да билгеле бер үсешен күзәтергә мөмкин.

Шагыйрь социалистик реализмны узган чор сәнгатенең иң яхшы традицияләрен үзенә туплаган, яңа әдәби система итеп кабул итә. Ул тәп игътибарны социалистик реализм сәнгатенең принципиаль яңалыгына юнәлтә. Бу яңалык чынбарлык һәм марксизм-ленинизм идеяләре белән коралланган совет язучысының дөньяга карашы белән бәйләнгән. Вакыт үтү белән, Җәлил, акрынлап, бу билгеләмәләрнең үзара нык бердәмлеген аңлый. Утызынчы елларда уртасыннан ул социалистик реализм төшенчәсендә аның яңа сыйфатларын күрү һәм аңлау белән бергә реализмның классик традицияләренең әһәмиятен тану мөһим дип саный. Ул тәнкыйтьче буларак татар халкының классик мирасына зур кызыксыну белән карый. Җәлил, РАПП ялгышларыннан арына барган саен Г. Тукай, М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал кебек классик язучыларның иҗатларын яңадан карау өчен актив һәм эзлекле рәвештә чыгышлар ясый.

Бүгенге көндә — тар белгечлек чорында, Җәлил кебек тигез дәрәҗәдә әдәбиятның төрле жанр һәм төр үзенчәлекләре турында тирән аңлап язучы һәм шулар белән бергә үк метод, тел һәм стиль проблемаларын эшләүче, тәрҗемә мәсьәләләрен күтәрүче, опера драматургиясе теориясен дәлилләп аңлатучы, аны үстерүче эрудитлар юк диярлек. Хәер, хәзер аның кирәге дә бар микән? Ләкин әле егерменче-утызынчы елларда әдәбият һәм сәнгать алдында бихисап яңа проблемалар һәм хәл ителмәгән мәсьәләләр туа. Аларга һәр өлкәнең үз белгечләре үсеп җиткәнче кичектергесез җавап бирү сорала. Җәлил, үзенә генә хас ашкынулы тынгысызлыгы белән, вакыт-вакыт ялгышса да, авырлыклар каршында рухын төшермичә совет тәнкыйтен һәм әдәбият белеме белән берлектә җавап эзли, таба, татар совет әдәбиятының үсеш юлларын билгели.

Безгә бүген: тәнкыйтьче Җәлил шагыйрь Җәлил кебек үк татар совет әдәбияты тарихыннан аерылгысыз дип әйтергә тулы җирлек бар.

****

ЗУР ПЕДАГОГ

Профессор Мөхетдин Хафизетдин улы Корбангалиевнең исеме республикабыз чикләреннән еракта да билгеле. Мәҗит Гафури әле 1925 елда ук, соңгы 10—15 елда татар һәм башкорт мәктәпләрендә укыганнар арасында аның дәреслекләреннән файдаланмаган кешеләр юктыр, дип яза. М. Корбангалиев рус педагоглары Ушинский, Вахтеров, Флеров һәм башкалар эзеннән бара. Ул татарларда марксистик педагогик фикер үсешендә мактаулы урын алып тора. Бигрәк тә башлангыч белем бирү дидактикасы, телләр укыту һәм татар мәктәпләре өчен дәреслекләр булдыру өлкәсендә зур хезмәтләр куя.

Мөхетдин Корбангалиев 1873 елның 25 ноябренда Вятка губернасы Алабуга өязенең Биектау авылында (хәзер Әгерҗе районы) туа. Башлангыч белемне ул туган авылында ала, мәктәпкә биш яшеннән үк йөри башлый. Анда ул 15—16 яшьләргә кадәр укый.

1887 елда авылда рус-татар мәктәбе ачыла. Корбангалиевнең рус телен өйрәнүгә сәләтле зур икәнлеге ачыклана. Ул рус теле, әдәбияты белән мавыгып китә һәм укытучылык эше турында хыяллана башлый. Әтисе аның теләгенә каршы төшми һәм Мөхетдин — Казандагы татар укытучылар мәктәбенә (учительская школа) укырга керә. Монда ул дөньяви фәннәрне тырышып үзләштерә, мәҗбүри дәресләрдән тыш үзлегеннән дә укый. В. В. Радлов, Каюм Насыйри һәм башкаларның тюркология буенча язган хезмәтләрен өйрәнә.

Укытучылар мәктәбендә М. Корбангалиев беренче тапкыр К. Насыйри белән очраша, өлкән мәгърифәтче аңа татар һәм рус телләрен өйрәнү буенча практик киңәшләр бирә. Корбангалиевнең татар фольклорын җыю белән мавыгуын ишеткәч, К. Насыйри халык җырларын һәм риваятьләрен авылдагы карт кешеләр авызыннан җыярга һәм бигрәк тә крепостной крестьяннар тормышын чагылдырганнарына игътибар бирергә киңәш итә.

К. Насыйри артыннан М. Корбангалиев та укытучылар мәктәбендә укыган чакта ук туган тел проблемаларын өйрәнүгә һәм эшләүгә зур игътибар бирә. Яшь Корбангалиевнең татар теленең фонетик төзелеше мәсьәләләре дә кызыксындыра. Ул Казан университетының рус теле кабинетына йөри, анда профессор В. А. Богородицкий җитәкчелегендә татар теленең эксперименталь фонетикасын өйрәнә.

1895 елда мәктәпне тәмамлагач, М. Корбангалиев Мамадыш өязенең бер авылына укытучы итеп җибәрелә. Ул К. Насыйриның рус китапларын, дәреслекләрен ала һәм балаларны татар, рус телләренә заманы өчен яңа булган методлар белән укыта башлый. Аның укытуы татар муллалары күңеленә хуш килми, керәшен поплары да аны үзләре өчен зыянлы кеше итеп күрәләр. Поплар Корбангалиев өстеннән Казан архиерие һәм зур миссионер эшлеклесе Ильминскийга әләк язалар. Нәтиҗәсе дә күренә. Корбангалиев мәктәбе өчен дә жаваплы булган халык училищелары инспекторын ашыгыч рәвештә Мамадыштан Казанга чакыртып алалар һәм анда миссионерлык җитәкчеләре инспекторга каты дәгъва белдерәләр. Янәсе, алар татарларны руслаштырырга, православие диненә кертергә дип 300 ел көч түгәләр, ә инспектор хәтәр татар укытучысын чакыра да казна акчасына татар китаплары тарата. Җәза рәвешендә инспекторны башка урынга күчерәләр. Ә яңа килгәне Корбангалиевне, һаман да татарча укытса, эштән куу белән яный.

Язгы сынауда исә М. Корбангалиев укучыларының рус телен яхшы белүе күренә. Шуннан соң инспекторның да күңеле йомшара. «Чын методист икәнсең,— ди ул.—

Бөтен көчеңне татар балаларына рус телен өйрәтүгә салсаң, алар өчен рус телендә дәреслекләр язсаң, татарларга файдаң күбрәк тияр иде. Ә син, барыбер бетәсе татар телен укытып, көчеңне әрәм генә итәсең».

М. Корбангалиевнең дөньяга карашы алдынгы рус иҗтимагый-педагогик фикере йогынтысы астында бара. Рус педагогларының һәм методистларының хезмәтләрен өйрәнү, студентлар һәм укучылар хәрәкәтендә катнашу, мәктәп эшендәге кадимлеккә каршы актив протест революцион-демократик позицияләргә басуына булышлык итә.

Рус-татар мәктәбе царизмның руслаштыру политикасын үткәрергә тиеш була. Инспекторлар да шул юнәлештә эшләүне ныклы контрольдә тоталар. Әмма М. Корбангалиев, К. Насыйри үрнәгендә мәктәпне мәгърифәт учагы һәм дөньяви белемнәр чыганагы итеп карап, аны татар халкына хезмәт итү өчен файдалануга ирешә.

М. Корбангалиевнең педагогикада марксистик позицияләргә күчүе революцион көрәштә катнашуыннан килә. Мамадышта чакта ук ул (1901—1903 еллар) политик яктан гаепләнеп сөрелгән кешеләр белән якыная. Аерым алганда, эшче Васильев белән танышып китә. Аңардан марксистик әдәбият алып тора. Укытучы Петров һәм земская управа хезмәткәре Михеев белән бергә ул яшьләр, бигрәк тә татарлар арасында политик агитация алып бара.

Беренче рус революциясе алдыннан М. Корбангалиев Казанга күчеп килә. Биредә ул татар революционерлары Х. Ямашев, Г. Коләхметов һ. б. белән таныша, Маркс хезмәтләрен өйрәнә.

М. Корбангалиев иҗтимагый-революцион эшкә актив катнашып китә, матбугатта мәкаләләр бастыра, прокламацияләр яза, хөкүмәтне һәм чиновникларны халык дошманнары дип атап, самодержавие строен фаш итә. Моның өчен ул кулга алына, полиция күзәтүе астында яши, хатларын патша цензурасы тикшереп тора. Галимҗан Ибраһимов сүзләре белән әйткәндә, ул Октябрьны үз Октябры итеп каршылый, культура төзелешендә Советларның беренче ярдәмчесе була.

Зур иҗтимагый һәм революцион-политик эш алып бару белән бергә, М. Корбангалиев педагогик эшеннән беркайчан да аерылмый. Октябрь революциясе көннәренә кадәр ул Казанда ятимнәр өчен мәселман приютында укыта, бер үк вакытта татар мәктәпләре инспекторы да була.

Ә педагогик эшне М. Корбангалиев фәнни-методик эш белән бергә алып бара. Аның «Татар әлифбасы» (1912) дәреслеге татар мәктәбендә укырга-язарга бөтенләй яңача өйрәтүне башлап җибәрә. Бу әлифба аваз методы белән төзелә һәм 1918 елга кадәр 7 тапкыр басылып чыга. Шул елларда үк ул башлангыч мәктәп өчен «Татарча уку китабы»ның дүрт кисәген чыгара. Аларда М. Корбангалиев шул чордагы татар язучыларының (Г. Тукай, М. Гафури һ. б.) иң яхшы әсәрләрен һәм К. Д. Ушинский, Л. Н. Толстой дәреслекләреннән тәрҗемәләр кертә, балаларның дөньяга карашын киңәйтү өчен хайваннар, игенчелек турында, географик һ. б. материаллар урнаштыра. М. Корбангалиев китаплары дөньяви характерда була. 1919 елда ул Х. Бәдигый белән бергә «Татар теле» (морфология һәм синтаксис) дәреслегенең ике кисәген чыгара, алар да бернича тапкыр басыла. Моннан тыш төрле елларда ул «Хисап мәсьәләләре һәм гадәти мисаллар», «Дөнья-җәгърафия рисаләсе» һ. б. кебек төрле-төрле дәреслекләр язып бастыра.

Бөек Октябрь революциясеннән соң аңа фәнни һәм педагогик эшчәнлеге өчен киң мөмкинлекләр ачыла. М. Корбангалиев татар совет мәктәбен, укыту һәм тәрбиянең яңа методын күренекле оештыручылардан берсе, Коммунистлар партиясенең халык мәгарифе өлкәсендәге политикасын тормышка актив үткәрүче була. Совет властеның беренче көннәреннән үк ул мәктәпләр инспекторы, аннары Казан губернасы мәгариф бүлеге мөдире була.

Татарстан АССР төзелгәч, М. Корбангалиевкә ТАССР мәгариф халык комиссариаты каршында хезмәт мәктәбе бүлеге оештыру эше йөкләнә. Ул шушы бүлекнең беренче җитәкчесе дә була. М. Корбангалиев яңа педагог кадрлар хәзерләүгә, иске укытучыларны Совет власте ягына тартуга зур игътибар бирә; хезмәт мәктәпләренең эше буенча курслар һәм семинарлар оештыра, кадрларны хезмәт мәктәпләренең төп эш принциплары һәм яңа методлар белән таныштыра, уку планнары, программалар, дәреслекләр төзи.

М. Корбангалиев төрле фәннәр буенча бик күп дәреслекләр иҗат итә. Бигрәк тә татар мәктәпләре өчен татар һәм рус телләреннән дәреслекләр яза. К. Д. Ушинский һәм Каюм Насыйри үрнәгендә, ул туган телне киң халык массаларын агарту чарасы дип карый.

М. Корбангалиевнең татар теле буенча дәреслекләре материалны бирүдә методик системаның тирән уйланганлыгы белән аерылып тора. Аларның кайберләре совет мәктәбендә әле хәзер дә кулланыла һәм басылып тора.

М. Корбангалиев Россиядә яшәүче һәр кеше өчен рус телен өйрәнү бик кирәк икәнлеген күп тапкырлар күрсәтә. Укытучылык эшенең беренче елларында ук инде ул татар мәктәпләрендә рус теле укытуның зарурлыгын исбатлый.

Совет власте елларында ул татар мәктәпләре өчен рус теле буенча берничә ярдәмлек яза. 1934—1935 уку елында басылып чыккан «Русский букварь» татарлар өчен иң уңышлысы була. 1936—1938 елларда М. Корбангалиев татар башлангыч мәктәбенең дүрт классы өчен дә рус теле дәреслекләре төзи. Укытучылар бу китапларны бик зур шатлык белән каршы ала.

М. Х. Корбангалиев үз чорының ихтыяҗларын тоеп яши, күңеленә якын ала. Татарстанда укый-яза белмәүчелекне бетерү эшендә ул башлап йөрүчеләрдән берсе була, олыларны укытуның дидактик нигезләрен эшли. Шактый тормыш тәҗрибәсенә ия булган олылар, ди ул, программа материалын тизрәк үзләштерәләр. 1921 елда ул өлкәннәр белән эшләү өчен укытучыларга «Олыларны укыту һәм дәрес үрнәкләре» дигән методик ярдәмлек чыгара. Олылар психологиясенең балаларныкы белән чагыштырганда принципиаль үзгә булуыннан чыгып, М. Корбангалиев олыларны укытуның башка төрле методик нигезләрен билгели.

Укый-яза белмәүчелекне бетерү буенча Бөтенсоюз гадәттән тыш комиссиясе инициативасы белән 1923 елда Казанда методик конференция чакырыла. Бу конференциядә «Ликвидпунктларда укыту методлары турында» дигән доклад белән М. Корбангалиев чыга. Конференциядә катнашучылар аның олыларны укыту методикасын яхшы дип табалар.

1924 елда М. Корбангалиев Х. Бәдигый белән бергә, олыларның аң үсешен һәм интересларын исәпкә алып, «Крестьян әлифбасы» төзи. Ул башлап укый-язарга өйрәтүгә исәпләнгән, анда авыл хуҗалыгы, математика, география һ. б. буенча танып-белү материаллары бирелә. 1926 елда М. Корбангалиев аз белемлеләр өчен арифметика дәреслеге дә чыгара. Олыларның тормыш тәҗрибәсе шактый зуррак булуын исәпкә алып, ул аларга шул класслардагы балалар белән чагыштырганда катлаулырак материал бирә. Олылар өчен дәреслекләр һәм биремнәр төзү эшен ул соңрак та дәвам итә. М. Корбангалиев олылар мәктәпләрендә эшләүчеләр каршында күп тапкыр чыгышлар ясый, Совет властеның бу чараларының илебездәге культура революциясе һәм бигрәк тә милли республикалар өчен никадәр зур политик әһәмияткә ия икәнлеген күрсәтә.

Татар мәктәбе эшендә класс-дәрес системасын кертү өчен эзлекле көрәшеп һәм дәресне уку-укыту эшенең төп формасы итеп санап, М. Корбангалив дәрес методикасын эшләү, аның танып-белү мөмкинлекләрен киңәйтү өчен күп нәрсә эшли. Татар мәктәпләре эшендә ул балаларның фикерләвен үстерә торган эвристик әңгәмә методын киң кертә башлый. Укучыларны дәрескә, дәрестә белемнәрне мөстәкыйль үзләштерүгә тарту, аларның активлыгын һәм танып-белү көчләрен үстерү, иске һәм яңа материал арасында элемтә урнаштыру буенча М. Корбангалиев эшләгән методик алымнар системасының гомумдидактик әһәмияте әле хәзер дә саклана.

Укыту процессында ул укучының мөстәкыйль эшләвенә, эзләнү көчләренә зур игътибар бирә. Алга таба үсә барган уку идеясе, аңлылык принцибы, баланың танып-белү көчләрен стимуллаштыру — М. Корбангалиев татар мәктәпләре эшенә кертккән яңалыклар әнә шуннан гыйбарәт. Нәкъ менә аның тәкъдиме буенча татар укытучылары укытуда экскурсия, укучыларның дәрестә мөстәкыйль эшләве, тәҗрибә һәм күзәтүләр, сочинение яздыру, төрле-төрле күргәзмә әсбаплар һәм иллюстрация материаллары куллану кебек методлардан киң файдалана башладылар.

М. Корбангалиевнең педагогик хезмәтләре иң элек дидактика проблемалары һәм укыту методлары өстендә эшләүгә багышлана. Әмма, кайбер башка педагоглар кебек, ул укытуны тәрбиядән аерып карамый, укытуны тәрбиянең төп чарасы итеп

саный, оста куелган укыту баланы дәреснең эчтәлеге белән генә түгел, укыту процессының оештырылуы һәм укыту методикасы белән дә тәрбияләргә тиеш дип саный. Без яңа тормышны актив төзүчеләр хәзерлибез, ди ул, шунлыктан укучыда мөстәкыйльлек һәм активлык тәрбияләү, революциягә кадәрге уку йортларыннан үзгә буларак, совет мәктәбенең иң мөһим бурычы.

М. Корбангалиев Казан-педагогия техникумында һәм Кызыл командирлар курсларында (1920—1922 еллар), Көнчыгыш академиясендә, җир төзү техникумында, Татарстан өлкә совет-партия мәктәбендә, Татарстан коммунистик университетында укыта (1922—1924 еллар).

1924—1927 елларда ул Татарстан мәгариф халык комиссариатының Академик үзәге председателенең урынбасары була, Татарстанның иң зур фәнни көчләрен берләштергән бу оешманың фәнни һәм педагогик чараларына җитәкчелек итә. 1925 елда аның инициативасы белән Академүзәк каршында 1 баскыч мәктәпләре өчен дәреслекләр язу буенча коллектив оештырыла.

1928 елда М. Х. Корбангалиевне В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында беренче тапкыр ачылган татар теле һәм әдәбияты кафедрасына җитәкчелек итәргә җибәрәләр. Монда ул 1940 елга кадәр эшли. Бер үк вакытта юридик мәктәптә укыта (1928—1930 еллар), марксизм-ленинизм университеты тыңлаучыларына рус теле укыта.

Совет хөкүмәте М. Корбангалиевнең татар халкын агарту өлкәсендәге хезмәтләренә югары бәя бирә. 1928 елда аңа Хезмәт Герое исеме бирелә. 1930 елда, Казан университетының 125 еллыгы уңае белән, ул ТАССРның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исем ала. 1940 елда исә, Татарстан АССРның 20 еллыгы уңаеннан, ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Ә тиздән галим РСФСРның атказанган фән эшлеклесе исеменә лаек була.

1940 елда, сәламәтлеге какшау сәбәпле, М. Корбангалиев кафедрадан китә һәм тулысынча фәнни эшкә бирелә. 1941 елның 3 июнендә ул вафат була. Үләреннән аз гына элек М. Корбангалиев РСФСР мәгариф халык комиссариаты заказы буенча милли мәктәпләрнең 8—10 класслары өчен рус теле дәреслеге язу эшенә җитәкчелек итә.

М. Корбангалиев гомумпедагогик һәм методик характердагы бик күп фундаменталь монографияләрнең, педагогик темаларга язылган журнал һәм газета публикацияләренең, башлангыч мәктәптә укытыла торган барлык предметлар буенча дәрәслекләр авторы. Үзе язган бөтен хезмәтләрдә — китапларда, мәкаләләрдә, дәреслекләргә сүз башларында, программаларга аңлатмаларда М. Х. Корбангалиев башлангыч мәктәптә укыту теориясе һәм методикасының мөһим проблемаларын тирәнтен һәм оригиналь хәл итә. Ул Татарстанда халык мәгарифен күренекле оештыручы һәм совет тәрбия системасының теоретикларыннан берсе булды.

Гөлнур ЗӘЙНИЕВА,
Казан дәүләт педагогия институты аспиранты.

Үкенеч

Атаклы гармунчы Фәйзулла Туишевның өенә берничә әдип һәм татар сәнгатьчесе белән беркөнне Тукай да килә. Иптәшләре, нишләптер, бу ике мәшһүр кешене бер-берсе белән таныштырырга оныталар. Тукай дәшмичә генә ишек катында утыра-утыра да чыгып китә. Еллар узгач, инде бөек шагыйрь Тукай турында сүз иярә сүз чыккач, Туишевтан мәрхүм шагыйрьгә теге вакытта илтифатсыз калуының сәбәбен сорыйлар. Ул:

— Аның Тукай икәнен кем белгән бит... Ул икәнне әйтсәләр, мин Тукай белән бергә карточкага төшеп калган булыр идем! — дип җавап бирә. — Кем белгән бит аны...

Ике Туфан

Хәсән Туфанның 70 еллык бәйрәме мәҗлесендә драматург Туфан Миңнуллинның олуг шагыйрь шәрәфенә әйткән шәраб алды сүзе:

— Хәсән абый, мин тугач та, мең тугыз йөз утыз бишенче елны әти сезгә хөрмәт йөзеннән миңа Туфан исеме куйдырган. Сез, Туфан абый, ижатыгыз белән дә, яшәешегез белән дә минем исемгә тап төшермәдегез! Олуг рәхмәт сезгә, олуг шагыйрь Хәсән абый Туфан! — ди драматург өлкән шагыйрьгә.

— Тырыштым! — дип җавап бирә Хәсән Туфан.

Кулга урын табып булмый

Хәсән Туфанның 80 еллык бәйрәме дә шаулап, бик матур узды. Бәйрәм арасында бер яшь язучы Туфанга болай ди:

— Хәсән абый, кәефләрегез ничек соң? Юбилейдан сез канәгатьсезме?

— Һәй, энем, әрләгәндә мин үземне ничек тотарга кирәклеген беләм. Йодрыгыңны йомарлыйсың да түзәсең. Ә менә мактаганда нишләргә кирәклеген белмим шул. Мактаганда кулга урын таба алмый аптырыйм, — дип җавап кайтарган шагыйрь.

«Кызыклы хәлләр»нең журналга Роберт Батулла әзерләде.

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

16 ноябрьда язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында «Казан утлары» журналының узган елгы 1—9 саннарын тикшерүгә багышланган җыелыш булып узды. Җыелышта төп игътибар партиябез әдәби журналлар алдына куйган мөһим бурычларны тормышка ашыруда «Казан утлары» журналы үзеннән нинди өлеш кертүенә юнәлтелде.

Төрле әдәби жанрлар буенча докладлар белән Р. Мостафин (проза), М. Малюкова (очерк һәм публицистика), Ф. Хатипов (әдәби тәнкыйть), Р. Фәйзуллин (поэзия) чыкты.

Тыңланган докладлар буенча фикер алышуларда язучылардан С. Хәким, Ә. Еники, Г. Ахунов, Р. Гатауллин, Арча районының «Искра» колхозы председателе Ф. Галиев, Э. Гаффар, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис һ. б. катнашты.

Җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин чыгыш ясады.

РИЗА ФӘХРЕТДИНЕВКӘ БАГЫШЛАП

26 ноябрьда Оренбург шәһәренең Х. Ямашев исемендәге китапханәсендә Риза Фәхретдиневнең тууына 125 ел тулуга багышланган кичә үткәрелде.

Кичәдә галимнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүче өлкән укытучы Мәдинә Рәхимкулова Риза Фәхретдиневнең Оренбургта яшәгән чоры, шул чордагы күпкырлы иҗаты, галим тарафыннан оештырылган һәм 1908—1917 елларда чыгып килгән «Шура» журналы турында сөйләде. Риза Фәхретдиневнең Оренбургта, Казанда, Уфада басылып чыккан кайбер китаплары белән таныштырды.

Партия һәм хезмәт ветераннары Гөлсем Хәсанова, Сабит Якупов Риза Фәхретдинев турында кызыклы истәлекләр сөйләделәр.

Китапханәнең уку залында галимгә багышлап оештырылган күргәзмәне кичәгә килүчеләр зур кызыксыну белән карады.

БАШКОРТСТАНДА МУЗЫКА ФЕСТИВАЛЕ

22—26 ноябрьда Уфа шәһәрендә Идел буе һәм Урал ягы автономияле республикалары композиторларының Икенче музыка фестивале булды. Бу фестивальнең беренчесе узган ел Казанда уздырылган иде.

Фестиваль программасы бай һәм күп төрле иде. Биредә өч симфоник концерт бирелеп, аларда зур күләмле әсәрләр башкарылды. Аларны Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт филармониясенең ТАССРның халык артисты Р. Салаватов җитәкчелегендәге симфоник оркестры башкарды. Өч камера концертында инструменталь музыка, вокаль цикллар, композиторлар тарафыннан эшкәртелгән халык җырлары яңгырады. Болардан тыш этнографик музыка концерты зур уңыш казанды.

Фестиваль концертларында Татарстан композиторларыннан Н. Жиһанов, Р. Яхин, Х. Вәлиуллин, Б. Мулюков, М. Яруллин, Р. Еникеев, Ф. Әхмәтов, А. Луппов, Ш. Шәрифуллин, Ә. Шәрәфиев, Р. Белялов, Б. Трубин, Л. Любовский, Р. Абдуллин, Л. Хәйретдинова, А. Миргородский һ. б. ларның әсәрләре тыңланды.

Фестиваль рамкаларында музыка белгечләре һәм фольклорчыларның киңәшмәсе үткәрелде.

Икенче музыка фестивале Уфаның Нефтьчеләр культура сарае сценасында тантаналы шартларда төрле милләт сәнгать осталарының йомгаклау концерты белән тәмамланды.

ТЕАТРНЫҢ ЮБИЛЕЕ

Татар дәүләт драма һәм комедия театры төзелүгә 50 ел тулды. Шул уңайдан 5 декабрьда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында тантаналы кичә булды.

Кичәдә хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдәге нәтиҗәле эше өчен һәм төзелүенә 50 ел тулу уңаеннан театрга ТАССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы тапшырылды.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татар дәүләт драма һәм комедия театрының баш режиссеры Р. Р. Тумашев театрның иҗат юлы турында сөйләде.

Республикабызның партия оешмалары, хезмәт һәм иҗат коллективлары вәкилләре театр коллективын олы юбилей белән котладылар. Аннан соң театр артистлары катнашында «Еллар һәм юллар» дигән әдәби-музыкаль композиция күрсәтелде.

Тантаналы кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев катнашты.

ТАБИГАТЬ ҖЫРЧЫСЫ

...Бер табигать фасылының икенчесенә күчеш мизгеле. Җир өстенә кар яткан, ләкин агачларның яфраклары әле тулысынча коелмаган. Елгадагы су өстен дә боз капларга өлгермәгән...

Тышлыкның беренче битенә урнаштырылган әлеге картинаның авторы — Татарстанның халык художнигы, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты С. О. Лывин.

Художникның 35 еллык эшчәнлеге чорында иҗат ителгән барлык әсәрләре дә туган җирнең матурлыгына соклану, поэтик күтәренкелек белән сугарылганнар. Илленче елларда язылган беренче картиналарында ук Сергей Осипович үзенә балачактан якын булган табигатьне ихлас күңелдән ачып бирергә омтыла. Әнә шул омтылыш тора-бара көчәя һәм бөтен иҗатының лирик юнәлешен билгели.

Пейзаж жанрында тәҗрибә туплаган художник алтмышынчы елларда нефть районнарына багышланган картиналар сериясе өстендә эшли башлый. Иҗат процессында ул яңадан-яңа ачышларга килә. Кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә күпмедер үзгәреш кичерүче табигатьнең гомумиләштерелгән һәм мәһабәт образын тудыруга ирешә.

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән художник дәһи юлбашчыбыз беренче тапкыр сөргендә булган төбәкнең табигате турында сөйләүче һәм уртак идеягә буйсындырылган әсәрләр сериясен иҗат итә. Биш картинадан торган бу сериядә Кокушкино авылы һәм аның тирәсендәге күренешләр сурәтләнгән.

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай әсәрләрендә дан җырланган урыннарның искиткеч матурлыгы да аның полотноларында үзенчәлекле чагылыш тапты. Ул ике ел дәвамында Кырлай, Өчиле, Кушлавыч авылларында эшләде, Тукай поэзиясенең лирик дөньясын сынлы сәнгать чаралары белән җанландырды.

Ленинга бәйләнешле урыннар, шулай ук Тукайның туган якларына багышланган әнә шул әсәрләр өчен С. О. Лывин ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

С. Лывин тынгысыз иҗат кешесе булу белән бергә, актив җәмәгать эшлеклесе дә. Ул — авыл темасына иҗат итүче художниклар группасы җитәкчесе.

В. ЦОЙ,
Татарстан сынлы сәнгать музеенең бүлек мөдире.

Тышлыкның дүртенче битендә: Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» исемле пьесасы буенча куелган спектакльдән күренеш — Әлмәндәр һәм Йөзембикә рольләрендә СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров һәм артистка Рузия Мотыйгуллина уйный.

Рөстәм **МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210

КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)